ISSN 0206-4189 12+
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2015



№9 (1115) 2015 **БУ САНДА:**



**Энгель ФӘТТАХОВ:**
**«Бүген төп бурыч — укучыларга сыйфатлы белем бирү»**

— Безнең милләт талантлы шәхесләргә бай. Халкыбызның рухын саклап калган Габдулла Тукай, Муса Җәлил — әнә шундыйлардан. Туган тел һәм әдәбият укытучыларының 2015-2016 уку елына планлаштырылган Бөтенроссия мастер-класслар бәйгесе, фәнни-гамәли конференцияләр һәм башка бик күп чараларның төп үзенчәлеге — күренекле шагыйрьләребез юбилейларына багышланган булуы.

## КИЛӘСЕ САНДА:

**Вахит ИМАМОВ**
**«Сөләйман солтан»**
*Тарихи роман*



«Ибраһим паша Хүррәмнең колагына иелеп пышылдады:
— Бер атнадан Сөләйманны солтан тәхетенә мендереп утыртабыз. Чит мәмләкәтләрдәге падишаһ-корольләргә чакыру озаттылар. Төрек солтанына буйсынган пашалыклар һәм вилаятьләр дә үз вәкилләрен сайлап җибәрәчәк. Бүләкләр мул агар. Надир шаһның хәтта алтын бишек коеп юллавын да беләм. Иллә мәгәр аларның берсе дә синдәй гүзәл бүләктән кадерлерәк һәм кыйммәтрәк була алмас төсле».

www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель ФӘТТАХОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе. ....8

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Нур ӘХМӘДИЕВ. Күпме тарих тузга язылган. *Шигырьләр.* ....3
Рәфкать КӘРАМИ. Кая чабасың, гомер юртагы? *Роман.* ....14
Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Түзә алмый җаным моңлыктан. *Шигырьләр.* ....84
Айдар ХӘЛИМ. Ала-коладагы дүрт Иван. *Хикәя.* ....121
Розалина ШАҺИЕВА. Сукмагыңнан киттем — җыр булып. *Шигырьләр.* ....117

КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ

Сәйдә ЗЫЯЛЫ. Агулы теш. *Бәян.* ....88
*100нче бит:* Җәүдәт СӨЛӘЙМАН. Кызыл Чишмә янә гөрли. ....100

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Төрки сүз сәнгатенә бер караш. ....133
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Төркилектә төрле булсак та, бергә без. ....137
Гөроглы. *Дастаннан өзек.* (*М.Вәлиев әзерләде*). ....138
Омор СОЛТАНОВ. Мизгелләр ага тиз сызып. *Шигырьләр.* ....142
Якуп ӨМӘРУГЛЫ. *Хикәяләр.* ....145
Әскәр ДОДУЕВ. Һәрбер кеше үз юлыннан бара. *Шигырьләр.* ....156
Мөхәммәт ӘХМӘТОВ. Тәсбих. ....159
Тамара ГАНИЕВА. Моңаю бар күкнең үзендә дә. *Шигырьләр.* ....164
Сәйран СӨЛӘЙМАН. Берләшик Ватанда. *Шигырьләр.* ....167

ЮБИЛЕЙЛАР

Маннур САТТАРОВ. Ике бомба, теш һәм Изольда. ....170
Лилия ХИСМӘТОВА. Әсәрләрендә буыннар язмышы (*Мәдинә Маликовага 80 яшь*). ....171

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рабит БАТУЛЛА. «Далалан килүче» хикәясе турында бер-ике сүз. ....178

КИТАП КҮЗӘТҮ

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Тарих булып дәшә Чура батыр... ....180

СӘНГАТЬ

Аида АЛМАЗОВА. Татар музыкасын яңартучы (*Алмаз Монасыйповның тууына 90 ел*). ....184

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

ТМ
татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1268).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.08.2015, график буенча 27.08.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2328. Тираж 4010.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Нур
Әхмәдиев

# КҮПМЕ ТАРИХ ТУЗГА ЯЗЫЛГАН

## Туган җир иртәсе

Сызылып таң ата, дөнья уяна,
Ингә-ин торып, кошлар серләшә.
Иртә торганга фәрештә юмарт,
Бәхетне ана мулдан өләшә.

Иртәнге сафлык җиргә тарала,
Табигать җырлый, табигать көлә.
Әк(е)рен генә томан да эри,
Чәчкә-гөлләрдән хуш ис бөркелә.

Илһам уяна минем күңелдә.
Җыр-моңнарымны илгә таратам.
Фатиханны бир, яшел бишегем,
Туган җиркәем, әй газиз Ватан!

Газиз Ватаным! Бөек Болгарлар,
Алтын Урдалар кайталмый кире.
Бабам торган җир, атам туган җир –
Тарих хәтере мәңгегә тере.

## Август

Дөньяларның шундый хозур мәле,
Гарештән үк инә яктылык.
Кояш нуры әллә кытыклыймы:
Шырык-шырык көлә ак болыт.

Җир өслеге гүя кызган таба,
Тәмугның нәкъ үзе диярсең.
Дөнья гаме аңа берни түгел,
Өйтүбәдә гөрли күгәрчен.

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик; «Аһәң», «Амбирак», «Абага чәчәге» һ.б. китаплар, шул исәптән дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. «Татнефть» ААҖ һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Әлмәттә яши.*

Игенченең ташый куанычы:
Унды быел бодай, арыш та.
Комбайнчы, алны-ялны белми,
Алдын чыгар өчен ярышта.

Чүмәләләр арта, эскерт үрчи,
Сөреп өлгерәлми трактор.
Күз житәргә кул сузымы гына,
Ә кышларга?
Зәмһәрир кыш әле еракты.

## Татар җыры

Еш кына безгә әйтәләр:
Җырларыгыз сагышлы.
Булыр, булыр, җырларда бит
Халык холкы, язмышы.

Язмыш исә татарларны
Жиз иләктән иләгән.
Күкләр зәңгәр, далалар киң,
Бәхетсез бул, димәгән.

Ат өстендә туган татар,
Ат өстендә өйләнгән.
Яңа туган сабыена
Бишек җыры көйләгән.

Даладагы учаклары
Янган, янган да сүнгән.
Безнең җырга шул учакның
Төтен исе дә сеңгән.

Океаннан Дунайгача
Яңгыраган бу көйләр.
Кылганнар шуны дәлилләр,
Әремнәр шуны сөйләр.

Әремнән күчкән әрнүләр,
Кылганнан — ярсулары.
Шаһит моңа Енисейлар,
Шаһит Идел сулары.

Җырларда — толлар үксүе,
Җиңүләр тантанасы.
Ни булса да, җырлар аша
Кайгыра, шатланасы...

Тарихта халыкка бәя
Әле ак, әле кара.
Шулкадәрле кичереп тә,
Кайгы-хәсрәт эчереп тә,
Сагышлы булмый кара!
Моңы — йөрәгемә бәлзәм,
Сагышы — җан актара.

Белдегезме, ник татарның
Җырлары бик сагышлы?
Чөнки аларда халкымның
Моң саркыган язмышы.

## Соңгы күмер

Дөрләп янган Сөю учагында
Сүрелмичә калды бер күмер.
Ай күрде дә, кояш алды кебек –
Сизелмичә узды бу гомер.

Соңгы күмер...
Иртә, кич тә узды,
Алсуланып, якты таң атты.
Саба җиле, айга-вайга куймый,
Учактагы көлне таратты.

Соңгы күмер...
Пыскып янган күмер...
Җылысы да юньләп сизелми.
Утын салсаң, кабат дөрләп китәр,
Дигән өмет һаман сүрелми.

***

*Ата сандугач кына сайрый, диләр.*

Сандугачлар көзен сайрамыйлар,
Яз белән җәй җитә аларга.
Су буена төшсәң, искитмәле —
Моң эленеп тора талларда.

Бакчаларда алмагачлар җырлый,
Шомыртлар да моңга төренгән.
Былбыл җырын тыныч тыңлап булмый,
Дулкын бәрә йөрәк түреннән.

Җырлар идем мин дә сандугачтай,
Барып чыкмый — тавыш карлыккан.
Юк тавыштан фәрештәләр кача,
Әдәп кушмый — оят халыктан.

Былбыл егет сайрап туя алмый,
Кайтавазы йөзә суларда.
Мәхәббәте чиксез — җанкисәге
Талбишектә бала чыгара.

Кешеләр дә нәсел калдыралар,
Ләкин ирләр түгел сандугач:
Хатыннары тулгак газабында,
Алар йөри айныр-айнымас.

## Шайтан турында

*Гамил Авзал болай әйбәт шагыйрь,*
*Аны бары шайтан аздырган.*
*Әйбәт шигырьләрен үзе язган,*
*Начарларын шайтан яздырган.*

Ш.Галиев

Хак Тәгалә үзе яралтканмы,
Кеше генә уйлап тапканмы...
Капкын иканлеген абайламый,
Шул капкынга үзе капканмы?

Шайтан бит ул!
Адәм-Хаваны да
Оҗмахыннан җиргә сөрдергән.
Шундый өлгер — Адәм баласына
Күпме этлек эшләп өлгергән.

Шайтан — шайтан инде.
Бертуктамый,
Армый-талмый тора котыртып.
Алтын таулар вәгъдә итә дә ул,
Төп башына китә утыртып.

Туры юлдан гына барган чакта,
Көтмәгәндә «сулга» каерта.
Күгәрчендәй гөрләп гомер иткән
Хәләл җефетләрне аерта.

Шайтан оста.
Аның мәкеренә
Каршы тора алыр кем генә!
Кәеф өчен наркотигын бирә
Йә төшерә шешә төбенә.

Шайтан кайда туган?
Шайтан белсен,
Бармыни соң аның ватаны?
Галәмдәге Ата Шайтаннан тыш
Һәркемнең бар шәхси шайтаны.

Акыллыга акыл өстәми ул,
Тик тилерәк итә тилене.
Әгәр мине шайтан котыртмаса,
Бу шигырьне язар идемме?!

## Тормыш

Бер киселгән икмәк ябышамы?
Нигә ябышмасын — ябышыр.
Яшьлегендә җае чыкмаганнар
Картайгачтын, бәлки, кавышыр.

Дөнья бит ул: әле битен куя,
Көтмәгәндә куя сыртын да.
«Мин кем! — диеп йөргән кемсәләр дә
Хуҗа түгел фани йортында.

Ун диплом да ярдәм итә алмый,
Тормыш кайчак шундый болгавыр:
Күпме гомер итеп аңлап булмый,
Үзе кызык, үзе бик авыр.

## Папирус һәм Мисыр

Мисыр белән данда кем көрәшә,
Беркөн килеп ул да егылган.
Шушы хакта сөйли папируслар —
Ә аларга мөһер сугылган.

Тиңсез каһарманлык, хыянәтләр —
Папируска бар да язылган.
Мисырда да фасыл алышына,
Кышлардан соң тагын яз булган.

Кылыч белән кылыч бәрелгәндә,
Очкыннардан йолдыз кабынган.
Йөрәкләрдә дөрләп гыйшык янган,
Мәхәббәткә вакыт табылган.

Нефертити гыйшык тотмаганмы?!
Гашыйк булган хәтта коллар да.
Бәндәләргә сөю шифа булган,
Дәва булган авыр елларда.

Кулдан-кулга күчкән Клеопатра
Азгынлыктан гына түгел лә,
(Падишаһлар йә нәжескә бата,
Йә бөеклек-данга күмелә.)

Кавем белән кавем, кабиләләр,
Илләр белән илләр ызгышкан.
Жинүчегә бәйрәм: коллар кайткан,
Ганимәтләр кайткан сугыштан.

Фиргавеннәр өчен кытлык түгел
Чибәр туташ, купшы ханымнар.
Майда йөзгән, балда гына йөзгән
Хөкемдарлар — Тутанхамоннар.

Аллаһының жирдә илчеләре —
Хуфу, Рамзеслары ни тора!
Эхнатоннар начар яшәгәнме,
Тыялмасаң, нәфес котыра.

Бер кузгалса, аямаган давыл,
Ком ташыган бөек чүленнән.
Фиргавеннәр калган, китмәгәннәр,
Фәрештәләр качкан иленнән.

Данлы, канлы вакыйгалар белән
Ярларына сыймый, Нил аккан.
Пирамидалары, маяк булып,
Юл күрсәтеп тора еракта́н.

Кәгазь уйлап тапканчыга кадәр,
Күпме тарих тузга язылган.
Кыялары сурәт белән тулы,
Укый алучысы аз булган.

Мисырлылар язган папируска,
Битекчеләр бик нык тырышкан.
Укый алсаң, күпме сер ачасың
Ул борынгы канлы тормыштан.

Тарихы юк халык бөек түгел,
Ә тарихы үзгә Мисырның.
Папируслар аша танышабыз
Бай тормышы белән ул чорның.

Тик, кызганыч, күпме папируслар
Укылмыйча ята бүген дә.
...Ымсындыргыч якты йолдыз яна
Могжизалы Мисыр күгендә.

# ЭНГЕЛЬ ФӘТТАХОВ: «БҮГЕН ТӨП БУРЫЧ — УКУЧЫЛАРГА СЫЙФАТЛЫ БЕЛЕМ БИРҮ»



***Менә тагын яңа уку елына аяк бастык. Белем-тәрбия бирү өлкәсе белән бәйле булган һәркем өчен җаваплы көннәр башланды. Милли мәгариф һәрчак мөгаллим-тәрбиячеләр, укучылар һәм ата-аналар өчен генә түгел, ә гомум дәүләт күләмендәге иң мөһим сәяси мәсьәлә булды. Мәгариф өлкәсендә нинди яңалыклар, хәл итәсе эшләр бар? Шул максаттан без ТР Премьер-министры урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттахов белән әңгәмә кордык.***

**— Үз иленең мәгарифен үстерү — һәр дәүләтнең стратегиясе. Милли республикаларда исә бу икеләтә җаваплы бурыч. Бу декларатив бәяләмә генә түгел, соңгы биш-алты елда республикабызда мәгариф челтәрен үстерү буенча биниһая эшләр башкарылды... Әле генә булып узган Бөтенреспублика август киңәшмәсендә Татарстан Республикасы Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Р.Н.Миңнеханов бу мөһим өлкәдә ирешкәннәрдән бигрәк алдагы елларда хәл итәсе мәсьәләләрне яктыртты... Үзегезнең докладта да яңа башлангычлар, яңа таләпләрне үтәүгә күбрәк басым ясалды. Шуларның иң-иңнәрен киң катлау укучыларыбызга да җиткерик әле?**

— 2015 ел Татарстан Республикасы мәгариф системасы өчен аеруча да әһәмиятле булды. Беренчедән, 2030 елга кадәр Социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыра башлыйбыз. Икенчедән, агымдагы елда биш елга кабул ителгән, эре инновацион проектларны башкарып чыгарга, Татарстанга мәгариф системасын модернизацияләү өлкәсендә Россия Федерациясендә әйдәп баручы республика дип танылырга ярдәм иткән Мәгариф үсеше стратегиясе буенча эшне йомгаклыйбыз.

Заманыбыз таләп иткәнчә, Федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры китереп, мәгариф оешмаларының укыту-материаль базасын яхшырту буенча күп эшләр эшләнде. «Ана теле», «Татарстан Республикасында инглиз теле», «Электрон журнал», «Электрон колледж», «Мәктәп картасы», «IT-чемпион» һәм башка бик күп башлангычлар тормышка ашырылды. Укытучылар, укучылар һәм ата-аналар өчен Россиядә уникаль электрон аралашу һәм мәгариф мохите булдырылды.

Балаларны мәктәпкәчә белем оешмаларында урын белән тәэмин итү юнәлешендә зур эш башкарылды. 2013-2015 елларда гамәлгә ашырыла торган

дәүләт программасы кысаларында 156 балалар бакчасы төзелде, 30 меңнән артык өстәмә урын булдырылды.

Урта гомуми белем оешмаларының материаль-техник базасын ныгыту юнәлешендә шактый эш башкарылды. Соңгы өч ел эчендә 632 мәктәп капиталь төзекләндерелде.

Республикада 550 база мәктәбен үз эченә алган гомуми урта белем оешмалары челтәре булдырылды. Бүгенге көндә сәләтле балалар өчен интернат тибындагы 16 гомуми белем бирү оешмасы уңышлы эшләп килә.

Урта һөнәри белем бирү һәм югары уку йортлары системасында да сизелерлек уңай үзгәрешләр бара. Әлеге уку йортларының материаль-техник базасы ныгытыла, белгечләр әзерләү системасы камилләштерелә. 2019 елда эшче һөнәрләре буенча WorldSkills 45нче Халыкара чемпионатын үткәрү хокукы Казаныбызга бирелүе – шуны раслаучы факт.

Сәләтле балалар белән нәтиҗәле эш алып барыла: өченче ел рәттән Татарстан укучылары командасы Россия дәрәҗәсендә өченче урынны яулады. Быел укучыларның бөтенроссия предмет олимпиадаларында 109 укучы җиңүче һәм призёр булып танылды. Иң яхшы нәтиҗәләр экология, химия, хокук, биология, физик культура һәм технология фәннәреннән.

Укучыларыбыз Халыкара олимпиадаларда да уңышлы чыгыш ясады, физика, химия, биология фәннәреннән барлыгы 7 призлы урын яуланды.

Белем бирүнең барлык баскычларында да тәрбия мәсьәләсенең әһәмияте чагыштыргысыз зур. Шуны истә тотып, яңа уку елында мәгариф оешмаларына тәрбия бирүнең сыйфатын яхшырту бурычы куела. Ул «2025 елга кадәр Россия Федерациясендә тәрбия бирүнең үсеш стратегиясе» дигән документ нигезендә башкарылачак. Татарстан Россия төбәкләре арасында беренчеләрдән булып 2015-2025 елларга укучылар тәрбияләү буенча үз стратегиясен кабул итте.

**— Мәгариф өлкәсендә нинди генә яңа бурычлар куелмасын, алар бер максатны — белем бирүнең сыйфатын тагын да күтәрүне күздә тота. Сыйфат дәрәҗәсен билгеләүдә БДИ нәтиҗәләре бердәнбер критерий түгелдер, шәт?**

— Белем бирү сыйфатын билгеләү шактый катлаулы. Ләкин шуңа да карамастан, хәзерге вакытта Россиядә һәм Татарстан Республикасында аны бәяләүнең нәтиҗәле һәм объектив системасы формалаша. Белем бирү сыйфатын билгеләүнең региональ системасы (РСОКО – региональная система оценки качества образования) башлангыч, төп, урта мәктәптә бәяләү процедураларын үз эченә ала.

Башлангыч сыйныфта төп игътибар – баланың мәктәпкә кергәндә психологик әзерлегенә һәм уку елы ахырында ирешелгән уңышларны күзәтүгә бирелә.

4нче сыйныфтан соң исә төп фәннәрдән диагностик тикшерүләр күздә тотыла. Агымдагы елда республиканың гомуми белем бирү мәктәпләрендәге 4нче сыйныф укучылары арасында чит тел, татар теле, рус теле, әйләнә-тирә дөнья, математика буенча тестлар үткәрдек. Барлыгы 36 меңнән артык укучы катнашты. Төп максатыбыз – балаларны дәүләт йомгаклау имтиханнарына әзерләүдә системалы эш һәм методик ярдәм булдыру.

5-9нчы сыйныфларда диагностик бәяләү процедуралары һәм мониторинг үткәрү гамәлдә. Агымдагы елда 5-7нче сыйныфларда математика, физика, тарих, җәмгыять белеме, рус теле буенча 7-8нче сыйныфлар арасында сайланма мониторинглар узды. 9нчы сыйныфларда татар теле буенча бердәм республика тесты уздыру безнең өчен әһәмияткә ия. Төп мәктәптә белем сыйфатын бәяләү 9нчы сыйныфта дәүләт имтиханы тапшыру белән тәгалләнә.

Югары мәктәптә белем бирү сыйфатын билгеләүнең региональ системасы, тест үткәрүнең федераль үзәге белән берлектә, 10нчы сыйныфларда рус теле һәм физика (яки җәмгыять белеме) буенча мониторинглар үткәрү һәм 11нче сыйныфта — математика һәм рус теленнән БДИ тапшырып караудан гыйбарәт булды.

Әлеге процедураларның һәммәсе баланы 11нче сыйныфта бердәм дәүләт сынавын уңышлы үтүгә әзерләү максатыннан эшләнә.

Шулай итеп, Татарстанда белем дәрәҗәсен тикшерүнең яңа моделе БДИ нәтиҗәләре белән генә чикләнми, контроль һәм сыйфат мониторингы белем алуның һәр баскычында башкарыла.

**— Безне, әдәби басма буларак, һәрчак ана телебез, әдәбиятыбызны укытуның торышы кызыксындыра. Сез, шәхсән, тарихка барлык сыйныфлар өчен өр-яңа әдәбият дәреслекләрен төзүне оештыручы булып кереп калырсыз, мөгаен... Белем бирүнең сыйфаты дәреслектән тора, әлбәттә... Тарих, башка гуманитар фәннәрдән дәреслекләрне яңарту федераль үзәк тарафыннан эшләнәдер инде... Республика мәктәпләре өчен аерым фәннәр буенча дәреслекләрне яңартуның кирәге бармы, алар ничек хәл ителәчәк? Махсус урта һәм югары уку йортлары өчен әдәбият дәреслекләре язу күздә тотылмыймы?**

Төп гомуми белем бирү өчен татар теле һәм әдәбияты буенча яңа төр дәреслекләр төзү юнәлешендә 2014-2015 уку елында Министрлык тарафыннан эшләгән эшләр нәтиҗәле булды. Әлеге дәреслекләр белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры китереп эшләнде. Татар теле һәм әдәбияты буенча I-IV сыйныфлар өчен барлыгы 15 комплект (51 исемдә), V-IX сыйныфлар өчен 35 комплект (55 исемдә) дәреслекләр әзерләнде. Шул исәптән 12 линия (54 исемдә) дәреслекләр федераль исемлеккә кертелде. Шулай итеп, Татарстанда татар теле һәм татар әдәбияты фәннәре буенча дәреслекләргә булган сораулар нигездә хәл ителде.

Белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары кертелү барышында мәктәпләрнең китапханә фонды яңартыла. Тарих белеме концепциясе кертелү һәм әлеге фәннән яңа басмалар барлыкка килү сәбәпле, Россия тарихы дәреслекләрен алыштыру зарурлыгы килеп туды.

Урта һөнәри белем алучылар өчен уку-укыту әдәбиятының электрон фонды эшләп килә. Югары белем бирү оешмаларының да бүгенге көндә укыту-методик базасы бай.

**— Югары уку йортлары турыдан-туры федераль үзәк вәкаләтендә булсалар да, гомуми мәктәпләр, махсус урта һәм югары уку йортларында эшләүче педагогик кадрларны республика үзе өчен үзе әзерли бит. Республикабыз мәктәпләре өчен милли педагогия институты булдыру зарурлыгы турында фикерләр еш ишетелә башлады. Бу хакта Сезнең фикерләрегезне беләсебез килә...**

Татарстанда елдан-ел педагогик кадрларга сорау артуын исәпкә алсак, квалификацияле белгеч әзерләү мәсьәләсе әһәмиятле. Шул исәптән татар телендә белем бирергә сәләтле кадрлар мәсьәләсе дә. Агымдагы елда республикада милли (татар телле) педагогик кадрларга ихтыяҗ — 161 белгеч. Прогноз буенча, 2019 елга кадәр белгечләр шул күләмдә таләп ителәчәк.

Югары сыйфатлы педагогик кадрларны республикада алдынгы вузлар әзерли — Казан федераль университеты һәм Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты (НИСПТР). Республиканы педагогик, шул исәптән милли кадрлар белән тәэмин итү эше ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы

һәм әлеге белем бирү оешмалары белән берлектә башкарыла. Казан федераль университеты белән укытучыларны билингваль мохиттә әзерләү, шулай ук татар телле аерым төркемнәр булдыру мөмкинлекләре карала. Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты быел «Башлангыч белем» һәм «Мәктәпкәчә белем» белгечлекләренә татар төркемнәре дә җыйды.

Максатыбыз — Татарстанда инде эшләп килгән, югары квалификацияле педагогик составы һәм яхшы үсеш алган инфраструктурасы булган университетларда эшнең сыйфатын яхшырту, нәтиҗәлелеген арттыру. Булганнан тулысынча файдалану кирәк. Һәм, әлбәттә, тормыш үзе безгә юлын күрсәтер. Янаны инкарь итү түгел бу фикерем.

**— Узган ел республикабыздагы 39 татар гимназиясенең 24ендә булырга өлгердек... Белем бирү сыйфаты, дәрәҗәсенә бәя бирүгә алынмыйм, ә менә милли гимназиядә укучылар белән очрашуларда, Әлмәттә, Чаллыда, Актанышта, Алабугада, Казанның үзендә булмасын, һәркайда милли рух сизелеп тора... Аларда күпсанлы иҗат башлангычлары — түгәрәкләр эшли, алар ук республика конкурсларында актив катнашалар, милли әдәбиятыбыз, сәнгатебез белән, милли матбугат белән танышып баралар. Киләчәктә милли гимназияләрне ачу, шул исәптән рус, башка милләтләрнең уку йортларын ачу дәвам иттереләчәкме?**

— Ин әүвәл, инде әйткәнемчә, республикада эшләп торган мәгариф оешмаларының белем бирү сыйфатын күтәрү өстендә нәтиҗәле эшләргә кирәк. Бу гомуми сүз генә түгел. Милли мәгариф өлкәсендә эзлекле хезмәттәшлек оештыру, урыннарда эшчәнлекне активлаштыру максатыннан, агымдагы елда милли мәгариф өчен җаваплы методистлар һәм татар гимназиясе директорлары белән тыгыз эш алып барылды. Муниципаль берәмлекләр җирлегендә киңәшмәләр уздырылды.

Татар гимназияләрендә туган телдә белем бирү сыйфатын күтәрү, аларның көндәшлеккә сәләтлелеген арттыру максатыннан, узган уку елында министрлык белән Татарстанның 39 татар гимназиясе директоры арасында килешү төзелде. Моннан тыш республика күләмендә муниципаль районнарның рейтингын билгеләгәндә дә, төп критерийларның берсе буларак, укучыларга туган телдә белем бирү күрсәткече кертелде.

Бүгенге көндә республикада ана телендә белем бирүче уку йортларының бербөтен системасы формалашкан: татар телендә белем бирүче 827, чуваш, удмурт, мари телендә белем бирә һәм мордва, башкорт телләре, иврит өйрәтелә торган 153 мәктәп шактый уңышлы эшләп килә. Рус телен тирәнтен өйрәнү һәм рус этномәдәни компонентлы 203 уку йорты эшли. Якшәмбе мәктәпләренең 35 бүлекчәсендә 23 милләт вәкиленең теле, әдәбияты һәм мәдәнияте өйрәнелә.

Укучыларга сыйфатлы белем бирү, уку йортларын тәҗрибәле кадрлар белән тәэмин итү, матди-техник базасын ныгыту йөзеннән, алдагы уку елына Мәгариф һәм фән министрлыгы уку йортларының оптималь челтәрен булдыруны максат итеп куя. Бу җәһәттән республика күләмендә 550 мәктәп база мәктәбе итеп билгеләнде. Әлеге уку йортлары арасында милли мәгарифне әйдәп баручы татар гимназияләре һәм милли мәгариф буенча ресурс үзәкләре булган мәктәпләр дә бар. База мәктәпләренең төп максаты — алдынгы тәҗрибә мәйданы, районлагы башка мәктәпләр өчен методик үзәк, әйдәп баручы булу.

Бүген министрлыкның һәм шәхсән минем төп бурыч — укучыларга сыйфатлы белем бирү, заман таләбенә җавап бирерлек шәхес тәрбияләү. Ә моның өчен бездә уку йортларының оптималь челтәре бар. Алда әйткәнемчә, максат — сан белән түгел, ә сыйфат белән алдыру.

Яна уку йортларына килгәндә исә, агымдагы елда Иннополиста халыкара стандартларга туры килгән яңа мәктәп, КНИТУ-КАИ каршында лицей, Казан шәһәрендә 179нчы номерлы яңа мәктәп ачыла. 1 сентябрьдән Лениногорск, Буа, Яңа Чишмә районнарында яңа гомуми белем бирү оешмалары, Әгерже, Чүпрәле, Чирмешән районнарында башлангыч мәктәп-балалар бакчалары кулланылышка тапшырыла.

**— Сез — укытучылар гаиләсендә тәрбияләнеп үскән шәхес. Әтиегез — гомере буе авыл мәгарифен җитәкләгән кеше. Бүген авыл мәктәпләре, укучылар саны аз булу сәбәпле, кыскартылу, ябылуга дучар... Нишләмәк кирәк, демографик вазгыять шундый... Әтиегез Нәвап ага исән булса, аңардан нинди киңәшләр сорар идегез? Укыту-тәрбия эшендә әткәйләрдән калган искерми торган нинди традицияләрне саклау зарур бүген?**

— Белем бирү, бер яктан, бүгенге җәмгыятьнең иң консерватив, икенче яктан, иң инновацион институты. Мәктәпләргә милли гореф-гадәтләрне саклап калу һәм бер үк вакытта халыкара мәйданда көндәшлек итәргә сәләтле XXI гасыр шәхесе тәрбияләү бурычы куела. Әтием укытучы һәм мәктәп директоры булып хезмәт куйды, Актаныш районында белем бирүне үстерү өчен күп нәрсә эшләде. Үземнең көндәлек тәҗрибәмдә мин аңлы рәвештә һәм тоемлап аның киңәшләренә таянам.

Әлбәттә, тәрбия һәм белем бирүнең нигезен тәшкил иткән рухи кыйммәтләр дә бар. Аларны сакларга тырышырга кирәк. Туган телгә һәм туган якка мәхәббәт кебек кыйммәтләр бик мөһим. Үткәнен хөрмәт итүче, мөстәкыйльлеккә әзер һәм киләчәгенә җаваплы караучы шәхес үстерүнең нигезе ул.

**— Инде искә алуыбызча, милли республикалардагы һәр җитәкче — ул үзе җитәкләгән тармакның әйдәманы, оештыручысы гына түгел, ә милли мәнфәгатьләребезне, милли дәүләтчелегебезне тәэмин итүче сәясәтче дә... Татарстан Республикасы Президенты да республика лидеры гына булмыйча, бөтен татар дөньясының яки Бөтендөнья татарларының Илбашы булган кебек, Сез дә Бөтендөнья татар мәгарифен оештыручы, сәясәтче бит. Милли мәгарифне саклау, үстерү буенча якындагы елларда республикабызда һәм Федераль үзәктә нинди хокукый нигезләр кирәк дип уйлыйсыз?**

— Күп гасырлык тарихы булган милли мәгариф бүгенге көндә яңа сынаулар алдында тора. Ул яңа уку елыннан урта гомуми белем бирү мәктәбендә федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә кертү белән дә бәйле.

Шул сәбәпле 2014-2015 уку елында милли мәгариф системасының ныклы базасын булдыру юнәлешендә федераль министрлык белән тыгыз эшчәнлек алып барылды. Урта гомуми белем бирү буенча Мәгарифне үстерү институты каршында республика укыту-методик берләшмәсе төзелде. Аерым игътибар дәүләт телләрен укытуны тигез күләмдә саклау, федераль министрлыкка фәннәрне укытуда милли-төбәк компонентын исәпкә алу буенча тәкъдимнәр бирү, татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программаларны федераль реестрга кертүгә юнәлтелде.

2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш концепциясе әзерләнү белән бәйле рәвештә, «2015-2030 елларга Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясе» проекты эшләнде. Концепцияне галимнәрдән, мәгариф өлкәсе белгечләреннән торган махсус төркем төзеде. Стратегик документ күпмилләтле республикада милли мәгариф системасын үстерүнең гомуми векторын, принципларын һәм өстенлекле

юнәлешләрен билгели. Концепция милли мәгарифнен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләреннән алып һөнәри белем бирү системасына кадәр үсеш перспективаларын колачлый. Әлеге документны эшләү, тулыландыру, төзәтмәләр кертүне 2015 ел ахырына кадәр тәмамлап кабул итү планлаштырыла.

Концепцияне тормышка ашыру өчен, «Милли мәктәпкә 25 адым» дип аталган 5 эш юнәлешеннән торган «юл картасы» төзелде. Алар:

1. Милли мәгариф үсеше белән бердәм идарә итү системасын булдыру;
2. Туган телдә сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү системасын, туган телне укытуның методикасын һәм технологияләрен камилләштерү;
3. Милли мәгариф системасы өчен педагоглар һәм идарә итүче кадрларны әзерләү эшен камилләштерү;
4. Ресурсларны көчәйтү;
5. Милли мәгарифне үстерү мониторингы механизмнарын эшләү.

Һәр юнәлеш буенча 5әр чараны тормышка ашыру күздә тотыла.

2015-2016 уку елына «2015-2030 елларга Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясе» проектында тәгаенләнгән максатларны гамәлгә ашыру буенча эшне нәтиҗәле оештыру бурычы куелды.

**— Яңа уку елы быел да бик тә истәлекле вакыйгаларга бай... Бөек Тукаебызның туууына — 130 ел, Муса Җәлилнең туууына 110 ел тулачак, тагы да дистәләгән бөек шәхесебезнең тормышына, эшчәнлегенә бәйле вакыйгалар бик күп көтелә... Бу чараларны мәктәпләребездә үткәрүдә әдәби журналларыбыз чын-чынлап ярдәмче була алалар.**

— Безнең милләт талантлы шәхесләргә бай. Халкыбызның рухын саклап калган Габдулла Тукай, Муса Җәлил — әнә шундыйлардан. Туган тел һәм әдәбият укытучыларының 2015-2016 уку елына планлаштырылган Бөтенроссия мастер-класслар бәйгесе, фәнни-гамәли конференцияләр һәм башка бик күп чараларның төп үзенчәлеге — күренекле шагыйрьләребез юбилейларына багышланган булуы. Укучылар арасында үтәчәк иң масштаблы проектлардан — татар теле һәм әдәбиятыннан Халыкара олимпиада, Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча республикакүләм олимпиада, яшь язучылар һәм шагыйрьләрнең «Илһам» бәйгесендә әлеге темаларга зур игътибар биреләчәк.

Мәгълүмати җәмгыять шартларында милли матбугат һәм мәгариф оешмаларының максатчан хезмәттәшлек итүе аерым игътибарга лаек. Чөнки татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү — безнең уртак бурычыбыз.

Әлеге юнәлештәге эшчәнлек киләчәктә дә уңышлы дәвам итәр һәм, әлбәттә, «Казан утлары» журналы һәм башка матбугат чаралары белән безнең хезмәттәшлек тагын да киңәер дигән ышанычта калабыз!

**— Тирән эчтәлекле, ихлас җавапларыгыз өчен зур рәхмәт! Сезне, Сезнең йөздә барлык фән, мәгариф өлкәсендә эшләүчеләрне яңа уку елы белән тәбрик итәбез. Уртак максатларыбызга ирешүдә бергә булыйк, бердәм булыйк.**

*Әңгәмәдәш* — **Илфак ИБРАҺИМОВ.**



Рәфкать
Кәрами

## КАЯ ЧАБАСЫҢ, ГОМЕР ЮРТАГЫ?

РОМАН

**(«Олы юл да сикәлтәле» исемле трилогиянең өченче кисәге)**

**1**

Габделнур һушына килде. Авырлык белән күзен ачты. Беравык үзенең кайда икәнен аңышмыйча торды. Ул куаклар арасында ята иде. Уң кулы белән юеш салкын җиргә таянып торып басты. Башын селкеде, чалбар балакларын, пиджак итәген каккалады. Куакларны аралап, тар сукмаклы ачыграк урынга чыкты, як-ягына каранды. Ниһаять, үзенә ни булганын хәтерендә яңартты.

Ул кичке якта төзелеш комитетының торак-көнкүреш комиссиясе әгъзасы белән әүвәл Северный бистәсендә, халык телендә, «сипушка» дип йөртелә торган, туган-тумачасының ихатасында тактадан әтмәлләнгән, мунча хәтле генә өйдә яшәүче бер балта остасында булды. Аннары алар идарәнең өченче участогында монтажчы булып эшләүче берәүгә бардылар. Ир кеше хатыны һәм ике кечкенә баласы белән Соцгород читендәге ике катлы барактагы кысан гына бер бүлмәдә яшәп ята. Төзелеш идарәсендә ике ел эшли, хезмәтендә гаеп-кыеклары юк. Чиратны бераз алгарак күчереп булмас микән, дип гариза язган. Тикшерү шуның өчен кирәк дип табылган. Моны Габделнурга идарәнең профсоюз оешмасы рәисе җиткерде. Комиссия әгъзалары монда да Северный бистәсендәге эшне башкардылар: бу эшченең дә яшәү шартларын үз күзләре белән күреп, кирәкле кәгазьләрне карап-барлап, акт төзеделәр. Хуҗа бик кыстаса да, әлбәттә инде, юк сәбәпне бар итеп, чәйгә калмадылар.

Барактан чыккач, юлдашы бер якка китте, Габделнур — икенче якка. Караңгы төшә башлаган, якын-тирәдәге өйләрнең һәм ике-өч катлы йортларның тәрәзәләре саргылт төскә кергән. Көне ямьсез, җил, карасу авыр болытлар түбәнтен генә агыла. Урамда кеше-кара сирәк, бала-чага да күренми.

Гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, егетнең юлы бакча аркылы иде. Кинәт агачлар, куе куаклар эченнән ачыргаланып кычкырган хатын-кыз авазы яңгырады.

---

Рәфкать КӘРАМИ (1942) — *язучы; «Каргышлы этаплар», «Очар кошлар белән янәшә» романнары һ.б. әсәрләр авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

— Ярдәм итегез! Талыйлар!

Габделнур туктап калды. Әйләнә-тирәдә беркем юк. Баягы чырылдавык тавыш янә кабатланды:

— Коткарыгыз!

Егет ике уйлап тормады: кисәк сулга борылды һәм, озын куакларны аралап, алга омтылды.

Һәм шул минутта ук егетнең каршында бер әзмәвер шәйләнде, аның нидер тоткан куллары күтәрелде... Бу шулхәтле тиз арада булып алды ки, егет аңышырга өлгермәде: ни кулын күтәреп саклана, ни читкә тайпыла алмыйча калды. Башына сугудан аның күз аллары карангыланды, гәүдәсе мәлҗерәде, ул һуштан язды...

...Ачыграк урынга чыккач, өс-башын каккалаганда, ул пиджак һәм чалбар кесәләренең әйләндерелгән булуын, кульяулыгының һәм пәкесенең дә урынында түгел икәнен белде, димәк...

— Ах... — дип, әшәке итеп сүгенде егет.

Әйе, димәк, теге хатын-кыз ярдәмгә юри чакырган.

— Ә бит ничек чәрелдәде, мәнсез нәрсә, артист кына буласы... Шулхәтле ышандырырлык итеп кычкырды...

Егет үзенең гыйбадлыгы, һәрчак һәм һәркемгә ярдәмгә килергә атлыгып торуы, моның алдын-артын уйламавы аркасында ниндидер усал ниятле бәндәләрнең кармагына капканын аңлады. Шунар шөкрана итәргә кала: хезмәт хакы, аванс алган вакыт түгел, акчасы ун-унбиш сумнар тирәсе генә иде. Дөрес, аена йөз кырык-йөз илле сумнар алып эшләгән кешегә бу да аз акча түгел. Баш исән булсын диярга генә кала.

Сул күзе томанлагандай булгач, битен сыпырса — кан. Башы да сызлый. Уң кулы белән чәченә кагылды — бармаклары кып-кызыл. Чыккан җиренә — куаклар арасына кереп, кульяулыгын табып алды, пәкесе күренмәде. Шунда ук бер метр чамасы озынлыктагы, уклау юанлыгы тимер торба ята иде. Әле дә ярый акт кәгазьләрен теге иптәше, иртәгә иртән конторга керәсем бар, постройкомга тапшырырмын, дип, үзе белән алган иде.

Аннары бакчадан чыкты, як-ягына күз салды. Канга баткан егеткә шикләнеп карап, җәһәт-җәһәт атлап, ике кыз узып китте. Бу хәлендә урам буйлап барса, тагын бәлагә таруы ихтималын (милиция күзенә чалыначак) уйлап алды. Кайдадыр шушы тирәдә хастаханә барлыгы исенә төште.

Хастаханә ихатасы биек тимер койма белән әйләндереп алынган, әнә бәләкәй капкасы да күренә. Аның аша узып, эчкә керде.

Габделнур, табиб ни кушса, шуны тыңлап, башы авыртса да, тешен кысып түзеп утырды. Чиста ак халатлы ир-ат үз эшен бик белеп һәм җиренә җиткереп башкара, күрәсең, аның өчен бу еллар буена күнегелгән гадәти, көндәлек нәрсәдер; таза тәнле, буй-сынлы егетнең юк-барга шыңшымасын белгән сыман, авыртамы, юкмы, дип тә кызыксынмый. Шулай да үзе йомшак, ягымлы тавышы белән һаман сораштыруын дәвам итә. Габделнур моны шулай тиешле кебек кабул итте. Табиб кеше сораштырырга бурычлыдыр, әнә шулай сөйләштергән арада авыруга бераз җиңеллек тә китерергә телидер, дип уйлады. Алар халкы сүз белән дә дәвалый, дип ишеткәне бар иде. Ә чынлыкта исә табиб бу вакыйганы милиция бүлегенә хәбәр итәргә тиеш, сораштыруы шуның өчен иде.

— Хәтерлисеңме, көз көне дә шушына охшаш бер хәл булган иде, — дип, ул журналга берөзлексез нидер язып утырган шәфкать туташына мөрәҗәгать итте.

— Әйе, — диде кыз, каләмен кәгазь өстендә йөртүен туктатмыйча гына баш кагып.

Эшен бетергәч:

— Борчылырлык әллә ни юк, тәнең таза, төзәлер, — диде табиб. — Моннан соң чит-ят җирдә, караңгы урыннарда саграк йөрергә тырыш. Ә безгә берәр атнадан килеп күренерсең. Яланбаш йөрмә, әле суык.

Трамвайда селкенеп кайтканда, егет каршылыклы уйлар кичерде. Менә бүген кич алар икәү, кемнәрнеңдер мәнфәгатьләрен кайгыртып, эштән соң йөрделәр. Ярый, ул — буйдак, ә теге иптәшен өйдә гаиләсе көтә, үз йортында яшәгән кешенең вак-төяк мәшәкатьләре дә бардыр. Эше булмаса, авыр хезмәт көненнән соң ял итәргә хаклы түгелмени? Габделнурга да ял тиеш. Чөнки берникадәр вакыттан соң кулына китап-кәгазь, каләм алачак — политэкономиядән «Халык хуҗалыгының планлы рәвештә үсеше», Азия һәм Африка яңа тарихыннан «Һиндстанның 1857 елгы азатлык восстаниесе» дигән темаларга контроль эшләр тапшырасы бар. Ә ниндидер зобанилар, мөгаен, эчәргә акчалары беткәннәндер, аңа һөҗүм итәләр... Бәлки, алар иртәгә Габделнурга һәм башка бик күпләргә медицина ярдәме күрсәткән табибны да таларлар? Ә ул кайчандыр аларның туганнарын дәвалагандыр... Хәер, табиб булгач, ул кан дошманын да, хәтта бакчадагы теге әтрәк-әләмнәрне дә авыр хәлдә калдырмас, чөнки институтта Гиппократ анты биргән...

Габделнур, теге явызларны күрмәсә дә, менә хәзер кайдадыр эчеп утыруларын (аның кесәсен актарып, талап алган акчага), бу «эш»не ничек оста итеп майтарулары турында берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә мактануларын күз алдына китерде. Аларның кылган җинаятьләренә вөҗдан газабы кичермәүләрен, бәлки иртәгә-берсекөнгә янә шуңа сәләтле икәнлекләрен дә ачык шәйләде егет. Бу адәм актыклары алар тарафыннан кыерсытылган намуслы кешеләр урынына үзләрен куеп карамыйлардыр шул. Юкса юлбасарга әверелмәсләр иде. Ни аяныч, алар гөнаһны да белми, куллары да корышмый. Яңадан кешегә кул күтәрмәм, кабат кеше малына тимәм, дигәнче алтыдан үрелгән каеш камчы белән ярасы иде үзләрен мәйданда, халык алдында...

Егетнең зәклар белән эшләве хәтеренә төште. Аларның да берише кылган явызлыклары, бозыклыклары белән масаеп лаф ора иде бит. Хәтта озын торык авыл гыйбады да, берәүне исертеп (чит кеше түгел, якын танышы турында сүз бара), хатыны белән аның өендә үк әвәрә килүен селәгәен агыза-агыза сөйли иде. Аның, төрмәдә утырмаган кеше кешемени ул, дип әйткәне дә хәтерендә. Теге чакта Габделнур ул мәхбүсләргә битараф булса, хәзер исә мөнәсәбәте үзгәрүен сизде. Әйтәләр бит: кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә...

Тулай торакка кайткач, Габделнур кием алыштырды, бүлмәдәге егетләр гозерләп сорагач, үзе белән булган вакыйганы кыскача сөйләп тә бирде.

Баш астына мендәр куеп, караватында китап укып утырган прораб Шәмсун иң беренче телгә килде:

— Шул кирәк сиңа! Бөке кебек, кайда тишек бар, шунда тыгыласың.

Габделнур үзе дә, бүлмәдәге бүтәннәр дә бермәлгә өнсез калган шикелле булдылар, Шәмсунның бу сүзләре — кеше хәленә керәсе урынга шулай каты бәрелүе — берсенә дә ошамады бугай.

Чәй эчеп утырган, кыска җиңле соргылт күлмәк кигән Миргаяз (ул үз янына яңа кайтып кергән бүлмәдәшен дә дәшкән иде инде) дустын яклыйсы итте, коңгырт күзләрен тутырып Шәмсунга карады:

— Нигә алай дисең?

Шәмсун, китабын ябып, тумбочка өстенә ташлады, күзлеген дә салып куйды. Житү чәчле, зур башлы, киң җилкәле бу егет утызга җитеп килә иде инде. Яшь чагында ул институт командасында волейбол уйнаган, шуңа күрә, атлаганда, башын аска иебрәк йөри, алгарак чыгып торган кулбашлары аркасын

бөкрәйтебрәк күрсәтә сыман, чынлыкта ул бөкре түгел, сау-сәламәт таза егет, хәзерге вакытта физик хезмәт белән шөгыльләнмәсә дә, куллары зур һәм каты. Бүлмәдә һәрчак зәңгәр төстәге йон спорт костюмыннан.

— Андый хәл баштан узган, — диде ул. — Бервакыт, урамда икәү сугышканны күреп, араларына кердем. Ни белән бетте дисең? Үземне үк гаепләделәр. Тегеләр туганнар булып чыкты. Алар бер-беренә сукканнарын оныттылар, ә мин аралаганда, берсенең, ялгыш егылып (чөнки исерек иде), кулын сындыруын кичермәделәр, мина сылтадылар. Бәхетсезлеккә каршы, милиция машинасы узып бара иде... Бүлектә дә бөтен гаепне мина чәпәделәр. Чөнки тегеләр икәү, аларга ышандылар... Менә шулай, егетем, икенче тапкыр кеше сугышканны күрсәң, әйләнеп үт, туктап та торма, эндәшсәләр дә ишетмә, күрмәгән-белмәгән — мең бәладән котылган...

Гәрчә бәхәстә һәркем үз фикерендә калырга тырышса да, Габделнурны да шактый уйга салды бу вакыйга. Нишләсең, ул шулай тәрбияләнгән, күрәсең. Ә бит төптәнрәк уйлап карасаң, Шәмсун сүзләрендә хаклык бар, шайтан алгыры.

Аларның бүлмәсендә узган ел беркадәр үзгәреш булды: Ваня хәрби хезмәткә алынды, ә аның урынына армиядән кайткан элекке солдатны — Сөмбәт исемле егетне керттеләр. Озын буйлы, ябык йөзле бу егет аз сөйләшә, күбрәк тыңлап торырга ярата. Ул чит илдә — Германиядә хезмәт иткән, Варшава Килешүе гаскәрләре белән узган ел август аенда Чехословакиягә кергән, чын мәгънәсендә дары исе иснәп кайткан. Дөрес, яраланмаган да, контузия дә алмаган, әмма ләкин ниндидер яшерен бер канәгатьсезлек күңелен борчыган: ул гамәлнең дөрес булмавын соңыннан аңлауммы (1968 елда Прага халкының совет гаскәрләрен 1945 елдагы кебек сирень чәчәге бәйләмнәре, төче чия пироглары тотып каршыламавын, танклар туктагач, офицерларны кочаклый-үбә өйләренә чакырмавын, бәлки, киресенчә, йодрык күрсәтеп, аларны оккупантларга санауларын һәм үзенең хезмәттәш солдат-сержантларның үлем-житемен күрүе) аның рухи халәтенә бәргән, холык-фигылен үзгәрткән булса кирәк. Ул күп вакытын күрше бүлмәдәге дусты, армиядә бергә хезмәт иткән удмурт егете яисә Шәмсун белән шахмат уйнап үткәрә, шуннан күңел тынычлыгы таба сыман. Аракы эчкәч холыксызлануын белгәнгә, «мәжлес» корган чакларда бүлмәдәшләре аны бик кыстамыйлар, үзе дә стакан күтәрергә атлыгып тормый. Менә шушы аз сүзле Сөмбәт бүген әңгәмәгә кушылуны кирәк тапты, ахры.

— Безнең каныбызга сеңгәндер инде, һаман кеше эшенә тыгылабыз, — дип куйды ул.

Әлбәттә, моны теләсә ничек аңларга була иде: Габделнурның бүгенге хәленә ишарә дип тә, чит илләрнең эчке эшләренә тыкшынуга кагылышлы сәясәткә ишарә дип тә.

— Алайга китсә, үзеңә сукканда да каршы тормаскамыни? — диде Миргаяз, инде сүрелә башлаган бәхәс-әңгәмәне янә куертып жибәрергә теләгәндәй. — Ялгыш берәрсен имгәтеп куюың бар.

— Ә юк, егетем, монысы инде бүтән операдан, — диде Шәмсун, җанланып. — Анысы самооборона — үз-үзеңне саклау дип атала. Американың Техас ковбойлары, алты кеше күтәреп алып барганчы, уникe кеше хөкем итсен, дия торган булган. Мәгънәсе аңлашыламы? Нигә уникe кеше дигәндә, аларда присяжныйлар суды бар, анда — уникe утырышчы.

— Шулаен шулай да, — диде Миргаяз, әмма тиз генә бирешәсе килмәде. — Арттырып жибәрсәң?

— Анысы — бүтән коленкор...

Егетләр арасында мондый сүз көрәштерүләр, бәхәсләр еш чыга. Әлбәттә,

анарга, бүгенге кебек, нинди дә булса вакыйга сәбәпче. Шәмсун институт бетергән, кулында һәрвакыт китап. Ул, тулай торакка кайткач, эш турында сөйләшмәскә тырыша, дөнья, рус классикларын, ЖЗЛ сериясен — атаклы кешеләр язмышына кагылышлы китапларны укый. Шунлыктан китап тотарга иренгән яки вакыты булмаган егетләрнең авызын тиз томалый. Ләкин бервакытта да аларны кимсетү юлына басмый, мәсхәрәгә калдырырга тырышмый. Ул белә: кемнәрдер, бик теләсә дә, сәләтләре чамалы булу аркасында укуны тарта алмаган, кемнәрнеңдер матди ягы кысан булган. Ә кайсыберәүләр үзләре теләми. Аларның күршесендәге абзый малайларын бик укытмакчы иде. Ләкин берсенең укыйсы килмәде. «Ун бармагым белән сарык бугын актарырга риза, укытма гына!» — дип, атасына ялынганын үзе сөйләде яшьтәше Шәмсунга... Әнә Габделнур бик теләп көндезгедә укыр иде, тик бу яшьтә ата-ана җилкәсенә авыр йөк булуны күнеле тартмаган. Шуңа күрә университетта читтән торып белем эстәүче егетне Шәмсун аеруча хөрмәт итә. Ул үзе көндезгедә укыды, ни дисәң дә — ике кулыңа бер эш. Дөрес, аңа да җиңел бирелмәде уку. Аннары ул да ата-ана кулына гына карап ятмады, матди якны үзе дә кайгыртты: иптәшләре белән әртилгә берләшеп, вагон бушатты, балалар бакчасында каравыл торды, җәен студент отрядлары белән Союзның төрле төбәкләрендә тир түкте. Ә бу эшче-студент егеткә шактый авырга килә. Җитмәсә, әнә җәмәгать эшенә җигәләр: тарткан атка һаман йөк салалар.

— Ләкин анда да чама дигән нәрсәне истә тотарга кирәк.

Шәмсун, шул сүзләрне әйткәч, кулына сөлге тотып юынырга чыгып китте.

Бу мәсьәләгә нокта куелып, әңгәмә бетте дигәндә генә, яңасы калкып чыкты. Чөнки егетләр ил-көн эчендә булган вакыйгаларга битараф түгелләр иде.

— Тагын утыз ике солдат-офицер әрәм булды, — дип куйды Сөмбәт.

Сүзнең март аенда Уссури елгасындагы Даманский утравында һәлак булган чик сакчылары турында барганын барысы да аңлый иде. Икенче март көнне безнең егетләргә кытайлар ут ача. Аларны өшкереп чыгардылар чыгаруын (йөзләгәнме, меңләгәнме солдатлары ятып та калган, диделәр), әмма үзебезнекеләр кызганыч. Үлгәннәрен дә, исәннәрен дә бүләкләделәр бүләкләвен. Бер сержантны бәхет басты — аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Егет хәзер кайда да югалмас, уч төбендә генә йөртерләр.

— Ул утрауда кеше дә яшәмәгән, — диде Габделнур.

— Алайса, аның кирәге дә шулхәтле генәдер инде.

Моны Миргаяз әйтте. Ә Габделнурның фикере башкачарак иде:

— Стратегик яктан караганда, бәлки, кирәге бардыр. Тагын шунысы: халык хакы дигән нәрсә дә бар бит әле. Рас ул безнең җир икән, аңа бүтәннәр кулын сузмасын.

Аннары сүз Брежневка атам дип космонавтлар утырган машинага ике пистолеттан ут ачкан кече лейтенант Ильинга күчте.

— Менә бит: тегеләр дә — илне саклаучылар, бу да — Ватанга тугрылык хакына ант биргән кеше.

— Аттан ала да туа, кола да туа, — диде Миргаяз.

Бераздан, Шәмсун юынып кергәнче, ул да тынды. Сөмбәт бик кыстагач, Миргаяз, гәрчә аңа оттырасын анык белсә дә, бер-ике партия шахмат уйнарга ризалашты.

— Детский мат куештан түгел, — диде ул, фигураларны тактага тезгәндә.

— Син хәзер сабыйлык чорын үттең инде, — дип елмайды кичәге солдат.

Чыннан да, беренче көннәрне ул аны өч-дүрт йөрештә үк бирелергә мәҗбүр итә иде. Сөмбәт — башлы егет. Хәрби хезмәттән, Габделнур укырга дип ничек

ашкынып кайтса, ул да шул уй белән яна, шыпырт кына әзерләнә дә, әмма әлегә уй-теләген кычкырып кына әйтми иде.

Бераз вакыт Сөмбәткә карап утыргач, Габделнур әтисен, аның белән әңгәмә корган чакларын искә алды. Йөргән таш шомара, дип юкка гына әйтмиләр. Аннары, дөнья күргән егетләрнең күзләре ачыла — алар чагыштырып карый башлыйлар. Габделнурның әтисе Галләм абзый да, бераз «кабып» алгач, сугыш вакытында Саратов өлкәсендә күргәннәрен сөйли иде. Анда Идел буе немецлары яшәгән, алар бирегә шактый еллар элек килеп төпләнгән булсалар да, сугыш башлангач, аларны Себергә, Казакъстанга куганнар. Ә йорт-җирләре, каралты-куралары, фермалары шул килеш утырып калган. Аларда инде сугышка хәтле үк сууткәргечләр, автопоилкалар һәм башка механизмнар булган. Безнең солдатлар андагы тәртипне, төзеклекне күреп шаккатканнар. Галләм абзый мондагы фермалар, аларның тирә-юне тездән пычрак булуына чын күнелдән борчыла иде.

...Уку димәктән, Габделнур бу арада Ленин районының 20 нче кичке урта мәктәбендә (шөкер, ул янәшә генә — Восстание урамында) педагогик практика үтә.

Тау чишмәсеннән агып төшкән чиста, тешләрне сындырырдай салкын су күл-елгаларны сафландырган кебек, гыйлем ияләре дә үз тирәсендәге аләми затларга аң-белем тарата, аларны мәдәни яктан агарта, рухларына байлык өсти. Габделнур белән дә шулай: укытучы-профессорлар белән күбрәк аралашкан саен, аларның лекция-дәресләрен күбрәк тыңлаган саен, үзендә нинди дә булса яналык сизә, ми күзәнәкләренең уйлау сәләте артканын, калебе чистарганын тоя, әйләнә-тирәсенә гамьлерәк караган төсле була.

Һәм менә дүрт елга якын вакыт эчендә алган белемнәрен тормышта кулланырга, шулар нигезендә бүтәннәргә сабак бирер көн килеп җитте. Ул унынчы сыйныфта «Бөек Ватан сугышы елларында совет халкының героик хезмәте», ә сигезенчедә «1861 елгы реформага хәзерлек» дигән темаларга комиссия алдында дәрес бирде. Хәзер аны алтынчыда «Капиталистик промышленностьның барлыкка килүе. Англиянең колониаль сәясәте» һәм унберенчедә «Социализмга күчү юллары» дигән ачык дәресләр көтеп тора. Житмәсә, унынчы сыйныфта тәрбия эше дә аның җилкәсендә. Шуна күрә ул, Миргаязлар кебек, иректә кош түгел — шахмат-шашка (домино, кәрт сугуны әйткән дә юк) уйнарга вакыты тар, әле тиз генә йокларга да ята алмый иде.

## 2

Кешегә дә, елга кебек, үз-үзен булып калу хас. Язын елга ярларыннан чыга, ташый, дулый, котырына, ә җәен корылыкта, киресенчә, тарая, саега, кибә. Вакыт узу белән, шифалы яңгырлар яугач, көз җиткәч, ул үзенең элекке халәтенә кайта. Кешенең холкы да нәкъ шулай бит: әгәр ул тыныч, уйлап эш итүчән, кешелекле, игелекле икән, кайбер вакыйга-хәлләр аркасында ничек кенә чыгырыннан чыкмасын, унай сыйфатларына вакытлыча хилафлык кылмасын, ахырдан барыбер үзенең асылына кайта.

Габделнур башым авырта дип ыңгырашып, иркәләнеп, урын өстендә ятмады, хәер, иркәләр кешесе дә юк. Аның гадәти тормышы дәвам итте: эшенә дә барды, укуын да онытмады.

Кичтән ярыйсы гына күнелле итеп утырганнар иде, чөнки Мамадыштан Миргаязның абыйсы килде. Билгеле инде, туганы килгәч, егет саранланып тормады. Шуна күрәдер ул төне буе саташып, кемнәр беләндер бәхәскә кереп, сөйләшеп ятты. Габделнур исә соң гына йокыга китә алды.

Иртән аны Миргаязның абыйсы уятты. Габделнур ана эшкә барасын әйтеп куйган иде.

Эштә Габделнурның кулдашы уртача буйлы, озын борынлы, кызгылт чырайлы, саргылт чәчле, узган ел гына армиядән кайткан Дөбәрис исемле егет иде. Кичке мәктәпнең тугызынчы классында укый, өйләнмәгән. Күрәсең, тиз генә камыт кияргә ашыкмас та, чөнки кызларны бик ярата. Аны да кызлар чит итмиләр, егет телгә оста, сөйләшә һәм сөйләштерә белә, һәрчак шат йөзле — дөньяга ачу тотып, аннан зарланып йөрми.

Габделнурны ул бик хөрмәт итә, һәрчак сүзен тынлый. Аның күп белүенә соклана, университетта укуы белән һәм шундый кешенең дусты булуы белән кызлар алдында горурлана.

Ракета гаскәрләрендә хезмәт итеп кайткан, эшен белеп, җиренә җиткереп башкаручы егетне төзү идарәсенең комсомол бюросы әгъзасы итеп тә сайлаганнар. Күрәсең, элекке офицер Митрохин тәкъдим иткәндер. Ул солдат шулпасы эчкән егетләрне җәмәгать эшенә бик теләп тарта.

Габделнур кулдашы Дөбәрис белән участокны әйләнеп чыкты һәм шулар ачыкланды: градирняга — чыгыр, бер корпуска — вибратор, бетон кабул итәргә күтәргечне тоташтырырга кирәк.

— Безгә мич кирәк, — диделәр буяучы кызлар, — туңабыз.

— Кая, үзем генә җылытыйм, — диде Дөбәрис һәм берсен биленнән эләктереп тә алды.

— Кит әле, — дигән булды училище бетереп кенә килгән яшь кыз, ә үзе, кыланчыкланып, электрик абыйсының куенына ук керде. — Кара, җылы икән монда.

Кызлар көлештеләр, усал телләре чеметтереп алырга да күп сорамады:

— Арык бит ул.

— Кая аның җылысы булсын, яшь тә түгел.

— Габделнур абый әнә тик тора, үзенең карт егет икәнен белә...

Кыз сүзен әйтеп бетермәде, Габделнур анысын эләктереп алды, битеннән үбеп тә алды.

— Әбәү, үпте.

— Шаяра гына бит ул.

— Шутили, шутили, а потом появились дети, — диде бер телгә үткене. — Аларга ирек куйсаң...

Кызлар чыр-чу килеп, егетләр бераз тел чарлаганнан соң аерылыштылар. Электриклар, чыгыр тоташтыргач, күрше участокка барып килделәр. Андагы коллегалары, бер телогрейка-бушлат аунап ята, дигән иде. Чөнки Габделнурга яңаны алганда, складка искене тапшырырга кирәк.

Аннары завод ашханәсенә юл тоттылар. Анда Габделнурның бер таныш кызы очрады һәм башын иеп китте. Аны күргәч, егет, кулларын бутый-бутый, юри кычкырып сөйләште.

Сүз бер моторист хакында иде.

— Аның хатыны үзеннән ике яшькә олы.

— Картрак икән, — диде Дөбәрис, әңгәмәне куертып, — бездә үзеңнән өч-дүрт яшькә яшьрәккә өйләнү гадәткә кергән...

Төшке аштан соң, тоташтыргыч һәм кабель күтәреп, күтәргеч янына киттеләр. Будкаларына кайтканда, аларны төзү идарәсенең энергетигы, дүрт ел флотта өйрәнгән гадәтенә тугрылыклы рәвештә аякларын киң итеп аерып баскан, кара куртка һәм фуражка кигән Сәгыйров көтеп тора иде. Ул үзе белән бер электрик та иярткән.

Алар машина белән алып килгән вибратор һәм трансформаторны бетон кабул ителәчәк корпуска илттеләр, тоташтырдылар.

Участок башлыгы чираттагы ялда иде, аның урынына калган прораб белән

сөйләшеп тордылар. Күбрәк энергетик әңгәмә корды, егетләр кирәк чакта гына сүзгә кушылдылар.

Прораб белән сүзен тәмамлагач, Сәгыйров:

— Егетләр, сезгә бераз премия бар, — диде һәм аларны үзе белән конторга алып китте.

— Унтугыз сум гына икән, — диде Дөбәрис, ризасызлык белдергәндәй, аннары үзе үк үз күңелен күтәрде: — Ярый инде, бер сумы да җирдә ятмый бит. Бу атнада авылга кайтмакчы идем, күчтәнәч алырга җитәр.

Дөбәрис Тау ягы районнарының берсеннән иде. Ул өенә еш кайта: әтисе совхозда партия оешмасы секретаре икән, әнисе сыер савучы, икесе дә олы яшьтә. Дөбәрис хәрби хезмәттә чакта утын хәстәрен күрү, бәрәңге алу, печән чабу кебек эшләр энесе җилкәсендә булган. Ләкин, абыйсы кайтканчы, аны да армиягә алып куйганнар, шуна күрә ул эшләгән эшләр Дөбәриска калган.

Алар ягында, «бардымые», «кайттымые» дип сөйләшәләр икән. Егет авылдан килгәч, үзе дә сизмәстән шул сөйләмгә күчкәли.

Шуны истә тотып:

— Тагын тел бозып сөйләшерсен микән инде? — диде Габделнур, күз кысып.

Дөбәрис үпкәләмәде:

— Ю-ук, — диде, аннары үзе дә, руслар әйтмешли, таякның шул ук башы белән шул ук урынга төрттереп алды: — Кеше көлкесе — кешедән көлә, ди. Син үзең дә кыдыл бодаулар йөргән басудан түгелме соң?..

— Ярар, ярар, ул тиклем эчкә кермә. Замнём для ясности.

...Егет күп укый. Иң яратканы — фантастика, детектив. Кино, театрга еш йөри, кызларга яттан шигырьләр укый.

Беркөнне, телефон рәтләгәндә, Габделнур аны чыбыкка җибәргән иде, бик озак торып килде, күрәсен, кызлар янында булгандыр. Ләкин алар сүзгә килмәделәр.

Тулай торакка кайткач, егетләр ашханәгә сугылдылар. Бераз ял иткәч, Габделнур уку белән юанды. Ул бүлмәдә берүзе генә. Миргаяз кибеткә чыгып китте, Сөмбәт күрше бүлмәдә, Шәмсун кайдадыр үз эшләре белән йөри булыр.

Озак та үтмәде, егетләр кайттылар. Кичәге солдат тиз генә бәрәнге пешерде.

Бүтәннәр кебек Габделнур тиз генә йоклап китә алмады, теге хәлне уйлап изаланды. Ул — яшь кеше, тәне төзәлер, ә менә җан ярасы... Бу арада аны гел бер уй борчып, бимазалап, күңеленә тынгы бирми йөдәтте: «Нигә теге зобанилар җәзасыз калырга тиеш әле?»

Әгәр син кемгәдер явызлык кылгансың икән, ул синең үзеңә үк авырлык китерердәй бер гамәл булып әйләнеп кайтырга тиештер бит. Һәм киресенчә: әгәр кешеләргә мәрхәмәтле булсаң, үзеңә дә игелек булып кайтыр. Моны кечкенәдән үк ишетеп, күңеленә сеңдереп үсте ул. Менә хәзер ана карата этлек эшләделәр. Ә җәзасын аларга кем бирә? Теге дөньяда түгел, ә монда һәм хәзер үк. Нигә әле ул кин күңелле булып кыланырга тиеш ди? Бер даһи, Леонардо да Винчи булса кирәк, әйткән: «Кем явызлыкны җәзага хөкем итми, шул аның тормышка ашуына булышлык итә». Юк, егет аларга теләктәшлек итүче түгел!..

Вакыт табып, ул хастаханәгә барып күренде. Аның ярасын теккән табиб, башын җентекләп карап, хәл-әхвален, кәефен, ашау-эчү һәм эшен сораштыргач, укуы белән дә кызыксынды. Егеттән төпле, унай җавап ишеткәч, ул канәгать калды.

— Борчылырлык урын юк, — диде, авыруның күзенә карап. — Төзәлә.

Егет, кайтышлый, үзенә таныш хәвефле урыннан үткәндә, як-ягына каранды. Өч катлы йортның подъезд төбендә салмыш бер адәм эскәмиядә утыра, янында хатын-кыз да бар. Ир-атка кушылып, ул да кычкырып-кычкырып сөйләшә, шаркылдап, урам яңгыратып көлә. Габделнур кинәт кенә туктап калды. Чөнки әлеге хатынның тавышында аңа таныш интонация-аһәң ишетелде кебек иде. Егетнең колагына аю басмаган, аз-маз музыка белән шөгыльләнгән кеше буларак, ул моны жинел тоемлады. Әйе, шик юк, ачыргаланып кычкырган, ярдәм сораган тавыш бит бу!

Егет йөрәгенең еш-еш тибүен тойды, башына кан йөгергәндәй булды, бөтен барлыгы нәфрәт белән тулды һәм аңарда үч алу теләге туды. Әйе, ул боларны акылга утыртырга тиеш. Алар үз җинаятьләренең җәзасын күрергә тиеш. Ә ничек? Милиция, дусты Ирек ярдәме беләнме? Юк, аны катнаштыру кирәкмәстер. Чөнки нәкъ менә бу адәм Габделнурга сукканны, тимер торба белән тондырганны исбат итү кыен булачак. Бүлмәдәшләрне алып килсәң? Әлбәттә, егетләр каршы килмәсләр һәм тегене ярыйсы гына изәрләр дә иде. Кирәкми, эшнең зурга китүе ихтимал. Нишләргә соң? Йөрәге дөп-дөп типкән егет, ботинка табаны жилемгә ябышкандай, беркавым кузгалып китә алмыйча торды. Йә, нишләргә соң? Әгәр чукынып кына китегезсәнә дип кул селтәсәң, онытырга тырышсаң? Алай итү тегеләргә, ярар, киләчәктә дә шулай дәвам итегез, уңышлар телим дигән кебек була түгелме соң бу?

Язгы авыр болытлар астында, шыксыз кичтә гел бер үк караңгы уй аның бәгырен кимерде: «Ничек үчен кайтарырга?» Һәм, трамвайда тирбәлеп кайтканда, озак баш вата торгач, ул, ниһаять, ныклы бер карарга килде.

Шул карарын тормышка ашыру нияте белән Габделнур икенче көнне кич янә әлеге хәвефле урынга юнәлде. Өстендә эшкә йөри торган киң куртка, аның якасы күтәрелгән, эчке түш кесәсе беленер-беленмәс кабарыбрак тора, башында ак фуражка.

Ул, трамвайдан төшкәч, таныш юл белән югарыга таба менеп китте, аннары уңга борылды. Ни булса, шул булыр, дип, кичә тегеләр утырган подъездга таба атлады.

Бүген дә анда, эскәмиядә, тегеләр икәү утыра. Кычкырып сөйләшүләреннән, кул хәрәкәтләреннән салмыш икәнлекләре әллә каян күренеп-сизелеп тора.

Габделнур исереккә салышты. Кирәк чакта артист та була белә ул. Алабугада аларны Мәскәүдә укып кайткан югары белемле режиссёр укытты, студентлар белән «Яшел эшләпә» дигән спектакль дә куйды. Билгеле, анда Габделнур да катнашты. Бергә укыган кайбер иптәшләре соңыннан хәтта профессиональ дәүләт театрына эшкә дә урнаштылар, чын артист булып киттеләр. Менә шул. Егет, аякларын чалыш-чолыш атлап, тегеләр каршына барып басты. Бер читтә үзенә таныш торба кисәген дә күреп алды. Әмма аны тануын һәм шуның аркасында ачуы кабаруын йөзенә чыгармады. Фәкать үзенең дөрес чамалавын гына аңлады.

— Сәлам, — диде ул тәкәллефсез генә. — Нәрсә каңгырап утырасыз?

Иске фуражка кигән башын аска иебрәк утырган ир-ат күзенең агы белән генә Габделнурга карады.

— Синең ни эшең бар? — диде ул төксе генә.

Аның өстендә иске телогрейка, тез башлары кабарып торган, гомерендә үтүк күрмәгән кара чалбар, аягында каптырмалары эләктерелмәгән «прощай» ботинкасы. Гәүдәсенә караганда, буе Габделнурдан чак кына калкурак булыр, жилкәләре дә шактый киң күренә, бөрешеп утырганга күрә үзе мескен кыяфәттә.

— Кореш, син нәрсә теш ыржайтасың? — диде Габделнур, телен

көрмәкләндереп, аның төртмә сүзенә үпкәләгәнен дә белдерергә тырышып.

— Мин сина бер начарлык та эшләмәдем бит әле.

Сакал-мыегы кырылмаган адәмнең чиртсән кан чыгарлык кызгылт чыраена карап, ана утыз биш-кырык яшьләр чамасы биреп булыр иде; сул күзе төбендә «фонарь» бар, борыны җәлпәк.

— Яхшылык та эшләгәнең юк, — диде ул.

Бу юлы сәрхушнең тавышы баягыча ук дорфа чыкмады, чөнки каршында торган егетнең салмыш икәнен, ә тавышында ныклык, үз-үзенә ышанганлык барын искәрде булса кирәк. Алар халкы, үзләре башкисәр булганлыктан, кемнең куркак, кемнең үз тиңе икәнне тиз төшенә бит.

Сүзгә янында утырган хатын-кыз да кушыласы итте:

— Ие.

Анысы да, ике чабата — бер кием дигәндәй, төс-кыяфәте, үз-үзен тотышы һәм кием-салымы белән янәшәсендәге адәмгә пар килердәй иде: аскы ирене күпереп зәңгәрләнеп-шәмәхәләнеп тора, күрәсең, шушы араларда гына берәр каты кулдан яхшы гына эләккән булса кирәк, эчә-эчә шешенеп бүртенгән битенә мул итеп сөрткән кызыл кершәне аның бизәнү серләрен бигүк белеп бетермәве яки кайчандыр белеп тә, инде күптән онытуы хакында сөйли. Башындагы кызыл береткасы да, өстендәге зәңгәр язгы-көзге пальтосы да таушалган-изелгән, аягындагы кыска кунычлы ак резина итеге дә тузган.

Габделнур, фәкать ир-атка гына мөрәҗәгать итүен сиздерү өчен, «син»гә басым ясады.

— Шеф, син зерә алай тупас сөйләшәсең. Мин синнән стакан гына сорамакчы идем. Ярый, хуш...

— Нигә ул сина? — диде ир кеше, стакан сүзен ишетүгә тагы да йомшый төшеп.

Хәзер инде Габделнур дилбегәне тулысынча үз кулына алды.

— Стакан белән нишлиләр инде? Син, фраер, бигрәк ангыра икәнсең. Шешә бар. Бугазыннан эчәсе килми, — диде егет һәм, курткасын чишеп, эчке кесәсеннән башланмаган ярты чыгарды.

Тегеләрнең күзләре ялтырады, үзләренә җан керде, йөзләрендә елмаю галәмәте чагылды. Әүвәл ир-атның теле ачылды:

— Башта ук шулай диләр аны.

Хатын да сүз кыстырды:

— Ие.

Габделнур янә иргә карады:

— Сина да өлеш чыгарырмын. Кая, стаканың юкмы?

— Ә мина? — диде хатын-кыз, еламсырап.

Ләкин аңа игътибар итүче булмады.

— Монда юк, — диде ир кеше һәм ярым борылып дәште: — Бар, алып чык.

— Бар үзең, — дип карышасы итте хатын аламасы, әллә торасы килмичә, әллә хәле юктан, әллә үзен кешегә санамауларына гарьләнеп.

— Нәрсә?! Ике әйттермә, юкса...

— Ярар, ярар.

— Ычкын!

Хатын көч-хәл белән, теләр-теләмәс кенә урыныннан торды, чайкалды, әмма егылмады, теге адәмгә сиздермичә генә, аларны авыр хәлдән коткаручыга күз кысты, кыек авызы, чалыш иреннәре белән елмайды һәм, арт санын уйнаклатып, подъездга кереп китте.

— Утыр, — диде ир-ат, уң ягына ишарәләп һәм чак кына урыныннан күчте.

Беренче елны зеклар белән эшләве ярдәм итте: «Үз кеше» булуында шик калдырмас өчен һәм ныграк ышандыру теләге белән, Габделнур тәмамысы болар сөйләменә күчте:

— Не хрен, постою, — диде һәм аягүрә калды.

Чөнки егет хатынның ничәнче катта, кайсы фатирда яшәвен дә, күпме тоткарланасын да белми иде. Житмәсә, вак кына яңгыр сибәли башлады. Шуңа күрә ул як-ягына каранып алды да:

— Синең акчаң төшкән, — дип, тегенең «прощай» ботинкасына ымлады.

Беркатлы бичара башын аска июгә, Габделнур күз ачып йомганчы аракыны башта сул кулына авыштырды, аннары уңы белән шешәне муеныннан тотты да хәмергә сусаган бәндәнең башына тондырды.

— Мә, хайван, эч!

Ташка таш бәрелгән кебек, тонык аваз чыгарып, шешә чәлпәрәмә килде. Пыяла ватыклары як-якка таралды, сыекчасы теге адәмнең фуражкасына, колак-муенына, түшенә-аркасына акты. Ә бу мизгелдә Габделнурны ай күрде, кояш алды — читкә ыргылды. Армия хезмәтендә занятиеләрдә һәм спорт ярышларында йөз метрга йөгергән чакларын исенә төшерде — жан-фәрманга очты...

Фәкать караңгы тыкрыктан олы урамга чыккач кына, ул йөгерүеннән туктады, әмма, тиз-тиз атлап, тукталышка таба баруын дәвам итте. Сул яктан троллейбус килүен күрде, йөгерә-атлый, аңа сикереп менеп утырды.

Ярамаган эш эшләсә дә, күңелендә ниндидер канәгатьлек тойгысы барлыкка килде. Аның йөрәге ярсып тибә иде. Юк, бу куркудан түгел, арттан куып житәрләр дип шикләнүдән дә түгел. Моның булмасын ул анык белә.

Бераздан, кайта-кайтышка, сулуы тигезләнде, йөрәк тибеше акрынайды, кан кайнарлыгы сүрелде. Беренче минутларда үзенең егетлек күрсәтүе аңа жан тынычлыгы китергән шикелле булды. Аракыга тотылган акчасы өчен дә уфтанмады, әле һаман сәрхуш белән әрепләшкәндәй әйтеп куйды: «Капланып киткере!» Әйе, кирәген бирде теге адәм актыгының, ләхәүләсен укытты, икенчеләй кешегә кул күтәрмәслек итте. Ләкин, троллейбус алга барган саен, бер тукталыштан икенчесенә күчкән саен, аның да күңеленә ятышсыз, жан әрнеткеч уйлар килеп, фикер сөреше үзгәрә башлады. Дөрес эшләдеме соң ул? Нинди «олы» эш кырды соң ул, йә? Үзе дә үҗәтлеге аркасында теге зобани ролена керде түгелме? Әгәр аңа торба белән кундырган кеше бу түгел, ә бөтән берәү булган булса? Димәк, ак эт бәласе кара эткә дигәндәй, нахакка кул күтәргән, явызлык күрсәткән була түгелме соң?! Ярар, теге кеше нәкъ үзе дә булды ди. Әгәр башы ярылып, жиргә егылып, аны каһәрләп ятса? Габделнур кебек бу да канга батса? Икесе дә бер калыптан — кан коючы-жан кыючы булалар түгелме? Бүген-иртәгә югары белемле укытучы белгечлеге алып чыгасы кеше теге аңгыра сәрхуштән нәрсәсе белән аерыла соң? Һәм аның тәрбияче сыйфатында мәктәп бусагасын атлап, балалар каршына барып басарга хакы булачакмы?.. Ә нишләргә иде соң? Кайсыдыр акыллы башның әйткәне хәтеренә төште: «Игелекле булырга тырышыгыз һәм сез яман эш кылырга сәләтсез икәнегезне күрерсез...» Әйтүе жинел ул. Ә тормышта... Аһ бу уйлар... Нишләп гамьсез генә яши алмый икән ул?! Ятса — уй, торса — уй дигәндәй... Бар бит артык баш ватмыйча гына яшәүчеләр дә... Ә ул...

Шуңа күрә егет тулай торакка яуда жиңүче сыйфатында башын горур тотып түгел, ә кәефе кырылып, төшенке күңел белән, эшләгән чатак эшеннән разый булмыйча, аннан шатлык-куаныч тапмыйча, канәгатьсез кыяфәттә керде.

Әнә шундый каршылыклы уй-кичерешләрдән соң ул булып узган вакыйга хакында авыз чайкамаска, беркемгә дә белгертмәскә, иң якын дус-ишләре белән дә серен уртаклашмаска үз-үзенә сүз бирде. Хәер, ул үзе дә бу күңелсез вакыйга турында уйламаска, артык баш ватмаска тырышты, чөнки алда мөһим бурыч — практика узу тора иде.

...Ниһаять, бүген ул мәктәптән җинел сулап, кош тоткандай шатланып чыкты: кулына директор, завуч һәм тарих укытучылары имзалаган белешмә алуга иреште. Алар практикантны һәрьяктан унай бәяләгәннәр, димәк, тырышуы, йокысыз төннәр үткәрүе бушка булмаган.

### 3

Габделнур эштән кайтуга, вахтёр хатын ана бер кәгазь кисәге тоттырды.

— Синең дустыңнан, — диде ул елмаеп һәм, егетне аптырашта калдырмас өчен, өстәүне кирәк тапты. — Милициядә эшләүче.

Фәлән ел ишек төбендә утырган бу апа карт егетләрнең (Габделнур белән Ирек Коллективная урамында яшәгәндә дә ул анда вахтёр иде) дус-ишләрен дә, йөргән кызларын да белеп тора иде.

— Рәхмәт, апа, — диде Габделнур һәм баскычтан күтәрелә башлауга ук дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәген ачты.

Язу рәвешеннән үк таныды — Иректән. «Картлач, вакытың булса, бүген кич җиделә «Маяк»та очрашыйк әле. Сөйләшәсе сүз бар. Ирек». Числосын да куйган.

Габделнур сәгатенә карап алды, тиз-тиз баскычтан күтәрелде, бүлмәсенә керде. Өйдә булган егетләр белән исәнләште, бер-ике сүз белән генә хәл-әхвәл белеште. Аннары яхшылап юынып керде, чиста киемнәр киеп, аска төшеп китте. Үз-үзенә, туйга барсаң, туеп бар, дип, гәрчә дусты ресторанга дәшсә дә, буфетта тамак ялгап алды. Восстание урамыннан җәяү генә өскә таба менеп китте.

Ирек граждански киемнән — костюм-чалбар, күлмәк, галстуктан, урамда аны көтеп тора иде инде. Гадәттәгечә җылы гына исәнләштеләр, эчкә уздылар, урнаштылар. Залда халык күп түгел, шулай да бер-ике өстәл янында ярыйсы гына «төшереп» алган ир-атлар кызып-кызып гәп куерталар. Талгын гына музыка агыла.

— Үзем заказ бирәм, — диде Ирек һәм, менюга күз салып алгач, тулы гәүдәле официант хатынга ашау-эчү ягыннан ни-нәрсә кирәген әйтте, як-ягына карап алды да аракы да китерергә кушты.

— Күп булмасмы? — дип елмаеп сорап куйды Габделнур.

— Житсә.

Бер-ике авыз сүз белән генә бер-беренең эш-гамәлләре хакында белештеләр. Аннары Ирек, дустына туры карап, житди генә әйтеп салды.

— Картлач, сөйләшәсе сүз бар иде.

— Тыңлыйм. Эштә берәр күңелсезлек килеп чыктымы әллә?

— Юк. Өйдә.

— Ничек?

— Шулай... Минем синнән дә якын кешем юк...

— Арттырма инде... Апаң, җизнәң...

— Юк, аларны тыкшындырасым килми. Аннары әти-әнигә тишелә, алар борчыла. Пока ишетелмәсен. Җайлап кына белгертермен әле.

— Үзең беләсең инде.

Ул арада официантка шешә, чәркә-фужерлар, кабымлык китерде. Берәрне каплагач, дусты сүз башлады.

Элек ут янып торган елтыр күзле, шат йөзле Ирек хәзер ничектер

сүлпәнләнгән, ябыккан, өметсезлеккә үк бирелмәсә дә, юл читында югалып калган ничарадан бичара кешедәй күренә. Гәүдәсе курачланган.

Ирек бәйнә-бәйнә үз хәлен, соңгы бер-ике елда башыннан үткәннәрне сөйләргә кереште.

Габделнур аны бүлдермәскә тырышып тыңлады. Ара-тирә салгалап, капкалап алганда гына Ирек тынып тора иде. Җан ачысы белән сөйләнгән өзек-өзек вакыйгалардан аның Фәнирә белән өйләнешкәннән соң башланган гаилә тормышы бөтен тулылыгы белән Габделнурның күз алдына килеп басты. Әйе, юкка гына, кеше күңеле — караңгы төн, димиләр шул. Моңарчы Ирекнең, гәрчә сирәк-мирәк очрашсалар да, гаилә хәлләре хакында авыз чайкаганы юк иде. Ул мәсьәләдә ир-ат халкы хатын-кыз кебек җәелеп китми бит, үз эченә җыя. Шуңа күрә Габделнур күп нәрсәдән хәбәрдар түгел, дусты сөйләгәннәр аның өчен яңалык, кайберләре хәтта гайре табигый хәл иде.

Күрәсең, «чуан» шулкадәр зурайган, тулышкан — тишелер дәрәҗәгә җиткән... Менә нинди иде дустының хәле.

...Ирек эштән кайтты, чишенде, юынды һәм, ашау өмет итеп, кухняда өстәл янына утырды.

Бу фатирны өйләнер алдыннан, аңа элек төзү идарәсендә бергә эшләгән таныш балта остасы табып бирде. Хуҗалары, ирле-хатынлы, ике елга Монголиягә командировкага китәселәр, балаларын авылга әти-әниләренә кайтарасылар, ә фатир — буш каласы.

Ирек, кайчандыр әбисе авызыннан ишеткән, ир хәстәрле булса, хатын калфаклы була, дигән сүзләрне истә тотып, бик тиз риза булды, тегеләр әйткән хакны да сатулашмады, чисталык, тәртип булачагына да ышандырды. Фатир хуҗалары да, егетнең милиция бүлегендә эшләүче икәнен белгәч, бик теләп ризалаштылар. Вакытлыча, үзенә хезмәт урыныннан берәр торак биргәнче яшәп торырга бик кулай иде бер бүлмәле, бөтен уңайлыклары, җиһаз-фәләне булган бу фатир.

— Кая, нәрсәң белән сыйлыйсың? — диде ул хатынына ягымлы гына. — Ачыктым. Нәрсәң бар?

Фәнирә төксе генә:

— Бернәрсәм дә юк, — диде. — Әнә, үзең пешер дә аша.

— Ничек?

Ирек аптырап китте, әле моңарчы хатынының болай сансызлык күрсәткәне, тупас кыланганы юк иде. Фәнирә янә дорфа эндәште.

— Мин эштә дә көнозын плитә янында торам...

Ирек гозерен кабатламады, сүзне зурга җибәрмәде, үзенчә фикер йөртеп, болайрак нәтиҗә ясады: «Авырлы бит, хатын-кызның холкы үзгәрә дип әйтәләр иде, дөрес икән».

Хатыны кухнядан чыгып ук китте. Ирек аптырап тормады (солдатта булган егет бит), тиз генә йомырка кыздырды, чәй кайнатты. Фәнирәне дә табынга дәште, ләкин анысы диваннан кузгалмады, телевизорга багынды, иренә борылып та карамады.

Ирек үзенчә, хатынының бу холыксызлануы вакытлы гынадыр, дип уйлады, көзге төннең томаны иртән кояш чыгуга таралган кебек, озакка бармас дип өметләнде. Кызганычка каршы, бу хәл еш кабатланды. Хатыны көннән-көн тупасланды, авызыннан аракы исе килгән чаклар да булгалады. Кайчагында Фәнирә эшеннән коры-сары алып кайта, ләкин Ирекнең каты-коты белән генә тамагы туймый, кайнар аш та тансыклый. Шуңа күрә үзенә пешерергә туры килә иде. Ничек кенә кәефе кырылмасын, ул хатынына авыр сүз әйтмәскә тырышты (кая анда кайберәүләр кебек кул күтәрү).

...Фәнирә, эштән кайткач, иреннән унайсызланган сыман тоелды, чишенгәндә тәнен дә күрсәтмәскә тырышты.

Ирек соңыннан белде: ул авариягә эләккән икән, директорның «Волга»сында булган бу хәл. Моны ул таныш милиционерлардан ишетте: хатынының фамилиясен, исемен әйттеләр. Кая барган, нишләгән? Төпченде, сорашты хатыныннан, әмма анык җавап ала алмады.

— Эш белән бардык, — диюдән ары узмады Фәнирә. Шуннан Ирекнең башына шик төште.

...Фәнирә тиктомалга сүз башлады.

— Бүген директорны бер хатын белән тоттылар.

— Ничек? — дип сорады Ирек.

— Директор аны бүлмәсенә чакырган да... эшкә дә керешкәннәр... Рестораннар трестыннан берәү килгән булган, шул өсләренә килеп кергән... Белмим, ничек алай оплошность җибәргәндер директор, ул ишеген бикли торган иде...

Фәнирә сөйли дә сөйли, күрәсең, бүген дә бераз «капкан» булырга тиеш. Ә Ирек аның: «...ишеген бикли торган иде», — дигән сүзләреннән зиһенен җыя алмыйча утыра. Димәк... Ләкин ул дәшмәде, үзенең «мөгезле» ир икәнен тою ана шулкадәр гарьлек иде, бу хурлыктан җир тишегенә керердәй булды. Ачу тулы күзләре белән хатынына карады, аннан-моннан капкалады да, бүлмәгә чыгып, кулына китап алды..

...Икенче вакыт Фәнирә (теләр-теләмәс кенә, бик иренеп кенә) аның эчке киемнәрен юганда:

— Хәзер ирләр мондый трусик кимиләр инде, — дип ычкындырды. Ә Ирекнеке гап-гади кара сатиннан иде.

Ул, артык сүз куертмас өчен, уен-көлкегә борды.

— Әнә, цирктагы клоуннар кия торган чуарны ал.

Юморны аңламыйча:

— Акча юк, — диде хатыны дорфа гына.

Ирек аптырады: ничек акча юк, әле кайчан гына хезмәт хакы алып кайтып шкафка куйды бит. Хатыны югында шкафны ачып караса — акчадан җилләр искән. Ә Фәнирәнең муенында шушы арада гына яңа алтын чылбыр пәйда булган иде. «Алай икән, — дип кенә куйды ир кеше. — Узган айда затлы күлмәк алган иде...»

...Ирек хезмәтендә йомыш төшеп, хатыны эшләгән ресторанга якын гына бер оешмада булгач, ул, Фәнирәне дә алып китәрмен дип (аның эше бетәргә тиеш иде инде), арт ишектән ресторанга керде һәм ак башлыклы бер хатынга мөрәҗәгать итте.

— Фаяны чакырыгыз әле.

— Китте бугай ул, — диде пешекче.

Боларның сөйләшүен ишетеп торган икенче хатын:

— Хуҗа янындадыр, аның күңелен күрмичә китмәс, — дип теленә салынды.

Беренче пешекче тегенә ачу белән карады, күз кысты, башын селкеде.

— Синнән сораган кеше юк, бар, эшеңдә бул, — дип усал гына дәште. Икенчесе, һи, дип, авыз кыйшайтып, китеп барды.

— Хәзер, көтеп торыгыз, — диде пешекче хатын Ирекка һәм китеп барды.

Ирек түзмәде, аның артыннан атлады. Хатын аны күрми иде. Ул директор бүлмәсенең ишеген шакыды. Ләкин шакуы радистлар куллана торган Морзе әлифбасын хәтерләтте: ике тапкыр кага да, пауза ясап, янә бөгәрләнгән урта

бармак сырты белән берне бәреп ала. Ул шулай ике мәртәбә кабатлады. Ишек ачылмады. Хатын артына борылды, Ирекне күреп, бермәл каушап калды, аннары бик тиз үзен кулга алды.

— Гафу итегез, анда бер кеше дә юк икән, Фая кайтып киткәндер, — диде кыңгыр эш өстендә тотылган кешедәй юаш кына.

Кырык-кырык биш яшьләрдәге бу хатын директорның ышанычлы кешесе яисә туганыдыр, ахрысы.

...Ирек нидер эзләгәндә шифоньер артына күз салды һәм... сискәнеп китте: анда сидеккә-букка каткан бала чүпрәкләре аунап ята иде. Димәк, бер яше тулуга имидән аерып, баласын авылына кайтарып ташлагач, хатыны аларны юмыйча шунда тотып аткан. Ирек чүпрәкләрне юып, балконга элеп куйды.

Хатыны эштән кайтты. Исәнме-саумы юк, ул серванттагы аракы шешәсенә үрелде.

— Син нишлисең?

— Нишләсәм дә эшләрмен. Анда синең ни эшең бар?

— Нәрсә? Бир! — Ирек хатыны кулыннан шешәне тартып алды. — Утыр!

— Йә, утырдым. — Хатыны диванга чүнкәйде. — Шуннан?..

Ирек, бәлки яхшылык белән әйткәнне аңлар дип, тавышын күтәрмичә генә үгет-нәсихәт бирмәкче иде. Ләкин бик тиз сүзгә килделәр, ызгыш купты. Фәнирә пәрмә-пәр талаша башлады, ярсыды, сүгенүгә үк күчте, чөнки салмыш иде.

Ирек тә җавапсыз калмады, хатынын бик каты әрләде һәм ахырда:

— Син мине генә түгел, баланы да юньләп карамыйсың! — диде.

— Нәрсә булган?

— Шифоньер арты тулы бала чүпрәге.

— Әллә кулың калдымы? Әнә, юып куйгансың бит, — дип Фәнирә балконга таба ымлады.

— Оятсыз! Мин сине бүген үк ташлап чыгып китәр идем...

— Куркыттың! Кит!

— Балам гына җәл...

— Җәлләмә! Ул синең балаң түгел!

— Ә?!

Хатын исенә килде, ләкин соң иде инде. Әйтәсе сүз әйтелгән. Ул тегеләй-болай боргалана башлады.

— Мин... син тапкан бала түгел, минеке дип әйтәсе идем... Аны мин тугыз ай корсакта йөрткән бит...

Ләкин Ирек аның аклануын тыңламый иде инде. Фәнирәнең: «...синең балаң түгел!» — дигән сүзләре аны тәмам ярсытты.

— Син кияүгә чыкканчы ук, Шекспирның Гертрудасы кебек, егетләрне алмаштырып торгансың, алар астына яткансың... Мин сине әллә туктарсыңмы дип уйлаган идем. Ә син һаман игә килмисең, сиңа һаман җитми икән... Шлюха!

— Кадерлем, мин...

Ирек: «Бу хайванга ник тел әрәм итәм соң?!» — дип, ишекне шапылдатып ябып, урамга чыгып китте. Аңа бу өйдә һава җитми, йөрәге дөп-дөп тибә, бәгырен корт кимерә; хатынына булган ачуы балага да күчте. Димәк... «Аптырый идем аны: хатын кара чәчле, минеке дә кап-кара, ә кыз сары чәчле...» Ул еш кына, ни өчен бу балага күңелем тартылмый, салкынлык тоям, дип пошына иде. Хәзер генә аңына барып җитте: үз каны булмаганга шул халәтне кичергәндер...

Бүген Габделнур белән киңәш-табыш итү өчен очрашты. Аңа бер бушанып алу да кирәк иде. Икесе ике җирдә эшләсәләр дә, әллә нигә бер

күрешсәләр дә, Габделнур анын өчен әле дә үз туганыдай якын кеше, серен чишәрдәй, күңел түрендәге ачып салырдай бүтән якын дусты юк. Ә күңел тулып ашты, эче тулы ут.

— Менә шундый хәлләр, картлач, — диде Ирек, ачынып.

— Әйе, шундый-шундый эшләр, тора-бара нишләр, дип кенә котылып булмый, — диде Габделнур, аптырап һәм дустының хәленә кереп. — Эшләр зурга киткән икән шул.

— Әйдә, тотып куйыйк, нәфсең булса, тагын заказать итәм.

— Бәлки, җитәр? Үзенә кара.

Рюмкаларны бушаткач, Ирек янә телгә килде.

— Үзеннән котылырга кирәк, шунсыз булмый. Йә кызулык белән берәр хәтәр эш эшләп ташлармын, башны төрмәдә черетер.

— Ну, анысын уена да китермә!

— Килә шул.

— Кызлар бетмәгән.

— Син хаклы булып чыктың, дускай. Хәтерлисеңме, мин Фәнирәгә өйләнер алдыннан: «Хатын-кыз икене татыса, анын өченчедә дә нәфесе булачак», — дигән идең. Мине кисәткән идең. Ә мин сүзенә колак салмадым, ярата идем шул.

— Да, күңелле хәл түгел. Тормышыңның җимерелүе начар. Янабаштан гаилә корырга туры киләчәк...

Алар әле тагын беркавым сөйләшеп-кинәшеп утырдылар, янә бер-ике рюмка тоттылар, тик хәмер берсенең дә башына китмәде. Чөнки сөйләшү — кысыр көеккә көю генә түгел, алда җитдирәк мәсьәләләр куера, аларны хәл итәсе бар — тормыш дигән олы дәрьяны кичү хакында иде уйлары...

...Ирек Фәнирә белән булган очрашуларны, ике арадагы сөйләшүләрне, корылган әңгәмәләрне кат-кат уеннан кичерде. Егет үзен нарат агачы дип белеп, кызгылт көрән төскә буялган калай торбаны чукыган тукран кебегрәк хис итте (бервакыт ул шундый күренешкә тап булган иде). Кызның елау-сыктауларын исенә төшерде. Бавыры бала басмаган булып кыланды бит.

Ирек һич аңламый һәм: «Нүжәли мин шулкадәр беркатлы булдым икән? — дип аптырый иде. — Әллә ул шултикле оста артистка булдымы? Үзешчән сәнгатьтә катнашкан бит. Алай дисәң, күз яшьләре чын кебек тоелды. Авырлы чакта гына яисә бала тапкач кына үзгәрдеме холык-фигыле, әллә электән шулай калыпланган идеме? Дөрес, аллашуын сизде сизүен, ләкин ялганын тотканын үзенә әйтмәде. Бәлки, шул чакта ук тәртәне кирегә борасы булгандыр?» Хәтеренә уелып калган сүзләре, бигрәк тә, бала яратам, диюләре... Ә чынында... Хәер, егетнең үзен дә ярата иде шикелле... Әллә ул мавыгу гына булганмы? Шулайдыр. Чын ярату булмагандыр.

Әйе, Ирек хаклы иде.

Җәй көне, яңгыр яугач, урамда күлләвекләр хасил була. Ләкин, кояш чыгып, җир өстен кыздыра башлагач, алар кибә. Әгәр чын мәхәббәт булмыйча, вакытлы мавыгу гына икән, анын гомере кыска — яңгырдан соң барлыкка килгән күлдәвек корыган кебек, ул да юкка чыга..

## 4

Кешеләр арасында үзара мөнәсәбәт шулайрак та була: әйтик, берәүне еллар буе беләсең кебек, ә менә аның үзенә генә хас нинди сыйфатлары бар, дип сорасалар, тәгаен генә берни дә әйтә алмыйсың, югалып каласың; ә кайсыбер кешене бер күрүдә үк истә калдырасың — ул үзенчәлекле яклары белән бүтәннәрдән аерылып тора кебек.

Габделнур өчен Шәйгазамов Солтангир Габсалихович та әнә шул икенче төркемгә керәдер, мөгаен, чөнки ул — шәхес. Киеме дә, сөйләме дә — барысы да фәкать аныкы гына.

Озын буйлы, зур башында тигез ятып торган сирәк ак чәчле Шәйгазамов һәрвакыт әйбәт костюм-чалбардан булыр, ак күлмәк һәм галстуксыз күзгә дә чалынганы юк; көрән кысалы, калын пыялалы күзлеге дә һәрчак үз урынында — туры озын борыны өстендә. Аның пиджагының түшендә, сул якта, дүрт рәт орден-медаль планкалары ялтырап тора, һәр рәттә — дүртәр, димәк, җәмгысы — уналты. Габделнур аларның нindирәк дәүләт бүләкләре икәнлеген белеп бетерми, ләкин берсен чамалый: «Кызыл Йолдыз» ордены. Әтисенеке дә бар иде. Димәк, әгәр абзый солдат-офицер халкы арасында иң дәрәҗәлеләрдән саналган бүләккә лаек булган икән — сугышта үз-үзен аямаган.

Габделнур күзенә чалынган ул орденның үзенә күрә тарихы да бар. Гаярь солдат Шәйгазамовка бу бүләкне июль ахырында дәүләт башлыгы (юридик яктан шулай саналса да, чынлыкта илгә Сталин хуҗа иде) — кәҗә сакаллы «Бөтенсоюз староста»сы Калинин бабай үзе тапшырды. Чөнки сугышның беренче айларында батырлык күрсәткән солдатлар һәм офицерлар бүләкне, Мәскәүгә барып, Кремльдә алырга тиеш иделәр. Берникадәр вакыттан соң моның мәгънәсезлек икәне аңлашылды һәм бүләкләү үзе СССР Югары Советы Президиумы исеменнән булса да, орден-медальләрне дивизия һәм полк командирлары гына тапшыра башлады. Дөрес, исемлек үзәк газеталарда тулысынча басыла килде. Аена егерме ике сум акча алган пехотачы солдатка немец танкын юк иткән өчен мең сум бирәләр, баштагы чорда орденга да өстәмә түләү каралган була. Ләкин Солтангир һәм аның иптәшләре орден һәм акча өчен түгел, ә Ватан өчен, Советлар Союзын басып алырга ажгырып килгән фашистлардан илне азат итү өчен үз-үзләрен аямыйча сугыштылар.

Шәйгазамов һәркем белән — гади ташчыдан алып идарә башлыгына кадәр — үзен бик иркен тотып сөйләшә, чөнки аңа шәхсән үзе өчен берни дә кирәкми: бүтән оешмада намус белән эшләп алган иркен фатиры бар, ул-кызлары үсеп житкән — балалар бакчасына чиратта тормый, шәһәр читендә дача корасы юк — төзелештән очсызрак бәягә такта-кирпеч юнәтергә дип, участок башлыкларына ялынычы төшми. Шунлыктан прораб-мастерлар алдында ялагайлануны белмәгән техника куркынычсызлыгы инженерыннан барысы да шөлләп торалар.

Шәйгазамов — югары белемле инженер, үз эшен биш бармагы кебек белә, ләкин беркайчан да карьера ясарга омтылмады, артыгын күтәрмәделәр дә, чөнки партиягә кермәде. Кыстап карамадылар түгел, кыстадылар, әмма ул үз фикереннән кайтмады — җайлап кына баш тарта килде. Соңгы елларда инде аңа мөрәҗәгать итүче дә булмады. Чөнки фирка әгъзасы булырга атлыгып торучы инженер-техник хезмәткәрләр болай да буа буарлык иде. Ә аның партиягә кермәвенең үзенә күрә сәбәбе бар иде: авыл мулласы булган әтисен утыз жиденче елны алып китеп каядыр олактырдылар. Авыл куштаннары — активистлар ярдәмендә эшләнгән бу фаҗигане ул беркайчан да кичерә, газиз атасын кышкы буранда соңгы тапкыр күрүен һич кенә дә оныта алмады.

Әмма сугыш башлангач, повестка көтеп ятмады ул, егерме өченче июньдә үк үз теләге белән фронтка китте, чөнки болай фаразлады: әгәр фашист Мәскәүне алса, Идел буена да килеп житәчәк. Ул — ир-егет, Илен, Ватанын сакларга тиеш, гәрчә бу ил аны ятим итсә дә, чөнки аның бүтән Ватаны юк. Әгәр немец илне яулап алса, бөтен халык колга әйләнәчәк, тарихта моның мисаллары меңләгән. Әйе, аларга Мәскәүне алу гына кирәк, аннан инде юл ачыла — кайчандыр, Казан ханлыгы җиңелгәч, Хаҗитарханга һәм Себергә юл ачылган кебек.

Буйсынган илнең халкы беркайчан да басып алучылар белән бертигез хокукта була алмый, ул кол хәлендә яшәргә дучар ителә, икеләтә буйсындырылса, ул кавем икеләтә колга әверелә. Аңлык кына зиһене бар иде Шәйгазамовның, чөнки бу төшенчәләрне ана әтисе кечкенәдән үк сеңдереп килде. Илнең эше ир муенында, ирнең эше ил муенында, дигәнне дә анардан отып калды. Мулла абзыйның китап шүрлегендә дини басмалар белән янәшә дөньяви китаплар да байтак иде. Шуңа күрә старшина Шәйгазамов, бернichә тапкыр яраланса да, фашист ләгыйньнәрне үз өнендә — Берлинда тончыктырмыйча иленә кайтмады.

Зур ихтыяр көченә ия булган Шәйгазамов һәркайчан үз фикерен турыдан ярып сала һәм аны алга сөрә, нинди кинәшмә-җыелышлар булуына һәм аларда кемнәр катнашуына карамастан, төзелештәге гаеп-кыекны ачыктан-ачык әйтеп бирә иде. Шуңа күрә аны идарә башлыгы да, баш инженер да өнәп бетермиләр. Ләкин төзүчеләрнең эш урыннарында — участокларда тиешле тәртип урнаштыру өчен җан атып йөрүен белгәнгә күрә түзәләр, ана тел-теш тидермиләр. Бигрәк тә баш инженер (гәрчә ул моны күрсәтмәскә тырышса да) һичкем алдында тәлинкә тота белмәүче хезмәткәрне хәтта хөрмәт итә иде. Чөнки объектларда хәвеф-хәтәр булса, таякның юан башы ана төшә бит.

Участокларда йөргәндә, гаделлектле, әмма бик таләпчән Шәйгазамов мастер-прорабляр һәм бригадирлар белән пәрмә-пәр талаша (ләкин сүгенми), җитешсезлек күрсә, — балтасының сабы бик кыска, — акт төзеп, аларны штрафка тарттырырга да күп сорамый. Шуңа күрә бүтән төзү идарәләрендә еш була торган бәла-каза монда сирәк күренеш. Дөрес, биредә дә бөтенесе дә ал да гөл түгел, әмма аларның күпчелеге техника куркынычсызлыгы мәсьәләсенә игътибар җитмәүдән түгел, ә төзүчеләрнең үзләренең ваемсызлыгы, башбаштаклыгы яисә эш вакытында авызларына хәмер кабудан, нәфесләрен тыя алмаудан килеп чыга иде.

Шәйгазамовның тагын бер ягын искәрткән иде Габделнур: абзый татарлар белән һәрчак ана телендә сөйләшә, кайвакыт русча фамилияләрне юри татарчага әйләндереп тә әйтә иде.

Беренче елны, ул эшләгән участокка килгәч, инженер, электрик егеттән саф татарча:

— Прораб Казов үзендәме? — дип сорады.

Эшкә кергәндә аның бу гадәтен белмәгән Габделнур аптырашта калды:

— Бездә андый фамилияле прораб юк бит.

Абзый, көлеп:

— Син гусьның татарча каз икәнен белмисенме әллә? — диде.

Икенче вакыт ул мастер Зайцевны Куянов дип, прораб Бородинны Сакалов дип сорады. Беренче карашка кырыс, хәтта усал ук дип әйтерлек менә шушы, кем әйтмешли, тояк суы эчкән кеше, ни хикмәттер, Габделнурны якын итте, олы башын кече итеп, күргән саен укуы, тормыш-көнкүреше белән кызыксынды. Егет моны абзыйның кайчандыр нефть чыккан якларда эшләве, аны якташ сыманрак үз итүе (гәрчә тумышы белән Шәйгазамов бүтән төбәктән булса да) дип аңлады. Ләкин ул соңрак моның төбе бүтәндә, тирәндәрәк — аның тарих бүлегендә укуы икәненә төшенде.

Бүген дә Шәйгазамов, конторда Габделнурны күргәч, егетнең сәламләвенә җавап итеп, әүвәл кул биреп исәнләште һәм укуы белән кызыксынды.

— Габделнур, син ничәнче курста әле, дүрттәме, биштәме?

Гәрчә абзый бу сорауны беренче мәртәбә генә бирмәсә дә, үзеннән өлкәннәргә каты бәрелергә күнекмәгән егет төгәл җавап кайтарды. «Олы кеше бит, бәлки, онытКандыр, — дип уйлады ул. — Әллә юри сорыймы?»

Бәләкәй чакта бер агай, аны урамда күргән саен туктатып, һаман:

— Син кем малае әле? — дип сорый торган иде.

Габделнур үзенең кем баласы икәнен, әтисенең исемен әйтә:

— Галләм малае!

Шуннан агай:

— И олы тел, ул синең яшьтәшеңме әллә, Галләм абый, дип әйт, — ди дә мәзәгеннән тәм табып, мыек астыннан гына елмаеп китеп бара.

Ә Габделнур аның артыннан:

— Әти кеше абый булмый инде, — дип кычкырып кала иде.

Шәйгазамов Габделнурны бүлмәсенә дәште. Солтангир Габсалиховичның эш урыны конторның беренче катында урнашкан җыйнак кына бүлмәдән гыйбарәт иде. Ике өстәл, сейф, урындыктан тыш монда пыялалы шкафлар да бар, аларның киштәләре төрле-төрле китаплар, брошюралар белән тулы. Диварларда куркынычсызлык кагыйдәләре язылган рәсемле плакатлар эленеп тора. Бер генә булса да, тәрәзәсе зур, бүлмә эче, хуҗасының йөзе кебек якты.

— Утыр, — диде хуҗа, егеткә урын күрсәтеп.

— Рәхмәт!

— Син тартмыйсың бугай?

— Юк.

— Бик әйбәт. Мин дә ул агуны йотудан азат. Чәй эчмисеңме?

— Юк, Солтангир абый, рәхмәт!

Шәйгазамов күзлеген салды, аны дүртпочмаклап бөкләгән ап-ак кульяулыгы белән чистартып, янадан борын өстенә элде. Анын борыны шактый мулдан — тотрыклы, кашлары салына башлаган, күзләре ягымлы, чиста итеп кырынган яңаклары эчкә батмаган, әмма бик тулышып та тормый, куллары зур, ул — эре сөякле, яше шактый булса да, энергиясе ташып торган ир кеше.

— Сезгә нинди фәннәр керә соң? — дип сорады ул.

— Байтак. Күпчелеге — тарих.

— Алай икән. Алтын Урда, Казан ханлыгы, Болгар дәүләте турында мәгълүмат бирәләрме соң?

— Юк.

— Үзебезнең тарих бөтенләй керми икән, алайса, сезгә.

— «Татария тарихы» дигәне булды, икенче курста.

— Шуның белән вәссәламмы? Анысы да ялган тарих.

— Ничек? Китапны укып тапшырдык.

— Һәй, энекәш, кәгазь барысын да күтәрә ул: чынын да, ялганын да. Ә сез укыган китапта чын дөресе бик аз. Аны бит, минут саен Мәскәү ягына карый-карый, «өлкән абзый» ни әйтер икән дип, калтырана-калтырана язганнар. Без бит куркытылган халык... Юкса безнең халыкның тарихы әллә кайларга барып тоташа, безгә аны күрсәтмиләр, белгертмиләр генә. Һаман шул бер балык башы: «татар-монгол игосы». Имеш, ул урыс халкына фәкать начарлык, яманлык кына алып килгән, имеш, алар вәхшиләр, варварлар булганнар. Алайга китсә, шундый артта калган халык ничек ярты Европаны яулап алгандыр?! Әле тикшереп карарга кирәк: кем яланаяк яисә чабата киеп йөргән дә, кем күн итек киеп йөргән?! Бөтен дөньяга данлыклы болгар күне каян килеп чыккан соң ул?! Урыс дәүләте оешуга кем булышкан?..

— Кем? — дип сорады Габделнур, абзыйның тарих төпкелләренә үк төшеп «лекция» укуына шаккатып.

— Алтын Урда дәүләте булышкан. Анда дәүләтчелек чын мәгънәсендә чәчәк аткан, аның бөтен атрибутлары булган, дин ирегә хөкем сөргән, шәһәрләрендә

мәчетләр генә түгел, чиркәүләр дә эшләп торган, әллә ничә төрле милләт халкы яшәгән... анда гыйлемлек нык алга киткән...

Шәйгазамов шулхәтле тирәнгә кереп китте ки, үзен студентлар белән тулы аудиториядә хис иткән профессор кебек, фикер агышын туктата алмыйча сөйли дә сөйли. Чөнки аны күңел биреп, аңларга тырышып тыңлаучы бар. Берәү генә булса да... Ул бит белгәннәрен теләсә кайда кычкырып йөри алмый, ә монда, бүлмәсе кысан булса да, иркенлек, хөрлек.

— Әнә шулар Болгарда, Казанда дәвам ителгән... Синең Мәскәүдә булганың бармы?

— Әйе, армиядә чакта, мине партиягә дә шунда алдылар.

— Кремль тирәсендә Василий Блаженный соборын күрдеңме?

— Әйе, — диде егет һәм елмаеп куйды.

— Нигә көләсең? — дип сорады Шәйгазамов, аптыраган кыяфәттә егеткә карап.

Габделнур үзе белән булган хәлне сөйләп бирде. Экскурсовод «бу собор Казанны җиңү хөрмәтенә төзелгән» дигәч, үзенең «җиңү түгел, ә басып алу хөрмәтенә» дип каршы төшүен һәм шуннан соң беларус егете өлкән сержантның (аларны Мәскәүгә алып килүче) бу хәтәр урыннан аларны тизрәк алып китүен әйтте.

— Ә син аның Казаннан сүтеп алып киткән мәчет икәнен беләсеңме?

— Юк.

— 1812 елда Наполеон Мәскәүгә керә бит.

— Әйе.

— Кремль янына килә һәм Василий Блаженный храмын күргәч әйтә: «Бу нинди мәчет?!» — ди. Ул инде күп илләрне-җирләрне гизгән кеше, мәчет белән чиркәү бинасын аера, таный белгәндер...

— Әйе, дөньяны байтак гизгән, — диде егет, өлкән абыйсының сүзен раслап. — Африкага хәтле барып җиткән. Әле анда барыр алдыннан солдатларның сәламәтлеген кайгырткан — ике йөз мең кара күзлек хәстәрләтеп куйган. Чөнки тегендә кояш мәрхәмәтсез кыздыра бит.

Шәйгазамов өчен монысы яңалык булса да, ул үзенең татар халкына кагылышлы мәгълүматлары белән уртаклашасы килүен сиздерде. Чөнки ана төзү идарәсендә дә, өендә дә, гомумән, ул аралашкан даирәдә бу мәсьәлә хакында фикердәш юк иде. Сүз катар кеше очраса да, әңгәмә озакка бармый — өзелә. Беренчедән, күбесенең белем ягы такыр, икенчедән, һәрберсе тирә-ягына каранып яшәргә гадәтләнгән, ялгыш сүз ычкындырудан куркытып тәрбияләнгән иде. Ә Габделнурны, тарих бүлегендә укыган студентны, сөйләшеп-аралашырдай тин кеше итеп, үз күрә. Шунысы да бар: яшь кеше буларак, аның күңеленә курку-өркү кереп оялламаган, шик-шөбһә салынмаган. Моны Шәйгазамов беренче очрашудан ук төшенде, теләсә кайда тел озайтып йөрмәячәгенә дә ышана иде.

— Татарлар, монголлар турында Рәшид-эд-динның язмалары бар. Ул үзе яһүд кешесе, ислам динен кабул иткән һәм монголлар тарихын язып калдырган. Монгол тарихы дигәнне татарлар тарихы дип тә аңларга кирәк. Чөнки Чыңгыз ханның бабасы татарлар белән сугышта үтерелә.

— Ничек, безнең бабайлар анда ук барып чыкканнармыни?

— Бармаган. Алар хәзерге Кытай, Монголия территорияләрендә яшәгән. Сахалин утравы белән Олы җир арасында Татар бугазы бар. Ул исем бит ана кичә-бүген генә бирелмәгән, борынгыдан калган.

— Солтангир абый, ә без ничек монда килеп чыкканбыз соң?

— Анысы үзе бер тарих... Аларның кая хәтле яу чапканын беләсеңдер... ә бирелә безнең икенче борынгы бабаларыбыз — болгарлар яшәгән.

— Без ике халыктанмыни?

— Әйе.

— Мичурин бабай тәҗрибә үткәргән шикелле икән...

— Юк, киресенчә. Аның бер тамырда ике агачы җимеш бирә, ә без ике агачтан бергә әйләнгәнбез. Татар исеме өстенлек алган. Ә Болгар дәүләтенең тарихын Әхмәд ибне Фадлан язып калдырган.

— Анысы кем?

— Тугыз йөз егерме икенче елны Ирак хәлифәтеннән бирегә Багдад илчелеге килә, аның секретаре Әхмәд ибне Фадлан юлда күргән-белгәннәрен язып барган.

Габделнур өчен болар яңалык иде, әлбәттә. Ә Шәйгазамов боларны каян белә икән соң? Сораштыра-сөйләшә торгач, егет шуны ачыклады: аның туганнан туган абыйсы зур галим икән, Мәскәүдә яши, Казанда булмаган китаплар таба, архив материалларының хикмәтләләре белән дә таныша ала икән.

— Безне сүгәргә булса, татар-монгол игосы, диләр, ә безне зур итеп күрсәтмәс өчен, монгол тарихын гына алга сөрәләр. Һәй, энекәш, безгә билгесез нәрсәләр бик күп бу дөньяда. Сугыш вакытында безнең егетләр булмаган часть юк иде. Ә синең берәр кинода татар солдатын яки офицерын күргәнең бармы?

— Юк.

— Шул-шул менә... Өч солдат батырлык кылса, аның берсе татар була торган иде. Ул әле хәзер дә шулай...

— Әйе, Әсхәт Җиһаншиннарны гына алыйк...

Шәйгазамов:

— Бездә халыкның үзаңы юк, — диде. — Урысның бер акыллы кешесе Столыпин, кем икәнен беләсең инде, әйе, шул, менә болайрак әйткән: «... милли үзаңын югалткан халык тирескә әйләнә, һәм шунда бүтән халыклар үсеп чыга».

— Бу безгә атап әйтелгән кебек.

— Юк, ул аны үзләренә карата әйткән. Чөнки унсигезенче-унтугызынчы гасырларда аларда Көнбатышка табыну бик көчле булган. Югары катлау кешеләре балаларын французча, немецча укыткannар, өйләрендә чит телдә сөйләшкәннәр, үзара аралашканнар. Ул Александр Өченче сүзләрен истә тотып әйткәндер, анысы «Россия — руслар өчен һәм русча» дигән.

— Ул патша тарихка «Миротворец» исеме белән кереп калган, — диде Габделнур, исенә төшереп. — Унөч ел тәхеттә утырган вакытта бары тугыз рус солдаты үлгән, алары да — чик сакчылары.

— Ярар, энекәш, мин сиңа әллә ниләр сөләп ташладым, чөнки ышанам. Үзең генә бел дә күңеленә бикләп куй. Кешегә чыгарма, юкса кыен ашарсың.

Бу эчкерсез егетне кисәтеп куюны да үзенең бурычы дип санады Шәйгазамов. Дөрес, бүген утыз жиденче ел түгел түгелен, шулай да дус бар, дошман бар дигәндәй, авызыңны үлчәп ачу комачау итмәс. Борынгылар язып калдырган бит: «Бөтен белгәнеңне һәрчак әйтмә, әмма һәрчак ни әйтергә икәнен бел».

Аннары Шәйгазамов, матур әдәбияттан мисаллар китерә-китерә, татар халкы турында сөйли башлады:

— Максим Горький безнең киң күңелле, ягымлы, әйбәт кешеләр булуыбыз, пакь тормыш белән яшәвебез хакында матур-матур фикерләр әйтә. Ник әйтмәсен — дөресе шулай. Аннары, кем аны үлемнән коткарган — татар кешесе.

— Кайчан?

— Ул яшь егет чагында үз-үзенә кул салмакчы була һәм, шәһәр читенә чыгып, револьвердан күкрәгенә ата. Әнә шунда бер татар агае аны күреп ала...

Толстой да безнең турыда начар сүз әйтмәгән... Кавалерист кыз Надежда Дурова турында ишеткәнең бардыр инде...

— Минем аның каберен дә күргәнем бар.

Абзый кызыксынып сорагач, егет Алабуга турында сөйләп алды.

— Менә шул кыз да безнең турыда язып калдырган... Мин сиңа, әгәр теләсәң, кайбер китапларны бирермен, алар миндә байтак. Хәер, синең вакытың болай да тар инде. Ярар, укуыңны бетергәч бирермен, караштырырсын, үзең өчен генә...

Әңгәмә ахырында Шәйгазамов егеткә үзебезнең халык язмышына караган, борынгы бабаларыбыз тарихына багышланган кайбер китапларның исемнәрен дә атады. Әлбәттә, университет курсында, уку процессында боларның берсе дә юк, алар студент өчен яңалык иде. Әйе, әллә кайчан җимерелеп юкка чыккан Урарту, Ассирия дәүләтләре, Рим империяләре тарихын күз бетереп дигәндәй укыды-ятлады, ничек тә «койрык» калмасын дип тырышты — имтихан-зачётлар бирде, контроль-курс эшләре язды, ә үз тарихы... читтә кала бирде. Баксаң, әллә никадәр белемнән мәхрүм булып йөргән икән. Хәер, Габделнурның бу хакта сөйләшер кешесе дә юк иде шул.

Гарәпчә укырга-язарга өйрәнгән, латин алфавиты нигезендә дә укып калган Шәйгазамов белән чагыштырганда, Габделнур үзенең, надан дип әйтерлек булмаса да, гыйлем ягыннан берьяклы гына, шактый сай кеше икәнен сизде. Дөрес, аларга да латин теле, шул графикадагы немец теле, борынгы рус теле керде. Ә менә гарәп телен, язуын бөтенләй өйрәтмәделәр. Хәер, уку процессы тулаем урыс телендә барды бит.

...Өлкән иптәше яныннан чыкканда, Габделнур үзен әле яңа гына күзе ачылган мәче баласыдай хис итте, бер мәлгә аптырап калгандай булды... Әмма, контор каршында очраган кешеләр белән исәнләшеп, электр цехындагы хезмәттәшләре белән гәпләшкәннән соң, ул бу турыда уйламас булды. Кем әйтмешли, аны дөнья мәшәкатьләре басып китте...

## 5

Кеше, берәр төрле эшкә алынгач, көннән-көн аңа күнегә бара, еллар узу белән, ул инде аның авырлыгын да тоймый.

Хәрби хезмәттә дә шулай: гаскәри халык шаярып әйткәнчә, беренче елны иләшә, икенче елын хезмәт итә, өченчесендә кайтырга җыена. Әлбәттә, бу шаярту гына. Чөнки өч ел эчендә шактый четерекле хәлләр дә булгалый. Ләкин, һәрхәлдә, хезмәт елдан-ел авырлашмый, ә, киресенчә, җиңеләя бара.

Ә менә уку мәсьәләсенә килгәндә, бу алай ук гади түгел икән. Ул елдан-ел үзенә күбрәк игътибар итүне сорый, синең физик һәм рухи мөмкинлекләреңне күбрәк туплауны таләп итә, әле әхлакый яктан тотнаклылыгыңны да сыный. Тагын шунысы да бар: ярты елдан ярты елга имтихан-зачётлар тапшыру өчен син һәр көн диярлек үзеңне эшкә җигәргә, кайвакыт мәҗбүр итәргә дә тиеш. Ә моның җимеше-нәтиҗәсе — алты ай буе китап имүеннең, тырышуыңның җилгә очмавы берничә көн эчендә семестр ахырында күренә.

Габделнур сессияне июньнең сигезендә «Славян тарихы»ннан башлаган иде, менә бүген, егерме икесендә, «Политик экономия» белән тәмам итте, — өч зачёт, биш имтихан бирде, — тырышты-тырмашты һәм ерып чыкты. Дөрес, билгеләре әллә ни дан түгел — «өчле» дә «дүртле». Эшләп укучы кешегә артыгы кирәк тә түгел, иң мөһиме — «койрыксыз».

Ул бүген дә, гадәтенчә, беренче алтылыкта керде. Шуңа күрә университетта төшкә хәтле үк эше бетте. Бауман урамындагы «Блинная» кафесына сугылды, бик тәмле коймак ашады. Дөрес, әнисе пешергәнгә җитми инде җитүен, шулай да, ит югында — майлы шулпа дигәндәй, ярап тора. Аннары, ярты гомерен

тулай торакларда яшәп үткәргән (өч ел армиядә — казармада) кеше ризык талымлыймы?!

Нинди матур көн: кояш кыздыра, башыңны югары күтәрсәң, зәп-зәңгәр күк йөзен күрәсең. Урамда өзлексез үтеп-сүтеп торучы троллейбуслар, машиналар һәм... чибәр кызлар күзгә чалына; әйе, бик теләсәң, шәһәр ыгы-зыгысыннан да ләззәт алып була икән.

Ул, салмак кына атлап, ары китте. Үзәк банк янындагы чәчтарашханәгә керде, чират юк икән — чәчен төзәттерде. Чәч алучы мөлаем кыз, егетне чибәрләп, хушбуй сибеп, тагын килүенә өмет итеп, елмаеп озатып калды.

— Әгәр иртәгә өйләнмәсәгез, тагын килегез.

— Нигә алай дисез?

— Мин сезне кыз куенына керәсе кияү кебек көяз егет иттем бит, — диде оста кул, үз эше белән мактанып.

Чыннан да, көзгегә карагач, Габделнур үз кыяфәтеннән канәгать калды. Шулай да чыгып барышлый уйлап куйды: «Ашыктырма, сеңелкәш, әле бер ел укыйсым бар. Аннары күз күрер...»

«Матбугат йорты» дип аталган, утызынчы елларда ачык китап рәвешендә төзелгән карасу төстәге зур бинаның беренче катын буеннан-буена китап кибете биләп тора. Габделнур шунда сугылды. Киштәләрне карап йөргәндә (аны бигрәк тә тарихи басмалар кызыксындыра иде), күзе «Медицина» бүлегендә басып торган бер сылуга төште. Бер уйлаганда, азмы кибеттә хатын-кыз: сатучылар, сатып алучылар. Араларында шәпләре бар. Ләкин Габделнурның күзенә фәкать берәү генә чалынды, фәкать берәү генә игътибарын җәлеп итте.

Егет түзмәде: якынрак барды да туктап калды. Хәзер инде ул аны яннан күрә: иңенә үк төшеп торган дулкын-дулкын кара чәч, килешле генә туры борын, кыйгач калын кара каш һәм күзен йомганда сирпелеп алучы озын керфекләр, башын борганда күренеп киткән кечкенә миң. Таныш миң. Кыска җиңле, аксыл төстәге күлмәк кигән, билен киң пояс белән буган, сул кулының беләгендә җыйнак кына кара сумка тоткан бу хатын-кыз үзе дә таныш. Элеккегә караганда бераз гына тулылана төшкән, әмма зифалыгын җуймаган буй-сын да хәтерендә. Ләкин зур шәһәрдә атаңа охшаган урыс күп булыр ул дигән кебек, йөз чалымнары кемгәдер тартым кешене очратуың бик ихтимал. Шуңа күрә, чит кешегә ялгышып сүз катмас өчен, Габделнур ашыкмады: йөрәге ешрак тибә башлаганын, бөтен барлыгын шатлык-куаныч биләп алганын, сабый баладай сөенгәнен тойса да, сабыр итәргә булды. «Үзе генәме? Бәлки, минем якка таба борылыр. Әйе, кибеттән чыкканда, Ул, һичшиксез, бирегә таба киләчәк бит», — дип фараз кылды.

Егет Аны бер мәртәбә аэропортта күргән иде бит инде. Янына да бара алмады, чөнки янәшәсендә ире бар иде. «Бүген кем белән икән? Үзе генәме, әллә түгелме? Казанга нигә килгән? Йомыш беләнме, әллә кая да булса үтеп барышлый гына сугылганмы?» Мизгел эчендә төрле уйлар башыннан йөгереп уздылар. Менә Ул, үрелеп, киштәдән бер китап алды, караштырды. Шунда егет мондыйрак фикергә килде: «Иң яхшысы — урамда көтеп торырга!» Үзе генәме, түгелме икәнен дә тәгаен беләчәк.

Габделнур тәрәзә каршына басты, дивар буйлап сузылган тимер торбага таянды, кибет эченә күз салды. Әнә Ул касса янында, әнә Ул ак туфли кигән тыгыз балтырлы төз аякларын як-якка каратыбрак атлап (йөреш-торышында әллә ни үзгәреш юк икән) чыгып килә. Үзе генә. Егет җиңел сулап куйды.

Рәйсәнә ишектән чыгуга, аның янына килеп тә житте.

— Исәнмесез!

Башта Ул аптыраашта калды, ни диярге дә белмәде. Зур коңгырт күзләрен

тутырып, каршында басып торган озын буйлы, җиннәре сызганулы ак күлмәкле, галстуклы, ыспай киемле ир-атка карады. Моннан байтак еллар элек армия сафларына озаткан сөйгәнен хәтерләтүче, ияге-янаклары зәңгәрләнеп торган ябык чиста йөзле, кыска кара чәчле, кин иякле җитди йөзле бу кеше чит-ят кебек тә. Әйе, килеш-килбәте нык үзгәргән, буй тарткан, чын-чынлап ир-егеткә әверелгән.

— Габделнур?

Бу — күнеле җилкенгән егетнең шатлык тулы авазына тәңгәл булмаган, фәкать сорауны гына аңлаткан сүз иде. Әйе, сигез ел гомер узганнан соң, башкача була да алмас иде. Хәтта, танығач та, аның йөзендә балкыш күрмәде. Шулай да егет үзенең нәүмизлеген сиздермәде.

— Әйе, мин.

Рәйсәнә кулын сузды. Егет аны кысып озаграк тотмакчы иде, ләкин йомшак кечкенә кул аның учыннан шуып чыкты. Тик бераздан хатынның да йөзе яктырып китте. Чөнки ул да яшьлек чорын, матур гына очрашып йөргән шушы кыюсыз егетне яхшылык белән хәтерендә янартты. Алар арасында бер-беренә үпкә-рәнҗеш саклардык начар истәлек-сәбәп юк. Дөрес, Рәйсәнә аны көтмәде. Ләкин андый язмышлы парлар бер алар гынамы? Бер анардан гына калганмы солдатны көтмәү?! Үз вакытында үпкәләсә дә, тора-бара егет аны дөрес аңлагандыр.

— Нинди җилләр ташлады безнең калага? — дип сорады Габделнур, баскычтан төшкәндә, үзе алданрак атлап, Рәйсәнәгә кулын сузганда.

Монысы хатын игътибарыннан читтә калмады.

— Рәхмәт! — диде ул, ак сәйләндәй тезелеп киткән тешләрен күрсәтеп. — Мин ГИДУВта бераз ан-белем арттырырга килдем. Артуын-артмасын белмим, шулай да килгәнемә үкенмим, яхшы укыталар — лекцияләр тыңлыйбыз, практик занятиеләр була.

— Алай икән, — диде егет, янәшә атлап. — Күптән мондамы?

— Айга якын. Тагын бер атнадан китәбез. Шәһәрегез бик шау-шулы. Мин, шәһәрегез, дип, дөрес әйттемме?

Егет раслап баш какты:

— Әйе. Армиядән соң монда калдым.

— Безнеке алай түгел, — диде Рәйсәнә, баягы фикерен дәвам итеп. — Элек тә тыныч иде, хәзер дә.

— Беләм. Анда минем абыйлар яши, сирәк-мирәк булгалыйм. Мәскәү белән чагыштырганда, Казан да тынычрак күренә, Нью-Йорк кешесе Мәскәүгә карата шуны ук әйтер иде. Ул шулай булырга тиештер инде. Кала зуррак булган саен...

Габделнур, гүяки бөтен дөньяны инләп-буйлап йөреп чыккан кешедәй, бераз фәлсәфәгә бирелеп алды, кала белән сала арасындагы аермага да тукталды. Ләкин болар ул әйтергә теләгән сүзләр түгел иде. Аны кызыксындырган нәрсәләр бүтән иде. Шуңа күрә ул җайлап кына сорап куйды:

— Кызың әле укырга кермәгәндер?

— Юк, киләсе елга керә. Ә син аны каян беләсең?

Егет, элекке вакыттагы кебек, җинелчә генә әңгәмә корып, Рәйсәнә белән «син» дип сөйләшергә теләсә дә, хәзер алай итәргә базмый иде инде. Чөнки аның каршында унсигез яшьлек туташ түгел, ә ике бала анасы булган ханым басып тора бит. Ул, ялгыш аңлап, үзенә «син» дип эндәшкәнгә куанды. Чөнки анарга Рәйсәнә кичергән тойгылар әлегә ят иде.

— Бәбиләреңнең икәү икәнен дә беләм әле мин, — диде егет, елмаеп, алар Чернышевский урамы чатына җиткәннәр иде инде.

— Менә ничек?!

Юл аркылы чыккач, Габделнур аларны аэропортта күрүен сөйләп бирде.

— Әйе, исемдә, төнлә Мәскәүгә очкан идек. — Аннары ул зур тәрәзә каршында туктады. — Мин мех кибетенә кермәкче идем. Котәсенме?

— Билгеле.

Береаздан Рәйсәнә чыкты.

— Алмадым, әле бер атнам бар, өлгерермен.

Нәрсә алмаган — анысы егет кеше эше түгел, шунлыктан Габделнур төпченеп маташмады.

— Мин сине Казан белән таныштырыйм әле, — дип, ары таба алып китте. — Ирең белән бер больницада эшлисеңме?

— Юк, аны нефтьчеләр поликлиникасына күчерделәр, баш врач итеп.

— Үсә кешеләр, — диде егет риясыз гына һәм көнләшмәгәнен сиздерергә тырышып өстәде: — Бик яхшы булган, югары белемле кеше югары үрмәләргә тиеш.

«Син боларны каян беләсең? — дип сорамакчы иде Рәйсәнә, ләкин тыелып калды. — Бер җай белән үзе әйтер әле». Аны егетнең язмышы кызыксындыра иде.

— Үзең ни хәлдә? — диде ул гади генә, әйтерсең лә алар әле бер атна элек кенә аерылышканнар. — Кайда, кем булып эшлисең?

— Төзелештә, Әлмәттәге һөнәрем буенча.

— Берәр кая укырга кердеңме? Әллә бетердеңме инде?

Габделнур кайда укуын әйтеп бирде.

— Бүген мине бәхет басты — берьюлы ике сөенеч: беренчесе — сине күрүем, икенчесе — дүртенче курсның соңгы сынавын әле моннан ике сәгать элек кенә тапшырып чыгуым.

— Икенчесе — чыннан да, зур шатлык, — диде Рәйсәнә һәм әңгәмәдәшенә бакты. — Беренчесенең ни куанычы бар инде? Мин хәзер ир хатыны, әнием әйтмешли, кеше кешесе, ике балалы...

— Барыбер, — диде егет һәм, туктап, Рәйсәнәнең нур чәчеп торучы коңгырт күзләренә тутырып карады. — Минем әле һаман да синең кебек кызны очратканым юк. Мин шуны аңладым: була йөргән кызлар, була сөйгән кызлар... Болар — икесе ике әйбер.

— Мин кайсысы? — дип елмайды Рәйсәнә.

Аңарда хатын-кызларга хас ярыш азарты, «көнчелек күбәләге» канатын җилпеде. Баштарак ул Габделнурны очратуына бик сөенмәде, дөрес, пошынмады да, чөнки инде, үткән-беткән дигәндәй, еракта-еракта, томаннар артында калган еллар бит, күп сулар аккан... Ә менә егет күзендә сөю чаткылары күргәч, аның да күңеле йомшады, үзенә дә аңлашылмаган дулкынлану билэп алды.

— Син — соңгысы! Әйе, мин һаман да сине оныта алмыйм. Ләкин син дөрес аңла: мин сиңа, кабат мәхәббәт янартыйк, дип әйтергә җыенмыйм. Шулай да мин очрашуга бик шатмын. Сине бик күрәсе килгән чаклар була иде. Аннан да бигрәк мин синең тормышың көйле баруына бик шатмын.

Габделнур үзенең, кем әйтмешли, китап сүзләре белән сөйли башлавына аптырап китте. Хәер, монда искитәрлек бернәрсә дә юк кебек. Ул, чыннан да, яшьлек дустын күрүгә шат, шат кына түгел, бу — сөенеч. Ничә еллар күңел түрендә йөрткән кешеңне очратуның, шуңа шатлануның ни гаебе бар?! Юк, әлбәттә. Ләкин барыбер электәгегә тиң җанлы, эчкерсез сөйләшү, ихласлык булмас шул инде.

Рәйсәнә сорап куйды:

— Баянда уйныйсыңмы соң әле? Онытып бетермәдеңме?

— Бер өйрәнгән һөнәр онытылмый инде ул. Концертларда катнашканым юк, вакыт ягы тар. Шулай да бүлмәдәге егетләрне җырлаткалыйм.

— Салып алгачмы? — дип елмайды хатын.

— Әйе. Син минем баянда уйнавымны да хәтерлисенмени?

— Билгеле. Сине район үзешчәннәре концертында хәтеремә сеңдереп калган идем. Чөнки син анда минем кече абыйны беренче урыннан мәхрүм иттең.

Көлешеп алдылар. Шулай сөйләшә-сөйләшә, Кремль тавына менделәр. Алагаем зур биек таш өстендә чәнечкеле тимерчыбыкларга уралган, әмма карашын алга төбәгән, горур басып торган каһарман шагыйрьгә карап тордылар. Һәйкәл артында көрәштәшләренең барельефлары һәм исем-фамилияләре.

— Менә монысы безнең район егете, — диде Габделнур, Зиннәт Хәсәнов рәсеме каршында туктап.

— И мактанчык! — диде Рәйсәнә, елмаеп.

— Мактанырлыгым бар!

Аннары Спасс манарасына таба атладылар. Рәйсәнә сул як дивардагы элмә тактага игътибар итте:

— Күчмә театр шушындамыни ул?

Габделнур елмайды:

— Монда, кем әйтмешли, конторлары гына. Аларның үз биналары, заллары юк. Шуңа күрә театр гел тәгәрмәч өстендә — гастрольдә.

— Казанга кайталардыр бит?..

— Кайткалыйлар. Яңа спектакльләр әзерләп чыгарырга кирәк бит. Кайчагында шәһәрдә дә куялар. Мин баргалыйм.

— Яратасыңмы?

— Анысы да бар. Аннары, анда Хәлил исемле таныш егет эшли, шуның уенын карарга барам. Ул Чупай таш карьерында мастер булып эшләгән иде. Мин армиядә чакта, Казанга килеп, театр техникумын бетергән. Бик талантлы егет. Сирәк-мирәк күрешкәлибез.

Кремль эченә керделәр. Габделнур сул яктагы, бераз вакыт үзе хезмәт иткән өч катлы озын казарманы, күккә ашкан Сөембикә-ханбикә манарасын күрсәтеп, тарихка кагылышлы хәлләрне сөйләп йөрде. Ул берөзлексез сөйләде дә сөйләде, Рәйсәнә исә аны бик бирелеп, күп белүенә сокланып тыңлады. Һәм хатын бер нәрсәгә игътибар итте: егет мәктәп дәреслекләрендә язылган вакыйгаларны үзенчәрәк аңлата, аларга бәяне дә бүтәнчәрәк бирергә тырыша. Кайчандыр булып үткән, гасырлар төпкелендә калган хәлләрне бәян иткәндә, тарихтагы гаделсезлекне хупламавы, алар белән килешмәве, фактларны җиткерүдә кемнәр беләндер бәхәскә керергә теләве, аларның дөреслегенә шикләнеп каравы сизелә иде. Дөрес, ул аларны үз исеме белән атамый, ләкин игътибар белән тыңлаган һәм үз халкына азмы-күпме ихтирамы булган кешегә тел төбе аңлашыла иде. «Күрәсең, тарих бүлегендә укуының тәэсиредер», — дип кенә уйлады хатын.

Спасс башнясы астыннан кире чыкканда, каршыга бала җитәкләгән бер хатын очрады. Сабыйның кара чәче бөдрә иде.

— Моның чәче негрларныкы кебек, — дип көлде егет.

Ә үзе җәһәт кенә хыял иркенә чумып, анда йөзеп тә алды. Әгәр Рәйсәнә белән кавышсалар, аларның да шушы малай яшендәге нарасыйлары булыр иде. Дөрес, ул бу малай кебек бөдрә чәчле түгел, әмма барыбер уртак бәхетләренең матур дәвамчысы — мәхәббәт җимеше булыр иде.

Әлеге малайга тап булгач, Рәйсәнәне дә балалары турындагы уйлар биләп алды. Ләкин анысы хыял түгел, ә чынбарлык; аларны сагына да, алар өчен борчыла да иде ул. «Нишләп йөриләр икән? Өс-башлары чиста микән? Тамаклары тук микән? Әбиләре сүзен тыңлыйлар микән? Әтиләре килә

микән?..» Китәр алдыннан ул сабыйларын әнисенә илтеп куйган иде. Дөрес, бер кичне ул, шәһәрара сөйләшү пунктына барып, ире белән телефоннан сөйләште. Ире борчылмаска кушты. Ләкин ана күңеле тыныч була аламы соң?..

Егет каршыдагы ике катлы озын матур бинага — музейга күз салды. Рәйсәнәне шунда алып кермәкче иде, ләкин бу уеннан кире кайтты. Кабат һәйкәл тирәсендә басып тордылар.

Еракта-еракта, Иделнең аргы ягында, уңга да, сулга да яшеллек каплаган таулар тезелеп киткән. Каршыда, уртада, зур гына авыл шәйләнә. Иделдә нәни генә булып теплоходлар, баржалар күренә. Аларның хәрәкәт иткәне беленми дә. Зәп-зәңгәр күк йөзенә, сирәк-мирәк аксыл болытларга, Ослан тауларына, киң җәелеп яткан чал Иделгә сокланып, хозурланып торгач, түбән таба төшеп киттеләр.

– Казан ошыймы сон? — дип сорады Габделнур һәм Рәйсәнәгә яннан карады.

– Ошый, — диде хатын, җанланып. — Бик матур, чиста да.

– Бездә һәр чәршәмбе — өмә, завод-фабрикалардан, төзелеш оешмаларыннан, учреждениеләрдән халык урам себерергә чыга. Гомумән, Казан элек-электән чиста. 1767 елны Казанга килгәч, Әби-патша — Екатерина Икенче дә аңа сокланган, күсе-тычканнар булмавына шаккаткан. Аңа борынгы, нәселле мәчеләрнең күп булуын әйткәннәр. Киткәндә, ул үзе белән утыз ата мәче алып киткән. Менә шуннан «Кот Казанский» дигән гыйбарә барлыкка килгән.

– «Казанская сирота» дигәнне ишеткәнем бар иде, ә монысын — юк.

– Хәзер дә шул «Кот Казанский»ның оныклары Ленинградтагы Эрмитажны күсе-тычканнардан саклый, — диде егет, елмаеп. — Алар анда солдатлар шикелле — довольствиедә торалар.

Баскычтан төшеп, килгән юл белән, Бауман урамы буйлап, кире киттеләр. Троллейбус тукталышына җиткәндәрәк, Габделнур тәкъдим ясыйсы итте. Ләкин ул аны әйтергә кыенсынып торды. Әүвәл: «Мин тулай торакта яшим. Буйдак егетнең куышын күреп китәсең килмиме? — димәкче иде, ләкин бу уеннан кире кайтты. — Дөрес аңлармы? Бу бит туганының яисә ахирәт кызының кунакка чакыруы түгел, ә ир-атның хатын-кызны үзенә дәшүе». Күңелен рәнҗетмичә, хисләренә кагылмыйча гына әйтеп карарга булды. Чөнки теләсә кемгә ияреп китәргә әзер торган урам кызы түгел бит ул. Житмәсә, яшьлегендә сөйгән яры. Хәзер дә ул аны тел тидермәслек хатын дип күзаллый. Егетнең үзенә үк шундый уйның башына килүе оят тоелды. Шулай да ул әйтмичә кала алмады.

– Мин Ленин районында яшим.

– Фатирың шундамыни?

– Мин тулай торакта көн күрәм.

– Әле өйләнмәдеңмени?

– Юк, — диде егет һәм сүзен баягы эзгә төшерде: — Безнең яклар бик матур: яңа йортлар, скверлар, кирәк икән — кибетләр күп. Казансу елгасы аша күпердән чыгасы. Ул тирәләрне күргәнең юктыр әле.

Рәйсәнә аңа күтәрелеп карады. Чын әйтәсеңме, янәсе, әллә мине сынап карыйсың киләме? Ләкин егетнең житди йөзеннән берни дә укый, аңлый алмады, әмма үпкәләмәде дә, чөнки нииндидер астыртын, мәкерле уе барлыгын сизмәде. Хәер, Габделнур җебегән егеткә дә охшамаган. Хатын, җавап кайтармыйча, акрын гына атлап китте. Егет әлеге тәкъдимен бүтәнчә кабатламады, аның да бу көннең гүзәллеген, очрашуның бәхетле мизгелләрен ямьсезлисе килми иде.

Егет үзе Рәйсәнә белән гәпләшеп бара, ә күзе — каршы яктагы афишаларда. «Родина» кинотеатрында «Лёвушки из Рошфорда» фильмын күрсәтәләр, ә

Качалов театры бинасында Кырым дәүләт драма театры гастрольләре бара икән. Ул сәгатенә карап алды. Көндезге спектакль уникедә — күптән башланган, бетеп киләдер. «Татарстан» кинотеатрында бу арада «Место встречи — Женева» дигән фильм күрсәтәләр икән. Көндезге сеансларның берсе сәгать өчтә. Ул Рәйсәнәнең керүенә әллә ни өмет итмәсә дә, ятып калганчы, атып кал, дип әйтеп карарга булды.

— Бу киноны караганың юкмы? — диде ул Рәйсәнәгә, каршыдагы бинага ымлап. — Әчен дә күргәнең юктыр, бәлки? Кереп чыгабызмы?

Чыннан да, караган киносы түгел икән. Шулай да хатын, өзеп җавап биргәнче, сәгатенә күз салып алды.

— Мин соңга калып йөрергә гадәтләнмәгән, — диде ул, рияланмыйча гына. — Занятиеләр беткәч тә фатирга кайтам. Бүген сине күрәсемне күңелем сизгәндер, юкса кибетләргә иртәгә чыкмакчы идем, аннары кире уйладым. Синең белән очрашу хөрмәтенә кагыйдәмне бозармын, ахры, әйдә, кереп чыгыйк.

Габделнур аның бернинди ясалмалык чагылмаган табигый тавыш белән әйткән сүзләрен ишеткәч, тәкъдимгә ризалашкач, әүвәл үз колагына үзе ышанмагандай, сөйгәненә карап куйды. Аннары аны талгын бер рәхәтлек биләде: гүя алар моннан сигез ел элек аерылышмаганнар да, гүя алар — яшь кыз белән яшь егет — Әлмәт каласында Ленин урамындагы «Родина» кинотеатрына кереп баралар.

Рәйсәнә нишләп бу егет белән киноога керде соң? Беренчедән, ул үз-үзенә нык ышана, вәсвәсәгә бирелмәсен белә, кино карап чыкканнан гына укам коелмас әле, дип уйлады, икенчедән, ул Габделнурга бик рәхмәтле иде. Ни өчен? Чөнки егет, хәрби хезмәтен тутырып кайткач, кайберәүләр кебек, аны бимазалап, эзәрлекләп йөрмәде. Мисалга ерак барасы түгел иде. Рәйсәнәнең уртанчы абыйсы, армиягә хәтле йөргән кызын (ул да солдатны көтмичә тормышка чыккан иде) иреннән аерып алырга теләде, салган баштан өйләренә барып йөдәтте, тавыш чыгарды, ялынып-ялварып борчыды, баласын да үз балам кебек багар идем, дип, селәгәен агызып, үкереп-үкереп елады. Аны хәтта берчакны тәпәләп тә кайтардылар. Бары әти-әнисе бик каты сүгеп-үгетләп, абыйсы орышып, арт сабагын да укыткач кына игә килде егет.

Габделнур, бүтән чакта андый тәм-томнарга бик исе китмәсә дә, берочтан үзенә дә туңдырма алды. Дивардагы плакат-афишаларны, актёрларның фотосурәтләрен карап йөргәндә, Рәйсәнә аның туңдырма ашый белмәвен күреп көлеп куйды, ләкин оялтмады.

Сеанс барышында, күзе экранда булса да, яшь чагын исенә төшереп, егет хатынның атсыз бармагында алтын йөзек булган кулына үрелде. Ләкин яшьлек дусты, нәзакәтле итеп, җайлап кына егетнең кулын читкә этәрде. Габделнур исә бу хәрәкәтен янадан кабатламады, кулы үз тезендә калды. Шулай да аның бу рәхәт мизгелне — Рәйсәнә тәненең кайнарлыгын тоеп, инне ингә куеп янәшә утыруны — бик озакка сузасы килә иде. Чәченнән таныш «бүлнис исе» килгәндәй булды. Габделнур аны затлы ислемайларга да алыштырмас, ләззәтләнеп утырыр да утырыр иде. Әмма... фильм тәмам булды, залда ут кабынды. Күз ачып йомган ара кебек кенә тоелган кадерле минутлар үтеп тә китте.

Кольцога җитәрәк Габделнур:

— Әйдә берәр ресторанга кереп тамак ялгап чыгыйк, — диде. — Кунакны сүз белән генә сыйлап булмас бит инде.

— Рәхмәт! Кыстама да. Ни өчен икәнен үзең беләсең.

Егет кабат бу хакта сүз куертмады. Әйе, ул аның баш тартачагын белә иде. Димәк, ялгышмаган. Шулай да Рәйсәнәдән аерыласы килми иде.

— Бәлки, кичен театрга барырбыз? Камал театры Горький урамында гына бит, син төшкән фатирдан ерак түгел. Дөрес, алар бу арада үзләре юк, Свердловск, Чиләбе, Магнитогорск якларына чыгып киттеләр.

— Анда Башкорт академия театры гастрольләре икән. Без кичә кызлар белән «Упкын» дигән спектакль карадык, ә бүген сигезенче яртыга «Кәккүк чакыра» спектаклен карарга барабыз.

— Өлгер үзегез, — дип елмайды Габделнур, әмма әле һаман баягы уе тынгылык бирми иде. — Бәлки, иртәгә бергә барырбыз? Ялгышмасам, «Кара йөзләр» бугай.

— Габделнур, зинһар, ачуланма, яме, синең белән бармыйм. Рәхмәт!

— Мин сиңа ничек ачулана алыйм инде?! — диде егет, өзгәләнеп.

Тукталышта Рәйсәнә Габделнурның кулын үзе тотып алды, бик озак аны җибәрмичә торды, яшьлеген сагынуыннан күзләре дымланды, чамасын белеп кенә иннек сөрткән күперенке иреннәре дерелдәп куйды.

— Синең әйбәт егет икәнеңә тагын бер кат инандым, — диде ул, яшьлек дустының күзләренә тутырып карап. — Бер сүз дә әйтмә, озатма да. Матур аерылышыйк. Кайчагында таулар гына түгел, кеше белән кеше дә очрашмый. Бәлки, кабат күрешеп тә булмас. Бер җыр исемә төште: «Сандугачым, әйтеп сайра, кайсы талга кунарсың? Күзем йомсам, күз алдымда торган кебек булырсың». Ләкин бу кыска вакытлы булыр. Хуш. Яшьлектә ачуыңны китергән өчен рәнҗемә миңа, дөрес аңла. Бу дөньяда кешеләр үз дигәнчә генә яши алмый...

Егет сөйгәненә соңгы тапкыр йотлыгып карый. Рәйсәнәнең бит алмалары хәзер элеккечә тулышып янып-кызарып тормыйлар. Ләкин аның бераз суырылган озынча аксыл йөзеннән, коңгырт күзләреннән сихри, илаһи нур бөркелә сыман — ике бәби үстерүче бу ханым үзенчә ягымлы, үзенчә мөлаем; егет өчен ул һаман да якын икән...

Габделнур хәзер кызлар кулы тотмаган тәҗрибәсез егет түгел инде, кем әйтмешли, ак белән караны аера белә: ул Рәйсәнәдә ярата һәм яраттыра белүче назлы хатын-кыз затын күрде, шуңа күрә аның дулкын-дулкын куе кара чәчен сыйпыйсы, дәртләндергеч иреннәрен онытылып-онытылып, суырып-суырып үбәсе килде. Шик юк, ул кабарынкы иреннәр дә аңа шундый ук теләк белән җавап кайтарган булырлар иде. Ни аяныч, егетне үзенә тартып, дәрт ташып торган калку күкрәкле бу сылу гәүдәгә, тезелеп киткән ап-ак тешләрен күрсәтеп чак кына ачылып киткән бу ымсындыргыч татлы иреннәргә ул кагыла алмый иде шул. Аларга бүтән бер бәхетле ир-ат хуҗа... Кадерен белә микән? Рәнҗетми микән? Кем әйтмешли, какмый-сукмый тәрбияләп кенә тота микән? Хәер, батыр ир яуда җиңелмәс, матур хатын ирдән җиндермәс, дигән кебек, Рәйсәнә үзе дә җебеп төшмидер, үз кадерен үзе беләдер. Шулай гына булсачы...

Китте... Йөрәк әрнүен дә онытып, торып йөгерәсе иде шул трамвай артыннан... Туктатасы иде. Рәйсәнәне гомер бакый үз янында калдырасы иде. Юк шул, бу — күнеле нечкәргән егетнең тормышка ашмастай хыялы гына. Әнә ераклашканнан-ераклаша бара... Трамвай түгел, аның яшьлектә сөйгән яры мәңгегә китеп бара. «Хуш, сөеклем! Исән-сау бул! Бәхет касәң һәрдаим тулып-ташып торсын!..»

Икенче номерлы трамвай тукталышында калган Габделнур бармакларында әле һаман яшьлек дусты кулының җылысын тойгандай булды.

Бераздан «Татпотребсоюз» бинасының аскы катындагы ашханә яныннан узды. Бүтән вакытта ул, һичшиксез, анда сугылыр иде, чөнки кайда туры килсә, шунда тамак ялгарга өйрәнгән. Ул ашыйсы килүен дә онытты, урам аша чыкты, балык исе тышка ук аңкып торган кибет яныннан үтте; гүя сукыр — беркемне

күрмәде, берни ишетмәде, аяклары үзеннән-үзе аны таныш юлдан тукталышка алып килде. Чөнки бөтен уе тауга менеп киткән трамвайда һәм ана утырган Рәйсәнәдә иде. Менә ул ГИДУВ каршында трамвайдан төшәр, Комлев урамы буйлап сулга таба китәр (шунда бер апада фатирда торам, дигән иде бит).

Егетнең уй-хыяллары әле һаман аксыл күлмәкле сылу алиһәгә ияреп бара, ә үзе Бауман урамы чатында, аптека каршында туктаган беренче номерлы троллейбуска утырып, тулай торагына, дүрт кеше яши торган, биш атламлы шыксыз бүлмәсенә кайтып бара. Алгысыган күнеленә урын таба алмады егет. Рәхәтләнеп, җырдагыча, күз керфекләре талганчы күреп тә кала алмады, назлап күкрәгенә дә кыса алмады бәгырькәен... Парә-парә булган йөрәге ярсуын басарлык итеп, Рәйсәнәнең гүзәллеген бөтен галәмгә ишеттерерлек итеп, кычкырып-кычкырып җырлыйсы килә иде аның: «Их, дускаем, матур да син, батып тора ияген, кай җирләренә урнашкан мәхәббәтле сөяген?..» Очрармы ана тагын Рәйсәнә сылуны хәтерләткән, бөтен йөрәген ут белән чорнап алырдай берәр мәхәббәт кошы?! Кайларда йөри икән ул ана сөю-сәгадәт бүләк итәчәк насыйп яр?! Их бу тормыш... «Чынбарлык һәрвакыт кешегә ул таләп иткәннән азрак бирә» дигән бер акыллы баш...

Соңрак аны икенче төрлерәк уй-хисләр биләп алды. Кәефе кырылган егет ихтыярсыздан монарчы үзен басып-изеп торган ниндидер авыр йөктән арынгандай булды. Тик бу авыр нәрсә таш та, тимер дә түгел, ә аның күнеленә кереп укмашкан юшкынның юкка чыгуы, аның күнеленең пакьләнү тойгысы иде...

Габделнурны биләп алган тәэссорат Рәйсәнәгә дә ят түгел иде. Ул да егеткә фәкать унышлар, яхшылык, үз мәхәббәтен табуны, күнеленә хуш килердәй кыз очратуны тели иде. Чөнки ул бу егеттән золым-җәбер күрмәде бит. Азмы егетеннән алданып, соныннан балавыз сыгып үкенүчеләр, ташлама, дип ялынып-ялварып йөрүчеләр, авырга узгач, эшләгән җиренә килеп зарланучылар яисә, ир туганнарын дәшеп, янап, өйләнергә мәҗбүр итәргә тырышучылар яки бәхетсез башларын ташка оручылар — үз-үзләренә кул салучылар...

Әйе, ул үзенең бүгенге хәленнән канәгать: якыннары һәм газизләре — ире һәм балалары сау-таза; авырыксынмыйча башкара торган яраткан эше бар; муллыкта, үзенең әти-әнисе, туганнары белән һәрдаим аралашып яши... Аның чит ирләр белән бәйләнештә булганы, бу хакта ялгышып кына да уйлап та караганы юк, моннан соң да тугрылык саклар (айдан төшкән түгел, җир кешесе — төрле хатын-кызны очраткалый, күрә, күбесен танып белә). Әле бүген дә ул яшьлек дусты белән киного кереп дөрес эшләде микән? Хәер, намусына хилафлык китерердәй бер гамәл дә кылмады бит, андый нәрсә уена да кереп карамады. Ә шулай да... «Иремә моны әйтергәме, юкмы?» Әйе, ул ана әйтәчәк. Арада бер-беренә белдермәстәй сер калмасын өчен, бөтенесен сөйләп бирер. Ире аңлар. Ул Габделнур атлы солдатны белә, чөнки кияүгә чыгар алдыннан, үзе сөйләгән иде.

Рәйсәнә, салмак кына тирбәлеп кайта-кайтышка, күзен йомды, теләсә-теләмәсә дә, бүгенге көн ана шатлык күндерде. Аның каршына төз гәүдәле, киң җилкәле, ак күлмәк җиңнәре сызганулы таза беләкле, житди йөзле чын ир-егет Габделнур килеп басты. Сөйләгән, елмайган, уйчанланган мизгелләре, хәтта калын, ләкин ягымлы тавышына кадәр хәтерендә янарды. Хатын үзе дә сизмәстән елмайды. Рәхәт иде ана шул минутларны янарту. Ләззәт бирә иде ана үзен әле дә кемгәдер кирәкле кеше итеп, әле дә кемдер өзелеп сөя ала торган кеше итеп тоюы. Чөнки ул да бит хатын-кыз затыннан... Әмма берникадәр вакыттан соң күз алдындагы Габделнурны ак халатлы ире алыштырды.

Рәйсәнә үзенең бүгенге хәлен күз уыннан үткәрде һәм теге вакытны

атмаган куянга, асмаган казанга өметләнмичә ялгышмавын аңлады. Чөнки аның яшәр өчен үз оясы бар, сөекле балалары таза-сау үсеп килә, яраткан ире янында. Ире хатынын менә бу егет шикелле яратамы соң? Мөгаен, яратадыр. Телдән әйткәне булмаса да, эш-гамәлләре белән шуны раслый, хөрмәт итүен күрсәтә: бар тапканын өенә алып кайта, туган көнен бүләксез калдырмый, бәйрәмнәрдә һәм кунак-төшем вакытында әз-мәз тоткалавын исәпкә алмаганда — авызына хәмер капмый, хезмәтендә аңа буйсынган хатын-кызлар күп булса да, һәр итәк артыннан тагылып йөрми, чит түшәккә кызыкмый (моны Рәйсәнә, шикләнмичә, үз-үзенә икърар итә ала), ачуы чыккан чакларда кул озайтмый (анысы хатынның үзенә бәйләнгән — учактагы утны вакытында сүндерә белә). Кыскасы, әлегә аңа кияүгә чыгуына үкенерлек бер сәбәп тә юк.

Рәйсәнә күзен ачмады. Чөнки каршыда пәйда булган иренең юкка чыгуын теләми иде... Тик ул берүзе генә түгел, ике кулында ике сабые белән. Алар хәләл җефете һәм әниләре булган кадерле, изге кешене каршыларга килгәннәр... Ире хатынына карап елмая, ә аның көчле кулларындагы нарасыйлары нәни учларын өскә каратып, нәзек бармакларын тырпайтып, әниләрен чакыралар иде...

**6**

Сөмбәт Энергетика институтына көндезге бүлеккә укырга керде һәм тулай торактан китеп барды. Аның урынын балта осталары бригадасында эшләүче яшь егет алды. Ул төзүче-инженерлар институтының беренче курсында читтән торып укый икән; Казан арты районнарының берсеннән, бик тәртипле, ипле егет булып чыкты.

Габделнур йокыдан торды. Әле караңгы, урамда вак яңгыр ява, кайбер урыннарда җир өсте ак, димәк, төнлә кар яуган. Егет радионы ачты, соңгы хәбәрләр тыңлады, тиз-тиз генә юынып-кырынып кергәч киенде дә киоскка барып газеталар алып кайтты. Ашханәгә төшеп тамак ялгап менде, ә егетләр әле һаман уянмаган.

Кичә Миргаяз салып кайткан иде, немецча сөйләште. Аның шундый гадәте бар. Укытучылары бик белемле һәм таләпчән булган, күрәсең. Хәтта шигырьләр дә өйрәнеп калган. Кичә ул шактый бытылдагач, егетләр түзмәделәр, ачуланып яткырдылар.

— Сәрим бездән китәргә йөри, ахры, — диде күзгә каршында торган Фәүҗәт Габделнурга. — Әйберләрен алып чыгып китте.

— Кая китә?

— Дүртенче тулай торакка.

«Берәр хәл бардыр», — дип уйлаган иде Габделнур, чөнки Сәрим ике-өч көн инде кунмый, элегрәк тә төнлә генә кайта иде. Егетләр, берәр мәткәгә ияләнгәндер, дип уйлаганнар иде.

...Алар бүлмәсендә яшәгән прораб Шәмсунга бәхет елмайды — фатирлы булды. Ул, озын-озакка сузмыйча, үз куышына китеп тә барды. Аның урынына Жилплощадкадагы бер тулай торактан Сәрим исемле егет күченеп килде.

Ул уртачадан озынрак буйлы, тулы битле, егерме биш-утызлар арасындагы бер егет иде. Аның өстендә — язгы-көзге пальто, аксыл, тар балаклы кара чалбар, муенында — яшел шарф.

Ул егетләр белән гомуми генә исәнләшкәч, алан-йолан каранды да үзенә ишек төбендәге караватт тигәнгә ризасызлык белдерде:

— Мин салага түгел бит.

Егетләр дәшмәделәр. Чөнки түр караватлар Габделнур белән Миргаязныкы, Шәмсун китү белән, Миргаяз аның урынына — тәрәзә янына күчкән иде.

Габделнур да, Миргаяз да чама белән яна килгән егет яшендәгеләр, берсе дә ана, рәхим итегез, әфәндем, дип, үз урынын бирәчәк түгел.

— Безнен ишек төбендә параша юк, — диде Габделнур, тынлыкны бозып, төксе генә. — Өлешенә тигән көмешен.

Алан-йолан карангалап торган Сәрим «параша» дигән сүзнен ни аңлатканын һәм кайда булганын ишетә белә иде, шуна күрә, дөнья күргән бу карт егетләр каршында әтәчләнә алмаячагын аңлап, ачуын йотарга мәҗбүр булды. Ул өс киемен, салып, шифоньерга элеп куйды — буйлы кара костюмнан калды, анысы — энәдән-җептән генә төшкән түгел икән. Пиджак эченнән зәнгәр күлмәк күренде.

Ул, чемоданын ачып, тумбочка өстенә китаплар бушата башлады. Габделнур, игътибар белән карап, кайсы югары уку йортында белем алуын чамалады, чөнки калын китап исемнәре үзләре әйтеп торалар иде: «Механика грунтов», «Основания и фундаменты», «Строительные конструкции», «Инженерная геология», «Железобетонные конструкции» һ.б. Алар янына төрле «Пособие», «Наставление», «Правила», «Нормы» кебек юкараклары, дәфтәрләр һәм логарифмик линейка да чыгарылды.

Аннары егет чыгып китте һәм беренче каттан, кастеляншадан, җаймалар, сөлгеләр алып менде.

Габделнур түзмәде:

— Әйдә, булмаса, танышыйк инде.

Ул үз исемен әйтеп кул сузгач, яна егеткә аны кабул итүдән бүтән чара калмады:

— Сәрим.

Миргаяз белән Фәүҗәт тә урыннарыннан тордылар. Аннары бер-берсе турында сораштыру китте.

— КИСИда бишенче курста укыйм, мартта — диплом, — диде ул эре генә. Армиядә өч елын да штабта писарь булып хезмәт иткән.

Миргаяз:

— Син ничәнче елгы? — дип сорагач, ул дөресен әйтмәде, ярпаеп, үзен өч яшькә олы итеп күрсәтте.

Габделнур мыек астыннан гына елмайды. Ул аның киләсен дә, кем икәнен дә белә иде инде, анкета тутыртмаса да, егет турында берникадәр мәгълүматы бар, яна кеше кертәчәкләрен тәрбияче әйткән иде.

Сүзләренә эчке бер мәгънә салып, ул:

— Алай икән, — дип кенә куйды.

Сәрим беренче көннән үк нишләптер бүлмәдәшләре белән уртак тел таба алмады, әллә теләмәдеме. Югыйсә, әти-әнисе канаты астыннан гына чыккан манка малай түгел: армиядә дә хезмәт иткән, читтән торып институтта да укый, төзелештә мастер булып та эшли. Бер карасаң, тормыш тәҗрибәсе дә житәрлек, эшендә дә көн саен кешеләр белән аралаша, тырышлыгы да бар — институтның соңгы курсына килеп житкән бит. Ә менә егетләр белән бергә-бергә күңелле итеп, кем әйтмешли, чөкердәшеп, бер гаилә булып яшәп китә алмады.

Ул үзе тумышы белән Бөгелмәдән — шәһәр малае. Ярыйсы гына мул тормышта тәрбияләнгән, авыл малайлары кебек калҗемә, кәҗә сакалы ашап көн күрмәгән, чабата киеп үсмәгән. Туган-тумачалары да урында эшли булса кирәк. Шуңа күрә үзенең хезмәт баскычыннан югары үрмәләп, үсәсенә шикләнми.

Әйе, Сәрим белән егетләр «ботка пешерә» алмады.

Ул беренче кичне каядыр китеп барды да бик соң гына кайтты. Егетләр ятканнар иде инде. Габделнур уянды. Бик озак Сәримнең нишләгәнен күзәтеп ятты. Ул чишенде, юынып керде, кулына китап алып, бер-ике бит укыды, аны

ташлады. Аннары, торып, Габделнур тумбочкасы өстендәге кәгазьләрне карый башлады. Төн уртасында кайтып, әле һаман ут сүндермәгәнгә ачуы килеп яткан Габделнур түзмәде:

— Анда берни дә юк. Актарынма.

Сәрим дәшмәде, койкасына барып утырды, тагын баягы китабын кулына алды.

— Бәлки, утны сүндерерсең. Кадер киче түгел бит.

Ут сүнде. Габделнур диварга таба әйләнеп ятты.

Иртән Фәүҗәт Сәримгә:

— Әллә син женнәр ияртеп килдең инде, — диде. — Төне буе саташып чыктым.

Миргаяз да тыныч йокламаган икән, ул иртән кычкырып уянган иде.

— Голубятников урамында нindидер бандитлар белән сугышып чыктым, — диде ул.

...Сәримнең тискәре яклары көннән-көн күбрәк ачыла барды: китап ала да урынына куймый, әҗәткә акча сорап тора да вакытында бирми. Аның «Смена-8М» фотоаппараты бар икән. Ләкин бүлмәдә берәүне дә карточкага төшермәде. Җавап кыска булды:

— Плёнка юк.

Үзе югында Миргаяз:

— Мактанчык, мактанчыкның арты ачык, — дип көлде. — Баксаң, аппараты төзек тә түгелдер әле. Ә кыланышы кырга сыймый.

Сәримнең ерак юлга йөртә торган шахматы бар. Күпчелек вакыт үзе генә уйный — кечкенә фигураларны тезеп куя да, китаптан карап, мәсьәлә чишә. Төннәрен укып ята да йоклап китә, ә ут сүнделмәгән килеш кала. Шуның аркасында егетләр еш кына сүзгә киләләр. Беркөнне өстәлдән тырнаклар таптылар, ул кисеп киткән булырга тиеш. Әмма егет, мин түгел, диде.

Ул Экзюпери, Плеханов әсәрләрен укый. Дусларым арасында фән кандидатлары — галимнәр бар, дип тә җибәрә. Нindидер фәнни хезмәт язып маташамы, һәрхәлдә, тел төбеннән шулай аңлашыла. Әллә күзгә төтен генә җибәрәме — һич аңламассың. Мунчада майка-трусигын гына алыштырганын, ай буе өстеннән һаман шул бер зәңгәр күлмәк төшмәгәнен егетләр күрмиләр-белмиләр дип уйлый, ахрысы.

Сәрим үзенең күп белүе белән мактана, кытай, япон фәлсәфәсе белән кызыксына. Нинди дә булса китап укып утыра да андагы берәр тәгъбирне яки фикерне кычкырып әйтеп куя. Бу тик торганда, ата казыгыз күкәй саламы, дигән сыманрак килеп чыга.

Беркөнне ул шулай тиктомалга:

— Японнар дүрт нәрсәдән курка: җир тетрәү, яшен, янгын һәм ата кеше ачуы, — диде.

— Ә кытайлар? — дип сорады Габделнур.

— Причём монда кытайлар?

Һәм Габделнур, үзләренең дә төшеп калмаганлыкларын күрсәтергә теләп, Фәүҗәткә күз кысып, бер мәзәк сөйләде.

— Кытайлар — астыртын халык, — дип башлады ул. — Порт-Артур элек Советлар Союзыныкы иде бит. Безнең ике яшь лейтенант гостиница шикелле җирдә яши. Күршеләрендә бер кытай карты тора икән. Офицерлар бабайны кызык итмәкче булалар: магнитофон җибәрәләр дә көне-төне акырталар. Карт дәшми. Шуннан лейтенантлар үзләре туялар — тавышка түзмиләр, кереп гафу үтенәләр, кабат магнитофон уйнатмабыз, диләр. Ярар, ярар, ди кытай, мин дә моннан соң сезнең чәйнеккә пес итмәм, ди. Боларның кухня общий икән.

Егетләр бүлмә янгыратып көлделәр. Бүксә киерергә яратучы Сәрим генә, үзенен сүзе өскә чыкмаганга, кашын жыерып утырды.

Кайчакта ул, белеме сай булса да, музыка өлкәсенә дә кереп чыккалый. Радиодан концерт барганда:

— Бу арада Гайдн «Серенада»сын, Моцартның «Рунда»сын тыңладым әле, — дип әйтеп куя.

Ә берчакны, тиктомалга Сократның хатыны Ксантиппа исемле булган, диде дә Шопенгауэр, Гегель исемнәрен телгә алды.

Миргаяз, чын күңелдән кызыксынып:

— Кем соң алар? — дип сорады.

— Шуларны да белмисезмени? — дип сорауга сорау белән җавап бирде Сәрим.

Миргаяз үпкәләде, ачуы чыкты, Габделнурга күз кысып алды, янәсе, кызык итәбез аны, һәм:

— Ә син, алай күп белгәч, әйтеп кара әле, — диде. — Терсәкле вал нәрсә ул?

— Мин аны каян белим? Русча әйтсән, бәлки, белермен дә.

— Коленчатый вал.

— Юк, белмим.

— Шул-шул менә! Ә мин беләм! — диде Миргаяз һәм рус телендә тезеп китте. — Коленчатый вал — это кусок железа, изогнутый до невозможности, и вращающийся как бешеная собака.

Сәрим сер бирмәскә маташа:

— Бу — фәнни түгел.

— Ә син белгәнне без әллә кайчан киптереп элгән, — диде Фәүҗәт эре генә.

Егетләр янә көлештеләр.

...Менә хәзер шушы егет китәргә йөри икән. Миргаяздан да җинел генә котылмакчы була, ахры. Эш шунда: Сәрим аның әр-яна кыска сырмасын сорамыйча алып кигән һәм походта югалтып кайткан. Үзе түләрмен, ди, ә һаман араны өзми.

Миргаяз янә телогрейка турында сүз кузгатты.

Биреше каты Сәрим, күзен дә йоммыйча:

— Ул сиңа кирәк тә түгел инде, — дип, бүлмәдәшләрен шаккатырды.

Миргаяз кызып китте:

— Кирәк булмаса, мин аны янымнан ун сум акча тотып сатып алмас идем. Күрмисенмени, янгырда тун киеп йөрим, бетерәм бит инде эштән чыгарып. Әнә, колхоз базарыннан ундүрт сумга мех пирчәткә сатып алдым, бар, аны да югалтып кайт, рәхмәт әйтермен.

Сәрим мескенләнә башлады:

— Бүген акчам юк.

Аның төлке шулпасы эчәргә маташуын яшь бүлмәдәше Фәүҗәт шундук сизеп алды, егетнең тумбочкасына ишарәләп:

— Акчаң булмаса, әнә, кичә алып кайткан транзисторыңны бир, — диде.

Әле генә юаш бәрәнгә салышкан Сәрим капылт кабынып китте:

— Ә?! Акылың кот икән! «Спидола» житмеш өч сум тора, ә телогрейка — ун.

Миргаяз кулын гына селтәде:

— Миңа кеше әйберсе кирәк түгел.

— Алайса, акча бирсен! — диде Габделнур катгый итеп, ул әле Сәримнең транзисторлы радиоалгыч сатып алганын белми дә иде. — Алмак бирмәк белән ярашырга тиеш.

Бүлмәдәше аның белән килешкәндәй булды:

— Ну ярар инде, бирермен, бирермен.

Фәүҗәт мыскыллы елмайды:

— Кызыл кар яугачмы?

— Чтоб иртәгә булсын! — диде Габделнур катгый итеп.

— Мондый малайларны күргән юк иде күпме общагада торып.

Монысы инде чамадан тыш иде. Габделнур түзмәде, Габдрахман Әпсәләмовның «Миңа унтугыз яшь иде» исемле повестен укып ята иде, сикереп торды.

— Син бит үзең әлләкем булып йөрисең. Безне кешегә дә санамыйсың. Порядок юк. Бу бит эт абзары түгел.

Соңгы вакытта бүлмәләре чыннан да чүп оясына охшап калды. Өстәлдә стаканнар, калаклар, банка, чәйнек, папирос һәм шырпы каплары теләсә ничек аунап ята, алар янында пычак, каләм, газета һәм китаплар да бар. Тумбочка өсләрендә дә китап-журналлар гына түгел, чыбыклар, өстәл лампасы белән янәшә шахмат тактасы. Кырыну кирәк-яраклары, кайчы, көзге ватыгы, гөл, үтүк кебек нәрсәләр белән тәрәзә төбе тулган. Шифоньер өстендә кәгазь төргәкләре, сызымнар, пирчәткә, газета, папкалар, ватык урындык аяклары, иске китаплар. Шкаф артында киез итекләр. Идәндә тапочкалар, туфлиләр, тәмәке төпчекләре, шырпы сыныклары. Карават астыннан табак менә чыгам, менә чыгам, дип ята. Урындык башларына кием-салым эленгән.

Шул шапшаклыкка игътибар иткәч, Габделнур ярсыды, чөнки бута-болама Сәрим килгәнче бүлмә болай булмый иде.

— Үзең ничек — без дә шулай. Борыныңны чөеп йөрмә. Син бит тоже бер кишлак. Давай, бир Миргаязга акча!

— Юк бит, — дип, тәмам бичарага салынды елан яше ялаган егет.

— Тап! — диде Миргаяз һәм, эшләр болайга киткәч, сикереп торды. — Ала белсәң, бирә дә бел!

Чөнки әгәр Сәрим бүген-иртәгә китеп барса, ул аны тиз генә очрата алмаячак. Нигә әле ул, аяк итен ашатып, аны эзләп йөрергә тиеш ди. Фәүҗәт, җиңнәрен сызганып, урыныннан кузгалды. Егетләр Сәримне уратып алдылар.

— Американнар, доброе слово и пистолет лучше, чем просто доброе слово, дияргә ярата. Син яхшылап әйткәнне аңламыйсың, — диде Габделнур ачу белән, ул да бу егеткә бик нык рәнҗегән иде. — Ну!

— Не нукай, җикмәдең бит әле.

Сәримнең бу сүзләре Миргаязны тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Жикмәсәк — ишәрбез! — диде дә тегенең яңагына китереп тә тартты. — Күрмәгәнеңне күрсәтербез!

— Миндә дә бар ул кул! — диде Сәрим, гайрәт орып, ләкин каршы сукмады. — Бер генә бирермен!

Фәүҗәт мыскыллы елмайды:

— Ие. Миндә гайрәт, миндә көч, миннән курка үрмәкүч...

Габделнур, күзгә төтен җибәрү өчен, беренче елны зеклардан ишеткән блатной сүзләрне кыстырып җибәрде:

— Нәрсә? Ты чё, фраер, раздухарился, а? Ты чё жабры раздул?! Тебя, чё, давно не били? Да мы тебя в гробу в белых тапочках видели! Сейчас в порошок сотрём! Понял?!

Фәүҗәт тә кыжрады:

— Кая, мин дә берне тондырыйм әле колак төбенә, бисмилласын укытыйм!

— Сабыр ит, юкса безнең аны үтереп ташлавыбыз да ихтимал, — диде Габделнур, яшь егетне тыеп.

Шул сүзләрне ишеткәч, Сәрим майлаган каеш кебек булды, өч әзмәвергә

каршы тора алмаячагын белгәнгә күрә коелып төште, шундук кесәсеннән унлыкны чыгарды.

— Эшен бетте, кодагый, борылып ятсаң да ярый, — диде Фәүҗәт, Сәримгә һәм Миргаязга карап күз кысып алды, елмайды.

Дөресен генә әйткәндә, Габделнурның эшне зурга җибәрәсе килми иде. Гауга коридорга ишетелми калмас, аннары комендант яисә тәрбиячегә барып ирешүе шиксез.

Сәрим җәһәт-җәһәт әйбер-карасын җыештыра башлады: караватастыннан чемоданын өстерәп чыгарды, шифоньер башыннан китапларын тумбочка өстенә күчерде. Бераздан, беркемгә бер сүз әйтмичә, бүлмәдән чыгып китте. Ике көннән соң ул күзгә-башка бөтенләй күренмәде. Бер атна үтүгә, аның урынын бер яшь егет алды.

...Урамда вак кар ява. Радиодан татарча концерт бирәләр. Ничектер сөйләшер сүз юк кебек.

Ишектә Дөбәриснең зәңгәрсу бүреге, күтәренке җилкәсе, озынча ябык гәүдәсе күренде. Ул җылы киенгән: муенында ак шарф, өстендә ясалма мех якалы куртка, яшькелт чалбар, аягында кышкы ботинка, кара перчаткаларын сул кулына тоткан, унында — бөгәрләнгән журнал һәм газета.

— Смирно! — диде ул, кәрә-керешкә. — Пошутил. Вольно! Сам рядовой.

Егетләр көлештеләр.

— Кирәгез, «иптәш генерал».

Исәнлек-саулык сорашкач, ул:

— Бүген нишлибез? — дип сүз катты.

— Ат булып кешнибез, — диде Миргаяз, авыз ерып.

— Кызлар янына барабыз, — диде Габделнур, дустына урын күрсәтеп.

— Әй, син бу арада ул изге «эш»не ташладың әле, — диде Дөбәрис, урындыкка чөмәшеп. — Минем бабай әйтмешли, гомер кыска, кадерен белеп калырга кирәк, матур итеп яшәргә...

— Уку каты бит, вакыт җитми.

— К...кә кыл да сыймый, балта сабы буш, дисең инде.

Дөбәрис алып кергән газетадан кино, цирк, театр белдерүләрен карадылар.

Дөбәрис:

— Камалда — «Кыю кызлар», — диде.

Габделнур кул селтәде:

— Батмый. Караган спектакль, дальше укы.

— «Туй алдыннан». Ә, юк, монысы берсекөнгә, сишәмбе икән. Циркта — чегәннәр.

— Ана билет юктыр инде, — дип өметсез генә әйтеп куйды Миргаяз. — Чегән кызларының итәк җилфердәтеп биюен яратам.

Фәүҗәт тә сүзгә кушылды:

— Кино кала инде.

Дөбәрис укый башлады:

— Ленин сараенда — «Дворянское гнездо», Урицкийда — «Госпожа Керри», «Костёр»да — «Это было на разведке»...

— Житәр, — диде Миргаяз, кырт кисеп. — Әйдә шуна гына, якын да.

— Мин абыйларга барам, юл уңаенда билетка керермен, — диде Дөбәрис.

— Бик соң булмасын.

Миргаязның сүзенә каршы Дөбәрис:

— Ярар, — диде дә кулындагы «Огонёк» журналын өстәлгә салды. — Шәп рәсем күрсәтимме?

Аның озынча битендә елмаю пәйда булды, бүреген салып, соргылт чәчен озын, ябык бармаклары белән сыпырып куйды.

Журналда шәрә хатын сурәте иде. Тел шартлата-шартлата, тотып ашардай булып, күзләрен түгәрәкләндереп, әлеге рәсемне карадылар. Унтугызынчы гасырда яшәгән рәссамның осталыгына хәйран калып, сокланып, аны мактадылар.

Миргаяз барысы да бердәй хуплаячак сорауны:

— Әллә салабызмы? — дип, уртага «ташлады».

Дөбәриснең дә кәеф күтәренке — бүлмә уртасына бастырып куелган әлеге сорауны дәррәү күтәреп алды:

— Көне нинди бит: пирәшләп утыра торган гына! Погода так и шепчет: займи, но выпей.

Фәүҗәт белән Габделнур да кесәләрен капшаштыра башладылар һәм кирәкле сумма бик тиз җыелды. Арада иң яше Фәүҗәт булса да, кибеткә киенгән Дөбәрисне генә җибәрделәр. Ул озак юанмады, шешәләр янына ипи, колбаса, «Дружба» сыры кебек нәрсәләр кыстырып, чаптырып кайтып та житте.

— Голландский сыр алмакчы идем, ике сум сиксән тиен икән, чукынган.

— Костроманыкын алырлар, ул ике дә кырык кына, — диде Миргаяз, өстәл өстен юеш чүпрәк белән сөртеп. — Ярар, монысы да тамакка аркылы килмәс әле.

Фәүҗәт аны үсендереп җибәрде:

— Зато колбасаның затлысын алгансың.

Дөбәрис түшен киерде:

— Аз кап, май кап, — дип елмайды ул.

Берәрне тоткач, Миргаяз карават астыннан хромкасын сөйрәп чыгарды.

— Егетләр, музыканы Суворов та бик яраткан: «Музыка сафларны икеләтә, өчләтә арттыра», дип әйтә торган булган, — диде Габделнур, аны үсендерергә теләп.

Ләкин Миргаяз озак уйнамады, туктады, Габделнурга дәште:

— Баяныңны тарт әле, бу әлхәрәйгә җырлап та, биеп тә булмый бит.

— Теләк юк, — диде Габделнур, ялындырып. — Үзең дә бик оста уйныйсың.

Егетләр Миргаязны, күтәреп, тәрәзә төбенә менгереп бастырып куйдылар.

— Әйдә, уйна, — диде Дөбәрис, кул чаба башлап. — Әйт шуны булмаса, таңкә ярым тулмаса...

Миргаяз оялды:

— Кит әле. Тиле тиле дигән саен тигәнәк буе сикерә, диярсез.

— Юк, әйтмибез.

Аның гармунын Фәүҗәт тартып алды да дәртле бию көен сыздырды. Миргаяз тәрәзә төбендә тыпырдый, Габделнур белән Дөбәрис кул чаба, бераздан такмак әйтә башладылар:

> Бие, бие, Хәйбулла,
> Биегән кеше бай була,
> Биегән кеше бай булганчы,
> Карт алаша тай була.

Миргаяз тәрәзә төбеннән сикереп төште.

— Анда урамда халык җыела башлады, — диде ул, авыз ерып.

Көлеш, шау-шу, стакан чәкештерү җыр белән аралашты, бүлмә эче гөр килеп торды.

Миргаяз, тәрәзә каршында ике учын авыз тирәсенә рупор сыман итеп куеп, урамга карап, сөрән сала:

— Граждане, воздушная тревога, воздушная тревога! У-у-у...

Дөбәрис көлә:

— Үзбәкстанда мөгезсез кәҗә күргәнием, синең тавыш нәкъ шуныкы кебек чыга.

Фәүҗәт, беркатлы сабый:

— Ишәкме? — дип шәрехләп сорый.

— Казакъстанда архар дигән кош бар, — ди Миргаяз, үпкәләмичә һәм үзе дә көлә. — Мин шуна охшатып кычкырам.

Габделнур бүлмәдәшенең көлүен ярата: Миргаяз башын артка кыйшайтып, рәхәт итеп, эчкерсез бер шатлык белән кычкырып көлә.

Көлеш, шау-шудан соң янә җыр агыла.

Кулъяулыгым икәү иде,
Берсе суларга акты;
Икебезне ике якка
Тормыш дулкыны какты.
Мәдинәм, гөлкәем,
Тормыш дулкыны какты,
Бәгырькәем.

Мин утырып хатлар язам
Синең исемнәреңә,
Син булмагач, серләремне
Сөйлим таң җилләренә.
Мәдинәм, гөлкәем,
Сөйлим таң җилләренә,
Бәгырькәем.

Ниһаять, «артистлар»ның тамаклары карлыга һәм алар үзләренең сәләтләре белән мактануга күчәләр:

— Карале, егетләр, ничава гына икән безнең тавыш, полный ансамбль.

— А как же, без бит чегән арбасыннан төшеп калган шалтай-балтай малайлар түгел.

— Ие, авылларда концерт куярга гына чыгып китәсе.

— Монда стройкада саз ерганчы...

Бу тема тәмам булгач, Дөбәрис Габделнурдан сорап куйды:

— Энекәшең Газиз Казанга килмиме?

— Юктыр, ахры. Мин переговорга биргән идем, көттем бер сәгать, килмәде.

— Ә син баш механик белән сөйләшкән идең бугай.

— Әйе. Ул, алырбыз, бер урын бар, дигән иде...

Алар гәпләшкән арада, Миргаяз белән Фәүҗәт юынып-кырынып керделәр.

Миргаяз, бритвасын тотып, Габделнур каршына килде.

— Булган булсын инде, яшьти, муенны кыр инде.

Картлачның чәчен төзәтүгә, яше килеп басты.

Бераздан егетләр киенә башладылар. Миргаяз кара костюм, ак нейлон күлмәк янына көрән төстәге капрон галстук та элеп куйды, зәңгәрсу шарф урап, яшел төстәге көзге пальтосын киде, башына бүреген чәпәде.

Фәүҗәт тә «чын ясау егет» булды: өстендә соры төстәге костюм, ак ефәк күлмәк, кара галстук, аркылыга буйлы кызгылт-яшел шарф, күе зәңгәр көзге пальто, дулкынланып торган кара чәчен бүрек белән каплады. Аның болай да кызгылт таза йөзе тагы да кызара төшкән, димәк, хәмер уртача буйлы, калынча таза яшь гәүдәсенә файдага киткән.

Миргаяз зарланып алды:

— Магазинда эшләпә юк. Язга хәстәрләп куясы булыр.

— Свердловскида бар иде.

Дөбәрис ул тарафка сеңлесенең туена барды. Габделнур аңа акча да биреп торган иде. Киенгән арада өйләнү хакында гәпләшеп алдылар.

Аннары чыгып киттеләр: Дөбәрис — абыйларына, Миргаяз белән Фәүҗәт — ашханәгә.

Габделнур берүзе калды, форточканы ачып, бүлмәне жиллэтте, урамга күз салды. Анда кар ява, бала-чага уйный, жир өсте ак, ә асфальт юл юеш. Ул да егетләр белән чыгып китәр иде дә, койрыгы бозга каткан — укуы жибәрми. Соңгы курста сынатмаска инде исәбе. Дөбәрис әйткән сүзләр исенә төште: «Син бу арада ул «эш»не ташладың әле». Ташлавын ташлап бетермәс, түз, йөрәгем, мин дә түзәм бит, дип, сабыр итәргә генә кала. Шулай да киноларга баргалый егет, әле күптән түгел «Катастрофа» дигән фильм карап кайтты.

Габделнур бүген укуына иркенләп тотына алмый иде әле. Чөнки кичә туганнан туган энесе Хәтфир вахтада язу калдырган иде, армиягә китәсе икән. Шуңа күрә ул да егетләр киткәч озак юанмады, өстенә кара төстәге көзге пальто һәм эшләпә киеп, Татвоенкоматка китте. Кайчандыр үзе дә шуннан хәрби хезмәткә алынган иде бит.

КППдагы сержантны көч-хәл белән күндереп (әле ярый хәрби билетын үзе белән алган иде, ярдәме тиде), эчкә керде. Район егетләрен — якташларын табып сораштыргач, шул ачыкланды: энесе коймa аша сикереп чыгып сызган икән. «Мәһрүсә апаларда түгел микән?» — дип уйлады егет.

Каршыдагы ашханәдә тамак ялгагач, «Победа» кинотеатры янәшәсендәге кечкенә базардан күчтәнәч алып, янә Свердлов урамына төште. Татвоенкомат каршында алтынчы троллейбуска утырып, Жданов урамына — Мәһрүсә апаларына юл тотты.

– Ике көн элек кереп чыккан иде, бүген күренмәде, — диде апасы.

Кичке якта туганнан туган энекәше, бер иптәшен дә ияртеп, үзе килеп керде. Алар икесе дә уртача буйлы таза егетләр иде. Габделнур аларны күрше тулай торакның ашханәсенә алып керде, кибеткә дә сугылды, аннары бүлмәләренә алып кайтты. Миргаяз да өйдә иде.

Ул, армиягә китәсе егеткә карап, астыртын елмаеп:

– Әле өйләнмәгән идеңме? — дип сорады.

– Юк, — диде Хәтфир, абыйсының караваты янына утырып.

– Безнең авылда берәүне өйләнгәч алганнар иде. Хатыны урам буйлап болай дип такмаклап йөргән, имеш:

И балалар, балалар,
Атагызны армиягә алалар.
Элек тә уйнаштан туган балалар
Тагы да ятим калалар.

Егетләр көлештеләр. Миргаяз «әкият» сөйләвен дәвам итте:

– Күрше авыл егете тужы өйләнеп киткән була. Өч елдан соң кайтса, түр башында өч бала утыра. Бу хатыныннан: «Болар кем балалары?» — дип сорый. Хатыны дулый: «Ничек кем балалары? Берсен киткәнче ясадың, берсен — отпускыга кайткач...» «Ә өченчесе?» — дип төпченүен дәвам итә кичәге солдат. Бик аптыраткач, хатыны: «Тәки каныкты шул сабыйга! — ди. — Тыныч кына утыра бит, ярар инде, бәйләнмә, утырсын инде шунда...»

Тагын бүлмә янгыратып көлешергә сәбәп табылды. Алар фотоальбом караштырган арада, Габделнур тиз генә табын корды. Өстәл янында сүз армия, өй хәлләре турында барды.

– Әткәй авырый, — диде энесе, — больниста калды.

Ул коридорга чыгып кергән арада, иптәше әйтеп өлгерде:

– Атасы үлгән инде. Минем йөргән кыз районда эшли, кичә телефоннан

сөйләшкәнием, шул әйтте. Абый, үзенә сиздермә инде, тыныч кына китеп барсын.

Кыскасы, бераз каба торган гадәте булса да, эчкерсез, беркатлы, фронтның гына түгел, әсирлекнең дә ачысын татыган жизнәсенең шулай иртә китеп баруы Габделнурга бик кызганыч иде. Әтисен күмешергә кайта алмаган энесе дә жәл.

Шулай да Габделнур аның дусты белән килеште, авызына су капты. Чөнки энесе барыбер атасының җеназасына кайтып өлгерә алмаячак: бездә мәетне озак тотмыйлар. Икенчедән, кулында телеграмма булмагач ышанмаслар, аны барыбер җибәрмәсләр. Әгәр инде рөхсәтсез качып кайтып китсә, әле хәрби ант бирмәгән призывник булса да, эшне зурга җибәрүләре бар.

Бераздан кузгалдылар.

Габделнур егетләрне Восстание урамындагы «Лакомка» кафесына алып керде, үзе йөгереп кенә «Светлана» кибетеннән бер акны эләктереп әйләнеп килде. Аннан кунаклар энекәшенең сабакташы — яшьтәше янына китәргә булдылар. Анысы Ветеринария институтында укый, төннәрен ниндидер бер конторда каравыл тора икән. Ул — түбән оч егете, Габделнурның беренче мәхәббәтенең энесе иде.

Аерылышканда Габделнур:

— Мә, монысын кесәңә тыгып куй, армиядә беренче чорда ашау җитми, кирәге чыгар, — дип, туганнан туган энесенә ун сум акча суздды.

— Рәхмәт, абый!

— Әйбәт хезмәт ит, исемемә тап төшермә, безнең нәселгә кызыллык китермә. Бер синнән генә калмаган, солдатка бару — егет кешенең бурычы...

7

Иртән гаҗәеп куе томан иде, машиналар фараларын яндырып йөрде. Көндез табигать, көз ахыры булса да, үзенең бөтен гүзәллеген күрсәтте: кояш, җылы, хет яланөс йөре. Ә участокта эшләр, үч иткәндәй, гел кирегә тәгәрәде: трансформатор янып чыкты, ут булмады. Ниһаять, өйләдән соң барысы да көйләнде.

Кичке якта Габделнур конторга китте, чөнки төзелеш комитеты утырышына дәшкәннәр иде. Утырыш идарә башлыгы кабинетында узасы икән, ни өчен дигәндә, ана партбюро әгъзалары да чакырылган һәм шуның өчен ул сирәк очракларда гына була торган берләштерелгән утырыш дип атала.

Идарә башлыгы, тәбәнәк, симез гәүдәле, йөзеннән кан чәчрәп торган Горохов, өстәл тирәли урнашкан кешеләрне күздән кичергәч:

— Афанасий Фёдорович, җыелып беттеләрме? — дип, үзенә иң якын урында, озын өстәлнең түр башында утырган партбюро секретарена мөрәҗәгать итте.

— Әйе, — диде Митрохин, чак кына калкынып.

Башлык утырган җирдән генә зур кулының юан бармакларына бер бит кәгазь алып эшкә кереште:

— Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: бүләкләр һәм премия бүлү. Сәгатьләр утыз данә. Кемгә бирәбез?

Конторның өске катындагы иркен бүлмәдә тынлык урнашты, ике катлы зур тәрәзә араларында кышкы йокыга талмаган булсалар, чебен очканы да ишетелер кебек.

Идарә башлыгы, чакырылганнардан кем генә авыз ачарга җөрьәт итәр икән дигән шикелле, кәгазьдән аерылып, киң битле башын күтәреп, җыелган халыкка усал гына карап алды һәм үз фикерен әйтеп тә салды. Күрәсең, ана кемнеңдер ниндидер тәкъдим кертүе кирәк тә түгел иде. Хәер, каты күңелле түрәнең холкын яхшы белгән халык аннан узып сүз башламас та иде.

— Егермесен эшчеләргә бирергә кирәк, алар — безнең идарәнең төп көче,

авыр йөкне тартып баручылар, — диде Горохов, салпы якка салам кыстыруны кирәк табып, чөнки бүлмәдә гади төзүчеләр байтак иде. — Сигезен — инженер-техник хезмәткәрләргә.

— Ә икесе? — дип сорады партбюро секретаре.

— Алары үземдә калып тора, кирәк кешеләр өчен, — диде башлык һәм, кәгазьгә карап алды да, сүзен дәвам итте. — Биш транзисторлы приёмник: икесен хәзергә үземдә калдырам, өчесен прораб һәм өлкән прорабларга.

— Алай гадел булыр микән соң? — дип сорады партбюро әгъзаларыннан берәү — монтажчы булып эшләүче ир-ат.

— Булыр, — диде идарә башлыгы, күзен дә йоммыйча, һәм, канәгатьсезлеген белдереп, чыраен сытты. — Егерме сәгатьнең унысын бригадирларга бирербез.

Ул шулай дип барчасының да авызын каплагач, ишек катындарак, дивар буена тезелгән урындыкларның берсендә утырган Габделнур үзен биредә артык кеше кебек хис итте. Хәер, бер ул гына түгел, бүтәннәр дә шундыйрак халәт кичерә икән. Аның янында утырган ташчы — төзелеш комитеты әгъзасы — пышылдап кына ризасызлыгын белдерде:

— Без монда — пешка.

Әйе, берәү дә йодрыгын кесәсеннән чыгарырга базмый — аның тавышы Габделнурдан башка бүтән берәү ишетерлек түгел иде. Егетнең армиядә, каравыл бинасында май бүлгән вакытлар исенә төште. Майны кем генә бүлсә дә, юрамалый гына әйтә торган гадәт бар иде: «Сиңа, миңа, тагын миңа, тегенә...» Ә монда чын-чынлап шундыйрак бүлеш бара.

Аннары идарә башлыгы акча өләшергә кереште һәм бик коры тотты:

— Унике мең сум премия булачак. Шуның дүрт мең ярымы — эшчеләргә, трест белән УПТКга, стройбатка да өлеш чыгарырга кирәк... Калганы — конторскиларга...

Премия бүлүнең бөтен нечкәлекләрен Габделнур да, биредә утырган гади эшчеләр дә бик белеп бетерми иде. Шулай да алар күңелендә дә егетнекеке шикелле уйлар пәйда булгандыр. «Трестка ни өчен бирелә? Тагы УПТК... Анысына, бәлки, ярыйдыр да... Бөтен кирәк-яракны алар аша алалар. Стройбат... Күрәсең, аларга төзү идарәләренең барысы да күпмедер өлеш чыгарырга бурычлыдыр. Хәер, трест дигәндә, бездәге контор хезмәткәрләре шикелле, төрле бүлекләрдә кәгазь белән эш итүчеләрне күздә тотарга кирәк бит. Димәк, аларга да тиеш. Ә шулай да кайсы оешмага күпме биреләчәге билгеледер бит. Нигә идарә башлыгы саннарын әйтми? Ә конторскиларга дигәне күпме? Анда утыручылар участокларда эшләүчеләргә караганда ун мәртәбә ким бит...» Бер яктан караганда, Габделнур — гап-гади эшче, аңа премиянең кая һәм күпме китәсен белүнең әллә ни хаҗәте дә юк сыман. Ләкин, икенче яклап килсәк, әгәр аны чакырганнар икән, әйтсеннәр иде. Ә болай... аларны — гади эшчеләрне санга сукмау була түгелме соң? Аннары егетне битарафлык хисе биләп алды. Ул премия суммасын белде ни дә белмәде ни — аннан гына нәрсә үзгәрә?!

Көн тәртибенә куелган мәсьәлә хәл ителеп, кимәленә китерү өчен куллар күтәртеп, әвеш-тәвеш китергәч, үз-үзеннән бик канәгать идарә башлыгы берләштерелгән утырышны ябарга да җыенган иде, әмма энергетик Сәгыйров — партбюро әгъзасы — сорау биреп, аның ачуын кабартты:

— Дмитрий Гаврилович, пенсионерларга да өлеш чыгарып булмас микән?

— Нәрсәдән? — дип сорады башлык һәм тәбәнәк, әмма юан гәүдәсен көчкә урындыктан кубарып торып басты.

— Безнең әле тагын премия булачак бит, — диде Сәгыйров.

Горохов Сәгыйровны тотып ашардай булды: саргылт кашлары җыерылды, симез йөзе кызарып-бүртенеп чыкты, соргылт күзләрендә усал чаткылар

кабынды, янак мускуллары кыймылдап алды; юан муенын болай да кысып тормаган галстугын бушатыбрак куйды.

— Кем хисабына? Сине мәхрүм итимме соң? Әллә синен житәкченне — баш механигыннымы?.. Кулларыгызны күтәрегез — кем риза?

Билгеле, берәүнен дә үзенә дошманнар арттырасы килмәс, — куллар күтәрелмәде. Төзелеш комитеты рәисе, нидер әйтмәкче булып, тулы гәүдәсен урындыктан аерган иде, идарә башлыгы ана, хатын-кыз булуы белән дә санлашмыйча, тәкәллефсез генә кулын сузып, имән бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Утыр. Предприятие фондын мин тупладым...

Калганы әйтелмәсә дә, кабинеттагы һәркем жөмләнен икенче өлешен фаразлый иде: «...үзем ничек телим, шулай бүләм!»

Габделнур янында утырган ташчы, тагын баягы кебек пышылдап кына, үз сүзен кыстырды: «Теләсәм — кемнедер күтәрәм, теләсәм — кемнедер сытып изәм». Бу мәгълүм гыйбарә Габделнур күнеленә дә килгән иде.

Әйе, идарә башлыгы нәкъ моны кычкырып әйтмәсә дә, барысы да анын тел төбен аңлады, шунлыктан берсе дә жилгә каршы төкерергә базмады.

Үзен барин кебек тоткан идарә башлыгы кабинетыннан һәммәсе, сөткә төшкән тычкан кебек, башларын иеп, теле кычытып торса да, үз сүзен әйтә алмаганга үрсәләнеп, әйтергә теләп тә мөмкинлеге булмаганга хурланып (чөнки һәркем идарә башлыгына бәйле: кем хезмәте белән, кем фатир чираты белән), оятларыннан бер-беренә күтәрелеп карарга кыймыйча, мыштым гына чыгып киттеләр.

...Габделнур йокыдан иртә уянды. Кичтән, «Сугыш һәм тынычлык»нын икенче китабын укып, бик соң гына яткан иде. Әллә бүлмәгә төшкән яктылык анын йокысын бүлдерде инде, югыйсә әле кояш чыкмаган. Тәрәзә төбендәге гөл ябалдашлары куе нарат агачын хәтерләтә. Күктә аксыл сирәк юка болытлар йөзә, йолдызлар күренә, аларга иш ай гына житми, көнчыгыш тараф алсуланып бара. Күк гөмбәзенең түбәсе зәңгәр, кояш чыгышы өлеше — аксыл-сары, ә көнбатыш ягы — каралҗым, куе зәңгәргә тартым, ул тарафтагы болытлар кара кучкыл булып күренә, ә үзләре диңгездәге корабларны һәм тагын әллә ниләрне хәтерләтәләр. Менә атна инде көннәр жылы, аяз, яхшы, катырмый әле.

Егетләр, эштә төшке ашка барыр алдыннан, өчәүләп Дөбәриснең бер яртысын кәктеләр. Ана сәгать бирәселәр, слесарь юри генә, юарга кирәк, дигән иде, дусты кыстырып та килгән.

Ашханәдән кайткач, Габделнур белән Дөбәрис буяучы-сылаучы кызлар янына керип утырдылар. Бу бригада әгъзаларынын яртысын кичә генә һөнәр училищесын бетереп килгән яшь кызлар тәшкил итә иде. Бытовкала жанлылык хөкем сөрә: өчәү домино уйный, берсе ирененә вазелин сөртә. Моны күреп, Дөбәрис төрттереп алды:

Шкатур, шкатур,
Шкатурлары матур...

Бу такмакның бик нык буянырга яраткан кызларга әйтелүен яхшы белгәнгә, киселгән чәче мангаена төшеп торган әлеге кыз да жавапсыз калмады:

— Үз иренем, кешенеке түгел, теләсә нишләтәм. Кысылма, кысылып калырсың, Әбәү, күзе шокәтсезнең, дәрте ташыган ата хамелеоннныкы кебек кып-кызыл.

— Көлмә кешедән, авызын өшегән.

Кызнын тагын жавабы әзер:

— Көлсәң дә ярый синең ишедән.

Ике кыз жыр өйрәнәләр икән, егетләр кергәч тә тынып тормадылар.

Берсе:

– Кушымтасын beләбез, — диде дә, матур гына тавышы белән җырлап та күрсәтте:

Илдарым, Илдарым,
Буталмадым сөйгән ярың.

Дөбәрис гадәтенчә шаярып сөйләшә:

– Әле соң түгел. Мин өйләнмәгән.

Кызларның чөенке борынлысы, домино шакмагын кулында тоткан килеш, чытлыкланып, Габделнурга күз кысты:

– Ә бу абый?

– Ул да, — диде Дөбәрис.

– Ул — шәп баянчы, җырларны күп белә.

– Шулаймыни? — диде аларның кара кашлы, елмаеп торган алсу битлесе. — Абый җаным, теге җырны өйрәт әле.

Габделнур да югалып калмады, уен-көлкеле гәпне дәвам итәргә булды:

– Син дигәндә — ике аягым идәндә, шырпы кабыннан сикереп төшәм. Безнең будкага үзең генә кер, өйрәтермен.

Кызый иренен турсайткан булды, урынында кыбырсып алды:

– Ие, кергән ди, акылың кот икән.

Дөбәрис һаман үз амплуасында — шаярту-ирештерүендә:

– Кызлар, аның беренче куплеты менә болай:

Кашларың кара синең,
Күзләрең зәңгәр синең,
Зәңгәр күзләреңнән, иркәм,
Их, кемнәр үбәр сине?

– Кит әле, бу ул җырныкы түгел, — диде буйга кыскарак, уймак кебек авызлы, түгәрәк битле икенчесе.

– Ә-ә, онытканмын, — диде Дөбәрис, күзләрен йомгалап, һәм җырлап-такмаклап әйтеп бирде:

Сулар сибеп үстердеңме,
Ап-ак икән шалканың,
Синең кебек гүзәл кызны
СССРда тапмадым.

Теге кыз тагын ризасызлык белдерде:

– Монда шалканның ни катнашы бар?

– Һи, шуны да аңламаска, кызларда икәү әле ул, — диде эскәмиядә утырган Дөбәрис, янәшәсендәге кызның калку күкрәгенә күз ташлап.

– И оятсыз да инде син, әйтермен бер сүз, онытмассың көзсез, — дигән булды кыз, иренен турсайтып. — Уеңда гел шул гына.

– Кызлар да шуны гына уйлый инде, — диде Дөбәрис, башын чак кына кыегайтып, иңнәрен сикертеп һәм мәзәк тә сөйләп алды: — Егет белән кыз кичен айга карап утыралар икән. Кыз сорый: «Син хәзер нәрсә турында уйлыйсың?» Егет әйтә: «Син уйлаганны». Кыз: «И кабахәт», — ди.

Көлештеләр.

– Абый, өйрәт инде, — дип ялынды кызларның берсе, Габделнурга нурлы күзен текәп.

— За ваши деньги — любой каприз.

— Бер сум житәме?

— Аз. Алайса, яратам, дип әйт.

— Яратам, яратам, приходи к воротам, этебездән талатам.

— И булмады инде бу.

Тагын бераз тел чарлаганнан соң, Габделнур кызлар сораган җырның тулы текстын язып бирде. Кызларның башлары түшәмгә тиде.

Ахырда егет тагын сүзне уен-көлкегә борды:

— Матурым, моны кем өйрәтте, дип сорасалар, сер бирмә, үзем белдем, диген.

Өстәл янында бер кыз нидер язып утыра иде. Дөбәрис карап куйды:

— Нәрсә язасың? Егетеңә хаттыр инде.

— Хатын хат та, егетемә түгел, бертуган абыема.

— Өендә иркенләп язмасаң...

— Вакытым юк, кич институтка йөгерергә кирәк, соң кайтыла.

Бу бер дә гаҗәп түгел, чөнки бригада кызларының яртысыннан күбесе диярлек кайсы кайда укый иде.

— Абыең армиядәме әллә? — дип сорады Габделнур, аларның әңгәмәсенә кушылып.

— Юк. Ул Иракка эшкә китте, әллә кая җәһәннәмгә, — диде кыз, борчылып.

— Габделнур абый, кайда соң ул Ирак дигәннәре?

Егет кызны, мәктәптә география дәресе кермәдемени, дип оялтмады, ул илнең кайда икәнен, нинди халык яшәгәнен әйтеп бирде. Ахырда, анда дөньядагы җиде могҗизаның берсе — Асылма бакча барлыгын да әйтте.

— Бакча борынгы Вавилонга карый, аны патша хатыны гүзәл Семирамида исеме белән бәйлиләр. Гаҗәеп матур бакча булган, бөек полководец Александр Македонский шунда күмелгән дигән фараз бар.

— Абый, син бик күп беләсең икән, безгә берәр дога да өйрәт әле.

— Әбиең өйрәтмәдемени?

— Үлеп китте шул.

— Тыңла, алайса: әлхәм шөкер, җилкәм чокыр, әлхәм тәбарәк, җилкәм тагарак... Йа Алла, йа кадыйр, йа бакый, йә рәхим, йә тәкъбир...

— И алдакчы... Андый дога булмый инде.

Көлештеләр. Алар арасында бер мари кызы да бар иде. Ул бик эшчән, тәртипле, пөхтә киенеп йөри, әле иннек-кершән якмый торган авыл кызы. Габделнур, көнбагыш чәчәгедәй сап-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, эш киеменнән дә зифа буе беленеп-сизелеп торган бу чибәр кыз белән сөйләшеп утырырга, алар халкының гореф-гадәтләре, яшәү рәвешләре хакында сораштырырга ярата иде. Кыз бик теләп аның сорауларына җавап бирә. Әле беренче курста ук узган этнография фәненә мәхәббәте-ихтирамы көчле булган егет аларны зиһененә сеңдерә бара. Мәсәлән, мәҗүсилектән чыгып бетмәгән марилар, җиләк, чикләвек, гөмбә җыярга урманга керер алдыннан, Тәңредән гафу үтенәләр икән: «Рас син безгә гомер биргәнсең икән, син аны сакларга да мөмкинлек бир. Без тукланырга җитәрлек кадәр генә синең нигъмәтләреңне алабыз». Агач кискәндә дә шулай итәләр. Бик яратып үрдәк асрыйлар икән, чөнки ул — җир, су һәм һаваны берләштерүче. Яраткан шөгыльләре — умартачылык.

Бүген Габделнур домино уйнаучы кыздан үзләренчә берничә сүз әйтүен үтенде.

— Нинди сүз? — дип сорады кыз, егеткә зәңгәр күзләрен төбәп.

— Исәнләшү сезненчә ничек була?

— Салам.

— Бәй, бездә дә яшьләр бер-берсенә «сәлам» диләр бит. Ә сау бул?

— Чевёрын.

— Рәхмәт?

— Тау.

— Кызык икән. Ә бездә «тау» биек калкулыкны, русча «гора» дигәнне аңлата. Ә «мин сине яратам» ничек була?

Кызның болай да алсу йөзе кып-кызыл булды, күз керфекләре генә түгел, башы да түбән иелде, домино шакмакларын тоткан сул кулын өстәлгә салды, уңындагы шакмакны куйганда буталып бетте.

«Әллә моның күңелендә миңа карата берәр нәрсә бар микән?» — дип уйлап алды Габделнур.

Бу чибәр кыз үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. Бервакыт ул марича «Канде шинча» («Зәңгәр күзләр») җырын җырлаганда һәм, үзләренчә тыпырдап, кызлар белән түгәрәктә «Кандыра» биюен биегәндә, Габделнур аңа баянда уйнаган иде. Әлбәттә, алдан идарәнең кызыл почмагында бер-ике тапкыр репетиция ясадылар. Шул чакта ук егет кызның ярату катыш сокланулы карашын тойган кебек иде. Ләкин ул моңа артык игътибар итмәде.

Ул арада аларның сүзләренә колак салып утырган бөтеркә чәчле бер кыз, турыдан ярып:

— Сине яратуын әйтсенме? — дип төрттереп алды.

Аның шулай бергә эшләгән дустының хисләренә тупас кагылуын, шәрран яруын өнәмичә:

— Мин гомумән сорыйм, — диде егет, мари кызын уңайсыз хәлдән коткару өчен. — Чөнки марилар угро-фин төркеменә керәләр.

— Анысы нәрсә? — дип сорады әлеге кыз.

Габделнурга аңлатып бирергә туры килде:

— Халыклар төрле төркемнәргә бүленәләр: сез — славяннар, без — төрки телледәр, ә алар — угро-финнар. Алар төркеменә мордва, удмурт, эстон, фин, венгр һәм башкалар керә...

Мари кызының дулкынлануы басыла төште, ул акрын гына үзләренчә әйтте:

— Мый тыйым йоратем.

— Нәрсә дидең?

— Сез сораганны әйттем.

Габделнур, баш иеп, рәхмәтен белдерде:

— Тау.

Кыз елмайды. Аны уңайсыз хәлгә куймас өчен, егет теманы үзгәртергә мәҗбүр булды, ашау-эчү ризыклары турында сораштыра башлады.

Егет үзен вәсвәсәгә бирелүдән һәм нәфис, әле дөнья күрмәгән, ышанучан кызны нәрсәгәдер өметләндерүдән — күңелен җилкетүдән шикләнә иде. Бу гөнаһсыз бала үзенең эштә унганлыгы белән дә, үз-үзен тотышы, җилбәзәк булмавы белән дә теләсә кайсы егет-җиләннең күңелен җәлеп итәрлек. Ә Габделнур, яше барган саен, үзенә кем кирәген аныкрак төшенә бара иде.

Ишектә ашханәгә киткән кызлар пайда булды. Алдан, бәбкәләрен иярткән ана каз кебек, кырык-кырык биш яшьләрдәге бригадир апалары, аның артыннан яшь кызлар керде. Боларына — монда калганнарына — сөттә генә пешкән коржик, майда кыздырылган итле пәрәмәч һәм өчпочмак рәвешендәге кәгазь каплы сөт алып кайтканнар иде.

— Ярый, кызлар, тәмләп ашагыз, — диде Габделнур, будка уртасындагы зур өстәл яныннан кузгалып. — Без карап торсак, йә авызыгыз оялыр.

— Бер капканда күп капмагыз, — диде Дөбәрис, елмаеп.

Егетләр чыгып барганда, бер ачы теллесе әйтеп калды:

— Гаепләп китмәгез инде...

Дөбәрис, анын кинаясен аңлап, артына борылды.

— Ярар, икенче юлы күрсәтерсез.

Кызлар бытовка ягыратып көлешеп калдылар.

Егетләр үзләренә кереп утырганнар гына иде, берәү кереп:

— Күтәргеч эшләми, — диде.

— Мотор әйләнәме соң? — дип сорады Дөбәрис.

— Әйе.

Слесарь (ул будкада, «черем итәм» дип, кызлар янына кермичә калган иде):

— Электерми инде, алайса, — диде. — Йә муфта, йә шпонка кырылган.

Өчесе чыгып киттеләр. Габделнур будкада калды. Озак та үтмәде, механик килеп керде.

— Градирняга күтәргеч алып килдем, — диде ул. — Прорабский бикле.

— Алар шунда булырга тиеш, — диде Габделнур һәм механик белән чыгып китте.

Габделнур шакыгач, бераздан ишек ачылды. Эчкә үттеләр. Участок башлыгы — өлкән прораб — түрдәге өстәл башында тешен каезлап утыра. Прораб телефоннан сөйләшкән булып кылана — авызына сөяк капкан эт шикелле, телефон трубкасын аркылы тоткан. Дивар буендагы урындыкларга ике бригадир һәм мастер кунаклаган. Күрәсең, качып-бикләнеп салып утырганнар, бишесенең дә йөзләре бурлаттай кызарган; бүлмә аңкыган — аракы һәм кипкән балык исе таралган; табынын җыеп өлгергәннәр, бары өстәлдә ипи валчыклары гына калган.

Механик белән исәнләшкәч, аның ни өчен килгәнен белгәнлектән, өлкән прораб әле быел гына эшли башлаган мастердан сорады:

— Багана утырттыңмы?

— Юк әле.

Сүз электр линиясе сузу өчен кирәкле баганалар турында бара иде. Участок башлыгы мастерга каты бәрелмәде, балта осталары бригадирына кешеләр бирергә кушты.

— Бүген үк әзер булсын.

Бераздан механик белән Габделнур урамга чыктылар.

Тулы гәүдәле, түгәрәк битле, кырык яшьләр тирәсендәге механик ачу белән әйтте:

— Мин моны баш инженерга җиткерәм. Мина барыбер, механизмнар аларга кирәк.

Механикның нилектән шулай усал телләнүенең сәбәбен Габделнур чамалый иде. Ул, ике ел Ливиядә эшләп, шактый мая туплаган, чекларына Мәскәүнең «Берёзка» кибетеннән кием-салым гына түгел, «Москвич» машинасы да алып кайткан; фатирны киткәнче үк алган булган; димәк, кендеге боларга бәйле түгел, хәзер теләсә кем белән аяк терәп сөйләшә ала.

— Ярар, әйтеп торма инде, — диде Габделнур, чөнки ана әле бу участокта эшлисе бит. — Линия сузарбыз. Чыбык һәм ыргаклар белән тәтәйләр кирәк.

— Китерермен, — диде өс-башын бик чиста йөртә торган механик, аяк астындагы пычрак суга басмаска тырышып.

Ул да юашлана төшкән иде, ахрысы. Механик киткәндә, Габделнур машина әрҗәсенә ватык вибратор һәм янып чыккан трансформатор салып җибәрде.

Аны озаткач, электрик янә прорабскийга керде. Анда фәкать участок башлыгы гына калган һәм ул, кара чәчле башын өстәлгә салып йоклап утыра

иде. Егет, алай-болай уянса дип, ишек катындагы электр мичен рәтләгән булып маташты да чыгып китте.

Смена тәмамланыр алдыннан Дөбәрис, прорабскийга кереп, бәйрәмгә каршы көннәрне кемнәр ничек эшлисен белешеп чыкты. Шуна карап, электриклар да эш бүлештеләр һәм кемнең кайчан чыгасын прорабка әйттеләр.

## 8

Габделнур бу арада гел багана башында булды һәм ана салкын тиде. Иртән тора — хәле юк, тамак төбе авырта, йөрәге еш тибә, томау төшә. Кичкә исә томау тагы да көчәя, еш һәм бик каты төчкерә — күкрәге янгырый, авырттырып-чәнчеп ала, борыныннан өзлексез су ага, колагы чатный. Кулын башына тидереп карый — кап-кайнар. Төнлә дә интегә: әле тегеләй, әле болай ята, әмма йоклап китә алмый. Колак төбендә тавыш: алачыкта тимерчеләр эшләгән кебек: берсе потлы кувалда белән гөрс-гөрс бәрә, ә икенчесе бәләкәй чүкеч белән чүки. Аптырагач, егет торып утыра. Утырса, колагы шаулый — малай чакта, кыш көне телефон баганасына башынны терәсәң, шулай шаулый торган иде.

Ул кура җиләге кайнатмасы (рәхмәт егетләргә, Габделнурның үзендә андый затлы ризык юк иде) белән чәй эчеп, төренеп ятты. Әмма барыбер йокыга китә алмады, аптырагач, кулы белән колакларын ышкыды, мангаен тотып торды, төчкерде, ютәлләде; койкасы шыгыр-шыгыр килә, бүлмәдәге егетләргә дә йокы бирми — алар да тынычсызлана.

Габделнур сәгатенә күз салды — өч тулып килә икән, ничек тә саграк кыланырга тырышып, ятагыннан торды, чыгып керде, тагын чәй эчте. Җылы киенүенә карамастан, свитер, спорт чалбары һәм йон оекбашка гына ышанмыйча, ике кат одеял өстеннән пальто да ябынды. Аның монарчы болай каты чирләгәне юк иде шикелле, ә хәзер өзлексез тәне кызыша, башы ярыла, колагы чәнчи, төкерек йотуы авыр — бөтенесе берьюлы килеп бөялде.

Миргаяз уянды, башын күтәреп сорады:

— Чәй куйыйммы? Эчмисеңме?

— Рәхмәт! Эчтем.

Бүлмәдәше чыгып керде дә, одеялын башыннан бөркәнеп, бөгәрләнеп ятты. Озак та үтмәде, аның тигез ритм белән сулыш алуы ишетелде, димәк, йокыга киткән.

Авыру урамнан төшкән ай яктысына, тәрәзә төбендәге гөлләргә, көзгегә, чәйнеккә, абажурга, аклы-каралы диварга бик озак карап ятты...

Икенче көнне, хәле булмаса да, янә эшкә китте. Дөбәрис аның хәленә керергә тырышты.

— Үзем эшләрмен, — диде ул.

Габделнур ялындырмады, юк, үзем эшлим, дип атлыгып тормады: урамда туна, аяк атлавының да рәте юк — исерек кеше кебек чайкалып китә, тез буыннары тотмый, төчкерә, колаклары чәнчешә, тәне кызыша иде.

Төштән соң ул тагын завод поликлиникасына китте (төзүчеләр шунда беркетелгән иде). Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, кичә генә күренеп киткән авыруның бүген карточкасы юкка чыккан.

Егет аптырады.

— Ничек инде? Мин аны үзем белән алып китмәдем ләбаса.

— Юк бит.

— Эзләгез.

— Мәгез талон.

Әмма табиб аны кире борып чыгарды:

— Карточка кирәк.

Габделнур регистратура тәрәзәсенә башын тыгып ризасызлык белдерде:
— Нишләп мине арлы-бирле йөртәсез?
— Янаны язып бирәм, ачуланмагыз, зинһар. Гаеп бездә.
Егет кабат табибка керде.
— Ике колагын да шешкән, — диде оториноларинголог. — Каяле, борыныңны һәм тамагыңны да карыйк.
Пациент дәшми генә утырды, ул бераз тынычланган иде инде.
— Бүген эшләденме? — дип сорады табиб.
— Әйе.
— Ә иртәгә?
— Барам.
— Юк, эшкә барма. Хәлен яхшырса да ашыкма, өзлегерсен. Больничный бирәм, дәвалан.
Кайтышлый шәфкать туташы кулына тоттырган рецепт кәгазе белән кирәкле даруларны алып, егет дүртенче каттагы бүлмәсенә көч-хәл белән менде, чишенеп, дарулар эчеп, караватына ауды.
Колагы авыртуга чик-чама юк: кемдер бераү без белән калаган кебек; аркасы да сызлый. Бәдрәфкә барырга дип чыккан иде, кире керде: теше-тешкә тими, шак-шок бәрелә — тәне калтырый башлады.
Егетләр кайтты. Алар да аптырады, ни кылырга белмиләр. Өстенә пальто кигертеп, сабый баланы биләгән кебек төреп яткырдылар.
— Йокла, бәбием, йокла, — диде Миргаяз, шаяртып.
Әмма барыбер авыруның тунуы басылмады. Аннары егетләр чәй кайнаттылар.
Миргаяз стаканга бер калак май салды:
— Мәле, эчеп жиппәр әле, сикереп торырлык булсын.
Кайнар чәй эчерткәч, колагына һәм борынына дару салдылар; төймәне Габделнур үзе йотты, янә ятты.
Фәүҗәт сорап куйды:
— Врач нәрсә диде соң?
— Монысы әйбәт кенә карады, — диде Габделнур, төкереген көчкә йотып. — Кичәгесе, зараза, юньләп карамады.
Бераздан Миргаяз кибеттән урап кайтам дип чыгып китте. Ә яшь егет янына шәкерт дуслары — курсташлары керде. Алар өчесе дә төзүче-инженерлар институтының беренче курсында укыйлар.
Берсе — олканрәк, утыз яшьләр тирәсендә, өйләнгән; өстендә куе зәңгәр костюм, ачык сары төстәге күлмәк; ябык йөзле, чәче кыска, калын таза гәүдәле, эре сөякле, куллары күбрәк лом, балта, кувалда өчен яратылган, ахры, каләмне бик уңайсыз тота; аңа уку да бик авырлык белән бирелә булса кирәк.
Икенчесе — кечкенә гәүдәлесе — вак шакмаклы яшел күлмәктән, аның жиңнәрен сызганып куйган, ачык изүеннән йонлач күкрәге күренеп тора, аның юан беләкләрен дә кара төк баскан, озын чәче маңгаена төшкән, бер кулы белән янагына таяна, икенчесендә — карандаш.
Алар өчесе дә өстәл өстенә иелгәннәр. Ә анда сызым кәгазе, ике-өч төрле каләм, тимер өчпочмак, сызгыч, бозгыч, мамык кисәге, кыска линейка, циркуль, китап-дәфтәрләр.
Фәүҗәт, арада иң яше булса да, — укытучы ролендә. Мөгаен, курсташлары, аның быел гына мәктәп партасы арасыннан чыгуын, зиһене әлегә сыра-хәмер ише нәрсәләр белән агуланмаган булуын да искә алып, аңа тулысынча ышаналар — белем дилбегәсен аның кулына тапшырганнар. Читтән караган кешегә шулай тоела, һәрхәлдә, Габделнур башына шундыйрак уй килде.

Урта мәктәптә төпле белем алган егетнең һәр хәрәкәтендә сабырлык, һәр нәрсәнең күләмен, үлчәмен төгәл чамалау сизелә. Юкка гына иптәшләре аңа тартылмыйдыр. Ул киң күңелле, һичкайчан аларга караңгы чырай күрсәтми.

— Бу плоскостьтанмы? — дип сорый студентларның берсе һәм эш дәвам итә...

...Габделнур үзенең авылда, җидееллык мәктәптә укыган чакларын исенә төшерде. Кем яхшы укый, аңардан күчерәләр, ярдәм сорап, аңа мөрәҗәгать итәләр иде. Гадәттә, кызлар арасында алдынгыраклар күбрәк була, хәер, малайлар — шуклар арасында да «башы эшли» торганнар табыла. Габделнур да начар укымады, шуңа күрә дәрәҗәсе ярыйсы ук иде.

Ул авыру хәлендә тулай торак бүлмәсендәге эшче-студент ир-егетләргә карап ята. Адәм баласы бертөрле генә түгел шул: кемдер мәҗбүр иткәнгә генә укый, ә кемдер — күңеле кушканга. Менә боларны да берәү дә мәҗбүр итми бит, ә тырышалар-тырмашалар — фән кыясын кимерәләр.

Ул үзе бүген кулына китап алмады диярлек, чөнки хәрефләргә, юлларга карагач, башы авырта иде. Ул бермәлне ирексездән уйлап та куйды: «Их, бер йөреп кайтырга, кызлар янына барырга, берәрсен кочарга иде. Басылмас иде микән авыртуларым...» Аннары үзе үк шул юләр уйлардан көлеп тә куйды, үзен үзе юатты: «Чирдән терелгәч тә, берәр кыз табам...»

Габделнур янә егетләргә карый. Фәүҗәт каләм белән башын кашый, борын тарта, сызганын резинка белән бетерә, торып баса, өчпочмак тота һәм икенче карандаш алып иелә-бөгелә, сыза. Фәүҗәтне өлкән курсташы алыштыра: сыза, резинка белән бетерә, мамык белән сыпырып ала, күрәсең, чистарта, кулбашын кашый, сызгырып та куя...

Үзләре һаман сөйләшәләр:

— Бер N монда килеп чыга. Аңладыңмы?

— Әйе.

— Горизонтальный үткәрәбез, фронтальный кала. Менә горизонтальныйның размерын алабыз...

Өченче егет тә каләм ала. Бармагы белән борынын ышкый, идәнгә аягын шапылдата, ютәлли, тамак кыргалап куя, гәүдәсен турайтып билен яза, каләмен ташлый, сызымын күтәреп карый, Фәүҗәткә бирә. Янә эшкә керешәләр.

Ул арада кибеткә дип чыгып киткән Миргаяз кайтып керде. Печенье алган. Немецча сөйләшә, димәк, кызмача.

— Әен фихтен баум, штеет әйн зам. Дуслар бар икән. Гутен таг.

Күрешеп чыга. Чишенә.

— Гутен абенд, — дип аны төзәтте Габделнур. — Кич инде.

— Ә, шулай бит әле, кич җиткән икән, — диде йөзе кызарган Миргаяз да, елмаеп. — Синең янда белер-белмәс башың белән бик күп сөйләшеп булмый. Шулай инде, укыган кеше — чукынган кеше.

Ул өс киемен салгач, тагын теленә салына башлады:

— Опять эшләр хөрти, — диде дә, кулына сабын-сөлге тоткан килеш бүлмә уртасында тукталып калды.

— Нәрсә булды? — дип сорады студентларның өлкәне.

— Америкада бер карчыкның кәҗәсе үлгән, — диде Миргаяз һәм ишеккә юнәлде.

Егетләр, аның шаяртуын аңлап, көлештеләр дә янә эш белән мәшгуль булдылар.

Миргаяз чәй эчеп алды, Габделнурны да печенье белән сыйлады, аннары койкасына барып утырды.

Егетләрнең бүгенгә эшләре тәмам икән.

— Бетте, — диде кечкенә егет, — дүрт мәсьәлә чишелде.

Фәүҗәт аларны озатып керде.

Габделнур ул егетләргә сокланып калды. Хәер, кем нәрсәгә сәләтле бит. Болар төгәл фәннәрне әйбәт белә, Габделнур тарихны, әдәбиятны ярата. Ул Толстойның «Сугыш һәм солых» романын кулына алган иде, Андрейның бәхет турындагы сүзләренә тап булды: «Тормышта мин ике төрле генә чын бәхетсезлек барлыгын беләм: вөҗдан газабы һәм авыру. Бәхет — менә шушы ике бәхетсезлекнең булмавы дигән сүз генә. Шушы ике бәхетсезлеккә очрамаска тырышып, үзең өчен генә яшәргә кирәк. Хәзер минем төп теләгем менә шул гына...» Ләкин ана Пьер каршы төшә, мәхәббәт, үз-үзеңне корбан итү кебек төшенчәләрне китерә. Кыскасы, алар бәхәскә керәләр...

Габделнур алар яшәгән чорны, аларның мохитен күз алдына китерде. Болар барысы да дворяннар, граф, кенәз, бай балалары, тормышлары житү, теләсәләр, хәрби булалар, теләсәләр — гражданский, һичбер вакыт мохтаҗлык кичермичә яшиләр. Чөнки алар өчен, аларның шулай типтереп яшәүләре, балда-майда йөзүләре өчен йөзләгән крестьяннар авылы-авылы белән бил бөгә, тир түгә, үз имениеләренә алар ял итәргә, киек җәнлекләр ауларга гына барып кайталар, ә торулары — Петербургта һәм Мәскәүдә.

Ә монда, тулай торакта... Габделнурның кабат башы чатный башлады, һәм ул китабын ябарга мәҗбүр булды.

## 9

Габделнурның курсташларыннан фәкать бер-ике кеше генә укытучы. Староста, мәсәлән, подполковник дәрәҗәсенә күтәрелгән хәрби кеше, бүгенге көндә хезмәт белән төзәтү колонияләре идарәсендә; бер егет комсомолның өлкә комитетында инструктор; бер хатын Югары Советта... Араларында Габделнур кебек гади эшчеләр дә байтак. Электән калган мәкальдәгечә, укып мулла булмассың, чукып карга булмассың, дисәләр дә, безнең халыкта аң-белемгә омтылыш, ихтыяҗ көчле. Руслар, гомер яшә, гомер буена укы — юләр булып үләрсең, дип тә җиппәраләр бит әле. Әмма барыбер егет-кызларның күбесе, яшь агач кояшка, яктыга авышып үскән кебек, югары уку йортларына керергә омтыла. Бер яктан, белемгә сусау тартса, икенче яктан, дипломлы яшь кешенең алга таба үсеш перспективасы бар.

Мәктәпләрдә практика узганнан соң, һәркем үзенчә бер нәтиҗә ясады булса кирәк, укуны тәмамлагач дәвам итәчәк хезмәт юлын, тормышын ачыграк күзаллый башлады. Коридорда яки занятиеләрдән кайтканда, мондыйрак фикерләр ишетелгәли иде:

— Миннән укытучы чыкмас, ахры. Моның өчен сәләт кирәк.

— Әзме-күпме сәләт һәр эштә кирәк инде ул анысы.

— Юк, монда баланы тәрбиялисе дә бар бит әле. «Педагог» сүзе грекчадан тәрҗемә иткәндә, баланы алып баручы, тәрбия кылучы мәгънәсенә ия бит.

— Шулаен шулай да, кичке мәктәптә укытсаң, аларны инде тәрбиялисе юк.

— Әйе, алар үзләре сине тәрбиялиләр.

Кемдер житди, ә кемдер шаяртkан булып фикер йөртә:

— Холкым мәктәпкә батмый. Түземлек тә, сабырлык та юк миндә, йә берәр тәртипсезен кыйнап ташлармын, баладан баш-аяк.

— Мин ел саен бер үк китапларны укып, иске темаларны сөйләп, һаман бер балык башын чәйнәп утыра алмам, ахры. Мин үзгәреш яратам.

Кыскасы, һәркем үзенчә фикер йөртә, киләчәккә планнар кора. Фәкать мәктәптә укытучы булып эшләүчеләр генә икеле-микеле уйда түгел: аларның барыр юлы билгеле һәм тип-тигез — күптән сайланган.

Габделнурның еш аралаша торган бер курсташы медицина инструментлары заводында токарь булып эшли иде.

— Бездә югары квалификацияле токарьлар берничә генә, — диде ул, үзара гәпләшкәндә. — Эш авыр, төгәллек сорый. Аның каравы хезмәт хакы әйбәт — аена биш-алты йөз. Ә мәктәптә мин ул акчаны алаламмы? Юк, билгеле. Узган ел кооператив фатир алдык, ел саен түлисе бар.

Практика узганда, Габделнурга мөгаллимлек һөнәре ошады. Бигрәк тә яшь буынга, дәреслекләрдән тыш та материалларны файдаланып, үз халкының язмышын искә алып (Шәйгазамов белән әңгәмәнең тәэсире), тарихны кинрәк һәм тирәнрәк укыту теләге уянган иде. Тарих — халыкларныкы, тарихчылар — патшаныкы, дигән гыйбарә бар бит. Әлеге дә баягы патшалар кушуы буенча гына язылган тарих укытмас иде ул. Үзебезнең кем икәнлегебезне — бөек халык, заманында дәүләт тоткан халык булуыбызны, телебезнең дә Русиядә икенче дәүләт теле дәрәҗәсендә (Пётр Беренче үз янында тылмач тоткан, бик күп дворяннар-зыялылар татар телен камил белгәннәр) йөрүен балаларның аңына сеңдерер иде. Ленин бабайның бер хезмәтендәге «Россиядә укымышлылык буенча татарлар беренче урында торалар» дигән юлларны укып күрсәтер иде. Ул бу фәнне ярата, чөнки, борынгы римлылар әйтмешли, тарих — тормыш укытучысы. Укытучы димәктән, университетта бер профессор аларга гел әйтә иде: «Яхшы мөгаллим аңлата, ә бөек мөгаллим рухландыра». Габделнур укучыларны дәртләндерә, илһамландыра алыр иде микән? Анысы билгесез, ләкин, һәрхәлдә, төшеп калганнардан булмас, балаларга әйбәт сабак бирүче булыр иде. Кызык, авыл мәктәбендә укыганда, әбиләре гел «сабак» дип сөйләшәләр иде: сабакка бардыңмы, сабагыңны кара, сабагыңны укы, сабагыңны онытма. Нинди мәгънәле сүз икән бит ул...

Әмма тормышның күзгә күренеп тормаган яклары, үз кануннары бар шул. Аңа хәзер егерме җиде яшь. Шуның унөч елы (армияне дә кертеп) тулай торакта узган. Анда аның чордашлары-яшьтәшләре елдан-ел сирәгәя, алар урынына яшь-җилбәзәк килә. Габделнурга инде алар белән кызык түгел. Аннары, башлы-күзле булырга да вакыт җиткәндер. Авылга кайткан саен (ә ул анда еш кайта), әти-әнисе дә читтән суктырып булса да, моны искәртәләр. Ә кайда яшәргә? Ярар, күнеленә хуш килгән кыз очрады да ди. Сөйгәне Рәйсәнә кебек үк булмаса да, кай ягы беләндер аны хәтерләткән, холык-фигыле белән аңа тартым гүзәл бер фәрештәгә юлыктың ди. Хәер, аның Рәйсәнәгә бөтенләй охшамавы да бик ихтимал — һәр хатын-кыз үзенчә матур, ир-ат күнелен үзенчә җәлеп итә бит. Аның унай якларын күрә белергә генә кирәк. Яисә башыңны югалтыр хәлдә, Ләйләсенә мөкиббән киткән Мәҗнүн кебек, аңа фанатикларча гашыйк булырга гына кирәк. Әйе, шул кыз белән матур гына йөреп, гаилә кору хакында да килештең ди. Тыйнак кына итеп туен да уздырырсың. Ә аннары?.. Кайда торырсың? Кая барып сыенырсың? Казанда, әйдә, килен балакай, төкле аягың белән, дип көтеп торган атаң-анаң йорты юк. Икең ике тулай торакта чиләнергә, баллы көннәрнең тәмен җибәрергә, кавышу минутларын көтеп газап чигәргәме? Ю-ук... Урыслар, с милым и в шалаше рай, дип әйтәләр әйтүен. Ләкин шәһәрдә, Разлив күле буенда качып яткан Ленин бабай кебек, шалаш та корып булмый бит әле.

Бөтен Союзда яңгыраш тапкан төзелештә эшләүчеләрнең киләчәккә өмете бар: заводта яңа комплекс кора башлауга, генподряд һәм субподряд оешмаларга, торак өчен дип, күпмедер күләмдә акча бүленә, һәм төзү идарәләрендә һәр елны фәлән хәтле яңа фатир бирәләр; кемнәрдер, гаилә ишәйгәч, кечесеннән зурга күчә, аларныкы да чиратта торучы яшьрәкләргә кала... Шулай итеп ел

саен чират алга баруын дәвам итә. Габделнурның да киләчәге гел үк өметсез түгел. Ә мәктәптә?.. Егет андагы хәлләрне тәгаен белми белүен... Хәер, аны сораштырып була. Ләкин һавадагы торнага алданып, куллагы чыпчыкны ычкындыру ярамастыр.

— ...Мин дә төзелештән тиз генә китмәмдер, ахры, — диде ул һәм курсташына хәлне аңлатты.

Шунда Рәйсәнә әйткән сүзләр хәтерендә янарды: «Бу дөньяда кешеләр үз дигәнчә генә яши алмый...» Әйе, теләк бер нәрсә, ә тормыш чынбарлыгы, яшәеш башкача хәл итә... Жан-Жак Руссо бугай: «Кеше ирекле туган, асылда исә, ул һәр җирдә зынҗырлы», — дигән.

Ә беркөнне, гыйнвар башында, взнос түләргә кергәч, егетне партия оешмасы секретаре Митрохин үз бүлмәсендә тоткарлады.

— Клавдия, син бераз һава сулап кер, — диде ул кадрлар бүлегендә эшләүче хезмәткәргә. — Бухгалтерия кызлары белән ләчтит сатыгыз. Без Галелҗанов белән гәпләшеп утырыйк әле.

Дәшми-тынмый нидер язып утырган хатын, ярар, диде дә чыгып китте.

Митрохин иң әүвәл, урыныннан торып, зур тәрәзәнең форточкасын ачты, папирос кабызды, калын иреннәре белән тәмәке суырды, төтенен тышка таба өргәч, урынына утырды, өстәлдәге көл савытын үзенә якынрак китерде.

Бүтән вакытта ана фамилиясе белән генә эндәшә торган Митрохин бүген егеткә исеме белән дәште һәм алдагы планнары белән кызыксынды:

— Тагын ярты ел укыйсың калды. Көндезгедә укыган студентларга биргән кебек, сезгә юллама бирмиләр, кая да булса мәҗбүри җибәрмиләр бит. Язмышыңны үзең хәл итәсең.

Әлегә Габделнурның төпле, анык бер планы да юк иде. Кая да булса китәргә дә исәбе юк. Митрохин белән ул ачыктан-ачык, кем әйтмешли, картларне уртага салып сөйләште:

— Афанасий Фёдорович, сез миңа беренче көнне үк, ата бурсык кебек ялгыз башың яшәмәссең, гаилә корырга кирәк булыр, дигән идегез.

— Әйе, хәтерлим, — диде элекке офицер, янә төтен өреп.

— Яшь бара. Тиздән егерме сигез тула. Тулай торакта яшәү дә туйдырды. Камыт кияр чак житкәндер дип уйлыйм.

Митрохин үткер күзе белән егеткә төбәлде, карашында кызыксыну һәм теләктәшлек чагыла иде. Ирен читләре белән генә елмайды:

— Камыты бармы соң?

— Әлегә юк.

— Муены булса, анысы табылыр. Эш турысында ничек?

— Мин идарәдән китәргә җыенмыйм.

Егетнең җавабы Митрохинга ошады ошавын, ләкин ул, армиядә хезмәт иткәндә дә, биредә кадрлар бүлегендә эшләгәндә дә, кешеләрне күп күрде, төрлесен очратты. Шуңа күрә аның һәр әйткән сүзгә ышана торган гадәте юк. Кат-кат, урап-урап сораулар биргәч, сөйләштергәч кенә, ул тиешле нәтиҗә чыгарырга өйрәнгән. Дөрес, Галелҗанов урамнан кергән кеше түгел, сыналган егет. Шулай да ул үзен кызыксындырган сорауларны бирмичә кала алмый, шик-шөбһәгә урын калмаслык булсын.

— Электрик булып эшләрсеңме?

— Әйе, — диде үз-үзенә нык ышанган Габделнур.

— Югары белем беләнме?

— Ә кая барыйм, туры килер.

Митрохин тулы гәүдәле булса да, бик хәрәкәтчән кеше, гаскәри хезмәт үз тәэсирен җуймаган иде әле. Урыныннан торып, кулларын артка куеп, ишекле-

түрле йөренде, кабат үз урынына чөмәште, тәмәкесен сүндерде. Янә егеткә туры карады:

– Әгәр эшче югары белем ала икән, ул үсәргә тиеш. Төзүче-инженерлар институтын бетергәннәр белән мәсьәлә тиз хәл ителә: мастер, прораб... Шуның өстенә бүтән идарәләр, трест бар — һәркемгә урын табыла. Ә син гуманитар белем аласың. Мин сине күптәннән күзәтеп киләм: белемең житәрлек, эш яратуың да мәгълүм, тәртип бозганың юк. Баш механик та, энергетик та синнән канәгать, җәмәгать эшенә дә салкын карамыйсың. Кыскасы, син безгә кирәкле кеше һәм сине дөрес, тиешле урында файдаланырга кирәк дип уйлыйм.

Митрохин Гаделҗановның төзелеш комитеты утырышларында турысын әйтүен дә исенә төшерде. Дөрес, ул кайчагында, бигрәк тә фатир бүлгәндә, эшчеләрне аяк терәп яклавы, кирелеге белән идарә башлыгының ачуын да чыгара. Митрохин монысын да исендә тота. Ләкин Габделнурны җибәрәсе килми.

– Әгәр сине төзелеш комитеты рәислегенә кодаласам?

Партбюро секретареның тәкъдиме Габделнур өчен көтелмәгәнрәк булды. Ул урын буш түгел. Аннары, кайбер инженер-техник хезмәткәрләр, бигрәк тә участок башлыклары аны өнәп бетермиләр. Чөнки ул, алдын-артын уйламыйча, һәрчак эшчеләрне яклый. Ә тегеләрнең мастер-прорабларны алгарак этәсе килә.

Митрохин белән әңгәмә шактый озынга сузылды. Габделнур быел диплом яклыйсы, дәүләт имтиханы бирәсе барын да искәртте. Шуңа да карамастан Афанасий Фёдорович үз тәкъдимен көчендә калдырды. Нигездә, егет тә аның белән килеште.

Төзү идарәләрендә профком рәисе штаты каралмаган, әмма барысы да элекке эш урыннарында хезмәт хакы алып, фәкать шул вазифаны гына башкаралар. Чөнки дүрт-биш йөз кешелек оешманы (барысы да профсоюз әгъзасы) җитәкләве җиңел түгел. Сайланган сурәттә Габделнур электр цехында исәптә торачак иде.

Ләкин, алга китеп булса да әйтик, мәсьәлә алар уйлаганча хәл ителмәде.

Ул заманда Советлар Союзы дөньяның күп почмакларында үз идеологиясен алга сөрү, йогынтысын арттыру өчен бөтен көчен куя иде. Кытайга дистәләгән завод-фабрика корып бирде, Һиндстанда гаять зур металлургия комбинаты төзеде, Куба, Ангола һәм башка илләрне туендырды. Көнбатыштагы социалистик илләргә «Дуслык» нефть үткәргечен сузып, юан-юан торбалардан көн-төн кара алтын кудырды. Монголия, Ливия, Ирак кебек дәүләтләрдә төзелеш эшләре алып барды. Аларда эшләү өчен илнең төрле шәһәрләреннән төзүчеләр җибәрелә иде. Кайберәүләр ул тарафларга бик теләп баралар: алар яхшы хезмәт хакы ала, монда эш стажы өзелми, ике-өч ел эшләп кайткач, Мәскәүдәге махсус «Берёзка» кибетләреннән чек белән кием-салым, машина юнәтәләр иде.

Монголиядә өч ел эшләп, әле шушы араларда гына кайткан бер бригадир, тресттагы таныш-белешләре аркылы төрле юлларын табып, үзен төзелеш комитеты рәисе итеп сайлатуга иреште. Митрохин, теше-тырнагы белән каршы торса да, үз кандидатурасын үткәрә алмады.

Кайберәүләр Габделнурны, гомумән, постройком әгъзасы итеп сайлатмаска да маташты, ә күпчелек, бигрәк тә гади эшчеләр, аны яклап чыкты. Рәис мәсьәләсе исә постройком утырышында хәл ителде. Монда инде аңа тавыш бирүчеләр Митрохин белән бер монтажчы гына булды. Идарә башлыгы да, трест вәкиле дә әлеге дә баягы бригадирны хуп күрделәр.

Утырыштан соң Митрохин, Габделнурның үзен генә туры китереп әйтеп куйды:

— Галелжанов, син турыдан ярасың, — диде. — Коеп яуган яңгыр астында да чыланмаска өйрәнергә вакыт. Исеңдә тот: тормышка яраклашмыйча булмый.

— Ярар, истә тотармын.

— Канцлер Бисмарк турында замандашлары «ул — куркыныч кеше, чөнки ул туры сүзле — ни уйлаганын әйтә» дигәннәр. — Аннары Митрохин елмая төшеп өстәде: — Ә син бит әлегә канцлер түгел.

Егетне якын итеп торган, хисап-сайлау конференциясендә аның файдасына үз сүзен кистереп әйткән Шәйгазамов, аны юатып:

— Күңеленне төшермә, — диде. — Чыңгыз хан, рухы төшкән җайдакның аты чапмый, дип әйтә торган булган. Ә бу кешене беләм мин: бер елдан артык эшли алмас, адәм ялкавы, белеме — ташка үлчим, җиде класс. Хәзер ана бригадир урыны юк, ә гади эшче булып эшлисе килми. Бәлки, шулай килеп чыгуы синең өчен яхшырактыр да әле. — Шәйгазамов көлеп куйды: — Бер елга куян тиресе дә чыдаган ди. Ул — синең урының. Так что, борыныңны салындырма, тыныч кына укуыңны бетер.

— Ә минем әллә ни исем китми, — диде Габделнур ихлас күңелдән.

Чыннан да, ул монардан трагедия ясамады; әлегә үз эшеннән канәгать, укуы да көйле генә бара. Кайберәүләр уйлаганча, университетта укыган башы белән «карга борыны» күтәреп, «тимер тырнаклар» тагып багана башында йөрергә гарьләнми. «Башлаган эшне бетерергә кирәк, аннан соң күз күрер», — дия иде ул үз-үзенә.

Әйе, рәис була алмадым диеп кенә сөмсере коелмады егетнең. Ул, житәкчесе белән киңәшеп, трест партия оешмасының Органик синтез заводын корудагы роле турында диплом эшенә алынырга уйлады. Бәхетенә булса, алашаң колынлый дигәндәй, материал эзләп җәһәннәмгә барасы түгел — кул астында гына: партком, профком, комсомол комитеты папкаларының тузанын как та иренмичә кара; күптиражлы трест газеталарының татарчасын да, русчасын да туйганчы актар, киңәш-табыш итәрдәй теләсә кем белән әңгәмә кор. Кыскасы, материалны шактый муллан тупларга мөмкинлек бар. Шуның өстенә игелекле доцент апасы ана проректор имзалаган бер кәгазь дә бирде. Бу студент Галелжановны архив фондына керергә рөхсәт итүләрен үтенеп Ленин райкомы секретаре исеменә язылган хат иде.

Әмма, материал жыелып беткәч, аны эш арасында, урык-сурык йөреп кенә, ыгы-зыгылы тулай торак бүлмәсендә генә ерып чыгу, игә-чөйгә китерү мөмкин булмастыр кебек тоелды. Диплом эше житәкчесенең фикеренә колак салып, егет «Казанга терәлеп кенә торган Васильево бистәсенә — Ял йортына путёвка алырга кирәк булыр» дигән нәтижәгә килде.

Җәмәгать эшенә килгәндә исә, рәис булмаса да, аңа төзелеш комитетының торак-көнкүреш комиссиясенә житәкчелек итү вазифасын йөкләделәр. Чөнки Габделнурның бу өлкәдә тәжрибәсе житәрлек иде инде.

## 10

Габделнур гашыйк булды.

Ел фасылларының һәркайсының үз яме бар. Дөрес, күпчелек кеше язны һәм җәйне ярата төшә. Ә, бактың исә, кышның да үз матурлыгы, җанга яз һәм җәй айлары бирми торган рәхәтлеге бар: бөтен жир өсте ак юрганга төренә, кырлар, елга-күл өсләре, авыл-шәһәрләр агара-чистара; иртән барча тарафны нурга манып кызгылт кояш чыкканда, күкрәк тутырып, салкынча саф һава сулыйсың; аяз көннәрдә күк йөзе гажәеп зәңгәр төскә керә, агач-куакларда, күзне чагылдырып, энжедәй кар бөртекләре җемелди, кыскасы, күңел күзен сукыраймаган булса, сокланып карарлык матурлык кыш көне дә житәрлек.

Гадәттә, җан ияләрендә яз көне тормышны дәвам итү теләге, яшәү дәрте уяна, диләр. Ә елның бүтән фасылларында тереклек итү тукталамыни? Һич юк! Бигрәк тә кешеләрдә. Адәм баласы өнендә бөгәрләнеп кышкы тирән йокыга талган аю түгел. Ул яши: тойгылары уяу, бүтәннәр белән бәйләнешы өзелми, уй-хисләре дә торгынлык кичерми, сөю-сәгадәт мәлләре тукталмый.

Менә шулардан чыгып фикер йөрткәндә, Габделнурның нәкъ кыш ахырында гашыйк булуы бер дә гаҗәп түгел.

Кышкы имтиханнар сессиясенә туры китереп, алдан хәстәрен күреп, ул трестның санаторий-профилакториена юллама алды. Анда күбрәк сырхаулар бара. Ләкин төзелеш комитетында егетнең дә хәленә керделәр — укуын тәгәллисе ел икәнен беләләр иде. Монда рәхәт: өч тапкыр шәп итеп ашаталар, чирең булса дәвалыйлар, кыскасы, ашау — байдан, үлем — Ходайдан, дип кенә ятасы.

Ул көндез ательега барырга җыенды. Җәйгә заманча иттереп — кесәләре алда, балаклары киң чалбар тектермәкче иде. Әмма, Гагарин урамыннан түбән төшеп, тукталышта сәгатенә карагач, сулга борылып китте. Китап кибетенә керде. Киштәләргә күз йөртеп чыкты. Ләкин аһ итәрдәй яңа нәрсә күрмәде.

Урамда гадәти тормыш: сирәк-мирәк машиналар, трамвай-троллейбуслар үткәли. Бер мотороллер пытырдап узды, велосипедка атланган үсмер чаба, кешеләр каядыр ашыга. Бар җиһанны яктырткан кояш нурларында кар бөртекләре энҗедәй җемелди, аяк асты шыгыр-шыгыр итә, озын күләгәләр сузыла. Нииндидер сихри көчкә ия матур кышкы көн.

Трамвай килде. Егет башта бер картка юл бирде, аннары ашыга-кабалана килеп җиткән бер хатын-кызны алдан үткәреп җибәрде, үзе аның артыннан керде. Мамык шәл бәйләгән әлеге хатын-кыз алга узмады, артта басып калды һәм борылды. Трамвайга менгәндә, егет аның йөзен юньләп күрмәгән иде. Башын күтәреп карагач, туктап хәйран калды: бит алмалары янып торган яшь кыз икән бит бу. Егет кулы белән өстәге тимер торбага тотынды һәм... йөрәген нидер сызып үткән кебек булды — кызга карап катып калды: калын кара кашлы, түгәрәк алсу йөзле, калынча алсу иренле кыз бик мөлаем иде. Югыйсә кигән киеме дә бик гади: башында йоннары күпереп торган көрән төстәге шәл, өстендә түгәрәк аксыл якалы зәңгәр кышкы пальто, кулында мамык бияләй.

Алар янына кондуктор килеп басты. Габделнур һушын җыеп өлгергән иде инде, үзенең егет кеше икәне исенә төште, кызга мөрәҗәгать итеп:

– Миңа билет алмагыз, — диде һәм, елмаеп, кондукторга акча сузды. — Ике билет.

– Берсе кемгә?

Габделнур алга карап ияк какты.

Кыз:

– Мин үзем алам, — диде һәм, бияләен салып, уң кулын кесәсенә тыкты.

Урта яшьләрдәге кондуктор хатын — дөнья күргән кеше:

– Ярар, аннан гына бөлмәс әле, сыйлаганда су эч, — дип, ике билет ертты да берсен — кызга, икенчесен Габделнурга сузды. — Егет фартавой күренә, эләктереп кал.

Кыз җавап кайтармады, оялып, башын аска иде, кулындагы билетны карады.

Габделнур елмаеп сорады:

– Бәхетлеме?

– Юк, — диде кыз тыныч кына.

Аның тавышында уфтану-борчылу да, кемгәдер үпкә-шелтә дә юк иде. Чөнки моның гадәти нәрсә — шаярту гына икәнен икесе дә яхшы беләләр.

Аның бит үзенә күрә йоласы да бар: саннар туры килеп, «бәхетле» билет эләксә, кайберәүләр аны чәйнәп йотарга да күп сорамый.

Габделнур кызны юаткан булды:

— Ярар, кайгырмагыз, бәхетле билет эләгү ул әле череп баю дигән сүз түгел. Ходай иман байлыгы бирсен, дип әйтә торган иде минем әби.

Кыз, башын күтәреп, үзенең яшькелт-зәңгәр төстәге зур күзләре белән егеткә карады, аннары, оялып, карашын читкә юнәлтте. Ә Габделнурга, кем әйтмешли, Ходай тел ачкычы бирде: гадәттә кызлар-егетләр арасында була торган әңгәмә башланды. Хәер, күбрәк ул сөйләде, ә гәптәше, әйе, юк, шулай, диебрәк, бер сүз белән генә җавап кайтара: йә аның фикере белән ризалаша, йә кире кага. Егет аңа туры карый, кыз да кайчагында кыяр-кыймас кына күзләрен тутырып карап ала да аннан башын читкә бора; әмма баскан урыныннан китми. Алар трамвайдагы кешеләр сөйләшкәнне дә ишетми, туктап торган арада кергән-чыккан пассажирларда да гамьнәре юк. Егет кызның алсу йөзенә, кул тимәгән кара кашларына, өскесе аскысына караганда чак кына югарак сыман күренгән, тулышып торган, иннек якмаган алсу иреннәренә һәм сүз әйткәндә күренеп киткән ап-ак тешләренә күз салып ала. Андый мизгелләрдә кыз ояла, аска карый, кулындагы билетын бөтәрли. Аңа карап егет үзе дә каушый төшә иде.

Трамвай «Мәктәп» тукталышына җитәр алдыннан, кыз кузгалды. Егет, алдан төшеп, аңа кул сузды (баскычтан ир-ат алдан төшәргә, ә менгәндә киресенчә кирәген егет үзләштергән иде инде). Ләкин аның кулы һавада асылынып калды.

— Рәхмәт!

Булышырга теләп тәкъдим иткән өчен булдымы бу рәхмәт, билет өченме, әллә бергә-бергә күңелле итеп сөйләшеп килгән өченме — егет аңышмады. Хәер, моның әллә ни әһәмияте дә юк иде. Егетнең сузылган кулына бер әби ябышып төште.

— Рәхмәт, балам, игелек күр!

Ул арада кыз юл аркылы чыккан иде инде, кыска кунычлы кара сапожки кигән матур аяклары белән тиз-тиз атлап ераклаша башлады.

Габделнур урыныннан кузгалырга кирәген дә онытып басып калды. Бераздан исенә килде һәм, юл аркылы чыгып, йөгерә-атлый кызны куып җитте. Чөнки ул үзен нәрсәдер югалтыр сыман тойды.

— Мин сезне озатам, — диде егет, үзенең кыюлыгына үзе аптырап. — Өч тиенлек билет алды да хәзер шуннан файдаланмакчы була дип әйтмәсәгез...

— Юк, әйтмим...

— Рәхмәт! — диде егет, һәм тагын бик сирәк әйтелә торган сүзләр теленә килде: — Сезнең күзләрегез миңа бик ошады.

Дөресен генә әйткәндә, ул атап кына кызның кай төше ошаганын да белми иде, теленә килгәнне генә әйтте. Ләкин кызның аңа ошавы хак иде.

Кыз, барган уңайга башын борып, егеткә карады, оялды.

— Мин туганнарыма барам. Бик срочно.

— Миңа тиз генә ательега кереп чыгарга кирәк. Әллә башта шунда барып киләбезме? Аннары сезнекеләргә.

— Юк, — диде кыз, кистереп, әмма тавышында ачулану юк иде. — Мин ашыгам. Ә сез барыгыз.

— Мин сезне югалтырмын дип куркам. Сез аннан соң кая барасыз?

Бу инде юлда очраган чит кешегә бәйләнү кебегрәк булса да, егет тыелып кала алмады. Чит кешесен чит кеше дә, ләкин ул яшь кыз бит, ә Габделнур — яшь егет. Кыз да моны дөрес аңлады булса кирәк, ачуы чыкмады.

— Кире кайтам.

– Алайса, остановкада очрашыйк. — Егет сәгатенә карады. — Ну бер егерме минуттан.

– Минем сәгатем юк, тагарга онытканмын.

– Мәгез минекен!

– Юк, кирәкми. Ә сез барыгыз барасы җирегезгә.

– Тәки бәйләнде дип әйтмәсәгез, тагын бер сорау бирим инде.

– Бирегез.

– Ә сез анда озак торасызмы?

– Юк.

– Алайса, мин сезне монда көтәрмен.

Кыз туктады, сизелер-сизелмәс кенә иңнәрен сикерткәндәй итте һәм бер сүз әйтмичә китеп тә барды.

Егет, аның пальто аша да сизелеп торган зифа буй-сынына карап беркавым тын торгач, тукталышка таба атлады. Урам аша чыгып көтә башлады, ательега бармаска булды. Бу тирәдә, шәһәр уртасы булуга карамастан, кешеләр үз йорты белән яши. Өйләрнең түбәләре кар белән капланган, морҗалардан төтен күтәрелә — гел авылча. Йортларның беришләре такта белән тышланган. Тышланмаганнарының бүрәнәләре каралган. Йортларның тәрәзәләре зур, урам якта өчәр. Капка-коймалары төрле төсләргә буялган. Бакчалардагы биек алмагачлар ышыгында сирәк-мирәк кызыл тәлгәшләре сакланган миләш һәм балан агачлары күренә. Капка төпләре көрәлгән, кардан арындырылган, бәләкәй капкаларга, турылап, олы юлдан сукмаклар салынган. Бу йортлардан арырак ике катлы озын таш бина — военкомат, ә тагы да өскә күтәрелсәк, наратлыкка килеп чыгасың. Каршы якта өч катлы мәктәп бинасы һәм унда унике катлы ак йортлар.

Зәңгәр күк йөзендә сирәк-мирәк күперенке ак болытлар йөзә. Бөтен җиһанга нурлы кояшның яктысы таралган: агачлардагы бәс тә, җирдәге кар да — барысы да җем-җем итә. Әйтерсең лә кыш уртасы түгел, ә ямьле җәй көне — кояш егетнең аркасын җылыткандай тоелды. «Нинди сихри көн соң бу?!» — дип уйлады ул, агачларда чыркылдашкан песнәк һәм чыпчыкларга карап. Алар, хуҗалары җыймыйча калдырган (бәлки, махсус шулай иткәннәрдер) миләш агачында мәш киләләр иде. Бөтен җиһанга яктылык сирпүче күктәге саргылт кояш нурына алар да сөенә иде булса кирәк.

Еpактагы биек агачлар ягыннан кошлар сайраганы ишетелде. Алар берөзлексез чутылдатып сайрамыйлар, шулай да сирәк-мирәк бер-беренә дәшәләр — үзләренә пар эзлиләр. Пар дигәннән, әнә бер ихата каршында яфраклары коздән коелып беткән ике каен үсә, алар, бер-берсенә сыенып, озын карасу чукларын салындырып, тын гына утыралар: яз килүен, бөреләре бүртеп, яфрак ярып, яшеллеккә төренер чакларын сабыр гына көтәләр.

Бераздан кызның бирегә таба килгәне күренде. Егет аның зәңгәр пальтосын еpактан ук танып алды. Ул, шәһәр кызлары кебек, кулларын як-якка җәеп кәттә түгел, ә гәүдәсен авылчарак тотып, әмма үзенә бертөрле килешле йөреш белән, матур аякларын тигез басып, ныклы адымнар белән килә иде. Башындагы мамык шәле дә аны олысымак итми, ә йөзенә бик килешеп, ямь биреп торган кебек: ак якасы аның каратут йөзен ачып җибәрә сыман. Кыскасы, егет кызның үзе генә түгел, хәтта кигән киеме, кул һәм аяк хәрәкәтләре — барысы да күңеленә ятышлы икәнен тойды. Ул аның мамык бияләй эчендәге кулларының да җылылыгын тоя иде шикелле. «Килә!» — дип авыз эченнән генә пышылдаганын егет сизми дә калды. Дөресен генә әйткәндә, исеме дә билгеле булмаган бу гүзәлнең килүенә, аның белән кабат күрешә алуына егет әллә ни өмет тә итмәгән иде. Ләкин күңел түрендә ниндидер бер чаткы кабынып-кабынып киткән кебек була, һәм шул чаткы аңа ышаныч, кызның, һичшиксез, тукталышка киләчәгенә

өмет итәргә көч бирә иде. Кыз ана таба якынлашкан саен, ул йөрәгенең леп-леп итеп ешрак тибүен сизде, чәч һәм уч төпләре тирләгәндәй тоелды, ана каршы йөгереп барудан ул үзен-үзе көчкә генә тыеп тора алды, ирексездән иреннәре язылып китте — елмайды, сөенечтән авызы ерылды. Сәер хәл иде бу яше егерме сигезгә житкән егет өчен. Әйе, бу анын белән сирәк була торган, соңгы елларда, гомумән, ул кичермәгән үзгә бер халәт иде.

Трамвайга утырдылар. Егет үзенең кайда эшләвен һәм яшәвен әйтте, нинди һөнәр иясе икәнен ул жыр тексты белән белдерде:

— «Без кабызган утлар сүнмәс алар, Сүнмәс алар хәтәр жилләрдә» дигән жырны ишеткәнегез бармы?

— Әйе.

— Безнең турыда чыгарылган жыр. Без дөньяны яктырак итәбез.

— Аңладым.

— Урта гасырларда яшәгән атаклы гуманист Эразм Роттердамский, анын әле «Ахмаклыкка мактау» дигән китабы да бар, болай дигән: «Яктылык бүләк ит, һәм карангылык үзеннән-үзе юкка чыгар».

— Анысы да сезнең турыдамы?

— Юк. Ул чорда әле электричество булмаган. Искә төшкәч кенә әйттем. Безнең үзебез чыгарган гыйбарә дә бар: «Яктылык булсын, дип әйтте электрик һәм шырпы сызды».

Кыз елмайды һәм кайда яшәвен әйтте. Ул да Габделнурлардан әллә ни ерак түгел — Октябрь урамындагы тулай торакта яши икән. Заводта лаборант булып эшләвен дә яшермәде.

Егет кайсы завод дип төпченмәде. Кирәк дип санаса, кеше үзе әйтәчәген ул яхшы белә. Шуна күрә хәтта исемен дә сорамады. Беренче минутлардан ук аптыратсаң, желегенә төшсәң, кызлар шаяртырга, ялганларга да күп сорамый ич. «Һәрнәрсәнең үз вакыты, жае бар», — дип уй йөртте егет. Кыз турында аның күбрәк беләсе килә иде. Ләкин болар — киләчәк эше.

Сүз иярә сүз чыкты: табигать, спорт һәм ана бәйле рәвештә төрле шәһәрләр телгә алынды.

— Рим — мәңгелек шәһәр. Ана бик күпләр сокланган. Немец шагыйре Гёте: «Римда булган кеше — аз булса да бәхетле», — дип әйткән. Ә Париж турында шундый гыйбарә йөри: «Парижны күрергә һәм үләргә».

— Ни өчен?

— Чөнки ул — дөньядагы иң матур шәһәрләрнең берсе. Анын символы булган Эйфель башнясы үзе генә ни тора! Ә Лувр! Ул Мәскәүнең Третьяков галереясыннан һәм Ленинградтагы Эрмитаждан да бай. Анда дөнья рәссамнарының иң мәшһүр картиналары саклана, шул исәптән Леонардо да Винчинын «Мона Лиза»сы...

Монда инде Габделнур үз стихиясендә иде — колач салып йөзде. Чөнки рәсем сәнгатен үз итә, бик күп рәссамнарны һәм аларнын эшләрен белә, алар турында фикер йөртә һәм белгәне белән уртаклашырга ярата. Аннары сүз бу арада укыган газеталардагы яналыкларга күчте. Ахырда егет кызның тавышына игътибар итте:

— Сезнең тамак авыртамы әллә?

— Әйе.

— Жылытып, сөт эчегез.

— Беләм, — диде кыз. — Бу бит — әбиләр рецепты.

Көлештеләр.

— Сезгә үзем генә сөт жылытып эчерер идем дә, тәртипләр катыдыр — кертмәсләр шул, вакытым да тар, — диде егет, елмаеп. — Минем иртәгә

консультация, ә берсекөнгә экзамен. Бик авыр фән — «Дәүләт һәм хокук». Тарих бүлегендә ул фәннең нигә кирәге бардыр?!

— Сез кайда укыйсыз?

Егет әйтте.

— О-о, — диде кыз, сокланып. — Көнләшәм укыган кешеләрдән.

— Ә сез укымыйсызмы?

— Юк. Кереп булмады. Укытучы буласым килгән иде, керә алмадым. Ә бүтән вузга күңел тартмады.

Кайберәүләр, фәлән фәнне тапшырганда, имтихан алучы артык катлаулы сораулар бирде, юри батырырга тырышты, дип әйтүчән булалар. Ә монда кыз фәкать үзен генә гаепле санады шикелле. Көнләшүе дә ак көнләшү иде булса кирәк. Болар берсе дә егетнең игътибарыннан читтә калмады.

«Воровский» тукталышында трамвайдан төшкәндә, кыз Габделнурның сузган кулына чак кына кагылып алды, рәхмәтен әйтергә дә онытмады. Почмакта, «Көз» кафесы каршында, кыз туктады.

— Моннан үзем генә кайтам, — диде ул. — Озатмагыз.

— Кемнән куркасыз? Әти-әниегез монда юктыр бит, кунакка килмәгәннәрдер?

— Юк. Әнием авылда, өй ташлап, кунакта йөрергә вакыты юк. Әтием күптән вафат.

— Гафу итегез. — Егет уңайсызланды, шулай да беравык тын торгач әйтте: — Минем тарафтан әрсезлек була инде бу, шулай да сезне кинога чакырасым килә. Кич белән Урицкий клубына килә алмыйсызмы? Сәгать жидегә. Тамагыгыз бик авыртмаса...

Кыз уйга калды. Егеткә күтәрелеп карады. Бу юлы аның карашы трамвайда беренче минутларындагы кебек юаш, оялчан түгел, ә үткен, сынаулы иде. Аларның күз карашлары очрашты, һәм әнә шул мизгел барысын да аңлатты кебек. Чөнки кыз егетнең күгелҗем күзләрендә соклану катыш ялвару күрде. Аның да күңел түрендә ниндидер нечкә бер кыл чиерткән кебек булды, әйтерсең тибрәлеп куйды. Каракүл якалы кышкы пальто, «Москвич» бүрек кигән, яшькелт шарф буган, озын буйлы, ябык чырайлы бу егет аның күңелендә ышаныч уятты булса кирәк. Чакыруы да ихластан шикелле.

Кыз ризалык белдереп баш какты.

Габделнур кичке ашка алданрак керде дә, тиз-тиз тамак ялгап, урамга чыкты. Гаҗәеп матур, җилсез кич иде. Шифаханә-профилакторийның дүрт катлы бинасы (Урицкий исемендәге Мәдәният сарае белән янәшә) артындагы нарат агачлары монсуланып утыралар, ә бакчадагы чыршыларның ботакларын кар сарган. Икесе җитәкләшеп барган кыз белән егет кебек — берсе калкурак, ботаклары да эрерәк, янәшәдәгесе чак кына тәбәнәгрәк һәм нәфисрәк.

Килерме, юкмы? Дөресен генә әйткәндә, егет кызның килүенә бик ышанып та житми иде. Юк, алдар дип уйлаудан түгел, ә сырхаулап торуыннан, шуның аркасында килмәү ихтималыннан шикләнә. Шулай да, өметсез — шайтан гына, дип, үзен дәртләндереп, алдан ук билет алып куйды. Мәдәният йорты каршында баскычта көтә дә башлады.

Халык берән-сәрән дә, парлап та, күмәкләшеп тә агыла, суыктан куркып тормый. Егетнең дә аягында җылы ботинка, туңарлык түгел — кышның салкынлыгы сизелми. Сәгатенә карап алды. Келт-келт иткәне колакка ишетелмәсә дә, ул үз эшен эшли — секундларны, санап, минутларга әйләндерә... И-и, ул кыз киләсе юлдан күзең алмыйча көтүләр... Кемнәр генә тилмермәгән ялыктыргыч минутларны санап!..

Тупыл, каен, чыршы-нарат аралашып үскән бакча артында ике катлы таш йортлар тезелеп киткән. Әнә шуларның берсе почмакта — урам чатында — ә

аннан арырак урнашкан өч катлы кызыл йорт каршында зәңгәр пальто күренде. Габделнур кызны әнә шулай ерактан ук шәйләп алды. Йа Хода! Килә! Күптән аның сабый баладай сөенгәне, кыз-кыркын күреп, шатлыктан йөрәгенен дәртләнеп типкәне юк иде. Беренче уе: Мәдәният йортының нык алга чыккан козырёгын терәтеп торучы ике юан колоннаның берсе артына качу иде. Бу балаларча уйның ничек башына килүенә аптырап, үзе үк көлеп җибәрде һәм түзмәде — ике атлап бер сикерүдә баскычтан төште дә кыз каршына китте. Көндез күреп калган шул ук матур, нурлы йөз! Шул ук буй-сынына килешеп торган кием! Хәер, киемендә бер үзгәреш бар икән — башында көрән төстәге түгәрәк чәшке бүрек, анысы да яннан чыгып торган кара чәчләрен чак кына күрсәтеп, йөзенә килешеп тора.

— Хәерле кич!

— Исәнмесез! — диде кыз тыйнак кына.

Икесе дә елмайдылар. Хәл белештеләр. Сөйләшә-сөйләшә, залга керделәр. Кыз туңдырмадан баш тартты, конфет та алдырмады. Бераздан ут сүнде, гадәттәгечә, әүвәл киножурнал булды, аннары «Секретная миссия» дигән фильм үзе башланды. Кызыклы гына икән, эчтәлеге дә ярыйсы, артистларның уены икесенә дә ошады. Күзе экранда булса да, егет үзенең кем белән янәшә утыруын онытмады, сирәк-мирәк сүз дә каткалады. Әмма кулына ирек бирмәде — кызга бөтенләй кагылмады.

Кинодан чыккач:

— Хәзер танышсак та була инде, — диде егет һәм исемен әйтте.

— Ә мин — Гөлзәрия.

— Бу — өч көн торгач, исәнме, кодагый, дигән сыманрак инде.

— Зыян юк, — диде кыз.

Алар, халык ташкынына ияреп, Королёв урамыннан түбән таба төшеп киттеләр.

Бу тирәдәге урам исемнәре космонавтикага бәйле булганлыктан, егет шуңа кагылышлы темага сүз кузгатты:

— Менә параллель урам элек Урицкий исемен йөртә иде.

— Беләм.

— Алтмыш жиденче елны, август аенда, Казанда совет-япон дуслыгы фестивале узды бит.

— Хәтерлим.

— Гагарин да килгән иде. Ул шунда «Идел» яшьләр лагеренда, аннары циркта, Соцгородтагы Пионерлар һәм яңа ачылган Спорт сарайларында булды.

— Ул чакта бөтен Казан шау-гөр килде инде. Безнең дә аны бик күрәсе килгән иде дә, насыйп кына булмады.

— Теге урамга аның исеме шул елны бирелде бит. Гагарин татарларны бик яраткан икән.

— Ни өчен?

— Аны очучылыкка өйрәтүче инструкторы татар кешесе була. Хәтта космостан җиргә төшкәч тә, аның беренче күргән кешеләре татарлар була.

— Ул бит Саратов өлкәсендәге бер авыл читенә, басуга төшә. Анда татарлар бармыни?

— Дөньяда татар булмаган җир юк, — диде егет һәм дәвам итте: — Саратовка килсәк, ул үзе дә Сары тау дигәнне аңлата икән. Армиядә теге авылдан бер егет бар иде, безгә шул сөйләде. Бер әби белән оныкасы бәрәңге утырта икән. Шулвакыт һавада парашют төшә: берсендә — зур шар, икенчесендә — кеше. Карчык куркып кала, китәргә итенә, ә оныгы, алты яшьлек Румия исемле кыз, әби, ул бит русча сөйләшә, ди. Әбисенең исеме хәтердән чыккан инде, әллә Әминә, әллә Хәят, дигән иде теге егет.

– Әби Гагаринны немец дип уйлады микәнни?

Икесе дә елмайдылар.

– Гагарин үзенең истәлекләрендә ул кызны ни өчендер «Рита» дип атаган. Мөгаен, аны редактор төзәткәндер...

– Нигә?

– Татарларны күрсәтмәс өчен.

Аннары егет авиациягә күчте. Чөнки Мәдәният йорты моторлар төзү заводына карый, ә урамның уң ягындагы бер катлы затлы өйләр сугыш вакытында безнең калага эвакуацияләнгән заводларның инженер-техник хезмәткәрләре өчен салынган, дип ишеткәне бар иде.

Сулга борылып, китап кибете яныннан узганда, ул соңгы вакытта укыган татар китапларын искә алды.

– Бу арада Галимҗан Ибраһимовның өч томлыгын кулга төшердем. «Яшь йөрәкләр»е шигырь кебек. Аның бер җөмләсен дә, бер сүзен дә алып ташлап булмый. Янгырашы гаҗәеп. Ә «Казакъ кызы» казакълар тормышы турында. Чөнки ул үзе, шул якларда казакъ балаларын укытып, мулдәкә булып йөргән.

– Без кызлар белән Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ен кулдан кулга йөртеп укыдык. Бик романтичный язылган.

– Әйе, җинел укыла. Китапның да төрлесе бар бит. Әгәр начар китап булса, аның артыннан тәмле чәй эчкәч, авызда чәй тәме генә кала. Ә яхшы китапның «тәме» озак тора, эчтәлеге бөтен нечкәлекләре белән хәтердә саклана...

Аннары егет театрларга кагылып үтте:

– Узган атнада «Шамил Усманов»ны карадым, әле «Гөлҗәннәтнең җәннәте»нә дә барырга исәп, җай чыкса, — диде егет һәм елмайды. — Нинди була икән ул җәннәт, күргән нәрсә түгел бит.

Кыз, аптырап:

– Сез бөтенесенә ничек өлгерәсез? — дип сорады.

Егет сүзне уенга борды:

– Ә мин, жираф кебек, тәүлегенә ике генә сәгать йоклыйм.

– Алар шуңа озын булып үсте микәнни? — диде кыз да, елмаеп.

– Юктыр. Алар өчен озын буйның үзенә күрә уңайлы яклары бар: алты метр биеклектән яфрак өзеп ашый алалар. Дөрес, аларга елгадан су эчү кыенрак. Ә менә кечкенә буйлыларга читен, — диде егет һәм университетта этнографиядән лекция тыңлаганда ишеткәннәрен уртаклашты: — Яңа Гвинеяда пигмей кабиләләре бар, аларның иң озын ир-аты да метр ярымнан артмый икән. Шулай да алар бик оста аучылар, хәтта филләрне дә үтерәләр. Гәрчә бөтен кораллары сөңге, арбалет һәм балтадан гына гыйбарәт булса да...

Кыз урамнарына житкәч тә нишләптер уңга борылмады, юлын дәвам итте. Ләкин егет дәшмәде. Тагын бераз баргач кына, кыз уңга каерды.

– Әнә безнең өй, — диде ул, ике катлы йортлар арасында калкып торган биек бинага ымлап.

П хәрефе рәвешендәге биш катлы кирпеч йорт. Каршыда зур мәйдан — бала-чага өчен корылган таганнар, зур «гөмбә»ләр, таучыклар...

Тулай торак янына кайтып житкәч, Габделнурның исәбе авырып торган кызны урамда озак тотмаска иде. Ләкин тоткарлык килеп чыкты.

Почмакта, ишек төбендә, кыска пальто кигән колгасар бер егет басып тора иде. Боларны күргәч, алларына килеп басты.

– Гөлзәрия, сиңа сүзем бар иде, — диде ул.

Кыз кистереп әйтте:

– Мин сине кисәттем бит: исерекләрне женем сөйми, килмә кабат, дидем.

— Юк, бүген эчмәдем, — диде егет, юаш кына акланып.

Мона артык сүз боткасы куертырга ирек бирмәс өчен, Габделнур дилбегәне шундук үз кулына алырга булды:

— Энекәш...

Ләкин егет ана сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

— Син кайчан минем абый булдың әле? Минем синен шикелле абыйларым Кытайда бер миллиард.

Габделнур ирен чите белән генә елмайды:

— Ярар, иптәш, диярмен, алайса.

— Тамбовның соры бүресе сина иптәш.

— Һәй, күрәм, син бик төксе сөйләшәсен әле, дус кеше. Нәрсә, тел чарлыйсың киләмени? Ниме, син ерак торасыңмы?

Егет бу юлы Габделнурның тел төбен анламады булса кирәк.

— Шактый ерак.

— Бар, алайса, өенә кайт, пока транспорт йөри.

Чандыр гәүдәле егетнен исәбе бүтәнчәрәк иде, ахры, һаман кирегә сукалады:

— Син кем булдың әле мине өйрәтергә? Теләсәм — кайтам, теләмәсәм — юк, — дип кәжәләнеп маташты һәм кызга карап әйтте: — Ул — минем йөргән кызым.

Анын бу сүзләре Гөлзәриянен күнеленә ятмады, ачуы чыкты:

— Нишләп мин синен белән йөрим ди әле? Бер озаттың. Кабат килмәскә куштым.

Габделнур нечкә-озын егетне пальто җиненнән чеметеп тотты:

— Әйдәле, энекәш, читкәрәк.

Кыз, ялынып:

— Зинһар, тимәгез! — диде. — Тавыш чыгармагыз.

— Борчылмагыз.

Кайбер егетләр кызлар алдында әтәчләнергә, сырт кабартырга ярата. Ләкин Габделнурның, көч-куәте ташып торса да, андый яман гадәте юк иде. Беренче көнне үк (бигрәк тә күнеленә ошаган кеше алдында) үзен сугыш чукмары итеп танытасы, анын алдында ятышсыз сүзләр әйтеп ямьсезләнәсе, кызның кәефен төшерәсе, үзеннән гайрәтен чигерәсе килми иде. Шуна күрә ул, гайрәт ормыйча, мәсьәләне ничек тә тавыш-тынсыз гына хәл итү ягын карады.

— Әйдә, башта танышыйк, — диде ул егеткә һәм, үз исемен әйтеп, кулын сузды.

Теге кулын биргүгә, анын бармакларын шундый итеп кысты ки... мескен исемен дә әйтә алмыйча калды.

— Ы-ы, — дигән аваз гына чыкты.

Габделнур, кызга таба борылып:

— Без сөйләшәбез генә, — диде һәм йорт почмагында, кызга ишетелмәслек итеп әйтте: — Энекәш, синен «хук», «джеб», «апперкот» дигән сүзләрне ишеткәнен бармы?

— Юк.

— Болар — боксёрлар бәргәләшкәндә кулланыла торган бокс алымнары. Безгә сугышырга ярамый, канишны, юкса спорт секциясеннән куалар. Ну әгәр бик теләсән, күрсәтә алам...

Калай әтәчнен кикриге шиндe. Ул һәр сүзендә ныклык, үз-үзенә ышаныч бәреп торган Габделнурга күтәрелеп карады. Күренеп тора, бу егет — йә әле күптән түгел генә авылдан килгән, йә шәһәрдә әнисе тәрбиясендә генә үскән йомшак әлләзи.

— Юк, кирәкми, — диде ул күндәм генә.

— Ярый, алайса, матур гына аерылышыйк, мә бишне, — дип, Габделнур егеткә уң кулын сузды һәм тагын бөтен көченә аның озын сыек бармакларын кысты.

Теге чак астына җибәрмәде һәм, башын иеп, саубуллашмыйча да китеп барды.

Янына килгәч, кыз Габделнурдан:

— Сез аңа ни әйттегез? — дип сорады.

Егетнең җавабы кыска булды:

— Саубуллаштым гына.

Кыз бу юлы аңа ышанмады, билгеле. Ләкин тулай торак каршында тавыш чыгармавына рәхмәтле иде. Шуңа күрә сүз озайтмады. Габделнур да, әлеге конфликтны беткәнгә санап, бу темага сүз куертмады. Кем булды ул егет, кай тарафтан килеп чыккан, кайда танышканнар, кызга нинди мөнәсәбәте бар — берни дә сорашмады. Кирәк дип санаса, кыз үзе әйтер иде. Дәшми. Димәк, аның тормышында ул кешенең бернинди әһәмияте юк дип уйларга гына кала.

— Тагын кайчан очрашабыз? — дип сорады Габделнур. — Бу араларда сезне борчыйсым да килми, өзләгә күрмәгез. Шулай да ике-өч көннән мөмкинме?

— Ярый.

— Алайса, «Җәннәт»не карарга бергә барырбыз. Җылы сөт эчәргә онытмагыз. Тыныч йокы.

— Сезгә дә тыныч йокы, — диде кыз.

Елмаешып аерылыштылар.

Гөлзәрия салмак адымнар белән, егетнең үзенә текәлгән карашын бөтен барлыгы белән тойган хәлдә, тулай торакка таба атлады. Хәзерге минутларда бу асыл зат йомшак озын толымнарының Габделнур атлы егетнең кыска каты чәченә гомерлеккә бәйләнәсен әле белми иде...

Егет, кая басканын да тоймыйча, теленә килгән беренче дәртле җырны авыз эченнән көйли-көйли китеп барды. Тулай торагына кайтасы иде, ләкин шифаханә-профилакторийда икәне исенә төшеп, Гагарин урамыннан өскә таба менеп китте.

## 11

Габделнур Мәһрүсә апаларына китте. Юл уңаенда, кибетләргә сугылып, күчтәнәч тә алды. Авылда яшәүче апасы Гөлсылу аңа балаларына киемсалым алырга заказ биргән иде. Егет, үз зәвыгына гына ышанмыйча, бу хакта Мәһрүсә апасына ирештерде. Ул бик теләп риза булды, чөнки пенсиядәге кешенең вакыты да күп, хатын-кыз буларак та ни-нәрсә аласын яхшы белә.

Егет Мәһрүсә апаларында озак юанмады, йомышын йомышлап, рәхмәт әйтеп китәргә җыенды.

Сеңлесе Линүзә дә өстенә киенә башлады.

Мәһрүсә апа:

— Кызым, кая барасың? — дип сорады.

— Габделнур абыйны озата чыгам.

Линүзәнең абыйсы белән күзгә-күз каласы килә иде бугай. Гадәттәгечә шат күңелле түгел иде ул. Боек, карашы моңсу.

Подъезд төбендә корсаклы яшь кенә хатын очрады. Ул Линүзәнең ишектән чыкканын күреп туктады, елмаеп күреште. Алар авызга авыз куеп серләшкәндә, егет читкәрәк китеп торды. Бераздан ахирәтләр аерылыштылар.

— Безнен йортта, күрше подъездда яши ул, — диде сеңлесе һәм тегене шелтәләп тә алды: — Узган ел КАИдан бер студентка кияүгә чыкты. Ирен гел битәрли, көнләшә, теләсә ничек сүгә. Ә үзе ана чыкканчы хатын иде инде, унҗиде яшендә үк аборт ясатты. Ә икенче иптәш кызым, татар кызы, анысы да кияүгә чыкты. Яшертен генә чиркәүгә алып барып, муенына тәре тагып кайтарганнар.

— Әти-әнисе риза булганмыни?

— Ничек риза булсыннар инде! Бик каты каргаганнар, йөрешмиләр дә.

— Балалары булгач, бәгырьләре йомшар да килешерләр әле, баламның баласы балдан татлы, диләр бит.

— Кем белә инде аны.

— Әйе. Бәлки, балаларын тирбәткәндә, иптәш кызының әнисе, и Аллаһу, Аллаһу, газраил, ал да шу, дип көйләр.

— Анысы ни аңлата? — дип сорады сеңлесе, Габделнурның елмайганын күреп.

— Яртылаш чит кавем баласын шулай итеп тирбәткән ди бер әби, безнең авылда маржага өйләнгән бер егетнең анасы... Ә кыз үзе ни ди соң?

— Люблю, ди, не могу без него жить, ди. Алар садиктан ук бер-берсен беләләр иде, бергә укыдылар. Каенанасы тәресен салдырмый икән, бик диндар карчык, гел кара күлмәк киеп, кара яулык бәйләп йөри, атна саен Бауман урамына чиркәүгә бара. Ә кыз хәзер муенын каплап йөри.

Аннары сеңлесе күрше-тирәдәге егетләр турында сөйләп алды, чөнки аның белән бер егет исәнләшеп үтте. Үзенең дә егете бар икән, шул хакта әйткәч, кызарды.

— Ә синеке татармы соң? — дип сорады Габделнур.

— Ие. Ату мине әни үтерә. Бәләкәйдән үк әйтә килде.

— Эшең ничек соң? Әйбәтме?

— Әйе.

Линүзә, техникум бетергәч, Ершов урамындагы бик дәрәҗәле «Татнииинефтемаш» фәнни-тикшеренү институтына урнашкан иде.

— Габделнур абый, мин ул эшне яратмыйм икән.

— Нишләп? Нефть белән бәйле бит, перспективасы бар.

— Шулаен шулай да... — диде кыз уйчан гына, алар арка астыннан озын йортның икенче ягына — Жданов урамына чыкканнар иде инде, ары киттеләр. — Мин кечкенәдән бию түгәрәгенә йөргән идем. Балерина буласым килгән иде. Кая инде безгә андыйга үрелергә. Ә бала чактагы хыял калды. Бәлки, быел Мәдәният институтына керермен әле, хореографлыкка укырга.

— Үзең беләсең инде. Бөтен хыяллар да тормышка ашмый бит ул. Мин дә очучы булырга кызыга идем.

— Сөйләгәнең бар иде шул, — диде сеңлесе, аннары йөзе җитдиләнде, бераз сүзсез барганнан соң, янә телгә килде: — Габделнур абый, сиңа бер сүз әйтим әле. Бәлки, киңәш бирерсең.

Габделнур сагая калды. Иң беренче уе шул булды: «Егете турында сөйләргә җыена, ахры. Әллә бер-бер хәл булганмы? Алай дисәң, йөз-кыяфәтендә дә, йөрешендә дә бернинди дә үзгәреш сизелми. Юраганы юш килмәсен тагы».

Ләкин кыз теманы үзгәртте һәм абыйсы бөтенләй көтмәгән, уена да китермәгән сүз әйтте:

— Күптән түгел бер хатын мине урамда очратты да: «Син Линүзә бит әле», — ди. «Әйе», — дим. «Әтиеңне күрәсең киләме?» — ди. Мин аптырап калдым. «Минем әтием юк, үлгән», — дидем. «Юк, — ди бу хатын һәм: — әнә теге ир-атка кара», — дип, бер кешене күрсәтте. Мин ул күрсәткән якка бактым. Кара

чәчле берәүнең аркасын гына күрдем. «Шул синең әтиен», — ди бу апа. Мин телсез калдым.

Линүзә сөйләвеннән туктады. Габделнур ни дияргә дә белмәде. Чөнки аның Мәһрүсә апасының ире турында ишеткәне дә, сорашканы да юк иде. Андый үтә дә нечкә гаилә мәсьәләләре белән кызыксынмаслык кына акылы бар иде. Әгәр Линүзә сугыштан соң туган икән, димәк, атасы фронтта һәлак булмаган. Кем ул, кая киткән — анысы аларның үз эше, дип фикер йөртә иде егет. Ниһаять, ул телгә килде. Сеңлесенә карап, атлавыннан туктады.

— Шуннан ни булды?

— Минем күнелем тулды. Тиз генә китеп бардым. Өйгә кергәч, әнигә сөйләп бирдем.

— Мәһрүсә апа нәрсә диде?

— Башта каушап калды. Бу турыда беренче тапкыр сөйләшүебез иде. Дөрес, элек мин, әти кайда, дип сорагач, үлде, дип әйтә торган иде. Ә бу юлы ачуланды, күп сөйләшмә, диде. Ул аннан алимент та алырга теләмәгән, күрәсең.

— Нишләп?

— Белмим. Безгә читтән бернинди дә акча килми иде, — диде кыз, уфтанып. — Ә минем әтине күрәсем килә. Кем ул? Нинди рәк кыяфәттә? Теге көнне мин аны арттан гына күреп калдым бит. Әгәр теге хатын дөрес әйткән булса...

Габделнур сүзне тирәнгә җибәрмәс өчен елмаеп әйтте:

— Сиңа охшаса, чибәр кешедер: кара чәчле, кара күзле...

Бөтен барлыгыннан яшьлек, сафлык аңкып торган сеңлесенең алсу бит очлары тагы да кызара төште, башын иде:

— Оялтмагыз инде, Габделнур абый, мин сездән киңәш сорамакчы идем бит.

Егет уйга калды. Әлбәттә, ул ятим үскән баланың хәлен аңлый, үксезләрне күп күрде. Чөнки авылда аның яшьтәшләре, классташлары, гомумән, чордашлары арасында сугыш кырында ятып калган аталарының назын күрмичә үскән ятимнәр бик күп булды. Андыйлар белән ул укыганда да, эштә дә, армия хезмәтендә дә (Кронштадтта ике ГДР эсминецы тора иде, немец морякларына карата безнең солдат-матросларның нәфрәте никадәр көчле икәнен үз күзләре белән күрде) — һәр җирдә очрашты һәм әле дә очрашып тора. Үзенең әти-әнисе тигез булса да, аларның хәлен яхшы аңлый иде. Шулай да бу очракта ул Мәһрүсә апасыннан узып аның кызына нинди дер киңәш бирүне үз өстенә ала алмый иде. Әгәр кирәк дип тапса, башта ук әйткән, күрсәткән булыр иде кызына әтисен. Димәк, ярамаган, сәбәбе бар. Ә ни өчен ярамаган? Бәлки, ул гаиләле ир булгандыр? Ә Мәһрүсәнең (ул вакытта утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге хатын-кыз) бала табасы килгәндер, картлык көнемдә терәк булыр дигәндер, ялгыз калсам, үлгәндә иренемә су тидерүче дә булмас бит, дип уйлагандыр. Боларын инде егеткә фараз итәргә генә кала. Шуңа күрә ул мөмкин кадәр итагатьле булырга, йомшак итеп әйтергә тырышты. Сул кулын сеңлесенең иңбашына салды, кочаклагандай итеп, үзенә таба якынайтты:

— Линүзә, мин ни дип әйтергә дә кыенсынам. Әниең әйтергә теләмәгән икән, димәк, җитди сәбәбе булгандыр.

— Мин дә шулай дип уйлыйм, — диде сеңлесе боек кына. — Бәлки, аның семьясы бардыр, бәлки, шушы тирәдә генә дә яшидер әле...

Әйе, алар икесе дә бертөрле уй йөртәләр икән. Ләкин егет моны әйтмәде. Алар урам чатында туктадылар.

— Трамвайга хәтле озатыйм, — диде сеңлесе, абыйсын култыклап.

— Рәхмәт! Ярар, йөрмә инде.

Нәүмизләнеп, чатта калды сеңлесе. Ә Габделнур урам аркылы чыкты, артына

борылып карады. Линүзә әле кузгалмаган, һаман да тора. Егет аңа кул болгады. Сеңлесе дә ун кулын күтәрде. Аннары акрын гына атлап китеп барды. Ул карасу төскә буялган зур йорт почмагына житкәнче, аның ябык, зифа гәүдәсе күздән югалганчы, Габделнур шул тарафка карап торды. Бик кызганыч булып тоелды аңа бу ятим үскән кыз бала. Ләкин ни-нәрсә белән, ничек ярдәм итә ала соң егет аңа? Фәкать юатып кына. Ә аларның гаилә хәлләренә тыкшынырга, нидер кылырга аның хакы юк.

Ул, уйларыннан арыну өчен, тирә-ягына күз салды. Ә анда, кемнеңдер кайгы-хәсрәте булу-булмауга карамастан, тормыш гөрли: Киров исемендәге Мәдәният сараеның галәмәт зур бинасында бүген йә берәр кызыклы фильм күрсәтәләрдер, концерт-фәлән булуы да ихтимал; бакчада бала-чага мәш килә, өлкәннәр, яшь-җилкенчәк күренә.

Алда дүртенчеме, алтынчымы трамвайның «Газовая»га таба үткәне күренде. Энергетика техникумы яныннан узып, егет тукталышка барып житте. Үзе трамвай көтә, ә башында уй: Линүзәнең әти-әнисе исән, ә ул — ярым ятим. Кыз әтисенең кем икәнен дә белмәгән, ата назын татымыйча, әти дип әйтергә тилмереп үскән. Әйе, аның да әнисенә генә түгел, әтисенә дә сыенасы килгән чаклары, бүтән балалар кебек, аның белән житәкләшеп йөрисе килгәндер, авыр чакларда таянычы барын тоясы килгәндер. Ә ата кеше юк... Бәлки, шуңа күрә кыз Габделнурны якын итәдер... Сугыш вакыты да түгел, ятимнәр исә туа тора... Габделнурның бала чагы исенә төште. Күрше авылда Балалар йорты бар иде. Балалар анда бик күп иде. Күрәсең, болар сугыш вакытында эвакуацияләнгән балалар булгандыр, чөнки андагы мәктәптә укыту рус телендә алып барыла дип сөйлиләр иде... Дүртенче трамвай килде, егет, аңа утырып, Кольцога таба юнәлде.

...Кичкырын Габделнур Гөлзәрия янына китте — Камал театрына билеты бар иде.

Сигезенче яртыда башланган спектакль соң гына бетте.

Театрдан чыкканда, фойеда жырчы Илһам Шакиров күзләренә чалынды. Бераз баргач, Горький урамыннан түбән таба төшкәндә, Гөлзәрия нидер исенә төшеп елмайды һәм әйтте:

— Узган ел без аның концертына барган идек, кайтканда, кызлар талашып беттеләр.

— Ни өчен?

— Бер кыз әйтә, ул миңа карап жырлады, ди, ә икенчесе, юк, фәкать миңа гына карады, ди.

— Шуның өчен сүзгә килделәрме?

— Юрамалый гына инде, — диде кыз, көлеп. — Аны бик яраталар.

Алар Горький урамыннан түбән таба төшәләр иде, бик озын гәүдәле бер егет узып китте.

— Бу егеткә баскетбол гына уйнарга, — диде Габделнур.

— Кызыгасыңмы?

— Әйе, югарыдан күбрәк күренә бит, — диде егет, көлеп.

— Әле үсәрсең, — диде кыз да, сүзне уенга алып.

— Юк инде, егетләр егерме бишкә хәтле генә үсә, ә миңа — егерме сигез.

— Ә кызлар?

— Алар егерме яшькәчә.

— Мин дә үсмим икән инде, өч ел элек үсүдән туктаганмын.

Сүз бүтән темага күчте, аннары әле генә караган «Баһадирлар» спектакле турында гәпләшеп алдылар, ул әңгәмә Опера һәм балет театры артында таксига утыргач та дәвам итте, кыскасы, юл буена сөйләр сүз бетмәде.

Машинадан төшкәч, Гөлзәрия, башын күтәреп, егеткә карап торды да акрын гына әйтеп куйды:

– Сез нигә минем белән очрашасыз?

Аның тавышы моңсурак, үз-үзе белән сөйләшкән сыманрак килеп чыкты. Карашы да гади генә түгел — сынаулы караш. Әйтерсең лә ул күнеле түрендә туган яшерен хисләрнең һәм шул ук вакытта шикле уйларның очына чыгарга тели, ләкин берүзе генә булдыра, анык бер фикергә килә алмый.

Бу — сүз югында сүз булсынга гына бирелгән сорау түгел. Димәк, егет, һәр сүзеңне уйлап әйтергә кирәк, кыз күңелендә шик калмасын; аңа бит уналты яшь түгел, бүген — берәү, иртәгә икенче белән йөргән кызга да охшамаган, башына төрле уйлар килә торгандыр, үзара мөнәсәбәтләргә ачыклык кертергә телидер.

– Мин белмим... Гадәти хәл инде, бөтенесе кебек, — диде егет, ләкин шундук моның дөреслеккә туры килмәвен үз-үзенә икърар итте һәм әле генә әйткән сүзләрдән үзе үк уңайсызланып китте. — Ләкин шул ук вакытта нәрсәдер бик якын шикелле. Безнең очрашу үзебезнеке генә, аерым төсмерле. Билгеле, сез башка берәүгә — как и все... Әйтик, миңа да берәр егетнең кызы әллә бар, әллә юк, ә син...

Ул буталып бетте: әле «сез» диде, әле «син»гә күчте, ләкин әйтер сүзе болар түгел иде, каушап калды. Әле трамвайда беренче күрүдә үк кыз егетне үзенең бертөрле гадилеге һәм шул ук вакытта гүзәллеге белән таң калдырган иде. Күрәсең, бу әле һаман дәвам итә, ул торган саен аңа гашыйк була бара, юкса болай югалып калмас иде. Егет үз-үзен кулга алды:

Ул, ярты адым артка чигеп, кулын кызның биленә салды.

– Әнә, тулган айны күрәсеңме?

– Әйе.

– Матурмы?

– Әйе.

– Без кечкенә чакта, айда Зөһрә исемле кыз, көянтә-чиләк асып, суга бара, дип ышана торган идек. Чыннан да, андагы таплар суга баручы кызны хәтерләтә бит.

Кыз белән егет икесе дә төнге күк йөзенә багалар: тулган айны, бихисап күп якты йолдызларны күзлиләр. Озаграк карап торсаң, алар үзләре генә сихри булып күренмиләр, ә яшь күңелләрне дә сихерлиләр, бөтен борчуларыңны оныттыралар... Бигрәк тә яшь йөрәкләр бердәй типкәндә, уй-хисләр тәңгәл килгәндә...

Габделнур:

– Минем сезгә бик кадерле сүзләр әйтәсем килә, — дип пышылдады Гөлзәрия колагына. — Ләкин йөрәктәгенең барысын да сүзләр белән генә аңлатып бетереп булмый...

Егет кызны җайлап кына үзенә таба борды, башын күкрәгенә якынайтты, кочты һәм, чак кына иелеп, иреннәреннән суырып үпте. Кыз карышмады, ләкин аңа шул ук дәрт белән җавап та бирмәде. Бераздан пышылдап кына әйтте:

– Янадан үпмә инде, иренем кабара.

– Ярар, ачуланма, яме.

– Мин керим инде.

– Әлбәттә, әйе, мин сезне тотып тора алмыйм, хакым юк, — диде егет, ә үзе кызны кочагыннан чыгармады. — Ләкин... Но не хотел бы... Билгеле, әле бер-ике очрашуда гына сезгә үземнең бөтен хисләремне әйтеп бирә алмыйм. Ышанмас та идегез...

Эштәге кызлар белән җиңел аралаша, теләсә ни сөйләшә, хәтта тозлырак

мәзәкләр дә сибә торган егет үзенең хәзерге халәтенә, бу гүзәл фәрештә алдында югалып калуына үзе дә аптырый. Әйе, Гөлзәриягә мөнәсәбәт — бөтенләй икенче.

— Мин керим инде.

— Мин сезне җибәрергә теләмәс идем. Ләкин безнең теләкләребез һәрвакытта да безнең мөмкинлекләр белән тәңгәл килми...

— Хушыгыз, — диде кыз, егет куеныннан чыгып, һәм акрын гына кузгалды.

Ул үзе дә каушаган иде булса кирәк.

— Гөлзәрия, туктале, — диде Габделнур, кызның пальто җиңенә кагылып.

— Нигә?

Егет исен җыеп өлгерде. Ана дип аталган хаты бар иде бит, бирер вакыт җитте шикелле. Ни булса, шул булыр, дип тәвәккәлләде. Куен кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарып, кызга сузды:

— Мә. Үзең генә укы.

— Нәрсә соң бу? — дип сорады Гөлзәрия, алыргамы-юкмы дигәндәй икеләнеп, ләкин хат аның кулына кергән иде инде.

— Укыгач белерсең, — дип, серле генә елмайды егет. — Тәмле йокы, тәмле төш.

## 12

Гөлзәрия үзе кызларның сорауларына җавап бирә (спектакль, артистлар уены турында), ә күңеле һаман егете янында, уйлары ул биргән кәгазьдә язылганнар хакында. Ул бүген бөтен эшләрен тиз һәм җиңел эшләде: кием алыштырды, иртәгә эшкә кияселәрен үтүкләде, кофтасын карават башына элеп куйды, чәй эчте, юынып керде, урын-җирен бүсте, түшәмдәге утны сүндереп, тумбочка өстендәге төнге лампаны кабызды, койкасына ятты, фотолар, открыткалар караган булды, кулына «Азат хатын» журналын алды. Кызлар ятканнар иде инде, берәм-берәм йокыга киттеләр. Ул фәкать шуннан соң гына Габделнур биргән хатны тумбочкадан алып укырга кереште.

*«Төн.*

*Тышта караңгы. Бүлмәдә ут яна. Тәрәзәдән үземне күрәм. Уйга талган башым тагы да зураеп киткән сыман, авырайган төсле. Нәрсәләр булды миңа. Хәер, мин аны яхшы беләм. Син дә беләсең. Бәлки, бу минутларда синең озын керфекләрең сирпелеп, Әдрән дингез суын хәтерләткән (гәрчә мин аны рәсемнәрдә генә күрсәм дә) яшькелт-зәңгәрсу уйчан күзләрең тәрәзәгә багалардыр, кемнедер эзли, көтәләрдер. Бәлки, алай да түгелдер. Чөнки мин үзем һәрчак кешеләр арасыннан сине эзлим һәм син дә мине күрергә телисеңдер шикелле. Ә мин һәрдаим сине уйлыйм, эзлим. Карый-карый күзләрем тала, уйлый-уйлый зиһенем чуала. Йә дөнья яңгыратып җырлап җибәрәсе килә. Юк, дөрес сөйләмим. Ул җырны урман эчендә яисә болында икәүдән-икәү, саф күңелле нарасый балалардай җитәкләшеп барганда, әкрен генә җырлыйсы килә...*

> *Нигә, нигә синең уйчан күзләр*
> *Күзләремә болай багалар?..*

*Әйе, күзләремә багалар... Багалар да йөрәгемне телгәләп, бәгыремне өзгәләп (бераз дорфа булса да әйтим) күз алдымда торалар. Хыялымда, ишетәсеңме, күз нурым, ә каршымда түгел. Ә минем аларны һәрчак каршымда күрәсем, иркәлисем, йөрәк җылым белән назлыйсым килә. Шашкандыр бу димә, шашмаган ул, гашыйк ул, гашыйк... Синең күзләреңә, назга сусаган иреннәреңә,*

*сылу буй-сыннарына — бөтен барлыгына. Аның әнә шуларның барысын да иркәлисе, назлыйсы, сөясе һәм... сөеләсе килә. Ник яшереп торырга: без бит сөяргә дә, сөелергә дә хаклы...*

*Башкаемны кулларыма салам, ә уйларымны... уйларымны кемгә сөйлим?! Әле дә ярый ак кәгазем бар, сөйли алмасам да, аңа тезәм, тигез юллар булып уйларым ак кәгазьгә төшә...*

*Талгын җилләр исте синең тарафтан. Әллә шул җилләргә генә юллыйммы? Әй, җилләр, ирекле, киртә-коймаларны белми торган, чик-тыюларны белми торган шук балалар, табигать балалары! Илтегезче сәламемне сөйгәнемә! Сыйпагызчы йомшак чәчләрен! Җилләр, сез кем сәламен алып килдегез, дип сораса, әйтмәгез, үзе сизсен, аңласын. Хәер, бу сүзләрем артык, алар минем күз нурымны рәнҗетерләр. Ул сизмиме соң, ул аңламыймы соң?! Ул бит мине күз карашымнан ук тоя...*

*Йа Хода, мин никадәр үз-үземә нык ышанган беркатлы Алла бәндәсе! Бәлки, ул... Юк, юк! Җилләр, сез дә минем ни әйтергә теләгәнемне сизмәдегез. Шулай бит?! Мин ялгыш кына да алай уйлый алмыйм. Аның күзләре ялган сөйли белми. Ул да мине сөя! Аның күз карашыннан бу тойгыны сизгәндә, мин — дөньяда иң бәхетле кеше! Озак көннәр, төннәр чүлдә, сахраларда йөреп, ниһаять, салкын сулы чишмәгә юлыккан мөсафир кебек, мин дә бәхет чишмәмә юлыктым, аны таптым.*

*Кемнәр белән бәхәсләшим икән? Килегез бөек философлар, психологлар, мин сезне дуэльгә чакырам, бәхәс дуэленә чакырам мин сезне. Мәхәббәтнең кайчан киләсен кайсыгыз әйтеп бирә? Бармы аның кануннары, кагыйдә-закончалыклары? Юктыр...*

*Исергәндер бу димә. Мин эчкән шәрабның исемен үзең дә беләсең... Менә шундый бер хыялый инде мин, күз нурым. Мин сөйлим дә сөйлим, чәчләреңнән сыйпыйм, сулышым белән иркәлим. Ә син төш күрәсең булыр, миңа елмаясыңдыр... Йә Тәңрем, бу хыялый башка көч вә сабырлык бир!*

*«Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы» дип җырлаган кызларыбыз искә төшә. Нишләп кызлар гына җырласын бу җыруны, егет-җиләннең дә уена еш килгәндер әлеге сүзләр... Ни өчен дип сорама, үз башымнан узганга беләм.*

*Синең сорау: «Кайда булдың соң син? Ник моңарчы күрмәдең?»*

*Минем җавап: «Күрәсең, кешеләрдә тышкы матурлык кына түгел, эчке матурлык та бардыр. Матурлык дигәч тә, бу чибәрләргә генә кызыга икән димә. Хәер, алай дисәң дә гаепләмим... Торган саен ныграк ачыла барган эчке матурлык мине әсир итте. Синең алдау-йолдауны белми торган саф күңелең мине отыры ныграк били бара, эчкерсез мәхәббәтең үзенә тарта. Минем аңа каршы торырлык көчем юк, теләмим дә...»*

*Син: «Мин ул мәхәббәттән куркам», — дисең.*

*Мин: «Кайсы гына чорларда аннан курыкмаганнар? Ләйлә-Мәҗнүн, Фәрһад-Ширин, Таһир-Зөһрә... Азмыни мисаллар... Алар да курыкканнардыр, ләкин куркак булмаганнардыр. Син дә, күз нурым, мәхәббәтеңә бөтен киртәләрне, кыенлыкларны җиңеп бар! Шулай булмаса, аның кадере дә булмас иде. Күп гүзәлләр, пәһлеваннар башларын салмас иде. Җиңел килгән бәхет озын гомерле булмый, диләр».*

*Син тагын нидер әйтергә телисең. Үпкәләмә, мин сине туктатып торам, уйларымның ташыган вакыты, күзләремә карап тыңла, сиңа сөйлим. Беркөн мин сине күрдем. Ул көнне мин яхшы хәтерлим. Синең өчен, бәлки, гадәти генә көн булып узып киткәндер ул. Ә миңа... мин сиңа гашыйк булганымны аңладым. Мин кинәттән үзгәреп киттем: кешеләргә ягымлы итеп карадым, һәрберсен күңелемнән генә булса да сәламләдем, хәерле көн теләдем, аларның*

*да минем сыман бәхетле булуларын юрадым. Шәһәр урамнары кинәеп, яктырып киткәндәй тоелды. Йа Хода, таш кала да минем халәтемне аңлады булса кирәк. Ул төнне мин йокысыз уткәрдем. Мин тан атуын курүдән мәхрүм булырмын дип курыктым. Син күрсән иде икенче көнне таңның ничек атуын! Бөтен тараф кояш нурларына чумып, һәр тереклек иясенә бәхет теләп, алсу таң атты!.. Ә минем хыялымда бер йолдыз калыкты — мәхәббәт йолдызы! Мин аны синең белән уртаклашырга булдым. Син аны акрын-салмак, шик-шөбһә белән генә кулына алдың. Ә аннары... анысы минем өчен әйтеп бетергесез куаныч булды... Син аны иреннәренә тидерден һәм кире мина суздың. Мин, синең уенны аңлап, әле синең иреннәрең жылысы сүрелмәгән йолдызны назладым һәм кулларымны күккә суздым... Чөнки гашыйкларның йолдызлары шунда бит...*

*Күз нурым, кичләрен чыгып, күк йөзенә караш ташла: сүнмәгәнме безнең мәхәббәт йолдызы? Юк, сүнмәс ул. Шикләнмә. Йөрәкләребез бер-берен сагынып типкәндә, уйлар дингезендә икәү бергә йөзгәндә, теләкләр бер булганда, һич сүнмәс ул безнең мәхәббәт йолдызы! Шикләнмә...»*

Гөлзариягә кинәт кенә әллә нәрсә булды: ул укудан туктады, як-ягына каранды, ләкин берни күрмәде, чөнки аның күзләре дым пәрдәсе белән өртелгән иде. Бу — яшьлегендә беренче мәртәбә шундый тәэсирле, сихерле хат алган кызның шатлыклы күз яшьләре белән томаланган мәле иде. Аның башы шаулый, ярсып-ярсып типкән йөрәге менә-менә күкрәк читлегеннән атылып чыгар кебек тоела. Егетнең уй-фикерләре, ташкын хисләре аны да биләп алды. Гөлзария мендәренә капланды, үксеп елап җибәрүдән үзен-үзе көчкә тыеп калды. Ләкин бераздан, башын күтәргәндә, мендәр тышының юеш икәнен шәйләде.

Йоклап яткан кызлар аның халәтен сизмәделәр. Гөлзария, аны әсәрләндергән кәгазь битләрен тумбочкасына яшереп, коридорга чыгып китте. Тынып калган кухняга керде, тәрәзә каршына басып, тышка карап торды. Үз халәтен аңлый да, аңламый да кебек: ана да нидер булды бит; шушы яшькә җитеп болай тәэсирләнгәне юк иде. Әгәр язмышы шушы булса?.. Монарчы тыныч кына яткан дулкын — мәхәббәт дулкыны аны да үз эченә бөтереп алып, үзе белән агызып китте түгелме? Әйе, шулай. Хәерлегә генә булсачы... Аның тагын күзе дымланды. Бу ни бу? Бүгенге халәттән, ашкынудан сөенүме, әллә алдагы билгесезлектән гаҗизләнүме? Белмәссең бу дөньяны...

Кем соң ул Гөлзариягә шундый хат тоттырып җибәрүче? Юньле кешеме?.. Кыз, дөресен генә әйткәндә, баштарак бу танышуга әллә ни әһәмият бирмәде. Кызлар белән егетләр танышу — гадәти күренеш. Бөтен очрашулар, сөю-сөелү хәлләре кавышу белән тәгәлләнми. Мавыгу дигән нәрсә дә бар бит әле. Ә чын мәхәббәт... Анысы нәрсә? Ул кешене шулай тилертер дәрәҗәгә китереп җиткерә микәнни?

Гөлзария тәрәзәдән күзен алды, читкә китте. Бүлмәсенә керде. Мыштым гына урын-җиренә ятты. Ләкин аны барыбер тиз генә йокы алмады... Үзенең халәтен аңларлык кеше белән серләшәсе килде, кинәш сорау уе да туды. Ә кемгә чишәсең эч серләреңне? Кызларгамы?.. Туган апаларынамы?.. Әниенәме?.. Әйе, аңардан да якын кешесе юк бит аның...

*(Ахыры киләсе санда)*



Шәмсия
Җиһангирова

# ТҮЗӘ АЛМЫЙ ҖАНЫМ МОҢЛЫКТАН

***

Бу фанида бары да бәйле бер-беренә:
Аерылмый камиллектә һич кешеләр.
Кайчак бездән акыллырак нәни бөҗәк,
Агымсуга башын игән нәфис тирәк.

Мин дә нәфис тирәк идем сабыйлыкта,
Бөдрә каен булып тордым балигълыкта.
Булдым юкә һәр чәчәген чаган үпкән,
Булдым имән — ябалдашын давыл кискән.

Күпме уйлап, күпме сынап, аңламадым:
Нинди агачка тиң булу соң яхшырак? —
Көз житүгә, өзелеп төшеп җиргә ята
Каенда да, имәндә дә шул ук яфрак.

Җәй буена агач күрке булган яфрак
Кар астында карала да череп бетә...
Яз житүгә, яна яфрак көтә җиһан!
Ә искесен... беркем алмый инде искә.

...Бу фанида камилрәк түгел кеше,
Безнең язмыш — җирдә яткан яфрак төсле.

***

Мин беркемне таба алмам, дигән,
Мин беркемне сөя алмам, дигән,
Җиһан эчләрендә япа-ялгыз йөргән,
Бәхет куралмаган дәрвиш сыман...
Карап торам сина. Каян килеп чыктың?
Бәхетме бу? Башымы соң әллә ялгышлыкның?
Куркып торам хәтта шатланырга...
Кемнекендер читтән карап торып була.

---

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА — *шагыйрә; «Ни өчендер безнең язмыш шундый», «Җирсу», «Якты сагыш» һ.б китаплар, күп кенә танылган җырлар авторы. «Татнефть» ААҖ һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Барысы җинел, бары да аңлашыла.
Ә безнекен ничек аңлатырга?!
Әйтсәләр дә, диеп, өендәген кешеләрдән сора,
Без сорамыйк әле кешеләрдән,
Тормыйк җавап көтеп.
Читләргә аңлашылмастыр үзебез төшенмәгән.
Тотыныйк та, әйдә, кулны кулга,
Таяныйк та бары бер Аллага,
Чыгыйк икәү генә белгән яңа юлга,
Китик алга таба.
Авырлыклар булмас, димим. Булыр!
Почмак саен гайбәт сүзләр,
Яман күзләр сакта торыр...
«Шулай булгач...» димә, башың имә!
Ышандыр үзеңне минем кирәклеккә!
Мин инандым инде — син миңа бик кирәк!
Күзләрем дөньяга гел башкача карый,
Гел башкача тибә хәзер йөрәк.
Көткәнем син минем! Ялварганым!
Сабырлыгым белән табалганым!

...Бара-бара аңларбыз калганын...

## Оран

И, татарым, унган да син, булган да син,
Ни кылсаң да, дан-шөһрәткә тулган да син!
Шулай булгач, ник белмисең үз кадереңне,
Җил иссә дә үзгәртәсең ник кәлебеңне?
Бармы синең башкалардан ким-хур җирең,
Егет-кызың хәтерләтә җиһан гөлен!
Гөнаһмыни балаларга-оныкларга
Бәһасез бер мирас итсәң газиз телең?
Нигә һаман татарлыктан ояласың,
Чит-ят телнең ләззәт-тәмен тояламсың?
Йомырканы салгач башка ояга син,
Гомереңне «яшәдем мин!» дияламсың?
Ничәү гомерең, максатсызга сарыф итәр,
Көч-егәрең, манкорт-куштанлыкка китәр?
Ач күзеңне, күп йокладың, булды, җитәр!
Шаула-даула мәгърур искән җилдән битәр.
Искән җилдәй, дәрья судай шауламасаң,
Күкрәк киереп мин-минлекне дауламасаң,
Үз кавемеңне бары үзең данламасаң,
Ата-бабаң биргән телне аңламасаң,
Яшәү нигә бары ашау-корсак өчен?
Җан фида кыл татар булып калыр өчен,
Яшәү мәгъкуль бары кемлегеңне аңлап,
Асылташтай, милләтеңнең саның барлап.
Бетәр малың, көне-төне арттырмасаң,
Исраф җаның, алда тозак-сак кормасаң,
Күңел күзең тома сукыр, җай күрмәсәң,
Баш очында кояш соңра ай күрмәсәң!
Исең китәр: бу ни хәйран, бу ни гаҗәп? —
Онытылып бетеп бара гореф-гадәт!

«Татарлыгы йөзенә чыккан!» дигән сүзнең
Аңлыйсыңмы чын мәгънәсен, әйтче, бүген?
Ни хәйраны, ни хикмәте тагын шунда —
Татарлыктан калмавы бар хәтта «т» да!
Ышанырсың болай булгач, шаять, син дә
«Татар башын татар ашар!» дигән сүзгә.
Бу фанида яманатың калдырма син,
Тарихыңны башкалардан яздырма син!
Кемлегеңне аңлап яшә, белеп яшә —
Уң вә сулга татарыңны куй янәшә!
...Кемем бар соң тагын шулай җаным атар,
Мин сыгынам бары сиңа, Кауме Татар!

***

Яратмый да яшәп була икән!
Яңа белдем!
Очкыннары сүнгәч кенә
Сөю көткән күзләремнән, —
Хата булганлыгын гомер буе
Җаным терәр кеше эзләвемнән...
Чаптың, йөрәк! Яндың, йөрәк!
Очкын биреп, ут дөрләтер
Кеше эзләп...
Йә! Тынычлан!
Килеп җиттек!
Ачып кердек. Күрдек...
Инде китик... җиңми генә!
Яратуның ни икәнен белми генә
Яшәгәннәр арасына...
Алгысынма! Ярсыма син!
Мин, дип, андый түгел!
Ә мин...
Яратмый да яшәп булганлыгын
Белдем бүген.
Нигә кирәк? Кемгә?
Күз яшь түгү сөям, диеп,
Синнән башка яши алмыйм
Бер көнне дә, үләм, диеп.
...Барыбер юк! Барыбер юк
Җан сыеныр кеше —
Күзләремнән тамып төшкән
Садә яшем
Бөртек-бөртек үбеп алыр өчен
Әзер берсе... Юк! Юк! Юк!!!

***

Чыктым да мин ялгыз сахраларга,
Чәчләремне җилгә туздырдым...
Сине лә генә уйлап, сине көтеп,
Гомерләрем зая уздырдым.

Белмәдем лә, дуслар, һай, белмәдем —
Тузган чәчләр авыр үрмәгә...
Бу дөньяга минем килүләрем —
Кайгы-хәсрәт кенә күрмәгә.

Энже яшем коям мендәремә,
Түзә алмый жаным моңлыктан...
Күз яшенен ачыларын белми,
Жаны сөйгән ярга юлыккан.

Эчләремдә ниләр кайнаганы
Мәгълүм бары кара төннәргә...
Зөһрәләрнен Таһирлары булган,
Ә мин жаным ачыйм кемнәргә?!

Чыксам әгәр кабат сахраларга,
Чәчләремне жилгә таратмам...
Дөньяларга кабат килер булсам,
Сине болай өзелеп яратмам...

***

Мин сыенам сина. Бу ни гажәп:
Икәү бер жан гүя, бер үк тән...
Мондый хисләр бездән башкаларда
Була микән, әллә юк микән?

Инде сүнгән, беткән дигән идем, —
Йөрәк тулы ялкын-ут икән...
Яшьлегемдә болай януларым
Булды микән, әллә юк микән?

Озак көттем сине, озак көттем,
Юктыр минем кебек, һай, көткән.
Ишек ябылуга, куркып куям:
Кайтыр микән, диеп, юк микән...

«Беркемгә дә бирмәм!» — дия алмыйм —
Үзем ташлап ләкин һич китмәм!
Ә син китсән, әйтермен уфтанып:
«Булды микән сон ул, юк микән...»

Яшик әле, әйдә, яшик әле!
Калган гомер безгә бик житкән.
Син дә көткән, мин дә көткән бәхет
Бар икән ул! Әйе, бар икән!

Беркөн килеп, бу фани дөньяны
Ташлап алданрак син китсән, —
Сөрәнләрмен жиде күкләргә мин:
«Андый булмас бүтән, юк бүтән!..»



Сәйдә Зыялы

# АГУЛЫ ТЕШ

БӘЯН

*Колхозлашу елларында репрессия корбаннары булган якын туганнарыма багышлыйм.*

Автор.

Авылдан куылуларына егерме өч ел узгач, 1956 елның җәендә Рәшидә туган якларын күреп киләсе итте. «Тагын күпме гомер бардыр?.. Исән чакта әти-әнинең, әби-бабайларның каберләрен зиярәт кылып кайтырга кирәк», — дип уйлады ул.

Гомере буе сагынып яшәде. Туган туфрагыма бер аяк басармын микән, калган кардәшләрем белән бер күрешермен микән дип, саргаеп яшәде Рәшидә. Балаларының кендек каны тамган, Сабиты белән бәхетле көннәре узган нигезне бер күрер өчен җанын фида кылыр чаклары булды. Өйләнешкән чакларында аңа бары унҗиде яшь иде. Ә Сабиты — унсигездә... Гөрнадирдай ике улы — Вакыйф та, Васыйл да япь-яшь килеш сугыш кырында ятып калды. Вакыйфка — егерме бер, Васыйлга унтугыз яшь иде... Күз нурларының сөякләре кайсы төбәкләрдә җирләнгән икән? Җирли алдылар микән әле? Окопларда гына күмелеп калмады микән? Уйлар, уйлар... Йөрәкләрне әрнетә, сулышлар кысыла. Инде менә акладылар да... Сабитның бер гаебе булмаган... Соң, аның гаепсезлеген шул чакта ук тикшерергә булмады микәнни?!. Тоткынлыкта узган гомерләрнең хакын бүген кем түли? Кичергән газапларның ярасын ничек төзәтәсең?! Гаепсезләрне гаепләүчеләр рәхәтләнеп яши бирә. Рәшидә шулай уйлап, еш кына үз-үзе белән сөйләшә.

Авылда Рәшидәнең бертуган энесе Гали яшәде. Ул репрессиягә эләкмәде. Гали — шәһәрдә укып кайткан кеше. Кайсы яктан нинди җилләр исүен тоюга, тормыш җилкәнен шул якка көйләде. Авылларны коллективлаштыру турында сүз калкына башлауга, мал-туарын әкренләп бетерде. Өч сарык, бер кәҗә, ике оя каз гына асраган Галигә тел-теш тидерүче булмады. Ул — авылның бердәнбер мөгаллиме дә бит әле. Яңача хәреф танып укый-яза белүче дә бармак белән генә санарлык. Казан тиклем Казанда чыккан гәҗитләрне укып баручы Гали сүзен дә үлчәп сөйләште. Мәзәкләр сөйләргә яратучы Сабитка да киңәш биргәләгән иде дә... Гата белән Шакир пычрак ыргытырга җай тапканнар шул. Пычрагы юылса да, эзе кала икән... Хәзер инде Гали дә юк, Сабит та. Мәрхүмнәр. Ярый әле, Аллага шөкер, Наиләсе белән Аниясе бар. Наилә узган ел гына кияүгә чыкты. Алар менә дүртәүләп ата-баба туфрагына, туган авыллары Елгабашка

кунакка кайттылар. Куылган чакта кызлар нарасый яшендә иде әле. Авылны бөтенләй хәтерләмиләр. Аларның хәтерендә — Пермь урманы, барак тормышы, хокуксыз балачак...

Рәшидә үзе Елгабашта туды, үсте. Шушында кияүгә чыкты, балалар тапты. Куылса да, сөрелсә дә, аның башка туган җире юк. Галинең хатыны Мәһупкамал кунакларны якты йөз, җылы сүз белән каршы алды.

— И, апакаем, күрешер көннәребез дә булган икән... Ничекләр кайтып җиттегез? — дия-дия, дымлы керфекләрен яулык чите белән сөртте.

Иртәгесен Рәшидә үз кое белән зиратка барырга ниятләде. Аниясе:

— Әни, мин дә синә иярәм, — дип сүз кушса да, Рәшидә риза булмады.

— Кызым, сез, әнә, җизнәң, апаң белән әрәмәлеккә чыгыгыз. Бик матур ул. Җиләк җыярсыз, кызынырсыз. Зиратта мин озак юанырмын. Коръән чыгармын дип торам. Икенче юлы бергәләп барырбыз.

Балачактан шигырь, хикәя язып җенләнгән Ания табигатьне үлеп ярата. Әйтерсең лә агачтагы һәр яфрак аның белән серләшә, урмандагы бар тереклек аны аңлый...

Авылга якын гына әрәмәлеккә күтәрелүгә, Тәлгать белән Наилә колачларын җәйгән имән күләгәсенә сузылып яттылар. Букчаларыннан икесе ике китап алып, мондагы чынбарлыкны оныттылар... Ания дә китап укырга бик ярата. Тик аның күнеле урынында түгел. Уенда — язылачак әсәре. Моннан җитмеш ел элек булган вакыйгаларны күзалларга тырыша ул. Аның геройлары менә бүген Ания басып торган юлларда йөргән. Ул чактагы кешеләрнең уенда ни булган? Әнә, күләгәсендә Наилә белән Тәлгать ятучы юан имәнгә дә җитмеш кенә яшь бар бит инде. Димәк, ябалдашларын канаттай җәйгән имән — шул чорларның шаһиты! Әй, әкияттәгедәй, телгә килсен дә сөйләсен иде ул белгәннәрен!

Наилә бераздан кызынырга уйлады. Күлмәген салып баш астына кыстырды да җилкәсен кояшка каратып сузылып ятты. Тәлгать тә каләшеннән калышмады. Өс киемнәрен салып, кояш нурлары кочагына тәгәрәде.

Ания, кошлар җырын тыңлый-тыңлый, уйларына уралып утырды да әрәмәлекнең тар сукмагы буйлап әкрен кереп китте.

«Урман нигә болай серле була икән? — дип уйлады Ания. — Һәр үсемлектән ниндидер тылсым бөркелә. Син аларны түгел, алар сине күзәтә сыман. Әрәмәлек, диләр. Әрәмәлек кенә түгел бу. Революциягә хәтле Шәрифҗан абый тоткан урман шушыдыр бит инде».

Монда Краснокама ягындагыдай мәгърур нәратлар гына юк. Усак, имән ише яфраклылар икән.

Ания, сукмак буйлап бара торгач, түгәрәк аланлыкка килеп чыкты. Аланлыкның бер ягында — миләшләр, икенче ягында балан куаклары тезелгән. Аяк астында бихисап җиләк. Җир җиләкләренең кайсысы бармак башы кадәр булып үскән, кайбер тармаклары ап-ак чәчәктә. Ания белән Наиләне урман кызы дип атасаң да, һич ялгыш булмас. Алар яши торган баракларданерак та түгел шаулап урман үсә иде. Әниләре белән әтиләре урман кисте. Алар кул пычкысы белән кисеп, юан-юан нәратларны ауларды. Ә беркөнне әниләре эшкә бара алмады. Ул чагында, мөгаен, Аниягә — биш, Наиләгә сигез яшь чамасы булгандыр.

— Балалар, — диде әниләре, авыртудан бирелеп уа-уа. — Карап керегез әле. Берәр хатын-кыз күренмәсме? Миңа ярдәм кирәк булыр...

Кызлар, яшь булсалар да, эшнең кая баруын тиз төшенделәр. Әниләре йөкле иде. Ания — бер якка, Наилә икенче якка бараклан баракка йөгерде, тик ярдәмгә килердәй кеше тапмадылар.

Рәшидә әкренләп җыена башлады. Тулгагы тукталып торган араларда оек-чабатасын киде. Бала тугач төрергә дигән иске-москы чүпрәкләр төргәген Наиләгә тоттырды.

— Урыс авылы ерак түгел, өч чакрым тирәсе генә. Ничек тә барып җитәрбез... Аллаһы Тәгалә рәхмәтен салмый калмас...

Юлга кузгалдылар. Наилә төенчекне тотты. Ания, әтисе ясап биргән кечкенә чанасын сөйрәп, арттан иярде.

Апрель аеның юмарт кояшы күзләрне чагылдыра. Кичтән җебеп боткаланган карны төнге салкын шытырдатып катырган. Атлаган саен, аяк астында изелеп кар шыгырдый. Ул шулай шытыр-шытыр килеп, юлчыларны ашыктыра кебек.

Тизрәк атларга кирәклекне Рәшидә үзе дә бик әйбәт белә. Ешайганнан-ешая барган тулгак аны туктата. Ул ике учы белән билен тотып боргалана, сыгылып-сыгылып төшә, гасабиланып тирә-якка күз сала. Үзе пышылдап кына Ходайга мөрәҗәгать итә. «И Аллам! Нарасыйларым хакына, кичергән газапларым хакына рәхмәтеңнән ташлама!..»

Алар шулай мең газап, көч-хәл белән авыл башына килеп житте. Кызлар авыл башындагы беренче йортның ишеген шакыды. Эчтән гайрәтле ир-ат тавышы ишетелде:

— Кто там?

Йорт янына килеп җитәрәк карга батып егылган Рәшидә, бер терсәгенә таянып калкынды да җан ачысы белән кычкырды:

— Памаги! Зинһар, памаги! Рожать!..

Иңенә сырма салган озын буйлы ир ишекне ачты.

— Что вам надо? — дип эндәште ул калын тавыш белән. — Откуда?

— Барак, барак, из барак, — дип үрсәләнде Рәшидә, мүкәләп тора-тора.

— А-а, — диде ир, ашыкмыйча гына, кемлегегез аңлашылды дигәндәй. — Враги народа. Уходите!

Балаларның борын төбендә шапылдап ишек ябылды.

Рәшидә көч-хәл белән торып, урам уртасына чыкты. Үзе күз яшьләрен йодрыгы белән сөртә-сөртә, берөзлексез теләк теләде. «И Ходаем, берәр игелекле бәндәңне юлыма чыгарсана... Чыгарсана».

Кызлар абына-сөртенә, егыла-тора барып, әле бер йортның, әле икенче йортның ишеген шакыдылар. Әмма аларга ярдәм кулы сузучы булмады. Әниләренең хәле авырайганнан-авырая. Ул, барган җиреннән кинәт туктала да сыгылып төшә. Тешләрен шыгырдатып әкрен генә ыңгыраша. Үзе кызларны юатырга тырышып сөйләнә:

— Курыкмагыз, балалар, Аллаһы Тәгалә ташламас... Берәр рәхимле бәндә очрамый калмас...

Тулгактан интегүче йөкле хатын, аның артыннан ике бала көпшәк карлы сукмактан әкрен генә атлый. Инде авылның түбән очына житеп киләләр. Анда, мөгаен, инеш агадыр. Каршыда, ерак та түгел, шактый зур таллык җәелгән. Озын-озын талларның очында карга оялары. Кошлар үзара каркылдаша-каркылдаша, үз оясы янында мәш килә. Мөгаен, чыгачак бәбкәләренә йомшаграк итеп урын әзерлиләрдер. Шул мәлне Рәшидә җан ачысы белән ыңгырашты да бөгелеп кар өстенә егылды. Ике кыз икесе дә, куркышып, әниләре янына йөгереп килде. Кызлар, елый-елый, әниләренең башыннан тотып:

— Әни, үлмә! Әни, жаным, үлмә! — дип, күз яше аралаш такмакларга кереште.

Арган, талчыккан Рәшидә бар көченә ачыргаланып кычкырып җибәрде:

— Ярдәм итегез! Кешеләр бит сез! Адәм балалары!

Тавыш, салам түбәле кыйшайган өйләргә бәрелә-бәрелә, урам буйлап таралды, нечкә билле яз җиленә кушылып, талларга килеп бәрелде. Кайтаваз булып кабат авылның икенче ягына китте:

— Яр-дәм и-те-геез! Сез бит ке-ше-ләәр. Адәәм ба-ла-лары!

Наилә кинәт торып басты да чишмә кебек аккан күз яшьләрен кул аркасы белән сөртә-сөртә, бар көченә аваз салды.

— Помогите! Ма-ма уми-ра-ет! По-мо-ги-те!

Тал башында үз эшләре белән мәшгуль кара каргалар, хәвеф килүен сизгәндәй, дәррәү күккә күтәрелде. Шулчакны ин кырый йортнын жил капкасыннан бер әби килеп чыкты.

— Господи, помоги! Господи... — диде ул, тиз-тиз генә чукына-чукына. Аннары Рәшиләнен иннәреннән алып торгыза-торгыза: «Потерпи, доченька, потерпи, милая», — дип юатты. Хатынны житәкләмәкче булды. Әмма Рәшидәнен хәле юк иде инде.

Карчык эшнен ашыгычлыгына төшенде. Ул тиз генә өенә чапты. Озак та үтмәде, аннан кул чанасы сөйрәп чыкты. Рәшидәне иплән кенә шул чанага утыртты да су буена таба ашыкты. Анда жир казып эшләнгән кара мунча бар икән. Мунчага кичтән яккан булсалар кирәк, шактый жылы тоелды.

Әби, Рәшидәне ләүкәгә урнаштыргач, ишек янындагы имән мичкәдә калган суга кулын тыгып карады. Су салкын иде. Әби тагын өенә йөгерде. Аннан мунчага ягып жибәрде. Мичтән төшкән ялкын яктысы мунча эчен яктыртып, жылытып жибәрде. Матчага кагылган юан калакка, таш өстенә жылынырга бирәр чиләк су куйды.

Рәшидә шактый тынычланды. Ана бөтенләй таныш булмаган рус карчыгы бу мәлдә әнисе кебек якын иде. Авырткан билен уа-уа, әбигә рәхмәтләр укыды. Түшәм-бүрәнәләрен кара корым каплаган мунча жылынгач, Рәшидә йокымсырый башлады. Тулгагы да кимегәндәй тоелды. Хатыннын халәтен һәрдаим күзәтеп торган карчык, ишекне ачып, мунчаны жилләтте.

— Йоклама, йоклама, әйдә, кызым. Бала юлда! — диде әби, анын эчен тоткалап.

Тулгакнын кимүе юньлегә түгеллеген белгән әби өенә кабат йөгерде. Аннан ниндидер үлән төнәтмәләре белән касторка мае алып төште.

— Эч, кызым, эч. Бала юлда. Көчән.

Янып-пешеп ике-өч сәгатьләп газаплангач, кара мунчада сабый тавышы яңгырады.

— Бог милостив... — диде әби, күз яшьләрен тыя алмыйча.

Рәшидә игезәк ир балалар тапты. Аларнын берсенә — Сәлим, икенчесенә Кәрим дип исем куштылар. Тик... малайлар кыска гомерле булды. Өч кенә көн яшәделәр. Әтиләре аларны, бараклардан ерак түгел, урман аланындагы тоткыннар зиратына жирләде. Каберләре югалмасын дип, пар миләш утыртты.

Әрәмәлек аланындагы миләшләр ерак еллар упкынында калган фажигане Аниянен исенә төшерде. Бу вакыйганы ул язылачак әсәрендә, һичшиксез, файдаланыр. Әнисенен Сәлим белән Кәримгә багышлап чыгарган бәетләрен дә кертер. Кич утырып бәйләм бәйләгәндә, шул бәетләрне көйләп утырыр иде:

Бисмилләһи вә билләһи,
Житте Корбан гаете;
Мин жырлыймын, сез тынлагыз
Игезәкләрем бәетен.

Карадин кара кайгылар,
Сап-сары сагышларым;
Урман шавы алып килә
Улларым тавышларын.

«Кыска булды гомеребез,
Өч кенә көн яшәдек;
Әнием, кара кайгыларны
Юа синен яшьләрен...»

Үз дөньясы сукмаклары буйлап сәяхәттә йөргән Аният ир-ат тавышы сискәндереп җибәрде.

— Ул каенны нигә терәтеп торасың? Аумый ул.

Ания, миләшләрдән күзен алып, тавыш ягына борылды. Озын чыбыркысын иңенә аскан, чүл гарәбедәй кара чырайлы, базык гәүдәле егет аның янына килеп баскан иде. Ания, егеткә баштанаяк күз салгач, җавабын да соравы сыман итеп бирде.

— Ә-ә, аумыймыни? Мин тагын ава дип торам.

Җөмләсен тәмамлауга, кыз китәргә дип борылган гына иде, егет аның каршысына басты:

— Ашыкма әле, чибәркәй. Танышмадык ич. Минем исемем — Хөснетдин. Хөснетдин Сәгъдәтшин. — Сәгъдәтшин дигән сүзне ишетүгә, Аниянең башы әйләнеп китте. «Әллә, Ходаем, шул Сәгъдәтшиннар малаемы?» — дип коты очты.

Ания сул учы белән маңгаен тоткан хәлдә китәргә дип тагын талпынган гына иде, Хөснетдин аны беләгеннән эләктереп алды.

— Нәрсә, авыл егете белән сөйләшеп торасың килмимени! Ә үзегез авыл кешесе үстергән ипине ашыйсыз, тартынып тормыйсыз!

Аниянең бу ябышкак егеткә җен ачулары чыкты. Теленә берсеннән-берсе усалрак сүзләр килде. Кыз аларны әйтергә генә ашыкмады. «Аллам сакласын, урман уртасында бәйләнеп маташуы бар. Гарьлеген кая куярсың», — дип уйлап алды. Бар сабырлыгын җыеп, сүзне йомшартыбрак җибәрергә тырышты.

— Хөснетдин, мин сезгә бер кәлимә сүз әйтмәдем бит әле. Тик торганда миңа бәйләнүегезнең сәбәбен аңламыйм.

— Э-э, аңламый ул, — дип мыгырданды егет, авызына капкан папиросына ут кабыза-кабыза. — Сөйләшәсе килмәгәнең күренеп тора ич!

— Мин сезне белмим, сез — мине. Ни турында сөйләшәсең?

Тәмәке төтенен борын тишекләреннән чыгара-чыгара:

— Ә мин сезне беләм. Атагыз колхозга кергән-керүен. Ну, гел корткычлык эшләп йөргән. Сез — шул Сабит кызы, — диде тегесе.

— Нинди корткычлык эшләгән соң ул?

— Анысын мин каян белим! Ну, тикмәгә кумаганнар бит инде.

Әти-әнисе кичергән газапларны, шатлыксыз, хокуксыз узган балачакларын, оясы туздырылган кошлардай вәйран калган гомерләрен күз алдына да китерә алмый торган бу мәгънәсез адәмгә Ания ни дип тә җавап бирмичә, бер мәлгә тынып калды. Аның җанында давыл кузгалды. Ул бөтерелә, дулый, актарыла. Фикер җебенең очы кайдан башлана да, ничек дәвам итә. Моны Ания хәзер генә таба алмый. «Менә шушы Хөснетдиндәй кешеләр аркасында бер гаепсезләр харап булган инде, — дип уйлап алды ул.

Җанында кузгалган давылны туктатырлык көче юк иде Аниянең.

— Сез, сез! — дип кычкырды ул ачуыннан. — Сез — провокатор! — Һәм кырт борылды да авылга таба йөгерде. Көтүченең:

— Ха! Чебен дулап тәрәз ваткан! — дип кычкырган тавышы гына ишетелеп калды.

Аниянең канына тоз салса да, Хөснетдин үз-үзеннән канәгать калмады: «Вәт, дур-рак! — дип сүкте ул үз-үзен. — Шушындый аулакта тәгәрәтә-тәгәрәтә, яратам, дип иркәлисе урында... Син — кулак кызы, имеш! Дуррак! Ну, ничава, провокаторын күрсәтәм әле мин аның...»

Әкренләп су буена туплауга баручы сыер көтүе артыннан Хөснетдин дә кузгалды. Сукмак буйлап Урта дисәтинә аланлыгына житсә, ни күзе белән күрсен! Өс киемнәрен салган ир белән хатын-кыз битләренә китап куйганнар да күккә карап яталар. «Ә-х-хх, — дип куйды Хөснетдин, — ул ир урынында мин булсам...»

* * *

Рәшидә зиратта озак юанды. Әти-әнисенен баш очына утырып ясин чыкты. Кабер тирәсендәге чүп үләннәрен утады. Аннары каенанасы белән каенатасының мәңгелек йортларын эзләп тапты. Ул, мәрхүмнәр белән күнеленнән сөйләшә-сөйләшә, башыннан узганнарны кичерде.

...Октябрь аеның саран кояшы төшлектән авышуга, ул көнне биек яр астыннан авылга таба агучы инеш өстеннән томан күтәрелә башлаган иде. Сабит урман буендагы ерак басудан жигүле ат белән көлтә төяп кайта иде. Тар инешнең яры кинәебрәк киткән сазламыкларыннан, инкүлекләреннән борнап чыккан томан, салкын сулышын өрә-өрә, кыр-басуларга тарала, елга буйлатып авылга таба тәгәри.

«Кара син бу галәмәтне, — дип уйлый Сабит. — Буп-буш, жисемсез авырлыгы белән дөньяны томалардай булып агыла». Бастырыклап төялгән көлтәләр өстенә кырын яткан хәлдә, ул игеннәре жыеп алынган басуга күз сала. Әнә, инеш аръягында алар басуы жәйрәп ята. Бу басулар бик күптәннән, Сабит туганчы — әллә кайчан ук аның бабаларыныкы булган. Аннан соң Сабитның әтисе Исламгали абзый иген иккән. Сабит та менә үз-үзен белә башлаганнан бирле жир сөрә, чәчү чәчә, иген игә... Ә басу?.. Басу хәзер — колхозныкы. Сабит та аерым хужалык түгел. Ул да — колхозчы. Бар малын биреп колхозга керде. Кул белән әйләндереп ашлык чистарта торган станогын да жәлләмәде. Хәер, жәлләп нишлисен? Синнән рөхсәт сорап тормадылар инде...

Сабит эшсез тора алмый. Нәселе эшчән. Колхозда да тырышып эшләде. Узган жыенда[1] да мактадылар үзен.

Уйлана-уйлана бара торгач, вакыт узганы сизелмәгән дә. Көлтәләрен ындырда бушатып, атын тугарып, Сабит өенә кайтып житкәндә, авыл урамнарын куе томан томалаган иде. Төнге уникеләр тирәсе булгандыр. Жиделе лампаны сүндергәч, хатыны белән бераз сөйләшеп ятты. Иртәдән кичкә кадәр басу күкрәгендә, саф һавада хезмәттә булган ирнең гәүдәсе мамык түшәктә бик тиз изрәде. Рәшидәсенең жылы сулышына битен куеп йоклап да кителгән.

Берзаман ишегалды ягындагы тәрәзәгә чирттеләр. Сабит сискәнеп уянды. Мич артындагы сәкедә йоклап ятучы Наилә белән Анияне уятмаска тырышып, шым гына тәрәзә янына килде.

— Кем бар? — диде ул, әкрен генә.

— Ач, Сабит... Бу — мин... Без... Гата, — диде тыштагы тавыш.

Гата исемен ишетүгә, Сабитның тыны кысылгандай булды, жаны, олы хәвеф сизгәндәй, калтыранып алды. «Авыл советы рәисе бу вакытта ник йөрер?..» — дигән куркыныч сорау йөрәгенең хәлен алды. Гата белән тагын таныш түгел ике ир бар иде. Төн уртасында нишләп йөрисез, дигәндәй, Сабит чакырылмаган кунакларга карады.

Килүчеләр төн уртасында нишләп йөрүләрен тиз төшендерделәр. Зәңгәрсу күлмәк өстеннән кара күн пинжәк кигән озын буйлы, какча яаклы, калын тавышлы ир:

— Өйдә кемнәр бар? — дип сорады.

— Бездә кем булсын? Үзебез, — диде Сабит, аптырап. — Хатыным да ике кечкенә кызым.

— Ә малайлар?! — диде калын тавышлы.

Сабитның йөрәге шуышып табан астына төшеп киткәндәй булды. «Вакыйфым белән Васыйлым бәхетсезлеккә юлыккан микәнни?» — дип коты очты.

— Алар — шахтада. Менә кем... Гатаулла белә инде, — диде Сабит, эчке кичерешләрен ничек тә тышка чыгармаска тырышып.

[1] Сабантуй бәйрәмен авылларда элек «жыен» дип йөртәләр иде. *(Авт. искәрмәсе)*

Малайлар турында озын буйлы бүтән сүз кузгатмады. Берничә секундка гына сузылган вакыт аралыгында Сабитның күнеленә җылы йөгереп өлгерде. Күзләрендә, болар хәзер чыгып китәр, дигән өмет очкыны кабынып алды. Шул нәни очкын өстенә көрәк белән юеш, авыр балчык ыргыткандай, озын буйлының калын тавышы яңгырады:

— Җыеныгыз!

Бу әмерне Сабитның аңы ансат кына кабул итә алмады. «Кайда җыенырга? Нишләп җыенырга? Малайларның кайдалыгын мин кайлардан белим...» — дигән сораулар башында буталды. Аның бу халәтенә игътибар итеп торган Гата сүзгә кушылды:

— Барыгыз да җыеныгыз! Гаиләнне дә уят.

Бу хәбәрдән телсез, өнсез калган Сабит мич кырыендагы эскәмиягә лыпылдап утырды. Тыны кысылды. Тез буыннары калтырады. Җилкәсеннән салкын тир бәреп чыкты. Ул, ике учын ике тезенә куеп, күзләрен йомды да үзалдына пышылдады: «И Ходаем...»

Ул арада озын буйлының тавышы тагын җанны кисеп үтте:

— Тизрәк селкен!

Сабит баш очындагы колгада эленеп торган күлмәгенә үрелде. Күлмәкне итәгеннән тотып тезләре өстенә куйды да җиңенә аягын тыга башлады. Җиңгә аягын кертә алмыйча интекте. Районнан килүчеләр аның бу гамәлен көлемсерәп карап торды. Адәм баласының соңгы чиккә җитеп каушап калуыннан алар канәгатьләнү хисе кичерә сыман иде. Ниһаять, бераздан Гата сүз кушты:

— Чалбар урынына күлмәк кимә инде син!

Түр яктагы ирләрнең сөйләшүен бүлмә артында басып тынлап торган Рәшидә хәлсезләнеп идәнгә чүгәләде. Эченә сыймаган җан ачысыннан кычкырып җибәрмәс өчен, ике учы белән авызын томалады. «И Аллам. И Аллам! — дип илерде ул эченнән генә. — Нинди гөнаһларыбыз бар соң безнең? И бер Аллам. Нишләп бу хәтле авыр сынаулар бирәсең? Төрмәгә ябарлар микәнни инде? Ни өчен? Нинди гаебебез бар соң безнең?..» Ул шулай ничарадан бичара берничә минут мышкылдап утырды да кинәт кенә елаудан туктады, йодрыгы белән күз төпләрен сөртте. «Ипием юк ич минем! — диде ул, ни кылырга белмичә. — Иртәгесен ипи салырмын дип кичтән баш кына ясап калдырдым! Күрше Зифага керим әле. Бер бөтен ипие булмый калмас...» Шушы ният белән бишмәтен иңенә салды да ишеккә таба атлады. Инде менә ишекне ачасы да чыгып кына китәсе иде. Тик Рәшидә өлгермәде, чыгып китә алмады. Районнан килүчеләрнең берсе аны беләгеннән эләктереп алды.

— Кая барасың? Качарга уйладыңмы?!

— Тышка гына чыгып керәм, — диде Рәшидә. — Кысталдым.

— Чыкмыйсың. Әнә, чиләгеңә утыр!

Рәшидә тагын почмак ягына кереп китте. «Юлга ризык кирәк бит. Безне кем көтеп тора?» Ул тиз генә ике чиләк бәрәңгене капчыкка салды. Киштәдә торган тары, солы ярмаларын да яулыкка төреп бәрәңге өстенә урнаштырды. Дүртесенә — дүрт кашык, дүрт тимер тәлинкә, ашарга пешерергә чуен алып, барысын да шул бер капчыкка тутырды...

Биш яшьлек Наиләне, ике яшьлек Анияне киендереп арбага чыгарып утыртканда, табигатьтә яңа тәүлек башланган иде инде. Стенага элengән сәгатьнең уклары төнге сәгать икене күрсәтә иде.

Район үзәгендә Сабитны, гаиләсеннән аерып, икенче камерага яптылар. Иртәгесен аны сорау алырга чакырдылар. Көне буе эшләп талчыккан, йокысыз төн үткәргән, иңенә акыл җитмәслек кайгы күтәргән хәлендә тикшерүче каршына килеп басты.

— Син ни өчен иптәш Сталинның фәрманына каршы барып, авылдашларыңны колхозга кермәскә өндисең?

Тикшерүче ана иң беренче шушы сорауны бирде.

— Иптәш тикшерүче, сезгә ялгыш...

Сабит җөмләсен әйтеп бетерә алмады, авыр йодрык өстәлгә бәрде.

— Мин нинди иптәш булыйм сиңа! Синең иптәшләрең Себердә! — дип җикерде сорау алучы. — Йә, колхозда нинди корткычлыклар оештырдың? Төкми-чәчми сөйлә!

— Мин үзем беренчеләрдән булып колхозга кердем. Бер көн эштән калганым юк.

— Син күз буяу өчен генә кергәнсең. Ә чынлыкта корткычлык эше алып барасың. Шулай бит.

— Һич алай түгел. Мин тырышып эшлим.

— Һе, эшли, имеш, — дип мыскыллы көлемсерәде тикшерүче. — Каравыл өендәниләр сөйләгәнеңне исеңә төшерергәме соң?

— Каравыл өендә ир-атлар җыелып җыен юк-барны сөйләшеп утыра инде. Ниләр сөйләгәнне кем искә алган.

— Шалишь, контра! Ә менә шайтан баласы турындагы әкәмәтне кем сөйләде инде? Шайтан әйтә, имеш: әйбәт булган, улым. Мин тыштан котыртырмын, син — эчтән... Шәп уйлап тапкансың, шә-әп!

— Мин сөйләдем, — диде Сабит, тикшерүченең йөзенә туры карап. Бу бит вәгазь генә. Кешене шайтан вәсвәсәсенә бирелмәскә...

Сабит җөмләсен тәмамламый калды, тикшерүченең усал тавышы аны бүлдерде.

— Значыт, вәгазь сөйләвеңне таныйсың!

— Таныйм. Аның ни гаебе бар?

— Вәт, контра! Колхозны тыштан да, эчтән дә таркатырбыз дип, ачыктан-ачык сөйләү, синеңчә, гаеп түгелме! Җинаять бу! Совет власте алып барган сәясәткә каршы гамәл бу! — Сабит, тикшерүченең бу сүзләреннән соң, өстәлдәге дәфтәр битедәй агарынып калды. — Менә сөйләшүебез беркетмәсе. Имзаңны сал! — диде тикшерүче, коры гына.

Сабит, үзенә сузылган кәгазьдә язылганнарны укып та тормыйча, кулын куйды...

Тикшерүче, үзенең эшеннән канәгатьлек алып, беркетмәне папкага сала-сала сөйләнде.

— Нинди иман? Колхозга кергән булып, аны эчтән таркатырга җыенгансың! Атаң Исламгали, бабаң Бикмөхәммәт гомерләре буе җир биләгән. Елгабаш хатын-кызлары бабаңнар басуында ялланып урак урган... Иман, имеш.

Сабит, башын аска иеп, тикшерүченең сүзләрен тыңлап утырды. Тыңлап утырды, уйлап утырды. «Бу адәм минем нәсел-нәсәбемне каян белсен? Димәк... мин берәүнең тамагына таш булып тыгылганмын... Ул берәү — Гата... Гата, — диде ул, үз-үзенә. — Елан шуыша, эзе калмый. Корбанын теле белән генә эзли. Җаен туры китереп, тешләп кенә ала... Елан тешенә эләксәң... Котылулар икеле. Елан теше агулы. Кем уйлаган ул чакта... Җен-шайтаннар турындагы сүзне Гата үзе башлаган иде бит...»

Җәй көне ерак болында печән чапканда, яннарына Гата килгән иде.

— Хәлләрегез ничек? Төнлә Мишәдән Су анасы чыгып саташтырмыймы? — дигән булды.

Ирләр ана каршы:

— Су анасын без үзебез юлдан яздыра идек әле. Күрәнми, — дип көлделәр. Шулчакны Сабит, сүзгә кушылып, кайчандыр әбисеннән ишеткән хикәятне

сөйләгән иде. Имеш, шайтаны да, жене дә бик гыйлем нәмәрсәләр икән. Атабыз Адәм белән анабыз Һаваны шул шайтан-иблис котыртып оҗмахтан кудыруга ирешкән ди. Шайтан үзе дә, җиргә сөрелгәч, Адәм балаларын гел котыртып, аларны юлдан яздырып яши башлаган. Моның этлегеннән Адәм балалары тәмам туйган. Беркөнне шайтанны саклап торганнар да тотып кыйнаганнар. Кыйнаганнан соң, бу берничә көн дөньяга чыкмыйча хәл җыеп яткан. Аннары элеккегедән дә кабахәтрәк эшләр кыла башлаган. Кешеләр моның баласын тотып алганнар да, мал шикелле, суйганнар. Итеннән бәлеш пешереп ашаганнар. И эзли икән карт шайтан баласын, и эзли икән. «Газиз балам, син кайда?» — дип өзгәләнгән икән. Беркөнне моның баласы чәрелдәп аваз салган: «Әти, җаным, мин монда! Адәм балалары эчендә», — ди икән. «Әйбәт булган, — дигән карт шайтан. — Әйбәт булган».

— Кара син шайтанны, ә, — дигән булды Гата, гадәтенчә, кул аркасы белән битен ышкып. — Кара син аны, ә...

— Әйе, — диде Сабит. — Безнең һәрберебезнең эчендә шайтан утыра...

«...Ул чагында кемнең башына килгән... Елан теле белән корбанын эзләгән икән...»

Шушы хикәятне, җинаятьләр кодексының 58-2, 58-9, 58-11нче маддәләренә туры китерерлек итеп бозып, Гата тиешле органнарга җибәрер, дип кем уйлаган?.. Бер генә үзгәреш керткән: каравыл йортында сөйләде дип язган. Вакыйганы эш вакытына күчергән.

...Тикшерүче өстәленә беркетелгән төймәгә басты. Бүлмәгә йөгереп милиция хезмәткәре керде.

— Алып китегез! — диде тикшерүче.

Сабит әкрен генә урыныннан кузгалды, әмма атлап китә алмый торды. Аягы астындагы идән шуыша сыман тоелды. Күз алларын куе томан каплады. Сорау алучы нидер әйтә бугай. Аның кул хәрәкәтләрен, иреннәрен шәйли шикелле, тик ул берни дә ишетми. Колагында аңлаешсыз шау-шу гына...

Кинәт аның ике калак сөяге арасына ниндидер авыр нәрсә китереп бәрде. Ул егылды...

* * *

Зираттан кайтышлый ук Рәшидә Мәһруйларга керәсе итте. Мәһруй — Исламгали абзыйның энесе Хәйретдин мулла кызы. Мәһруй дөньяга килгәндә, әнисе Сөембикә җиңги вафат була. Озак та үтми, Хәйретдин мулла да фанилыктан мәңгелеккә күчә. Ике яше дә тулып җитмәгән Мәһруй ятим кала. Ятимәне Исламгали тәрбиягә ала. Сабит белән Мәһруйның арасы өч яшь чамасы гына. Алар абыйлы-сеңелле булып, бергә уйнап үсә. Толымнары биле өстенә төшеп торган җитен чәчле, күк йөздәй зәп-зәңгәр күзле, туры, килешле борынлы, киң маңгайлы зифа Мәһруй Елгабашның күп егетләрен хыялга салып йокысыз калдырган кыз иде. Гатаның да күзе төште аңа. 1918 елны яраланып кайткан Галәви Шакиры, җизнәсе солдат Хөсәен белән аралаша-аралаша, Гата уналты яшеннән авылның иң актив революционерына әверелде. Ярлылар комитетында да ул бөтерелде, авыл Советында да ул кысылып йөрде. 1921 елгы ачлыкны кичкәч, 1924 елның көзендә, ул өйләнергә карар кылды. Борынгыча яучы әбигә мөрәҗәгать итеп тормады, күңелендә йөрткән кызның өенә туп-туры үзе китте. «Ул бит хәзер Агулы теш Гатасы түгел инде. Ул — Елгабаш авылы җитәкчеләренең берсе. «Без — бай!» — дип элек борынын чөеп йөрүчеләр аның белән исәпләшми булдыра алмастыр. Безнең илдә байлар да, ярлылар да юк хәзер. Һәммә кеше тигез», — шулай фикер йөртеп, Гата Исламгали агайларның ишеген шакыды.

— Исламгали агай, өйләнергә исәп барые, — диде ул, көрәк сакаллы, өстенә атлас камзул, буй-буй сызыклы озын ыштан кигән карт белән ике куллап күрешеп, хәл-әхвәл сорашкач.

— Сөбеханалла, улым, сөбеханалла. Бик күркәм гамәл.

— Мин дә шулай уйлыйм, агай. Сезнең бусаганы атлап керүемнең сәбәбе дә шушы.

— Аңлап бетермәдем, — дигән булды Исламгали, учын колак артына куеп.

Гата, тавышын күтәрә төшеп, сүзен дәвам итте.

— Маһруйны сорарга дип килдем мин, Исламгали агай!

Күпне күргән, күпне кичергән карт бермәлгә өнсез, телсез калгандай булды. Агулы теш Миңлегалинең оныгы, оялмыйча: «Маһруйны сорарга килдем», — дип торсын әле! — Менә бит дөньялар кая таба тәгәрәде».

— Ни бит, кем, улым Гатаулла, — диде ул, әкрен-әкрен фикерен туплап. — Синең сөальне әйтәм, бик кинәт булды бит әле. Көтмәгәндә, уйламаганда, дим.

— Уйлагыз, Исламгали агай. Уйлагыз. Мин тагын әйләнеп чыгармын!

Йорттан тынычлык китте. Исламгали агай малайлары белән дә киңәште — һәммәсенең фикере уртак: «Агулы теш»некеләр белән кода булырга теләмиләр.

Гатаның икенче килүенә гаилә мондый хәйлә уйлап куйды. Имеш, Маһруй Казанга, шәфкать туташлары әзерли торган курсларга укырга китәсе. Кыз укып кайткач, күз күрер, янәсе.

Гатаның өйләнергә йөрүе белән бәйле имеш-мимешләр бераз тынуга, Маһруйга сатучы Садретдин улы Гафурдан яучы килде. Озак та үтмәде, авылның ике могтәбәр кешесе туганлашты. Шулчакта Гата аңлады: «Укырга тели, Казанга китә...» — ише сүзләр һәммәсе ялган була. Сиңа нинди кыз бирү!.. — дип йөзенә бәреп әйтмәгәннәр генә. «Яр-а-ар! — дип, йодрыгы белән өсталгә сукты ул. — Исән булсак, күрербез! Мин сезгә әле агулы тешемне күрсәтермен! Кемнең кем икәнен шунда белерсез!..»

* * *

Маһруй килен булып төшкән көнне Гата иртүк Каенсарга, җизнәсе Хөсәен янына китте. Урыс авылыннан алып кайткан көмешкәне чөмерә-чөмерә, алар бик озак утырдылар.

...Капка ачылганда, ишегалдында тавык-чебеш туйдырып йөрүче Маһруй, Рәшидәне күргәч, кулындагы табагын төшереп җибәрде.

— А-п-аа-йй! — диде ул, үз күзләренә үзе ышанмыйча. — Апай, бәгърем, синме!..

— Мин, мин... Күрешер көннәребез дә булган икән.

— Кызлар кая соң, апай?

— Алар кияү белән әрәмәгә киттеләр.

— Әйдә, өйгә керик, апай. Самавыр яңартып җибәрик. Чәй янында рәхәтләнеп утырыйк!

Рәшидәнең иң беренче соравы Гафур турында булды.

— Сездән ни гаеп таптылар? Гафур исәнме?

— И-и, апай, — диде Маһруй, — шул Шакир белән Гата башыбызга җитте инде. Менә хәзер янымда тора торган малаем белән йөкле идем. Кызыбыз яшь ярымлык ие. Килеп керделәр. Гафурымны шул төнне үк алып киттеләр. Иртәгесен Гата белән Шакир тагын өйгә килеп керде. Мине өйдән куып чыгардылар. Ишегебезне бикләделәр. Кая барыйм? Нишлим? Кулымда яшь ярымлык бер бала. Икенчесен табар вакытым җиткән. Күршеләремә кердем

инде. Рәхмәт төшсен, курыкмадылар... Кабул иттеләр. Елый-елый тәрәзәдән карап торабыз. Шакир сыерны житәкләп алып чыгып китте... Шулай атна-ун көн күршеләрдә яшәгәч, Аллага тапшырып, үз өемә чыктым. Шуннан яшәп калдым. Ни хикмәттер, тимәделәр. Ә йорттагы бар нәрсәне алып чыгып киткәннәр ие. Аш пешерергә кәстрүл, ашарга сынар кашык та калдырмаганнар...

— Ә Гафур?..

— Белмим, апакаем... Белмим җан кисәгемнең язмышын. Аннан бер генә хат та алмадым. Гали кода минем исемнән хатлар язып эзләтеп тә карады. Рәхмәт инде аңа. Урыны җәннәттә булсын. Тик: «Тапмадык, белмибез», — ише җаваплар гына алдык. Атканнардыр инде, апай... Атканнардыр...

Иңнәренә кара болыт булып ишелгән кайгы астында ике хатын бераз тын утырды. Аннары, Рәшидә тирән сулыш алып, тагын сорап куйды:

— Гатаны әйтәм. Аның шул тиклем безгә нинди үче булды икән?

— Һе. Үзенә кияүгә чыкмавымны гафу итмәде. Бик кара эчле нәрсә икән. Мине куып чыгарганда, болай ди: «Ну, шәфкать туташы! Гафур әйбәт укыттымы? Мине иш итмәгән идегез... Дөнья куласа ул».

— Соныннан бәйләнеп маташмадымы соң? Ялгыз хатын... дип...

— Юк. Андый хәл булмады. Хезмәтнең иң авырына мине йөртте... Ялынып, дип уйлагандыр. Нәселемне корыткан, туганнарымның, якыннарымның башына җиткән җыланга ялынаммы соң?! Үз явызлыгы үзенә кайтсын!..

— Әйе, — диде Рәшидә. — Борынгылар кушаматны бик белеп биргән! Ул юньсез бәндә исәнме әле, Маһруй?

— Ул адәм актыгына таш булсынмыни! Ни төрле асыл ирләр сугыш кырында ятып калды. Авылдан киткән һәр өч ирнең берсе кайта алмады бит! Исәннәренең дә — кайсы кулсыз, кайсы аяксыз...

— Моңа берни дә булмаганмы?

— Сугышка бармады бит ул, апай! Бармады.

— Ничек бармады?

— Сугыш башланган дигән хәбәрне ишетүгә, телсез калды!

— Ә-ә, — дип ачылган авызын яба алмый торды Рәшидә. — Шулай да була микәнни?

— Була икән, апай җаным. Була икән. Район да брачлар да караган. Кеше кинәт курыкса, шулай телсезләнеп калуы мөмкин, дип әйткәннәр.

— Һаман шулай телсезме?

— Э-э, итәрсең телсез! Телле, бик оста телле. Сугыш бетүгә, теле ачылды. Елгабашта әллә кем булып яшиләр. Ат кирәк булса, алар янына барасы. Габделхәй белән Габделмән исемле малайлары атлар карый. Хөснетдин исемлесе көтү көтә. Бәйрәм саен и аларны мактыйлар инде, бүләклиләр... Косасылар килә. Түрәләргә ярыйлар шул. Гатаның телсезлеген дә район милициясе махсус оештыргандыр, дим мин. Авыл кешеләре турында хәбәр биреп торырга, дим...

— Бик мөмкин, — диде Рәшидә, уйчан гына. — Бик мөмкин... Ә Шакиры? Ул кабахәте исәнме соң?

— Исә-ә-ән! Исән, апай җаным. Чатан аягын өстерәп йөри.

— Чатан түгел иде бугай ич ул.

— Ике ай сугышта йөреп кайтты. Шунда сул аягының тәпиенә фашист пулесе тигән, имеш... Үз аягына үзе аткан, дип сөйли халык. Кем белә. Безгә караңгы. Хәзер, әнә, кыр каравылчысы. Трактор сөреп бара торган җирдә череп ята торган башакны да ала алмыйсың.

Язмыш өлешләренә тигән кайгы-хәсрәтнең, югалту-тетрәнүнең коточкыч упкынын кичкән ике хатын озак сөйләшеп утырды. Аларның йөрәгенә тирән җәрәхәт салган вакыйгалар күңелләре аша кабат узды...

* * *

Өлкәннәрнен сөйләвенә караганда, Гата Сәгъдәтшинның нәселе Елгабаш авылыныкы түгел. Бик күп еллар элек төрмәдән чыккан берәү, хәер сорана-сорана, Елгабашка килеп житкән, имеш. Өстенә иске чикмән, башына мескен бүрек, аягына тишек чабата кигән бу адәм, авылга житүгә, иң кырый йортның ишеген шакыган. Хәтирәбану исемле изге күңелле ялгыз хатын сорануочыны жәлләп, өенә керткән. Чәен куйган, бәрәңгесен пешергән. Юлаучы шул тиклем арыган, талчыккан булган ки, эченә жылы ризык кергәч, утырган хәлендә үк изрәп йокыга талган. Иртәгесен ул Хәтирәбануга үзенең башыннан үткәннәрне сөйли. Чынын сөйләгәнме ул, ялганлаганмы — моны берәү дә белми. Урман кискәндә өстенә агач авып ире вафат булган, биш ел инде берьялгызы яшәүче Хәтирәбануның күңеле тула. Жанының нечкә кыллары зеңләп, сулкылдый. Шунысы хак: Миңлегали исемле бу кеше, Хәтирәбануның күзләренә карап: «Минем көтеп торучым да, кайтып керер урыным да юк. Рөхсәт итсәң, бергә көн күрер идек... Шушында гына калыр идем», — ди. Киртә-коймалары да, абзар-куралары да күптәннән ирләр кулы тимәгәнлектән, кыйшая башлаган... Тол хатын риза була. Никахлашып тормыш башлыйлар. Ике-өч ел бик ару яши алар. Абзар-куралар да төзәтелә, киртә-коймалар да янартыла, Миңлегали жил-капка да ясап куя. Әмма тора-бара ирнең күңелен бер уй — хатынның балага узмавы борчый башлый. Ул арада чәнечке телле ир-атлар төрттереп тә алгалый: «Хәтирәбануны бу ире дә, ичмаса, бер бала белән сөендерә алмас микәнни?..» Йөрәгенә пычак булып калалган сүзләрдән соң, Миңлегали «Шимпанзе» кушаматлы Сәрбиҗамалның Мәхүп исемле сазаган кызына күз сала. Кушаматлары «Шимпанзе» булса да, Мәхүпне алай ямьсез үк дип әйтеп булмый. Ябык гәүдәле, озын буйлы, юка иренле, теле ни әйткәнне колагы ишетми торган бу кызый ирнең карашын тиз тоя. Икесенең дә күңеле очрашырга теләп, аулак урын эзли... Шулай йөри торгач, Мәхүп йөккә уза... Беркөнне Миңлегали, Мәхүпне житәкләп, Хәтирәбану янына алып ук кайта.

— Икенче хатын белән никахлашырга рөхсәт ит, Хәтирәбану жаным, — ди ул. — Миңа бу сүзләрне әйтү бик авыр... Бүтән чара да юк... Бала кирәк бит... Картайгач, ялгыз нишләрбез... Курыкма... Түр башында гына утырырсың...

Бу тамашадан өнсез, телсез калган Хәтирәбану каршы бер сүз әйтә алмый, тик тора. Ул арада башын аска иеп, бик итагатьле кыяфәт белән утырган Мәхүп сүзгә кушыла.

— Хәтирәбану апай, бергә-бергә бик тату торырбыз. Син бик әйбәт кеше бит. Сине хөрмәтләми мөмкин түгел...

— Мин рөхсәт итәм, — ди Хәтирәбану, ниһаять, телгә килеп. — Сез бит инде Мәхүпләрдә яшәргә җыенасыздыр?..

Шул мәлне, Мәхүп урыныннан торып, Хәтирәбануны кочаклап ук ала да:

— И, Хәтирәбану апай, сине ташлыйбызмы соң, Аллам сакласын! — ди.

Әлбәттә инде, Мәхүп: «Анда ничек яшисең? Миннән башка тагын кияүгә чыкмаган өч сеңел бар бит», — дип әйтә алмый. Алар шулай Хәтирәбану өеннән чыкмый...

Иртәгесен шушы хәлне белгән Елгабаш халкы «аһ» итә. Һәркемнең телендә шушы вакыйга яңгырый.

— Шимпанзе, диләр. Шимпанзе гына, пычагым! Селәүсен бу! Агач очына менеп башыңа сикерә, бугазыңны чәйни торган ерткыч!

— Мәхүбе барыр инде аның. Сораучы булмаганга гына интегеп йөрде.

— Аны хәзер дә кем сораган соң! Хатынлы иргә үзе тагылып кайткан ич!

## КЫЗЫЛ ЧИШМӘ ЯНӘ ГӨРЛИ

Туган авылым Кызыл Чишмәдән (Чуашстанның Батыр районы) Казанга укырга дип чыгып киткәнгә дә инде 43 ел узган. Әмма мин күнелемдә һаман шул авыл малае булып кала бирәм, уйларым һаман туган авылыма алып кайта.

Безнең авыл гомер-гомердән үзенең белемгә тартылуы, зыялылары, көчле укытучылары белән тирә-якта дан тотты. Без үскән совет чорында колхоз – миллионер, колхоз рәисе – СССРның Югары Советы депутаты, унган тракторчылары — районда алдынгылар, терлекчеләребез орден-медальләр белән бүләкләнә иде.

Кемнәр генә чыкмаган безнең авылдан: хезмәтләре белән Чуашстан, Татарстан, Рәсәй премияләренә, атаклы дәрәҗәләргә лаеклы булган, хәтта дөньякүләм танылган галимнәр, хәрбиләр, мәдәният хезмәткәрләре, язучылар, музыкантлар, җырчылар, рәссамнар, дәүләт структураларында югары урыннар биләүчеләр, Форбс исемлегендә югары урын тоткан эшмәкәрләр, дан казанган төзүчеләр, агрономнар, урманчылар. Бу хакта авылыбызның яраткан укытучысы, олпат зыялысы Ленар Якуп улы Исхаков иҗат иткән, «Авылыбыз Чишмә» дип исемләнгән китапта бик күп мавыктыргыч мәгълүмат бирелгән.

Әмма диндарлык белән дә әлләни дан тотмаган, кәсепчелекне дә әлләни якын итмәгән безнең авыл 90нчы еллар шаукымында югалып калды. Зыялылык, тыйнаклык, дәүләт-колхоз эшләрен тырышып эшләп, партия сүзеннән чыкмыйча тормышын алып барган халык кинәт килгән «хөрлек»не ничектер әллә кабул итмәде, әллә ышанмады, әллә инде тырышып эшләп кенә тормыш алга бармаячагын аңламый калды. Колхоз күз алдында шартлап тузды, банкрот дип игълан ителде, авыл халкы «ватык арба»га утырып калды. Төрле фәннәрдән район, республика олимпиадаларында, спорт ярышларында җинүче укучылары белән дан тоткан урта мәктәп күрше авыл мәктәбе каршында эшләп килүче БУҮгә (Балалар укыту үзәге) әйләнде. Ике дистә еллап дәвам иткән бу хәлләрне күреп, күңелгә өметсезлек шәүләсе үрли башлаган иде инде.

Әмма, Аллага шөкер, вазгыять үзгәрүгә бара. Авыл халкы сүлпәнлектән арынып, үз язмышын үз кулына алып яшәргә омтыла, авыл янә күтәрелеп килә. 1992 елда яңадан иске нигезенә күтәрелгән мәчет авылыбызның иң тырыш кызларыннан берсе Сафина Гүзәлия Мөхәррәм кызы ярдәме белән кинәйтелде. Авыл картлары гына түгел, урта яшьтәгеләр һәм хәтта балалар да дингә тартыла башлады. Авылыбызның имам-хатыйбы Мәгъсум Хәбибуллин тырышлыгы белән авыл мәхәлләсе дини мәсьәләләрне генә түгел, авыл өчен мөһим булган көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүдә дә актив катнаша. Малдый урманына якын гына яңа «Яшьләр» урамы төзелеп килә, һәр урамда яңа йортлар калкып чыга. Авылда быел инде өченче мәртәбә 50 бала катнашында «Сәләт-Батыр» уку-укыту аланы узды, киләчәктә бу алан ел дәвамында эшли торган уку-укыту үзәге булыр, шунда авылның барлык балалары һәм тирә-як авыллардан сәләтле балалар белем алыр... Авыл яшәргә, үз-үзен савыктырып яшәргә сәләтле. Аңа җылы сүз әйтү, җылы кул сузу гына кирәк.

**Җәүдәт СӨЛӘЙМАН**

— Оятсызнын да оятсызы икән бу Минлегали дигәннәре! Хәтирәбану аны йортка кертте, кеше итте. Ә ул! Жир бит!

— Юу-ук, жаный, бу адәм актыгын жиргә тинләмә син! Жир-ана ул — изге нәрсә. Бу — жылан! Шуышып килде дә Хәтирәбанунын куенына керде. Хәзер, әнә, агулы тешен йөрәгенә батырды. Өенә көндәш алып кайтсын әле! Башка сыярлык эшме бу?

Көннәр үтә торды. Әкренләп сүзләр дә тынды. Хәтирәбанунын гына жаны янудан туктамый, көннән-көн көчәя генә, яна-яна күмерләнә бара... Баштарак Минлегали бер көн — Мәхүп янында, икенче төнне Хәтирәбану янында йоклый. Дүрт-биш айдан, Мәхүпнен көмәне түгәрәкләнеп беленә башлагач, ир бөтенләй яшь хатын янына күчә. Өйнен ине белән жәелгән кин сәкенен бер ягында — Мәхүп белән Минлегали, икенче кырыйда Хәтирәбану икән.

Өй мәшәкатьләре белән көннәр тиз узган. Ә төннәр... Кышкы озын төннәр Хәтирәбану өчен тоташ газапка әверелә. «Ир бирмәк — жан бирмәк», — дигән борынгылар. Кечкенә генә өй эчендә Минлегали белән Мәхүпнен пышын-пышын сөйләшүләре, назлашып сөйләшү аһәннәре колакка килеп бәрелгәндә, Хәтирәбанунын йокысыз күзеннән чишмә-чишмә яшь ага... Ә беркөнне... Газап-сагышта янган йөрәгенең түзәр чамасы калмагач, күрше авылга, әнисенен сенлесе янына китә ул. Өч тәүлек узуга, Минлегали, Мәхүпнен әтисеннән ат алып, Хәтирәбану артыннан килеп тә житә.

— Бер сүз әйтми киткәнсен, Хәтирәкәем. Басудан кайтсак, син өйдә юк. Тәтәне сагындым, дип әйтәсен барые. Кайтыйк инде. Синнән башка өйнен яме, ризыкнын тәме юк, — ди бу, тасма теленә ирек куеп.

— Кара әле, кияү, — дигән Хәтирәбанунын апасы, мона каршы. — Син сайравын-сайрыйсын да. Сенелнен өенә көндәш алып кайтуын гына житмәгән! Ни көнгә төшергәнсен! Тәнендә чыпчык чукырлык ит калмаган!

— Тәтәкәем, гөнаһлы булма. Без аерым ашамыйбыз. Ашарга Хәтирәбану үзе пешерә, — дип жавап биргән Минлегали. — Әйдә, кайтыйк, карчыгым, — дип, хатынын йомшак кына кочып та алган.

Күнгән Хәтирәбану. Тәмле телдә таш эрер дип, юкка гына әйтмиләрдер шул. Күнгән. Үз өем — үз көем, дигәндер. Тәтә булса да, мин монда чит кеше, дигәндер.

Алар тәтәләре яныннан ат арбасына янәшә утырып киткән! Бу мизгелләрдә хатын иренен тән жылысын тоюдан изрәп, бәхетенен кабат кайтуына өметләнеп барган. Шулай бер-ике чакрым ара узгач, Минлегали атны кинәт кенә туктата да Хәтирәбануны төртеп төшерә. Хатыннын күнеленә әз генә булса да жылылык, яктылык бирә башлаган өмет кинәт юкка чыга. Күз аллары каранғылана, башы әйләнә дә сөрлегеп юл кырыена егыла.

— Син нәрсә!.. Хатын башын белән рөхсәтсез чыгып киттен! — дип акыра ир, камчысын уйната-уйната. — Мине мыскыл итәргә уйладынмы?! Мин үземне төрмәдә дә мыскыл иттермәдем. Харап булган — укасы коелган... Өстеннән көндәш алып кайткан! Бала табарга ие!

Хәтирәбану юл тузанын тырный-тырный үксегән.

— Үтер сон! Бәреп үтер мине! Мин үз өемдә үзем килмешәк булып яши алмыйм...

— Нишләп ул синен генә өен булсын? Мин аны кактым, суктым, төзәттем...

— Чыгып китегез! — дип өзгәләнә хатын.

Анын бу сүзләре янган утка керосин сипкән шикелле була.

— Ах, әле син безне куып чыгармакчымы? — дип кыза ир. — Кысыр башын белән йөкле хатынны урамга кумакчымы! Мина бала күтәреп хәер сораныргa

кушасыңмы?! — Миңлегали камчысын селтәп, бар көченә Хәтирәбануның җилкәсенә сызып җибәрә. Үзен-үзе белештермәгән ир җирдә яткан хатынны сүгенә-сүгенә кыйнарга керешә. Ярсыган үгездәй күзләре акайган Миңлегали бераздан, камчысын ташлап, юлда аунаган хатынны күтәреп арбага утырта. Аннары капчыктан литр сыешлы шешәгә салынган әче бал тартып чыгара. Башлап үзе эчә. Аннары хатынына суза. — Мә, эч. Җиңеләеп китәрсең... — ди.

Тынычлана алмыйча сулык-сулык килеп утырган хатын башын читкә бора.

— Кирәкми...

— Эч! — дип боера ир. — Эч. Гафу ит... Кызып кителде... Үзең бит... Чыгып китегез, дип... Әйдә, эч!..

— Минем аны авызыма да алганым юк!

— Алганың булмаса... Менә алырсың. Тәмле ул... Балдан гына ясалган. — Миңлегали хатынының башын үзенә борып, авызына шешәсеннән генә әчегән бал коя. — Менә шулай, — дип үзалдына сөйләнә ул. — Кая, күз яшьләреңне сөртим әле. Үзең дә инде... Авылда артымнан чыш-пыш килеп кала башладылар. Имеш, без сине куып чыгарган... Имеш, мин сине бик кагам икән... Мине беләсең бит инде... Кызып китә торган чирем бар... — Хәтирәбану бер кәлимә сүз дәшми. Кан тамырлары буйлап таралган әче балдан изрәгән гәүдәсе бушлык эчендә йөзә сыман. Ул үзе дә гел бушлыктан тора шикелле. Миңлегали нидер әйтә, нидер сөйли, әмма Хәтирәбану аларның асылына төшенми. Бераздан ир хатынына елышып ук утыра, иннәреннән кочып, күкрәгенә кыса. Күлмәк изүен чишеп, хатынның күкрәкләрен капшый... Әле генә күк күкрәп, яшен яшьнәп, давыллап яуган көчле яңгырдан соң яшәргән табигатьтәй, Хәтирәбануның күңеле дә яктыра башлый. Ул, үзе дә сизмәстән, иренең кочагына ава...

— Монда юл өсте. Эчкәрәк керик! — ди ир.

Алар басу өсләтеп барып, салам эскерте янында туктый. Ир белән хатын озак назлана. Иренең тән җылысыннан, кайнар сулышыннан кабат терелгән хатын кар эчендә чәчәк аткан умырзаяны хәтерләтә. Сөю-назлануларының иң югары ноктасына җиткән мәлендә янәшәдә басып торган карт алаша түзми — кыр-басуларны яңгыратып кешнәп җибәрә...

* * *

Мәхүп Миңлегалинең хыялын тормышка ашыра — малай таба. Аңа Сәгъдәтша дип исем кушалар. Гатаның фамилиясе шушы Сәгъдәтшадан килә.

Сәгъдәтша тугач, йорттагы тәртип бөтенләй үзгәрә. Иң беренче эш итеп Миңлегали мич артындагы тар аралыкка сәке ясый һәм Хәтирәбануның ятагын шунда күчерә.

— Синең урын-җир турына Сәгъдәтшаның бишеген асабыз. Сабыйга урын бирерсең инде, — ди.

— Чыбылдыгыгыз янәшәсенә дә элеп була ич, — дип каршы килеп карый хуҗабикә.

— Син нәрсә тагын! — дип күзен акайта ир. Аннары йомшаграк итеп: — Тиле, үзенә тыныч булыр. Бала җылаганны тыңлап ятканчы...

— Аның җылаганы мич артында да ишетелә инде. Җыласа... Җыласа, тирбәтерсез, — ди хатын, үз сүзен сүз итәргә теләп.

Аның һаман карышып торуы Миңлегалинең җенен чыгара башлый. Шуңа күрә, бүтән каршы сүз әйтмәсен дип, хатынның җан ярасына учлап тоз сала.

— Син иң элек малай тап! Бишекне кая эләргә икәнен аннары өйрәтерсең? Кысыр тәре!..

Инде йорттагы бар хезмәт Хәтирәбану өстенә төшкән. Көн саен су китергән,

мичкә яккан, гаиләгә ашарга әзерләгән, өй җыештырган... Ә төннәрендә аның сердәше күз яшьләре була. Мич артындагы тар аралык — хатынның яна-яна әкренләп корып баруының шаһиты...

Озак яши алмаган Хәтирәбану. Кырык яше тулар-тулмас якты дөнья белән хушлашкан. Аның үлемен авыл халкы авыр кичергән. Соңгы юлга озатырга олысы-кечесе — барысы да килгән. Мәрхүмәнең мәетен капка төбенә алып чыгып җеназа намазы укыгач, авылның нык тормышлы, мөхтәрәм карты Бикмөхәммәт түзмәгән:

— Күңелең булсын, Миңлегали! — дигән. — Тынычлап йокларсың инде... Йортлы-җирле булып калдың. Без синең нәсел-нәсәбеңне дә, туган җиреңне дә белмибез. Әмма менә үзеңне беләбез. Җылан син! Мескен булып шуышып килдең дә фәрештәдәй тол хатынның күкрәгенә агулы тешеңне батырдың!..

Шул көннән «Агулы теш» кушаматы Миңлегалигә ябышып калды...

* * *

Ания, җан тиргә батып, Наилә белән Тәлгать янына килеп егылды.

— Нәрсә булды? — диде апасы, аның кыяфәтенә карап. — Төсең киткән. Бүре күрдең мәллә?

— Әйе, — диде сеңлесе, еламсырап, күз читләрен сөртә-сөртә. — Ике аяклы... Бер кабахәт җан бәйләнде.

— Нәр-сә-ә? — дип сикереп торды Тәлгать. — Мин аңа хәзер учлап учына тоттырам!

— Юк, җизни... Алай түгел... Әтиегез корткыч булган, ди.

— Салага! — дип төкерде Тәлгать. — Нәрсә белә соң ул?

— Мин дә аңа: «Провокатор!» — дидем. Маһупкамал ападан сорарбыз әле. Хөснетдин исемле ул. Көтүче.

— Ә-ә, — диде Наилә. — Әнә, тегеннәнрәк чыбыркы сөйрәгән берәү безнең якка карый-карый узып киткән иде. Шулдыр ул.

Ания кич белән әлеге күңелсез очрашудан калган тәэсирләрен көндәлегенә төшерергә дип утырган гына иде, күрше хатыны Хәтимә килеп керде.

— Маһупкамал кая? — диде ул, Аниягә ямьсез генә күз ташлап.

— Хәерле кич! — диде Ания. — Алар түр якта. Чәй эчәләр.

Хәтимә эчкә үтте. Хәл-әхвәл сорашкач, чәйдән авыз иткәч, әле Рәшидәгә, әле Маһупкамалга карап:

— Әйтәсе сүземне ничек башларга белми утырам әле, — диде.

Маһупкамал сагаеп кына:

— Берәр хәвеф булмагандыр ич? — дип сорады.

— Юк ла, хәвеф түгел. Менә, балалар...

— Әйтсәң әйт инде, — диде хуҗабикә. — Балалар нишләгән?

— Минем кыз сыер сава бит. Әле генә эштән кайтты.

— Соң! — дип тәкатьсезләнде Маһупкамал.

— Менә шунда көтүче Хөснетдин... Ни дип... Маһупкамалларга кунакка кайткан бер пар көпә-көндез... чишенеп... Ялангач ук калып, малай... Мин сиңа әйтим, оятсызланып яталар... Ир-ат белән хатын-кызның нишләп ятканын аңлыйсыз инде... Яңгыр юк дип, ах-ух киләсез! Шундый хәлләрдән соң нинди яңгыр яусын! — дип әйтә икән.

Бу хәбәрне ишеткәч, Рәшидәнең чынаягы кулыннан төшеп китте. Йөзе бер агарды, бер кызарды. Ни әйтергә, ни дип җавап бирергә сүз таба алмыйча изаланды. Ниһаять, фикерен туплап, нык итеп бер сүз әйтте:

— Бул-мас!

— Мин дә шулай дип уйлыйм, — дип кушылды Маһупкамал. — Менә

нинди эссе көннәр тора. Кияүне майкадан да күргәнем юк. Өстендә һәрчак күлмәк.

— Балаларның үзләрен дәшим әле, — дип, урыныннан кузгалды Рәшидә.

— Ашыкма әле, — дип кинәш итте Маһупкамал. — Ашыкма, апай. Яшьләрнең күңелен пычрак гайбәт белән буяма. Көтүче Хөснетдин сөйләгән бит. Ул адәм актыгының кем икәнен беләсеңме? Ул — Сәгъдәтшин Гата малае!

— Алайса, аңлашыла, — диде Рәшидә. — Аңа ни җитми икән соң?

— Тик торганда түгелдер, апай. Кызларга күзе төшкәндер. Ә кызларның исе китмәгәндер. Ул малайның үзен, хатын-кызларны аулакта очратса, бәйләнә башлый, диләр...

— Жылан! — диде Рәшидә, бар ачуын, бар нәфрәтен шушы сүзгә салып. — «Агулы теш» дип Бикмөхәммәт бабай бик белеп әйткән.

— Жыланның җыланы, апай, — дип дәвам итте Маһупкамал. — Син аның мактанчыклыгын күрсәң... Косасылар килә. Кеше янында шундый әйбәт булып кыланыр. Ике кулы белән күрешкән булыр, хәл-әхвәлеңне сорашыр... Эшең төшә калса, игелек өмет итә күрмә инде.

— Гатаның нәкъ үзе икән, — диде Рәшидә.

* * *

Әтисе үлем түшәгенә ауганда, Гата уникенче яше белән бара иде. Мәңгелеккә күчәренә биш көн калганда, әтисе аны үз янына дәшеп алды.

— Улым, — диде ул, хәлсез куллары белән малаеның битләрен сыпырып. — Безнең нәселдә ир балалар әз булды. Мин үзем дә өч кыз янында бер малай булдым. Син алты кыз туганыңа — берәү. Ир-атсыз хатын-кызга авыр.

— Әти, син бар ич, — дип, борынын тартып алды Гата.

— Әй, улым... — дип куйды авыру. — Ичмаса, җизнәләрең дә башка авылда... Кызлар ялланып урак урырга бардылар да... кияүгә чыгып калдылар... Калган апайларыңа үз авылыбыз кешеләре насыйп булсын инде... Нык бул, улым. Иң элек үзең турында кайгырт. Бу кырыс дөнья киң күңелле, олы йөрәклеләрне өнәп бетерми.

— Олы йөрәкле кеше нык буладыр ич инде, әти? Көчле буладыр?

— Анысы шулай. Көчле була. Әмма андыйлар йомшак. Андыйлар кеше җәлләүчән була. Кеше дигәнең — катлаулы җан. Ул үзенә авыр чакта гына сиңа килә. Сиңа авыр чакта, читтән карап тора... Шуны онытма, улым: йомшак агачны корт баса...

Малай уйга калды. Бераз тын торгач, әтисенең сүзләрен түкми-чәчми хәтеренә сеңдерергә теләгәндәй, кабатлап сорады:

— Алайса, олы йөрәкле, йомшак күңелле булу әйбәт түгел инде, әти?

— Йомшаклык — синең үзең өчен әйбәт түгел ул, улым. Кеше иң элек үзе турында кайгыртырга тиеш. Мин менә яши-яши шушы фикернең хаклыгына инандым. Әнә, старостаны гына ал: үзебез өчен эшлибез, җәмәгать, дип сөйли халыкка. Э-э. Ул ничек яши дә... Без ничек?..

* * *

Әтиләрен җирләгәч, Гата өлкәнәеп киткәндәй булды. Кич җитүгә урамга чыгып йөгерү ягын гына карый торган малай уйчанланып калды. Әтисенең соңгы киңәшләре аңа тынгылык бирмәде.

«Жизниләр үзебезнең авылныкы булса, әйбәт икән дә бит. Кышлык утынны моннан соң ничек әзерләрләр? Ерактагы җизниләр килә алмас шул».

Шулай уйланып йөргәндә, малайның башына матур бер фикер килде. Яшьтәше Сабитның өйләнмәгән ике абыйсы бар. Аның ике апасына менә дигән

кияү инде алар. Зариф белән Касыйм абыйсын ничек жизни итәсе соң? Менә минем ике апай бар. Өйләнегез әле, дип әйтеп булмый бит. Малай, апаларын кияүгә бирү юлын тапмаса да, татлы хыялга чума. Әнә, ул Сабит белән бергә атлар коендырырга төшә. Апалары берәм-берәм сыер сава. Кергән арада Гатаны каймак белән сыйлыйлар. Сабит Гатанын терсәгенә төртеп ала. «Аша син, аша. Оялып утырма. Минем жингиләр юмарт», — дия-дия, аны кыстый...

Гатаның аяклары хыял тәэсирендә еш кына Зариф белән Касыйм янына атлый. Басуда эшләүче егетләр, Гатаны күргәч, елмаеп исәнләшә.

— О-о, Гатаулла! Нихәлләрен бар? Ниләр кырып йөрисең? — дип, елмаеп исәнләшәләр.

— Кырган нәрсә юк ла, — ди Гата, өлкәннәргә жавап бирергә тырышып. — Кыр бәрәнгесен карап кайтыйм, дигән идем.

— Әйдә, бераз ял итеп кит!

Бу тәкъдим малайның күңеленә сары май булып ята. Зариф белән Касыймның үз итеп сөйләшүләре аны үсендереп жибәрә. Егетләрнең кояшта янган йөзләренә, нык беләкләренә карап соклана ул. «Болар минем жизни булсамы?.. Мин яра алмаган тумранга болар калун белән бер генә суга инде», — дип уйлап куя.

Узган көзне утын әзерләүдә Гата да катнашты шул. Ин элек урман хужасының өенә әниләре барды. «Ике корыган имән бирермен. Килегез, карагыз», — дигән. Иртәгесен бер апасына ияреп, Гата урманга китте.

Көзге урман үзенчә матур. Аяк астын йомшак сары юрган сарган. Агачлар, үзләренең шәрәлегеннән оялгандай, тыйнак кына серләшә шикелле. Чыршы, наратлар гына көязләнеп, салкын жилләргә исләре дә китмичә, ямь-яшел килеш тора. Гата агач кәүсәләрен коча-коча хозурланып йөргән арада, урман хужасының өлкән улы Шәрифжан анын апасына корыган имәннәрне күрсәтте. Шәрифжан як-ягына күз ташлап алды да, Гатаның ерактарак икәненә инанып, кызның беләгеннән эләктерде.

— Миңсылу, арырак тагын бер имән бар. Анысын бушка бирәм. Минем теләгемне үтәсән, бушка...

Ир жөмләсен тәмамлаганчы, кыз кулын тартып алды да, кеше-кара ишетмәсен дигәндәй, пышылдап әйтте.

— Нишлисең син, Шәрифжан абый!

— Тукта әле син, ашыкма, — дип бүлдерде Шәрифжан. — Урман ул — яшәү чыганагы. Минем әти әйтә: «Үләсе килгән карга гына урманнан китә», — ди. Үзенне урманга эшкә алырмын. Печәнле дә, утынлы да булырсыз. Әйдә, якын булыйк, кире какма мине... Әйдә инде...

Болардан алты-жиде адым гына юкә кәүсәсе артында торган Гата аларның сөйләшүен ишетте. Шәрифжанның ни теләгәнен бик әйбәт аңлады. «Кара син аны, кәжә тәкәсе, үгез! — диде ул, эченнән генә. — Оялмый... Кызларга үрелмәкче була бит, ә! Хатының ишетсә, синең бугазынны чәйни бит! Апайга кагылып кына кара...»

Шәрифжан тагын ниләр сайрамакчы булгандыр, анысы бер Аллага мәгълүм. Ул арада Миңсылу ике куллап аның күкрәгенә төртеп жибәрде дә урманны яңгыратып кычкырып әйтте.

— Мин сине ару кеше дип йөри идем. Син Шәрифжан түгел, Шапшак жан икәнсең! Оятсыз!

Ул арада карт юкә артыннан Гата да калыкты. Шәрифжан каушап китте. Акланырга теләгәндәй, мыгырдана-мыгырдана сөйләнде.

— Нигә дип тавыш чыгарасың соң син? Тигән кеше юк бит әле. Мин сиңа тагын бер имән генә күрсәтим, дидем... Кирәк түгел икән, бигайбә...

Миңсылу аны тыңлап тормады. Ирнең пычрак тәкъдименә гарьләнүдән

кушучлап йөзен томалаган хәлдә, кайту ягына йөгерде. Авызыннан сөяге тартып алынган эт шикелле, Шәрифҗан ырылдап калды.

— ...Чеметим. Кем дип белдең син үзеңне! Хәерче тәре! Агулы теш! Ир күрми үлгере!..

Апасы исеменә әйтелгән бу сүзләрне Гата аермачык ишетте. Аның кечкенә йодрыклары таш булып йодрыкланды, тешләре шыгырдады, күзләреннән яшь бәреп чыкты. Әгәр көченнән килсә, ул шушы мизгелдә үк, Шәрифҗанның бугазына ябышыр иде, типкәли-типкәли җирдә аунатыр иде... Юк, булдыра алмый. Гата көчсез. Ул әкрен генә, мышкылдап, йодрыгы белән күз төпләрен сөртеп алды. Шул чакта әтисенең сүзләрен исенә төшерде... «Нык бул... — диде ул, аның киңәшләрен кабатлап. — Нык бул...»

Миңсылу утын әзерләргә урманга бүтән бармады. Бу эш әнисенә, кечкенә апасы белән Гата җилкәсенә төште. Ике тоткалы кул пычкысы белән коры имәнне кисүләре... куллардан хәл китә, аяклар сыгыла башлый. Кендегең аркаңа ябышкандай була...

— Йә, дөньяданиләр бар, Гатаулла? — ди Зариф, иске чикмән читенә утырып.

— Белмим шул!

— Һе, — ди Зариф, букчасыннан сөт тулы шешәсен ала-ала. — Ә апаеңнар нишли? Анысын беләсең инде.

Гатаның йөзе яктырып китә. «Апайлар турында тикмәгә генә сорамыйдыр...» — дигән уй аңа рәхәтлек бирә.

— Йөриләр инде шунда, — ди ул, тәгаен ни әйтергә белмичә.

Ә Зариф һаман төпченә.

— Кульяулык чикмиләрмени?

— Ә... Кульяулык... — ди, авызын ерып, Гата. — Чигәләр. Миңа да чигеп бирде Миңсылу апа.

— Матурмы?

Гата пөхтәләп төрелгән кульяулыгын, кесәсеннән алып, Зарифка суза.

— Менә!

Кырыйлары зәңгәр мулине җеп белән челтәрләнгән, өч почмагына өч алсу чәчәк чигелгән кульяулыкка бераз карап торгач, Зариф әйтеп куя:

— Минем мондый матур кульяулыгым юк!

— Булыр, Зариф абый! — дип кычкырып җибәрүен үсмер үзе дә сизми калды.

...Җәй үтеп, көзгә керделәр. Басулардан иген җыелгач, бәрәңгене алып бетергәч, ир-ат кичләрен каравыл өенә йөри. Каравыл өенә Гата да ияләште. Өлкәннәр телендә ни генә юк! Яшьлекләрендә булган мәхәббәт мажараларын да, кемнең кайчан нәрсә урлаганын да, көлке-мәзәкләр дә ишетәсең монда.

Шулай кыш чыгылды. Ә яз ул елны иртә килде. Мартның егермеләрендә үк кар астына су төште дә көннәр җылына башлады. Атна-ун көн эчендә көпшәкләнә-көпшәкләнә кар эреп бетә язды. Елгабашка терәлеп аккан тар инеш, ярларыннан чыгып, үзәннәргә, болыннарга, түбән урамнарга таралды. Ярыла-ярыла кисәкләргә бүленгән бозлар этешә-төртешә акты. Берничә көннән инеш бозлардан арынды, тынычланып калгандай булды. Болганчык салкын су эчтән генә кайный сыман иде.

Каравыл өендә ул көнне сүз гел язгы эшләр турында булды. Гата инде йокымсырый башлады. Кайтырга кирәк, дип кузгалган иде. Шул мәлне, башка авылларда көтүче булып ялланып көн күрүче Фазылҗан әйтеп куйды:

— Җыенда Исламгалинең Зарифы өйләнәсе икән.

Зариф исемен ишетүгә, Гатаның йокысы «эһ» дигәнче юкка чыкты. Колаклары торды.

— Кемгә өйләнәсе икән соң? — диде берсе.

— Исламгали абзый — акыллы кеше. Кем белән кодалашасын кү-үптән уйлап куйгандыр.

Ана икенче берәү каршы төште.

— Ба-ай кеше, диген син. Байлар бай белән аралашыр.

Зарифның кем кызына өйләнәсен берәү дә тәгаен әйтә алмады. Бу хәлдән Гатаның күнеленә җылы йөгерде. «Зариф абыйсы, әлбәттә, аның апасына — Минсылуга өйләнәчәк. Теге чакта юкка гына сораштымыни ул? Елгабашта аның апасыдай кем бар? Түбәночтагы чатан Санияме? Табак битле, тәбәнәк буйлы, бака күз Сәлимәме? Әйе, Зариф абыйсы, һичшиксез, аның апасын сайларга тиеш».

Ул төнне Гатаның йокы тишеге ачылды. Төн буе керфек какмыйча, хыял дөньясында йөрде. Хәзер алар Сабит белән кода булачак, җан дуслар. Бергә су коенырлар, бергәләп печән чабарлар... Берәрсе Гатага: «Агулы теш», — дип авыз ачса, Сабит очып кына куначак... Сабит көчле ул!

Инде җир кипте. Кыр эшләре башлана дип торганда, күк йөзен соргылт-кара болыт каплады. Болыты шултиклем түбән: агач очларына тиям, тиям дип тора шикелле. Озак та үтмәде, ишеп-ишеп, ябалак-ябалак кар яварга тотынды. Күз ачып йомганчы, урамнар, басу-кырлар ап-ак юрган астында калды, шәрә агачлар ак күлмәк кигәндәй булды. «Менә бит Алланың кодрәте, — диеште өлкәннәр. — Кыр эшләре башлана дип торганда...» Болыт ничек тиз килсә, шулай тиз китте дә. Яз кояшы тагын елмайды. Кар эреде, тик урамнар тагын пычранды, юллар сазланды.

Ул көнне Гатаның әнисе мунча яккан иде. Аларның үз мунчасы юк, һәрчак Дәүләтша абзыйлардан сорап торалар. Өйлә җитеп килгән чак булгандыр. Гатаны әнисе мунчага күз-колак булып кайтырга җибәрде.

— Томалар вакыт җитми микән? Янып бетмәгән кисәүләре булса, чыбык-чабык өстә, — дип өйрәтте.

Гата өйдән чыгып берничә адым гына киткән иде — Зариф абыйларыннан чыгып килүче Гөлсәгыйдә карчыкка игътибар итте. Игътибар итмичә мөмкин түгел: ыштанының бер балагы оек балтырына тыгылмаган иде. Мондый гамәл — Гөлсәгыйдә әбинең яучы булып баруы билгесе. Гатаның йөрәге кабыргаларына бәрелердәй булып тибә башлады. «Кемгә бара? Безгәме? Әллә... Зариф абыйсы башка берәүне сайлаганмы?..» Гата дөньясын онытты: Гөлсәгыйдәдән күзен алмады. Бу мизгелдә Гатага үзенең киләчәк тормышы, бар язмышы шушы әби кулындадыр сыман иде. Ул бит менә хәзер Гатага каршы очрарга тиеш иде ләбаса... Ул каршы килмәде, ары китте. Кемгә керер яучы карчык? Зариф абыйсы, бар күнеле белән үз итеп йөргән Зариф абыйсы, аның Минсылу апасыннан йөз чөереп, кемгә өйләнер?

Яучы карчык урман хуҗасы Шәрифҗаннарга кереп китте. «Димәк, Шәрифҗанның сеңлесе Нәгыймәне сайлаган», — дип пышылдады Гата. Ана бик күнелсез булып китте. Өмет тулы якты хыяллар, әле генә яуган кардай, эреп юкка чыкты. Аның бар дөньясын бушлык биләде. Ул үзенең бара торган юлын югалткандай хис итте. Ул, авыр йөк сөйрәгәндәй әкрен генә атлап, мунчага таба китте.

Олылар эшенә тыгылып, олыларча гәп корыр дәрәҗәдә түгел әле Гата. Әмма аны кечкенә дип тә әйтеп булмый инде. Авыл җирендә бала-чага тормышны иртәрәк таный башлый, иртәрәк кул астына керә. Урак өсте җиткәч, ул быел үзенең катгый сүзен әйтте.

— Исламгали абзыйның карчыгы килде, — дип сүз башлаган иде әнисе. — Минсылуны үзләренә урак урышырга дәшә.

Әнисенә карап Гата күзен акайтты да, җен ачуы белән:

— Киленнәре бар ич. Урсыннар! — диде. Аннары үзалдына сөйләнгәндәй өстәде. — Моннан соң без Исламгалиләргә ялланмыйбыз.

Гатаның ни өчен җенләнеп мондый карарга килүен аңламаган өйдәгеләр аңа каршы сүз озайтмады.

Ул җәйне Гата да, апалары да күрше Каенсар авылында эшләде. Бу 1916 елның җәе иде. Ирләрнең күбесе сугышта. Кайсы гына авылга барсаң да, моң-зар, хәерчелек. Шул моң-зарларның нигезенә төшенергә теләп, Гата көннәр буе уйланып йөри. Уйланырга да, моңланырга да аның вакыты җитәрлек. Ул көтү көтә. «Каенсар байлары да Елгабашныкыннан ким яшәми, — дип фикер йөртә. Берәүләрнең алты-җиде сыеры бар, ә кайберәүләр кәҗә дә асрый алмый. Әтиләре үлгәч, Гаталар да кәҗәгә генә калды. Сөрүлек җирләрен дә Исламгалиләргә саттылар. Байлар һаман байый. Ярлы һаман ярлылана... Ник? Гата эшләмимени? Аның апалары кул кушырып утырамы? Байлар бит үзләрен Алланың кашка тәкәсе итеп тота. Шәрифҗан хезмәтчеләренә: «Сез байлардан көнләшмәгез. Аллаһы Тәгалә үзе безгә бай язмыш язган. Аның насыйбы белән яшибез», — ди икән. Гатаның ачуыннан тешләре кысыла.

Беркөнне агач күләгәсендә малларның утлап йөрүен карап ятканда, аның янына бер солдат килеп туктады.

— Суың юкмы, энекәш? — диде ул көтүчегә. Гата аның тирләгән йөзенә, талчыккан кыяфәтенә, култык таягына күз салды да:

— Әйдә, утыр, абый! — диде.

Таныштылар. Хөсәен исемле икән. Сугышта яраланган. Хәзер менә Каенсарга әнисе янына кайтып килеше.

Гата букчасыннан агач җамыяк тартып чыгарды да сыерлар янына йөгерде. Аннан җамыягын тутырып сөт алып килде.

— Эч, абый. Суга караганда, сөт әйбәтрәк.

— Молодец, энекәш, — диде солдат. — Син чын пролетарий икәнсең!

Малай белән солдат дуслашып китте. Хөсәен дә узышлый көтүче янында туктала. Яңгыр явып, көтү алданрак кайткан көннәрдә Гата да Хөсәеннәргә кергәли. Ошый аңа Хөсәен абыйсы. Ул җавап таба алмый йөргән сорауларны Хөсәен гади генә итеп аңлата да бирә.

Ә көз көне, эшләр тәмамлангач, Хөсәен Гатаның җизнәсе булды. Миңсылу Каенсарга килен булып төште.

Кыш көне Гата Каенсарга кунакка да барды. Җизнәсе белән утын турадылар, кар көрәделәр. Хөсәен аннан Елгабаш турында сорашты.

— Шәрифҗаннардан, Исламгалиләрдән куркып торма син, — дип киңәш итте җизнәсе. — Тиздән аларның көне бетә.

— Бетми, җизни. Алар бит бик бай, — диде Гата. — Ул Исламгалиләрнең җирләре күпме икәнен беләсеңме син?

— Белмәсәм дә, чамалыйм, — ди аңа каршы Хөсәен. — Ул җирләр озакламый крәстияннеке булачак. Тиздән, энекәш, ил белән эшче-крәстиян комитетлары идарә итә башлаячак.

— Елгабашта андый комитет юк бит, җизни!

— Әлегә Каенсарда да юк. Аны без, безнең кебек ярлы халык оештырырга тиеш.

— Оештырып кара, бар. Жыеннарда ярлы-ябагай авыз ачса, Шәрифҗан абый хәзер урынына утырта. «Сез нәрсә, патша хәзрәтләре фәрманына каршы киләсезме? Себергә китәсегез киләме?» — дип кенә кычкыра.

— Ә сез курыкмагыз. Озата алмыйлар Себергә. Халыкны өркетмәкче генә була. Чынлыкта, үзе шыр җибәреп ята. Башкаланың кайнаганын, дөньяның айкалганын белмимени ул?! Белә. Так што, энекәш, син Шәрифҗаннан да, башкасыннан да курыкма! Алар бездән курыксын!

* * *

Ания өлкәннәрдән ишеткәннәрен түкми-чәчми язып бара. Яза-яза да туктап уйлана. Әле һаман да исән-имин йөргән Гата Сәгъләтшин Елгабаш авылыннан ун гаиләне кудырган. Алар һәммәсе — колхозчы. Һәммәсе мал-мөлкәтен бирен колхоз оештыруда катнашкан. Бер Сәгъләтшин сүзенә карап, никадәр кеше «тәмугка» озатылган... Гатаулла абзыйның бу кешеләрдә ни үче булган? Сораулар... Сораулар... Сораулар... Ания, аларга җавап эзләп, үзе тарих дәреслекләренә мөрәҗәгать итә. Ул тәмамлаган җидееллык мәктәп дәреслекләрендә язылганнарга караганда, Африка халыклары һаман әле азатлык өчен көрәшә. «Димәк, кешегә җир җитми булып чыга ич инде», — дигән нәтиҗә чыгара ул, үзенең яшь акылы белән. — Гата Сәгъләтшинның да җире булмаган. Алай дисән... бар җирләрен дә Исламгали бабайга сатканнар ич. Җирен булу гына җитми, аны эшкәртергә дә кирәк бит. Югарыдан килгән фәрманны үтәү генә — аның гамәле. Алай дисәң... Авылның ике бай гаиләсенә тимәгәннәр, ә көтү көтеп көн күрүче, ярлы Фазылҗан абыйны озатканнар...» Адашкан кеше, юлын табу өчен ялгыш киткән урынына кире килгәндәй, Ания дә тарихка кабат әйләнеп кайта. Тау итәгеннән бормаланып аккан инешкә сыенып утыручы Елгабашка революция шавы ничек килеп кергән? — Ания авылдагы шул көннәрне күз алдына китерергә тырыша.

...Ничәмә-ничә ел инде сугыш газапларыннан җәфаланып, хәерчелектән интегеп мон-зар белән яшәүче Елгабашка җәй уртасында Шакир Галләмов кайтып керә. Моннан бер ел элек кенә хәрби хезмәткә алынган егетнең кинәт кайтуы имеш-мимешләргә сәбәп була. «Хәзер Герман белән сугышасы түгел. Дошман үз авылыбызда. Байларны себереп түгәсе», — дип әйткән, имеш.

Кич саен халык җыенга җыела. Авылның бер башында урта хәлләләр, байлар нотык тота. Икенче башында — ярлы-ябагай. Үсмер Гата Шакирның һәр сүзен йотып кына бара. Сонрак Хөсәен җизнәсеннән алган мәгълүматлар ачлы-туклы яшәгән Гатаның күңеленә өмет нуры кертә. Ул карашының кинәюен, күкрәгенә куәт инә баруын тоя.

* * *

1917 елның 10 ноябре иде. Шәрифҗан өязгә китте. Ул аннан коточкыч хәбәр алып кайтты. «Вакытлы хөкүмәт бәреп төшерелгән! Хакимият эшче-крестьян комитетлары кулына күчкән...» Кинәт өстенә төшкән кара кайгыдан Шәрифҗан уйлау сәләтен югалтты. Ул бертуктаусыз: «Хәзер ни була инде?» — дип, үз-үзенә сорау бирде. Күңеле нидер сизенүдән бертуктаусыз ашкынды. «Китәргә, качарга... Ераккарак олагырга...» — дип уйлады ул. Иртәгесен атын җикте дә урманга китте. Алтын-көмешләрен чүлмәккә салып, юан имән төбенә күмде. «Дөньялар гел болай тормас әле... Бу бәхетсезлек вакытлы күренеш кенә», — дип уйлады ул, үз-үзен юатып.

Ә икенче төнне кирәк-яракларын капчыкка тутырып, бераз ризык алып, фәкыйрь генә киенеп, гаиләсе белән Урта Азия ягына юл тотты. Алты почмаклы итеп нарат бүрәнәләрдән салынган иркен йортта карт әтисе белән әнисе торып калды...

1918 ел башында унҗиде яше тулган Гата, ярлылар комитетының иң актив кешесенә әверелә. Февраль башында Гатаны Шакир район үзәгенә җибәрә. Егет аннан ярлылар өчен сөенечле хәбәр алып кайта. Узган елгы салымнарын түли алмаганнарның салымнан азат ителүләре турында була ул хәбәр. Моннан соң һәр авылда Совет төзеләчәк, дип аңлаталар ана районда. Озак та үтми, Елгабашта да Совет төзелә. Аның рәисе итеп Шакирны сайлыйлар, ә ярдәмчесе Гата була. Совет утырышы нинди карар чыгарса — закон шул буласы икән. Советның беренче утырышында ук Шәрифҗаннарның урманын, Исламгали агайның

жирләрен, Касыйм белән Зарифның тегермәннәрен җәмәгать файдасына алырга, дигән карар чыгарыла.

Кимсенүле хәерче балачагы, кышкы салкыннарда утынсыз интегүләре, Минсылу апасына Шәрифҗанның пычрак, гарьлекле тәкъдиме Гатаның җанына эремәс таш булып оялаган иде. Форсаты чыкты. «Бу карарга тагын бер өстәмә кертик әле, — ди ул утырыштагыларга. — Җәмәгать, абыйлар! Һәммәгезнең тәрәзә бусагасы җиргә тигән. Ишеләм-ишеләм дип торган терәүле өйләрдә яшибез. Шәрифҗан урманыннан агач бүлеп бирик без халыкка». Хөсәен җизнәсе киңәш иткән бу фикер Гатаның дәрәҗәсен күпкә күтәрә.

Икенче көнне Елгабаш Советы әгъзалары, өч ат җигеп, Шәрифҗанның өенә килә. Беренче чанада Шакир белән Гата. «Гата, мөгаен, яшь чагында, Хәснетдине төсле булгандыр, — дип уйлый Ания. — Кара чырай, астыртын явыз караш. Теленнән төшкән сүзләре ялтыравыклы, пычрагы эчендә калыр...» Әйе, әнә, Гата чана башына ук утырган да, бертуктаусыз дилбегәне кага-кага, атны куалый. Аның салкыннан кызарган битенә җил бәрә, бәс сарган борын тишекләреннән пар чыга.

Шакир, бу тантана ләззәтеннән әсәрләнеп, Гатаны ашыктыра. «Куала! Кабахәтләрнең ояларын тизрәк туздырыйк!»

Шәрифҗанның әтисе боларның килеп керүенә һич аптырап калмый. «Талагыз, тала! — ди ул килүчеләргә. — Кеше малы ишәк мае ул. Бик тиз бетә». Аннары Шакирга карап әйтә: «Синең бабаң карак булган. Атаң да карак иде. Күрше авыл Саттарның бердәнбер атын урлап сатты. Әмма баемады. Син талаучы ук икәнсең. Минем маңгай тире түгеп җыйган малларым бугазыңа кара кан булып тыгылсын да, син шуңа тончык!»

Бу сүзләрдән соң әби белән бабайны Шакир өйләреннән үк куып чыгара. Алар шул көннән мунчада яши...

Шәрифҗаннарның келәттәге бар ашлыклары, абзардагы маллары ярлыларга өләшенә...

Колхозлашу еллары башланганда, Гата инде Совет рәисе дәрәҗәсенә күтәрелә.

Ания, уйлары белән, ул чор вакыйгалары эзеннән баруыннан туктап, үз-үзенә сорау бирә: «Шушы хәлләрдән соң Гата ни бите белән Исламгали бабайның ишеген атлап керде икән? Маһруй апайга өйләнәм дип әйтергә ничек җөрьәт итте икән? Димәк, боларга «оят», «намус» дигән төшенчәләр билгесез... Юу-ук, бу гади үч алу гына түгел. Бу хәлләрнең асылы тирәнрәк. Әйе, революция җирсезләрне җирле иткән. Элек «бай» дип аталганнар да колхозга кергән. Дөнья тигезләнгән бит инде! Аларны нигә куарга? Утын ярган җирдә йомычка кала, дигәндәй, корткычлык кылып йөрүчеләр дә булгандыр, — дип фикер йөртә Ания. — Елгабашта андый хәлләр булмаган ич. Димәк, югарыдан фәрман килгән дә, болар аны бик тырышып үтәгән. Хәтта, әнә, кәҗәдән зуррак мал асрый алмаган Фазылҗан абыйны да озатканнар...» Аниянең башына кинәт мондый уй килде: «Аңа нинди яла яктылар икән? Маһупкамал апа белә торгандыр. Сорашырга кирәк».

* * *

Исламгали агайның малайлары — Касыйм, Зариф, Сабит — гаиләләре белән авылдан сөрелде. Алар артыннан ук Гафурны да озаттылар. Һәммәсенең дә гаебе «зур» — алар коточкыч «җинаять» кылган. Гаепләре җинаятьләр кодексының 58-2, 58-9, 58-10, 58-11нче маддәләренә туры килгән... Урак урганда күзенә камыл төртелүдән сукырайган карчыгы белән Исламгали агай ялгыз калган. Оялары туздырылган, ятим калдырылган әби-бабайлар кайгы йөген озак тарта алмый. Алар һәммәсе бер-бер артлы дөнья куя... Елгабаш сары сагышка уралып, монсулыкка төренеп кала. Шулай авыл үз көенә тын гына яшәп яткан бер иртәдә Фазылҗанның такмаклый-такмаклый елап йөгергәне урамнарны яңгырата.

— Бүреләр... Бүреләр... Харап иттеләр... Харап иттеләр, — дип үкси ул.

Көтү куганчы мал-туар тирәсендә чуалган хатын-кыз сарык фермасына йөгерә. Фазылжан — ферма каравылчысы. Бүреләр фермага һөҗүм иткән икән.

Буйдан-буйга ике рәт киртә белән генә тотылган утар эчендә унлаган сарык үлеп ята. Ерткычлар аларны буып, каннарын эчкән. Ул арада фаҗига булган урынга Гата белән Шакир килеп җитте. Аларга куркудан төсе качкан Фазылжан ияргән. Кия-кия инде тишелеп беткән киез эшләпәсе белән йөзен сөртеп, ул һаман берүк сүзләрне тәкрарлый:

— Харап иттеләр... Харап иттеләр!..

Фазылжанның тир белән каешланган күлмәк якасына, кырык ямаулы чалбарына Гата җирәнгәндәй караш ташлады да әче итеп бер сүгенде. Аннары:

— Төн буе йокы жыясың! Корткыч! — дип җикерде.

— Ничә тапкыр әйттем... Читән тотарга кирәк, дидем... — дип мышкылдады Фазылжан. — Йокламадым мин... Малларны карап кына кергәнием... Ятып кына торганыем... Шул арада...

— Улама! — дип җикерде Гата. — Түләрсең!

— Нәрсәм белән түлим мин аны?

— Башың белән! — диде Гата, исе дә китмичә.

— Син ни сөйлисең, Гатаулла? — диде арадан берәү. — Хәзер ач бүредән күп нәрсә юк. Бу бәхетсезлеккә бүген Фазылжан юлыккан. Ул булмаса, бүтән юлыккан булыр иде.

— Ялынма аңа, — диде Фазылжан, күз яшьләрен сөртә-сөртә. — Агулы тештән кем котылган?..

Бу сүзләрдән соң Гата Сәгъдәтшин кырт борылды да тиз-тиз атлап китеп барды. Ферма янына җыелган халык: «Бу хәзер үк Фазылжанны кулга алырга милиция чакырта икән», — дип уйлап калды. Әмма милиция килмәде. Авыл тынычланды. Ике көн эчендә сарыклар утарын озын читән белән әйләндереп алдылар.

Уракка төштеләр. Бәбкәгә куелган көлтәләрне әкрен-әкрен ташып, әвен базларында киптерә-киптерә суктырылган ашлыкны амбарга сала бардылар. Октябрь ае коры килде. Ай башында шатырдатып катырды да, шуннан эретмәде. Маллар ужымда йөреп кинәнде.

Ашлык амбарларына якын гына яшәүче кладовщик Кадыйр абзыйның бер асыл гадәте бар. Ул һәр көнне таң беленгәндә торып ишегалдына чыга. Ин элек үз малларына күз-колак була да амбарлар тирәсен әйләнеп кайта. Октябрьнең егерме алтынчы иртәсе иде. Кладовщик амбар янына килеп җиткәч, үз күзләренә үзе ышанмыйча туктап калды. Дүрт почмагы да калын-калын ташлар өстенә куелып салынган амбар астыннан бодай бөртекләре сибелеп килгән. «Тычкан-күсе тишкәндер, дисәм... амбар читенә бөртек ничек чыгар?» — дип уйлап, Кадыйр абзый арырак күз сала. Ни гаҗәп: бодай бөртекләре сибелгән эз су буена таба алып бара. Аннары яр астыннан урамга керә дә... инештән өченче йортта гына яшәүче Фазылжаннарга таба борыла. Кадыйр абзыйның күзе акая, җилкәсеннән салкын тир бәреп чыга. «Нишләргә? — дип пышылдый ул үз-үзенә. — Граммына хәтле исәптә бит аның! Үлчәве җитмәсә, мин җавап бирәсе... Хәзер үк Гатаны алып килергә...»

Амбарның идән арасын астан балта белән каерып, тишек капчыкка ашлык агызуның һәм аны Фазылжаннарга илтеп куюның Гата эше икәне берәүнең дә башына килми... «Карак»ны икенче көнне үк авылдан алып китәләр...

* * *

«Җәйге яңгыр өлешле була», — дигән иде Мәһупкамал апасы. Хак әйткән икән. Узган атнадагы болыт Елгабаш турысына ук килеп житкән дә иде. Дөбер-шатыр йөреп күк тә күкрәде, күк йөзен урталай бүлеп яшен жепләре дә сузылды. Тамчылап кына яңгыры да сибәләгәндәй итте. Аннары: «Монда туктасам, соңга калам», — дигәндәй, итәк-жиңнәрен жилфердәтеп, болыт китеп тә барды. Яңгырны дүрт күз белән көтеп торган елгабашлылар иртәгесен «ах-ух» килеп гәп корды. «И, малай, Каенсарда явып та караган, ди. Бала-чага урамда су ерып йөргән».

Бу хәлдән соң өч көн узуга, Елгабаш күге кырыенда канатларын җәйгән кечерәк кенә болыт пәйда булды. Тыйнак кына килгән кунактай, ул әкрен-әкрен авыл өстенә якынлашты. Бераздан эре-эре тамчылар сибәли башлады. Озак та үтмәде, яшен яшьнәп, күк күкрәп җибәрде дә, чиләкләп-чиләкләп яңгыр яварга кереште. Ания, ишегалды чирәменә яланаяк чыгып басты да ике кулын күккә сузды. Яңгыр жепләре бите буйлап, аннан култык астын кытыклый-кытыклый, тәненә йөгерде. Аның маңгаенда, битләрендә бертуктаусыз яңгыр тамчылары биеште. «Мондый рәхәт ләззәтне, сафлану хисен бары тик Табигать үзе генә бирә ала торгандыр», — дип уйлады кыз.

Күк күкрәү сирәгәйде, ә яңгыр туктамады: яуды да яуды. Авыл өстендә утырып, иркенләп, рәхәтләнеп яуды. Бераздан, юешләнүдән күшеккән сарыклар бәэлдәшеп кайтып керде. Башка вакытта тәм-том эзләп, туры кайтмыйча, ындыр тирәләрендә буталып йөрүче маллар да тизрәк коры торакларына ашыкты.

Дөньяга яңгыр исе таралды. Сулышлар киңәеп китте, һава җиңеләйде. Яфракка сарылган тузаннары юылган агачлар елмаешып утыргандай тоелды.

«Бүген яшьләр болынга чыкмый. Бүген алар йокы симертәчәк, — дип уйлады Ания. — Күрше Минжамал да фермадагы эшен иртәрәк тәмамлар. Көтү күптән кайтты ич».

Елгабашта кунак булуларына бер атна дигәндә, Аниянең көндәлегенә шактый мәгълүмат өстәлде. Әмма аның истәлекләре әби-бабайларына, әти-әниләренә генә кагылышлы. Аларның бүгенге дәвамы нинди? Үз-үзенә шушы сорауны бирүгә, күзалдына Хөснетдин килеп баса. «Минем белән ни турында сөйләшергә теләде икән ул? Мин үзем дә артык тупас кыландым бугай. Сөйләгәнен тынлыйсым калган. Язылачак хикәямә менә дигән бер мисал булыр иде. Провокатор, имеш... Минжамал безнең очрашуны белми ич. Сорашыйм әле...»

Көн саен иртүк торып көтүгә чыгучы Хөснетдин кайтуга ашап-эчте дә печәнлеккә менеп ауды. Урамда шыбыр-шыбыр яңгыр ява. Салам түбәләр астына куыш ясап оя корган чыпчыклар үзара нидер серләшеп, шыбырдашып ала. Хуш исле кипкән печән табигатьнең сихри бишеге сыман. Кош тавышлары, яңгыр шыбырдавы үзеннән-үзе йокыга талдыра. Ул уянып киткәндә, яңгыр туктаган, күк йөзе аязган иде. Кояш яңа гына тау астына тәгәрәп төшкән. Күкнең тау өстенә тоташкан урынында кып-кызыл болыт сузылып калган. Өйдәгеләр, тыштагы эшләрен тәмамлап, кичке ашны ашый, күрәсең. «Мине, йокласын, дигәннәрдер... Бүген яшьләр болынга да чыкмый инде. Йокы да туйды. — Көч-куәте ташып торган егетнең башына шулчак мондый уй килде. — Ылыслыга барсам... Бакча артлатып кына чыгам да... Ике чакрым тирәсе ара. Нина Алексеевнага туры керәм. Көмешкәсе булмый калмас...»

Бу уй аны үзеннән-үзе алга әйдәде. Күнеле торган саен ныграк кытыкланды. «Көмешкә булса... Ылыслыда яшь, тыгыз тәнле ялгыз хатыннар да бар...» Егет тиз-тиз генә киенде дә печәнлектән төште. Абзар артыннан бакчага чыкты да чирәмле сукмактан инешкә таба юл тотты. Аннан болын буйлатып кына туп-туры Ылыслыга китте.

Ул килеп кергәндә, Нина Алексеевна жиделе лампа каршысында нидер бәйләп утыра иде.

— Хоснетдин... — диде ул, аптырап. — Болай кичләтеп нишләп йөрисең?

Илле биш яшенә житкән Нина Алексеевна Елгабашның бар кешесен дә белә. Механизатор булып эшләүче ирләр ана кайчакта, яшертен генә, ашлык та китереп китә. Хатын аларга көмешкә чыгарып куя. Ашлык әчегән апара чүчкаларына булса, көмешкәдән үзенә дә өлеш чыгара. Хөснетдиннең дә көмешкә алганы булды.

Беркөнне бер сыер кинәт авырып китте. Мал ыңгырашты да ауды. Аптырады көтүчеләр. Хужасын алып килделәр. «Ярамас үлән ашагандыр. Чалырга кирәк», — диеште ирләр. Сыерны суйдылар. Көтү Ылыслы ягы болынында иде. Хужа шулчакны: «Хөснетдин, менә сиңа сыерның бавыры, йөрәге. Нина Алексеевнадан көмешкәгә алыштыр». «Мина көмешкә бирерме соң ул?» — дип икеләнде Хөснетдин. «Бирер, бирер, — диде хужа. — Хәлне сөйләрсең. Мин жибәргәнне әйтерсең. Бар, бар», — дип мутланып күзен кысты ир. Хөснетдиннең юлы унды ул чакта: литрлы банка белән көмешкә күтәреп килде.

— Хоснетдин... — дип, аптырабрак тагын эндәште хатын «о» авазын калын итеп. — Кичләтеп нишләп йөрисең?

— Мин... ни... — дип таптанды ишек төбендә Хөснетдин. — Мин бик туңдым... Яңгыр астында юешләнеп беттем. Өйгә кайтып жылы кием дә кидем. Барыбер калтырата, каһәр.

— Ә-ә, — диде хатын, эшнең нәрсәдә икәнен төшенеп. — Айда, утыр, уз. Тик без почмак якка керик. Милиция дигән халык та бар бит. Аларның шымчылары да житәрлек.

Нина Алексеевна, шулай сөйләнә-сөйләнә, жиделе лампасын тотып, аш-су әзерли торган якка атлады. Хөснетдин ана иярде. Хатын өстәл астыннан вак такталардан кагылган кечкенә әржә сөйрәп чыгарды да аннан бер шешә көмешкә алды. Тәлинкәгә бер-ике телем ипи кисте. Аның янына төбе белән йолкып алынган яшел суган куйды. Аннары стаканга көмешкә салып, Хөснетдин алдына этәрде.

— Айда, Хоснетдин, эчеп жибәр. Эченә жылы керер!

— Үзегезгә дә салыгыз инде, Нина Алексеевна, — диде. — Үзем генә әллә ничек... Күнекмәгән...

— Айда соң, — диде хатын, карышып тормыйча.

Хатынның көмешкәсе куәтле иде. Яшь егетнең гәүдәсе буйлап рәхәт жылылык йөгерде. Жинелчә генә башы әйләнгәндәй булды. Бу мизгелдә ана Нина Алексеевнадан да юмарт, аннан да әйбәт кеше дөньясында юк сыман иде.

— Әле мин мал суйганда сиңа тагын бавыр китерермен, — диде Хөснетдин, хатынга үзенең бик рәхмәтле булуын сиздереп.

— Ой, шап булыр, шап. Син аша але, Хоснетдин, аша, — диде Нина Алексеевна.

Аннары Нина Алексеевна Елгабаш кешеләре турында сорашты. Көтүдә сыерын суйган хужа да телгә керде. Шул мәлне аның: «Нина Алексеевна мине белә...» — дип, мут кына күз кысуы егетнең исенә төште. «Нинди тыгыз тәнле. Имиләрен тотып, башыңны куеп ятарлык... И-их, ничек итеп күндерергә...»

— Нина Алексеевна, — диде Хөснетдин. — Әйдә, пар булсын инде. Тагын берне сал. Игелегеңне гомер онытмам!

Тагын йөз грамм көмешкә эчеп куйган Хөснетдин үзенә куәт иңүен тойды. Беләкләренә көч керде. Сулышлары кинәеп китте. Янәшәсендәге шушы хатынны үзенеке итү теләге тәкатьсезләнеп кузгалды.

— Нина Алексеевна, чибәр булгансыз сез яшь чагында, ә? — диде егет, хатынның күкрәкләрен күзе белән «ашап».

— Яшьлек үзе чибәрлек ул, Хоснетдин. Син аны ул чакта аңламыйсың гына.

— Йо-ок, Нина Алексеевна, син особо матур кеше. Син һаман ир-атларның башын әйләндерә торган хатын.

Яшь егетнең күңелендә нинди теләк кайнаганын уена да кертмәгән хатын рәхәтләнеп кеткелдәп көлеп җибәрде. Бу көлүне үзенчә аңлаган Хөснетдин тиз генә Нина Алексеевнаның янәшәсенә үк күчеп утырды да иңеннән кочып алды.

— Мин сине шундый якын итәм, Нина Алексеевна, — диде.

— Мин дә якын итәм сине, Хоснетдин. А то синең белән шулай утырыр идемме?

Хатынның җылы сүзләреннән егетнең ташып торган дәрте ургылып ук китте. Ул, үзе дә сизмәстән, сул кулы белән ныклап кочаклады да уң кулы хатынның күкрәгенә ябышты. Егетнең кинәт купкан өермәне хәтерләткән бу хәрәкәте Нина Алексеевнаны бераз каушатып җибәрде.

— Чү, Хоснетдин! Нишлисең? Булмаганны... — ул, тыпырчынып, Хөснетдиннең келәшчәдәй кысып алган кулларыннан ычкынмакчы булды. Хатын карышкан саен, Хөснетдин кызышты, котырынды. Алар әүмәкләшеп идәнгә тәгәрәделәр.

— Җибәр, Хоснетдин! Кычкырам! — дип кисәтте хатын.

— Кычкырма, кычкырма... — дип кайнар пышылдады Хөснетдин. Хатынның әле иреннәрен суырып, әле муенын ялап. — Кычкырма... Икебезгә дә рәхәт кенә ич... Гайбәт таратма... — Әүмәкләшә торгач, егет өстенлек алды, җайлап урнашты. Әмма хатын боргаланды, тыпырчынды.

— Мин сине болай гына калдырмыйм. Милициягә җиткерәм, — дип еламсырады хатын.

Чалбар төймәләре чишелгән, тәкате төкәнгән Хөснетдин, «милиция» сүзен ишеткәч, түзмәде, йодрыгы белән хатынның колак төбенә тондырды.

— Син нәрсә, әүлия булып кыланасың соң!

Беразга тынып калган Нина Алексеевнаны ризалаштырдым дип уйлап, Хөснетдин аның эчке киемнәрен салдырырга үрелде. Ә хатынның күзе өстәл астында яткан балтага төшкән иде. Хөснетдин дә күреп алды ул балтаны. Ул, корбанына ташланган еландай, күз ачып йомганчы, хатынның кулын эләктереп алды да йодрыгы белән яңагына орды. Йодрык чигәгә туры килгән иде. Хатын ыңгырашып алды да, муены йомшарып, баш бер якка авышты. Кызышудан, үз-үзен белештермичә кылган бу гамәл Хөснетдинне кинәт каушатып җибәрде. Ул куркып калды. «Үлдеме әллә?» — дип уйлап алды ул. — Нишләргә инде? Ничек котылырга соң?» — егетнең башында шушы сорау бөтерелде. Тик ул бу мизгелдә уйлау сәләтен югалткан иде. Аның бар күзәнәге үз-үзен коткару инстинктына гына буйсынган иде. Ул тиз-тиз генә як-ягына карап алды. «Иң элек тәрәзәне капларга кирәк икән, — дигән уй үтте аның башыннан. — Яктылык ишегалдына да төшмәсен. — Хөснетдин сәкедәге одеялны алып, калтыранган куллары белән, тәрәзә өстенә кагылган тактага кыстырды. Тагын Нина Алексеевнага күз салды. — Үлгән микән әллә бу? Исән булса... минем баш бетә бит... Үлгән булса да... үтерүченең эзенә төшәргә мөмкиннәр... Нишләргә соң, нишләргә?.. Моннан тизрәк таярга кирәк бит... Тукта әле, мин тотып эчкән стаканны сөртим. Бармак эзләрем калмасын...» Егет, стаканны сөртергә ниятләп, эскәтер читен тарткан иде, өстәлдәге җиделе лампа ауды да керосины түгелде. Хөснетдин алны-артны уйлап тормыйча, ут капкан эскәтерне лампасы-ние белән идәнгә сөйрәп төшерде. Хәзер монда бер минут та калырга ярамаганын ул әйбәт аңлады. Ул тиз генә ишек катындагы галошын киде дә

иплэп кенә ишекне япты. Аннары, урамга чыкмыйча, бәрәңге бакчасы аркылы гына Елгабаш ягына элдерде.

Ылыслылар авылда янгын барлыгын абайлаганда, өй эче янып, түшәмнәр ишелеп, ут түбәгә үрләгән иде.

Күмергә әверелгән бүрәнә башлары өч тәүлек буе төтенләп торды. Нина Алексеевнаның каралып укмашкан калдыкларын ак җәймәгә төреп, гробка салып җирләделәр... Бар нәрсәне ут йоткан нигездә янгыннан каралган, төтен исе сеңгән мич кенә утырып калды. Ул мичтән ниндидер шом, каһәр тарала сыман иде...

* * *

Хөснетдин болынга чыккач, артына карый-карый, ярты юлга житкәнче йөгерде. Анын бөтен уе — янгын урамны яктырткачы өенә кайтып житү. Йөрәге, читлек эченә ябылган кыргый коштай, бәргәләнә-бәргәләнә тибә. Бу тибеш ана болында янгырый сыман. Ярый әле, төн карасы аны яшерә. Тирә-юнь тып-тыныч. Янгырдан сон, үлән аралары дымлы булгангамы, чикерткәләр дә сайрамый, этләр дә йокыга талган. Хөснетдин бераз хәл алды да тагын йөгерде. Ниһаять, ул кайтып житте. Бакча артлатып кына абзарга керде дә печәнлеккә үрмәләде. Тиз генә чалбарын, күлмәген салып печән өстенә жәеп куйды да ятагына ауды. Тик... күзен йокы алмады. Башында куркыныч сораулар буталды: «Ылыслы күгендә ут яктысы күренмәде бит. Ул юри генә яткан булгандыр да мин китүгә эскәтерләрне сүндергәндер. Иртүк милициягә хәбәр итәр... — Егет бу хәлләрне күз алдына китерә дә коты чыга. — Нишләдем мин, нишләдем!..» — дип кушучлап башын тота.

Иртәгесен ана әнисе эндәште.

— Улым, көтү куар вакыт житте. Тор инде.

— Авырыйм мин, әни, — диде Хөснетдин әкрен генә. — Төне буе калтыратып чыкты. Салкын тидергәнмен, ахры...

Хөснетдиннен «төне буе авырып чыгуы» көтү куарга чыккан урам хатыннарына да билгеле булды.

— Кичә, суга төшкән тавык шикелле, көтүдән күшегеп кайтканые. Төн буе йокламады. Жар булды, ут янды, балакаем, — дип сөйләде әнисе.

Тәнен уарга дип «авыру»га кибеттән аракы алып кайттылар. Ул аны әкрен-әкрен эчеп бетерде.

Ылыслыдагы янгын, андагы фажига хәбәре Елгабашка төш вакытында гына килеп житте. Нина Алексеевнаның янып үлүе авылдагы вак-төяк борчу-кайгыларны онытырды. Милиция хезмәткәрләре янгын чыгу сәбәпләрен төрлечә юрап карады, тик тәгаенләп әйтә алмады. «Учагыннан берәр күмер идәнгә төшкән булгандыр. Шул әкрен-әкрен көйрәп утыргандыр. Бичаракаем, йоклаган инде ул, йоклаган...» — дип фараз кылды авыл халкы.

* * *

Санаулы көннәр тиз уза. Кунакларның да китәр чагы житте. Аниягә авыл тормышы нык тәэсир итте. Үзенең көндәлеген укыган саен, сораулары арта гына барды. Чишмәләрдән баш алган кечкенә инеш ярына сыенып утырган Елгабаш авылының үткәнен, әле дә анда яшәүчеләрнең тормышын кабат-кабат күз алдына китерергә тырышты. Елгабаш өстендә дә сәяси жилләр уйнаган. Ул жилләр берәүләрне иркаләсә, икенчеләрне һәлакәт чокгылына очырган. Сәяси юл белән килеп чыккан һәр афәт адәм баласы кулы белән эшләнгән. Әнә, бар вакыйгаларның шаһиты булган нәни инеш тыйнак кына һаман ага. Анын вак дулкыннары өстендә көндез кояш, төннәрен ай шәүләсе чайкала. Ташудан сон

яки көчле янгырлар явып узгач, болганчык суда әлеге якты шәүләләр күренми. Болганчык су бар нәрсәне яшерә. Су төбендәниләр барлыгын инеш болганмаган чакта да күреп булмый... Ә кеше күнеле тагын да тирәнрәк. Аның төпкелләренә төшеп житәрмен димә. Адәм баласын нинди уйлар йөртә?

Илдә давыл кузгалып, дөнья болганган чакта, Гата Сәгъдәтшин да, Шакир да шул болганышның аерылмас бер кисәгенә әверелгән. Балачактан кимсенеп, интегеп яшәүләре үч булып укмашкан. Революция өермәсе аларны бөтереп кенә үз эченә алган...

Авылдан куылырга тиешле гаиләләрнең исемлеген Гата төзегән. Исламгали агайның Касыймы, төнлә үзен алып китәргә килгәч, аның күзенә туры карап әйткән: «Кешене туган туфрагыннан куып, бар мөлкәтен талап баермын, дип уйлыйсыңмы! Юк! Кеше күз яше, кеше рәнжеше барыбер бугазына тыгылыр! Үзеннекенә тыгылмаса, балаларыныкына тыгылыр, Агулы теш!» — дигән.

Гата тешләрен шыгырдаткан, йодрыкларын йомарлаган, әмма Касыймга кычкырмаган, үзен тыеп калган. Касыймның сүзләренә исе китмәгәндәй, елмайгандай итеп кенә: «Без хәзер агулы тешле түгел инде, без алтын тешле», — дигән.

...Еллар узгач, инде әнисен дә җирләгәч, Ания тагын кайтты. Бу вакытта инде аның күңделегенә теркәлгән вакыйгалар «Елан эзе» дигән беренче әсәрендә урын алган иде.

Ания дә, нәкъ әниседәй, иң элек зиратка барды. Әби-бабаларының, кардәш-ыруларының рухларына атап догалар кылды. Аннары район архивына барып эзләнүләр башлады. Кайда соң туганнары? Язмыш давыллары аларны кай тарафларга илтеп ташлаган? Эзләнә торгач ачыкланды: Урта Азия якларына юл тоткан Шәрифҗан Төркиягә үк барып җиткән. Аның бер оныгы фәннәр докторы, профессор дәрәҗәсенә ирешкән. Зариф абыйсының дәвамын ул Яңа Себер шәһәреннән эзләп тапты. Ә Касыйм абыйсы атылган. Таба алмады ул аның гаиләсен. Таба алмады. Ә Аниянең үз улы — Урал ягы шәһәрендәге бер зур заводның генераль директоры.

Нәрсә бу? Изелгән, сытылган, тамырыннан өзелгән күзәнәкнең, чит-ят җирләрдә шытым биреп, кабат тернәкләнеп китүен ничек аңларга? Адәм баласының күңел төпкелендә, җаны үзегендә гел игелеккә генә әйдәүче иман нуры булудамы? — Менә җавап табуы кыен.

Ания Елгабаш авылы читендәге чишмәләр янына барып утырды. Алар һаман ага да ага. Кешеләргә алар: «Сез бездән күн саен файдаланыгыз, кадеребезне белегез!» — дип тә әйтми. Тыйнак кына агалар да агалар. Табигать күзгә авышканда, чишмәләр юлы итәгеннән су җәелеп, инеш кинәеп киткән үзәннәрдән томан йомгаклары күтәрелә. Томан, салкын сулышын өрә-өрә, чишмә тирәсендә үсеп утырган тал-тирәкләрне урап ала. Әмма тал-тирәкләрнең томанга һич исе китми. Алар изрәп йоклап кына ала сыман. Иртәгесен кояш күренәчәк һәм томан пәрдәсе эреп юкка чыгачак. Тирәкләр иртән искән таң җилендә шыбырдашып алыр.

Елгабаш авылындагы һәр фаҗигане, һәр шатлык-кайгының шаһиты булган бу чишмәләр, инеш, тал-тирәкләр олуг Табигать кануннары белән яшәгән хәлдә, кешеләргә: «Дөнья фани, иманлы булыгыз!» — дип искәртә сыман.



Розалина
Шаһиева

# СУКМАГЫҢНАН КИТТЕМ — ҖЫР БУЛЫП

## Нью-Йорк Сабан туе

И, Сабантуй, пар канатлы җайдак,
Инде монда килеп җиттеңме?
Күңелләрне шулай җилкеттеңме,
Сахраларга алып киттеңме?

«Эйзенхаур паркы» шау-гөр килә,
Яшьләр бии, күкләр чайкала...
Сискәндереп татар авазлары
Сеңә җиргә, түзә башкала.

«Караларны», «акны» — барыбер ана,
Тик аптырап карый төркемгә.
Капчык кигән килеш убырылу
Мәгъкуль әйбер түгел һәркемгә!

Бу татарлар гаҗәп халык икән —
Аяк чаулы килеш чабарга?!
Әле дөбердәшеп биешәләр —
Рух какшамас, димәк, аларда!..

Дәү агачлар башын игән кебек
Милләтемнең ару моңына.
Җырлаучының хөр авазын тыңлап,
Сандугачлар канат кагына!

Шулай ага татар тамашасы,
Бер шоу булып, биләп дөньяны.
Сәях күңел, әллә саташасың,
Милли хис дигәнгә инанып?!

---

Розалина ШАҺИЕВА — *шагыйрә, сәнгать белгече; «Кара мәрҗән», «Ниса», «Шигърият — тереклек суы» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

«Казаныма кайтам», — диләр монда,
Тик хәл җыйыйм бераз килгәчтен.
Бу Сабантуй бездән хәбәр илгә —
Сарманыма, Мөслим, Күлбәшкә...

Ата-баба моңын, рухын саклау,
Узган буыннарга тоташу —
Сабантуйның изге бер бурычы,
Шуңа безнең монда сайрашу!

Шулай көн буена
Җыр һәм бию,
Нәзакәтле, үткен ярышлар
Биләп ала Америка паркын,
Үсеп чыккан сыман арышлар!

Континентлар, тарих, үткән юллар —
Сизгер күзәнәкләр, кан аша.
Хис дәрьясы, бер океан булып,
Сабантуйда шулай тоташа.

Курай уйный берәү. Берәү гармун...
Берәү җырлый өзелеп, талпынып!..
И, Ватаным, мондый бәйрәм өчен
Мең бурычлы туган халкыма!

***

Көн-төн иснәп йөрим
Америка чәчәкләрен —
Куакларда зур-зур,
алсу-кызыл —
Әллә гөлләр, әллә гашыйклар?!
Искә төшә Казан бакчалары —
Черек күлләр, татлы «ышыклар»!
Ләкин бу гөлләрнең исләре юк —
Әллә күп булганга чамасыз.
Ватанымның әреме дә тәмле —
Андый хуш ис каян табасы?!
Әллә тәпи йөргән балачактан
калган аңа сөю, мәхәббәт —
елата да Ватан, юата да —
агулы да үзе, дәва да!
Юлга чыгам —
Кайтам туган Илгә —
Кош күк очам, кагып канатым!
И, Илкәем!
Син дип күпме михнәт,
җәфа күрдем,
Күпме күңелемне талаттым!
Кадар камыл — кара тамыр җирем,
Синең белән тагын кавышмак!
...Баш өстемдә көләч нурлы йөзең —
Алсу гөлдәй — мәңге табышмак!

***

Чорнамагыз уйлар,
бумагыз —
Акрын гына аксын
сулышым!..
Тегермәндәй
дөнья әйләнә!
Аның белән бергә
барышым!
Алтын көнбагышлар,
серемне
сезнең орлыкларга
яшердем!
Сезнең кебек
янып яшәдем!
Сезнең кебек
янды гыйшыгым!..

***

Нинди газаплы син, иҗат!
Тетрәт, көйдер, елат, җырлат!
Алып кит җилләргә салып,
Йөзим йолдызларга талып,
Могҗизана хәйран калып!..
Ничек бетәр сәяхәтем? —
Шигырь юлы — син хәятым!
Илләр, чүлләр, елга, күлләр,
Тауларында чәчәк атыйм!
Сезгә карап, күккә ашам,
Сездән башка рухым ятим!

## Шагыйрьгә

Шигъри илһамына
мөкиббән мин...
Сукмагыңнан киттем —
җыр булып.
Гүзәл моннар җыйдым,
синең кебек,
Газиз туфрагыма
иелеп.
Кортка, бөҗәкләргә
гашыйк булдым.
Күлгә, чүлгә чумдым,
нур булып.
Өстим, диеп, тирә-юньгә
бәхет,
Яшь буынга — илһам,
җылылык.
Килеп җитәбезме, дустым,
сөйлә —
Камиллеккә,
гүзәл сыйфатка!

Иярченең синең.
Ә син — кояш...
Утырганбыз сыман
бер «атка».

***

Куакмы мин, гөлме, яфракмы,
Уйсыз, хиссез курчак —
шакмакмы?!
Ләкин күңел җанлы,
мең төрле —
талпынуы шундый сихерле!
«Язма-язма» укы күңелдән —
нинди уйлар аның түрендә!
Бер кәүсәгә сыйган
мең чәчәк!
Тарих, вакыт,
сөю, киләчәк!

***

Мин хөррият кошы идем,
Шигърият, диеп тилмердем.
Төзеп Илаһи
әхрамнар,
Илгә гүзәллек өрдем!
Гаҗәп тизлек!
Яңа буын,
корыгыз
җирдә җәннәт!
Кеше булып
калыгыз тик,
тудырмагыз җәһәннәм!
...Алсу атлар күз алдымда,
Зәңгәр-яшел басулар!..
Шунда безелди күңелләр,
Шунда калды ярсулар.

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Айдар
Хәлим

# АЛА-КОЛАДАГЫ ДҮРТ ИВАН

ХИКӘЯ

Миякәдән чыккач, атын куар өчен, кая ул дилбегәсен, керфеген дә селкетмәде. Нишләптер кинәт кенә жылытып жибәрде шул. Быелгы кыш карга ифрат саран булды. Житмәсә, күрелгән хәлме, кыш уртасында чиләкләп яңгыр яуды. Гыйнвар уртасында, СССР Верховный Советына сайлаулар көнне диген але!.. Февральдә генә кар төшкәләде. Барыбер кадимгечә ишелеп яумады, кырпак кебек, жиз иләк аша сайланып кына коелды. Коелды да эретте, коелды да эретте. Кәгазь калынлыгындагы кар астында калган уҗымнар, борынгы сырын-көртләрне сагынып яшәрде, жир дә сыртын тырпайтып ятты. Менә але, бүген, март башында, төштән соң, көтмәгәндә күк түрендә Мәрьямбикә кодагые кебек балкыган кояш, жир өстенә шундый итеп елмайды ки, ала-колага әйләнеп чуарланган, аклы-каралы сыер кебек алара төшкән юлдан чананың тимер табаны чыелдый-чыелдый, елтыр сызыклы эзләрен калдыра-калдыра, өстерәлде дә өстерәлде.

Бүген тан сызылмас борын алар ике туган агасы Габдерәхим белән кыз ягына аш чанасын, ягъни килен төшерер алдыннан кияүнең кыз ягына тапшыра торган аш-су күчтәнәчен, азык-төлек, әйбер-сәйберен, безнең яклар теле белән әйтсәк, тез ачу мәһәрен китергәннәр иде. Егерме чакрымда яткан район үзәгенә төн салкынындагы исән карларны сайратып килеп житкәннәр иде дә. Әмма, менә бит ничек: кире кайтырга чыгар алдыннан гына эретеп жибәрде — юллар ботка булды да куйды!.. Әйе, чанасына кырын ятып, балтасы суга төшкән мажик кебек аптырап сөйрәлгән Сәгъдәт кенә түгел, карайган жирдән мыш-мыш килеп шушы чанасында Сәгъдәтне дә өстерәгән Жирән ат та мондый кискен үзгәрешне көтмәгән иде. Яңгырлы кыш мал-туарга авыруча авыр икән. Кешеләрнең түгел, атларның да тыны житми. Алар корчаңгылап кашына, түземен жуеп, бетли башлый. Атның бу газаплы юлны ташлап, каядыр якты, ак карлы читкә чыгасы, кар борхытып, йогыртасы килеп, куян кебек кылый күзләре белән як-якка караштыра, әмма анардан читтәге үр-чокырлар, киртләч буйлар да ала-кола булып тын калганнар иде...

Шулай, агасы аны аш чанасын илтергә дип үзе белән алмаса, ул бу район үзәге дигән шәһәр жирен кайчан күрер иде? Кайчандыр ун еллар элек әткәсе моннан фронтка киткән. Менә ул, андагы бożрага-божра чыбыклардан сүз

---

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, публицист, прозаик; «Гомеремнең ун көне», «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Чаллыда яши.*

тапшырган телеграф баганалары, дөп-дөп килеп, торбасыннан дөм караңгы төтен чыгарып электр ясап утырган дизель станцасы, кәрәз кебек сары ике катлы бүрәнә йортны, ул гынамы, булачак җиңгәсен, Сәйфетдин кодасын, Мәрьямбикә кодагыен гына түгел, үзе дә кадер-хөрмәт күреп, тишелеп чыкканчы итле аш ашап, мендәр кебек күпергән бодай ипиен сыптырып, хәтта кодасы кулыннан, көчләтә-көчләтә бер көрәгә ачы бал да тәмләргә мәҗбүр булган бәләкәй кода, ягъни Сәгъдәт үзе була инде, менәтерәк әле, авылына кайтып барышлый, ала-коласына карамый, җырлап та алды:

Тирдаритта каласы,
Әллә кияүгә барасы,
Әллә кәләш аласы...

Аның тавышы матур иде. Бу тавышка ат та борылып карады. Сәгъдәтнең җырлап җибәрерлек, ошбу чана күтәрә алырлык шатлыгы да бар шул. Аны ат та тоя кебек. Агасы кәләшен кияүләп Миякәдә калды. Дөрес эшләде. Сәгъдәткә күз-колак кирәкми. Кәләшен карасын. Җиденче сыйныфта укыган ир-егеткә нинди күз-колак ди тагын?! Шатлык дигәне кесәсен җылыткан чигүле кульяулык. Аның өчен хәзер ике кояш: берсе күктә, икенчесе кесәсендә. Кодаларының өенә үткәч тә, яныннан кылдан да нечкә ислемай исләре калдырып, зифа кыз узды. Җиңгәсе, агасының кәләше, ягъни мәсәлән, булачак хатыны икән. Үз йортында кыз-кыркын, килен-киленчәк затын күрми, һәрнәрсәгә, хәтта буш абзардагы тычкан тишеге өчен салым түләп өйрәнгән гаиләдә үскән Сәгъдәт, бит очлары, бармак очлары алсу-алсу булып янып торган җиңгәсе кулыннан чигүле кульяулыкны алганда:

— Бушкамы?! — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. — Бушка бездә сыер да мышнамый!..

— Бушка булмый тагын!.. — дип зеңгелдәп көлеп җибәрде җиңгәсе. — Беренче танышуыбыз истәлеге. Син бит мин күргән беренче җан агам!..

— Җан ага — жарты ир, ир булмаса, бөтен ир! — диде мич арасында маташкан хатыннарның берсе. Алар чәчкәле чынаяк кебек матур киенгән иде.

— Кем әйтмешли, кияү сые — хан сые, җиңгә сые — җан сые... Әле тагын да килерсең... — дип өстәде икенчесе.

— Киләсем килсә... — диде малай эре генә. — Киләсем килгән хәлдә... Киләм дә куям...

— Син, энекәш, артыгын лыгырдама!.. — диде берничә ай гына элек армиядән кайтып, гимнастёркасын да салмаган, әле дә сары самавыр кебек аеллы каешын буып алган агасы, үзенең политзанятиеләрдән сыдырган тирән белемен кая куярга белмичә. — Теоритецки. Маркыс әйткән, Ингелис тәфсирләгән, Лилин кабатлаган...

Җиңгәсе алдына токмачлы аш, ашка катарга әче катык, леркелдәп пешкән ит, әчкелтеме борын тишекләрен кытыклаган арыш ипие китереп куйды. Бу кадәр мул ризык күреп, Сәгъдәтнең эчендә бүресе улады. Кодагые Мәрьямбану яшь кодасын ай-ваена куймыйча сыйлады. Уҗавы астыннан мае таммасын дип, астан учы белән каплап тагын шулпа китереп өстәде. Аның йотыгып ашаганлыгын күзәтеп тормыйлар микән дип, кашыгын кулына алганда, тирә-ягына каранды. Күрсәләр күрерләр инде. Бисмиллаһ иррахман иррахим. Өреле, катык катылган шулпа аһ тәмлекәй иде!.. Әмма малайның тишек колагы һәрнәрсәне эләктереп алды. Мич каршында чуен чүлмәкләр белән кыешкан хатын:

— Минем мужигым кичә кайтып керде дә... — дип башлаган сүзен әйтеп тә өлгермәде, икенчесе, почмактагы өстәлдә токмачлык җәймә җәйгәне, шундук:

— Мужик дип сөйләмә әле, пжалысты! — дип кисеп кенә төшерде ахирәтенең

телен. — Женем котыра, әйгенәм, шул сүзенә!.. Мужик дигән мал урыста гына була. Ирем, диген, никахлы булсаң...

— Анысы нәрсә тагын? ЗАГСмы?

— Юк, мулла укыган дога. Тез арасы догасы... Хи-хи...

Хатыннар кеткелдәп кенә көлештеләр.

— Безгә мулла укымады. Силсәвит.

— Шәп булган.

— Какуй разнитса!..

Сугыш ятиме Сәгъдәт хатын-кызларның эш арасында шулай мыгыр-мыгыр сөйләшүләрен ярата, ул аларда аерым бер шигърият таба иде. Ашаган унайга ул аларны күзеннән кичерде. Әнә ишелеп ташыган гәүдәле, якты маңгае өстендә өерелгән эре бөдрәле, сугандай кабарган күз кабаклы, шулай ук ишелеп төшкән иякле, ни-нәрсәсе беләндер аларның тарих китабындагы фельдмаршал Кутузовка охшаган хатын мичтәге чуеннарны һаман үзенчә чыйкылдаштырып, ухватына таянды да:

— Кайда була икән ул Минзәлә дигәннәре? Татарстандамы, әллә Башкортстандамы? — дип сөйләп китте. — Бүген радиудан бер жырчылары бик матур жыр жырлады. Ишеттегез микән?

— Безнең очта радиу юк бит әле. Үзебезнең тавыкларны гына жырлатабыз әлегә...

— Ну үзендә дә мон диген, ә!.. Изде генә, малай! — Шул Минзәлә дигән суларына барып, аягымны салындырып утырасым килеп китте...

— Аның кайда икәнлеген барып күрмичә каян беләсең! — диде талкынган сөс сыман аксыл йөзле, ухват сабы шикелле мичтән коргаксып чыккан ябык гәүдәле хатын.

— Ничек белмәскә? Син үзең шул яктан бит.

— Булса ни. Барысын белеп бетереп буламыни? Син менә Әндри казнасының кайда икәнен беләсеңме?

Барысы да көлештеләр.

Күргән-ишеткәннәрен күз алдыннан кичереп, Сәгъдәт ала-кола юлдан Йәрлекәү дигән урыс авылына житеп килә иде. Ул чанасы түрендә тирбәлеп барган аклы төенчеккә күзен төшерде. Төенчектән татар авылына әле күптән түгел генә килгән туклык исе аңкый. Төенчеккә чынлап та туклык төрелгән иде, диярсең. Бер бөтен ипи. Хуш исе танауны ярып керә. Теге Кутузовка охшаган хатын аның булачак жингәсенең жингәсе, ягъни агасының хатыны икән.

— Мә, үзеңә юлга ал әле, ала күр, яшь кода! Тамагың йотыгып китсә, теш арана кыстырып куярсың. Йомарт илнең итәге киң. Менә бит, ничек кенәләр мич авызына сыймаслык булып күпереп пештеләр!.. — Ул тегермән ташы кадәр бодай ипиен шәлъяулыкка төрде дә көчләп диярлек кодасының кулларына тыкты. — Әле ипи күргәнебезгә күпме генә вакыт бит!..

— Шулай, Мөслимә килен, дөрес әйтәсең... — Сәйфетдин кодасы төенчекне Сәгъдәтнең кулыннан алып, чана түренә бәйләп тә куйды. — Кара, Мәрьямбикә, син кодабызга юллыкка тагын берәр тәмле нәрсә сал!..

Тәмле нәрсә салмады кодагые, әллә онытты. Ярар, монысы да бик житкән. Сәгъдәт ипине алуына куанып бетәлми. Ала-колада жир сөреп йөк тарткан Жирәнкәйнең теш арасына кыстырырга да бик кәттә булачак әле ул.

Жепшеп яткан юлда әлләни хәрәкәт күренми, ат тизәге өемнәрендә типченгән соскы борын үрдәк, жеп сыйраклы чыпчык төркемнәрен санамаганда... Үрдәк яратып соса. Солы, үлән исе килгәнгәме? Әнә, уң яктагы ихата каршында ниндидер пычрак чүпрәк сузылып ята. Кинәт чүпрәк дигәне ыргып торып, Сәгъдәт чанасын амалады да, ишегалдына кереп сеңде. Эт икән. Һавада кара

каргалар өерелде. Кыш җылы киләсен белепме, алар быел китми калды. Көзен, җир туңганда, китәбез-китәбез дип ындыр табаклары, тау кыразлары өстендә репетицияләр үткәрделәр дә, сәгатьләре җиткәч кенә китми калдылар.

Авыл, аның илһамсыз сүнгән йортлары күнелсез иде. Моны күреп, малайның да эче пошып куйды. Ул чанасының төбенә капланып ятты да, ничек кенә булса да вакытын үткәрер өчен, үзеннән бер генә карыш аста шуышып артта кала барган җиргә табаннары арасына тезелгән жирдалар[1] аша карап саный башлады:

— Бер... егерме бер... йөз дә бер...

Ике йөз санына җиткәч, башын күтәрде. Йәрлекәүнең җимерек чиркәве каршысыннан үтеп бара икән. Утызынчы елларда шартлатылган иман йорты нә тәмам җимерелми, нә яңадан төзәтелмичә, ак баганалары белән тарих китапларындагы Афинаның җимерек баганалары кебек серәеп тора. Ник шартлатканнар? Нинди үч белән? Шартлаткычларын куяр урын булмаганмы? Тәресе-ние дә юк. Ул аңа булса да карамас иде. Әнисе тәреләргә карамаска куша. Әмма мондый ак бина эчендә гыйбадәт кылган кешеләрнең бик иманлы, бик яхшы булганына ышана ул. Ап-ак, әмма бер мәгънәсез җимерек яткан якты баганаларны кызганып Сәгъдәтнең күзенә яшь сарыкты. Алар авылындагы мәчет тә җимертелгән. Кемгә зыяны тигәндер. Әткәсе исән булса, ул бу гыйбадәтханәләрне җимертеп яткырмас иде...

Юл үргә үрли башлады. Бераздан бу юл зурысыннан аерылып, ачык яланнар һәм урманнар аша туган авылына юнәләчәк. Урман эчендә аны якты, шыгырдап торган кар каршы алачак, Алла боерса! Аты бер караганда җиңел генә булган йөкне дә йөрәксеп, бу карада тыны буылып тарта иде. Үзенә урын табалмыйча, яңадан саный башлады:

— Ике йөз бер... Өч йөз егерме...

Кинәт аның башына даһи ачыш килде: теләсән, җир йөзендәге һәрнәрсәгә сан сугып, дөньяны саннарга буйсындырырга мөмкин икән. Меңгә кадәр генә түгел, миллионга, миллионга кадәр генә түгел, миллиардка, миллиардка кадәр генә түгел, триллионга кадәр!.. Әйтик, дөньяны төрләргә, көрләргә, ябыкларга, сыйныфларга, акларга, кызылларга, сарыларга, айныкларга, исерекләргә, җанварларга, үләннәргә, тагын да әллә ниткән, әллә ниткән төрләргә аерып, мөһер сугып чыгарга һәм галәм белән сан аша гына идарә итәргә! Юкка гынамы юньсез кешегә сансыз, сантый, диләр?! Бу үзе бер фән булачак!.. Әйтик, кеше 1 саны, озын буйлысы — А, кыска буйлысы — Б, нык акыллысы — X, уртача акыллысы — D, түбән акыллысы — Y, акылсызы — Z , бае — S, ярлысы — N, башка сыйфатлары тагын да шулай билгеләнә, ди. Әгәр берәү икенчегә: «Син 1AXNны кабул ит», — дип хәбәр итә икән, димәк, бу таза, озын буйлы, бик акыллы, әмма ярлы кешене кабул итәргә әзер бул дигәнне аңлата. Сәгъдәт әллә катыклы аштан, әллә болай гына кәефе килеп, киштәсе җимерелеп төшкән бай кебек кикереп куйды. Бу аваздан Нимесе дә колагын шомрайтты һәм «горк!» итеп карынын бушатты. Җирән ат чынлап нимес аты. Колхоз идарәсендәге паспортында аның исеме — Прәгрис. Авыр эштән, кыйналып, кадерсез яшәүдән айгырдан алашага әйләнгән ганимәт, ягъни германнан килгән трофей аты. Сугыштан соң аларның колхозына биш баш шундый ат эләккән, икесе Сәгъдәтләр бригадында. Алар килгәндә, зур, таралып яткан күз кабаклы, бик эре нәселле булалар — сөякләре дә, тояклары да, кыллары да. Авылның сугышларны үткән кайбер аксакаллары татар аты белән нимес атын кавыштырып, нимес көче, нимес тәртибе белән татар тырышлыгын берләштергән яңа ат нәселен булдыру турында да хыяллана.Чынлап та, булган хәлдә, вәт ат тек ат булыр иде ул, ә?! Ләкин колхоз аранында үзләрен фрисләрчә иркен тоткан нимес атлары татар авылын куандырырга ашыкмаган. Әсир булсалар да, кол

[1] Жирда (жердь) — нәзек киртәлек агачлар.

итәлмиләр аларны. Кулга өйрәнү, жиктерү түгел, йөгән кидереп, сыртына да атландырмыйлар, каһәрләр. Силсәүит кушып, кулына чукмар тоткан Бастырык Гайжан олы авылдан төшкәч кенә һәм, жиннәрен сызганып, нимес атларының маңгай уртасына берне тондыргач кына алар мингерәүләнеп юашлана төште һәм авылның ин гаярь егетләре аларны йөгәнләргә, аннан ике яктан дилбегә белән уратып, аркаларына атландырырга, аннан жигәргә, аннан, ниһаять, ләштер-ләштер сабан сөрергә өйрәтә алды. Ат абзары янында: «У-у, фашист, Гитлер токымы, фрис, паразит, полицай», — дигән авазлар гына яңгырап торды. Сәгъдәт боларны хәтерли, ул заманнарда ыштансыз малай гына булса да. Малай герман тарафларыннан килгән атларны «фрис» дип сукми, киресенчә, мал итеп кызгана иде: гүя алар әткәсенең хатирәсе. Гүя алар сугыш азагында гына һәлак булган ирнең аты буларак ерак жирләрдән килгән хатирә. Ул аларның күзләренә карый: берәр нәрсә язылмаганмы? Ул аларның колакларын күзәтә. Кош оясы кебек, бу колаклардан хатлар очып чыкмасмы? Әйе, берничә арбачана ватканнан, баганалар аударганнан, дистәләгән егетебезнең бил-аркасын имгәткәннән соң гына «фашист»лыкларыннан ваз кичеп, татарга нимес тәртибе белән ач килеш жир сөрергә, урман, печән ташырга ризалаштылар...

Йәрлекәү үреннән унга таба яссыланып, Ырымбур далаларына таба төшеп югалган яланның бер-ике чакрымга сузылган очында «Түр» урманы башлана. Шул урманга житәрәк, Сәгъдәт берничә кеше сынын абайлап алды. Егерме чакрымлык юл-яланда ялгызы түгел икән. Күнеле күтәрелгәндәй булды. Чана табанының йөзектәй нәзек тимере юка кар астыннан чыккан кара жирдән эз салып, идән астындагы тычкан кебек чи-чи килеп баруын дәвам итте. Сәгъдәт белә: ул бу ала-коладан шул «Түр» урманына кергәч кенә котылачак...

Гомер буе абзардан чыкмый ат караган Сәйфетдин коласына да ошады аның Нимесе. «Бу ат хужасын бик ярата, күзгә карый, — диде ул, елларыннан сөеп. — Син, кода, онытма: арыган ат — чокыр саный, ачыккан ат — кулны ялый, яраткан ат — күзгә карый...» Сугыштан соңгы авыр тормыш шартларында эре нимес атлары да эреләтә алмады татар аты нәселен. Киресенчә, үзләре күзләре чепекләнеп, вакландылар һәм Гайжаннардан кыйнала-кыйнала, горур холыклы, гасаби айгырдан кол йөк атына, юаш алашага әйләнделәр. Уллар, ир балалар кирәк шул һәркайда һәм һәркайчан, ир-ат кирәк. Ат белән бер тәртәгә жигелгән ир-ат кына баһадир була ала. Кунак атны жиккәндә, Сәйфетдин кодасы: «Борынгылар юкка гына әйтмәгән, — дип тә өстәгән иде. — Ыруғын булса — улын, улың булса гына — ыругың булыр, дигәннәр...»

Уй-хыялларына бирелеп барган малай якында гына сөйләшкән тавышлар ишетеп сагайды. Сагаеп та өлгермәде, барысы бертуган кебек, күрер күзгә бер кайгысыз, шешенке, аксыл тамырлы, итләч бәдәнле дүрт әзмәвер, исәнлек-саулык сорашмый, чанасына менеп тә утырдылар. Бәй, ул теге карачкыларны куып та житкән ләбаса!..

— Куда едешь?

— Да, — диде урысча белмәгән малай. — Да. Как его.

Сораусыз-нисез чанасын басып алган үсемерләр үзләрен тулы хужа тоеп, шаярыша, әүмәкләшә, Сәгъдәткә ымлап, маймыллана, көлешә башладылар. Йөктәге артык авырлыктан юл ачуы чыккан чана табаны инде зәһәр итеп чыелдый-чиный башлады. Малайлар Хлебороб дигән күрше урыс авылыннан Миякә урта мәктәбенә йөреп укучы югары сыйныф укучылары булырга тиеш. Аркаларындагы токчайлары да шуны раслый. Анда дәреслекләр булыр. Авыл халкы хлеборобларны «шабра, знакум» дип йөртә. Имеш, алар икесе дә «күрше, ут-күрше» дигәнне аңлата икән. Ә менә итне алар «махан», диләр. Каян алганнар бу сүзне? «Шабра»лар тарафыннан болай түбәнсетелүдән малайның башы чыңлый башлады. Әле урман эчендәге

карларга байтак барасы иде. Буш чанасын да «Кара урман» көйләренә авыр йөк итеп тарткан Нимес, үзенә өстәлгән бу кадәр авырлыктан скрипка кылы кебек тартылды, кабыргалары калтайган рәшәткә тактасы сыман тырпайды. Чананың табаннары хәзер җир сөрә иде. Тегеләр дүртәү, ул — берьялгызы. Малай көнчыгыш һәм көнбатыш, көньяк һәм төньяктан камалышта иде. Урыс кавеме белән беренче тапкыр очрашуы булса да, шулай да курыкмады, киресенчә, бер-бер хәл килеп чыкса, алар мине нишләтер, дип түгел, мин боларны нишләтермен, дип газапланды.

— Куды едешь? — дип кабатлады ике теше иреннәре арасыннан тышка тырпайган һәм учма-учма озын сары чәчләре хәзер очып төшәм дип торган малахай бүрек астындагы малай. — Шо молчишь? Немой што ли?

Һәм ул куш көбәкле мылтык кебек аңа чекрәеп карады. Немой дигәнне Сәгъдәт аңлады кебек. Авылларында Телсез Сәлимә бар. Сөйләшә алмаганына ишарә итә, димәк.

— Он по-русски не знает! — дип өстәде ачык изүеннән шәрә киң күкрәге күренеп торганы.

— Даже по-русски не знает!.. Тат-тар-рин!.. — дип өстәде зур колаклысы. — Халя-баля, тара-бара!..

Кабантеш авызын һавага элеп шаркылдады, аңа баш кагып, башкалары да чайкалышып көлеште. — Неужели по-русски не знаешь?

— Это самый... — диде Сәгъдәт. — Того.

— А шо так медленно плетёшься? — Кабантеш Сәгъдәтнең дилбегәсенә үрелде. — Дай-ка, я сам поһоняю.

— Нет, дилбегә мой, — Сәгъдәт дилбегәсен бирмичә, читкә тартылды. — Дилбегә мой...

Карашы чана үрәчәсенә ипле итеп кенә беркетеп куелган каеш камчыга төште. Болар кулына кала күрмәсен тагын! Аркасы белән янтая төшеп, сул кулын тегеләр күзеннән яшерде һәм сиздермичә генә камчыны чишеп, сап бавыннан уң кулының беләзегенә киде. «Урман эченә керсәм, болардан котылырмын, бәлки, — дип уйлап алды. — Әмма... ул карларга барып җитәргә кирәк бит әле!»

— А шо там у тебя болтается? — елак йөзен тавык чуарыдай сипкел баскан үсмер чана түрендәге төенчеккә күрсәтте.

Кабантеш яткан урыныннан гына үрелеп төенчекне алды.

— Кагылма! Того.

Теге чиште. Төргәктән чыккан бодай ипиенең хуш исе тирә-якка таралды. Ике яклап чана канатына асылынган икәүсе — зур колаклы һәм ачык изүеннән йонлы күкрәге күренеп торганы — сорап та тормыйча Кабантеш кулыннан ике түтәрәмне каерып алып, лач-лоч китереп умырырга тотындылар. Атка чынлап та авыр иде. Кара җир сыдырып тиргә баткан Җирәннең бот буйлары, янбашларыннан чәчкә атып ала-колага ачы йолдызлар, көмеш алкаланып тозлы тәнкәләр коела башлады.

— Ипине миңа да калдыр!.. Как это.

— Ха-ха-ха!..

Инде бөтенләй дә сузылып ятып, чанага хуҗа булып ипи кимергән малайлар берсе-берсе белән укмашып көрәшә, аумаклый, шаярыша иде. Чанада женнәр, канатлы чана гүя женләнгән иде. Аты иписез кала иде. Ипи күбрәк атка кирәк иде. Нишләргә? Алар шулай унике чакрым буе Хлеборобларына җиткәнче утырып кайтырлармы? Атын йөгендермәсме? Әле бит аңа Хлеборобтан соң җиде чакрым кайтырга кирәк. Малай кайнар-салкынлы тиргә батты. Бу минутта аның чанасы, авылының, халкының, иген басулары, җир-сулары, хәтта мал-туар, сыер-ат, вак малларының вәкиле, вәкиле генә түгел, аларның туендыручысы булган бу чана — канатлы галәм, азыклы оҗмах аның өчен көтмәгәндә түзеп тора алмаслык кара тәмугка — ачлык һәм зар, дошманлык һәм күрә алмаучылык патшалыгына әверелгән

иде. Әгәр теге ала-кола мона каләр яланда гына булса, хәзер аның чанасын һәм җанының түрен басып алган иде. Чаналагы тынычлык — тынычсызлыкка, тынлык гаугага белән киерелгән иде. «Болар булган җирдә һәркайда тәмугтыр, — дип уйлап алды малай. — Миндәге кебек. Әле генә оҗмах иде, хәзер — җәһәннәм». Ничек кенә теләми карасын, ничек кенә баш тартмасын, ничек кенә кәнтәйләнеп, тыйнак холыклы булып кыйланмасын, ул үзеннән тартып алынган оҗмахны кире кайтару өчен көрәшергә мәҗбүр иде. Бу аны алҗытачак, көчен талаячак, көчләп тагылган һәм бөтенләй кирәкмәгән көрәш иде. Мона каләр үз чанасында үзенеке булган ай, кояш та, шушы газиз туфрак та гүя хәзер үзенеке түгел, чанабасарларныкы иде. Бу тормыш түгел, ә торып тормыш иде. Әле генә саннар санап килгән юлы да аныкы булудан туктар микәнни?! Ул аны үзенеке дә итә, сатып та алалмаячак.

Ялт итеп алдына караш ташлады. Урманга берничә йөз адым бар икән әле. Кабантеш Иван тулган ай кебек түгәрәк ипине тирестәй куллары белән өзгәләп бетергән арада аның бәгырендә нindiдер кыргый көч күтәрелеп бәрелде, ул, тыны буылып, нишләргә дә белми, Кабантеш кулыннан бер түтәрәмне тартып алып, чанасыннан сикереп төшкәнен сизми дә калды. Йөгереп килеп чана тәртәсенә асылынды һәм Җирәнен сыйлый башлады:

— Тизрәк кабып йот, малкай! Эссен!.. Тартып алалар!..

«Эссен»нын нимесчәдән татарчасы «ашарга» икәнлеген Сәгъдәт белә иде. Әле былтыр гына шушы юлдан — район үзәгеннән йөреп, аларга нимес теле укыта башлаган Чатан Гарифулла абыйлары өйрәткән иде. Малай чанасына бүтән утырмады. Ана утырырга намусы кушмый, вөҗданы җитми иде. Ул үзенә бирелгән кечкенә мие белән анламый иде: шушы ала-колада, газаплы юлда, артыннан кара эз калдырып, чак-чак тартып барган атка туң бүрәнә булып төялеп бару өчен нинди микъдарда тиле бәрән орлыгы ашарга, нинди агу эчәргә кирәк иде икән аның ут-күршеләренә? Нихәл итеп мондый булып була икән? Хәлне күрү, бәяләү, малны кызгану, күрше хәленә кермәсә, кеше хәленә керү дигән нәрсә юк микәнни боларда? Оятыннан якты күзе белән ала-колага да карарга кыймаган, иртәләгән яз сарысы атлаган саен пималарыннан сытылып чыккан малай аты белән беррәттән тәртәгә җигелеп, йөкне өстерәшә башлады.

— Төшегез, авыр бит!.. — дип үрсәләнде ул, борылып. — Әйдә, малкай, әйдә...

— Шо ты бормочешь?

Чанасын сөйрәшкән унайдан чакырылмаган кунакларын янә күзеннән кичерде. Алар исә үзе кебек җилләр тишкәләгән кыска сырмада, берсе, Сәгъдәт кебек, төпле пимада, икесе, шул исәптән Кабантеш тә, чабатада, дүртенчесе — хәллерәк, күрәсен! — эрзин итектә иде. Әмма алар чанада утырып, Сәгъдәт исә аты белән бергә алар утырган чананы өстерәп килә иде. Авылында чакта Сәгъдәт үзе дә чабата кия, ул җинел, матур, нәфис, ипле. Галимулла бабасының көмеш чәшлесе ана өч йомырка исәбеннән кәнбагыш мәмиләре кебек итеп тезеп шигъри чабаталар кидерә. Малайның юлдашлары белән сөйләшәсе, анлашасы, анлатасы килә, әмма телләрен дә, исемнәрен дә белмәгәч, телен тешләгән. Исемнәрен әйтеп танышмаган кунаклар аның өчен барысы да Иван иде: Кабантеш Иван, Чуар Иван, Зурколак Иван һәм Кинкүкрәк Иван.

Бу Иваннар арасында иң явызы булып Сәгъдәткә нәкъ әнә шул Кабантеш Иван күренде. Аллаһы Тәгалә ана шушысыннан аеруча сак булырга кушты. Ул ипиен сагыз чәйнәгәндәй лачкылдатып чәйни, әдәпсез рәвештә туктаусыз черт тә черт итеп еракка төкерә. Мона Җирән дә игътибар итә. Тамагын ныгытып алган Чуар Иван, йокысы килгәндәй, күзләрен йомды. Аның күзләрен ачтырыр һәм атка йөк булмасынга чаналан төртеп төшерер өчен ипи шүрлегенә менеп төшәргә тиеш иде Сәгъдәт. Юк, бәйләнми, Алла сакласын!..

Менә, ниһаять, алар типченеп, нә тунмастан, нә гөрләп акмастан чиләнеп

яткан чишмәле инкүлек аша «Түр» урманына керделәр. Инкүлектән чыгып, чиста карларга аяк баскач, чана табанының нәзек тимере ак кар өстенә иске кара эзне сызып бераз барды-барды да, моннан ары юлыгыз хәвефсез булачак, дигәндәй, тәмам да агарды. Урман эчендәге һава салкын, кояш нурлары юк дәрәҗәдә сүрән, ала-кола тулаем аклыкка күчкән иде.

— Останови, — диде тегеләрнең берсе. — Стоп, коняга!..

Боерыкка буйсынып яшәргә өйрәнгән акыллы Нимес туктады. Малайлар сикереп төшеп чәпрәй итәргә тотынды. Берсе, авырдан бушанырга дип, шунда ук юл читенә утырды һәм трактор кебек шытыр-шытыр килә башлады. Шуны гына көткән Сәгъдәт — «Ялт!» — чанасына сикереп менде дә камчысы белән — сыртына сыптырды.

— Аллаһ әкбәр!.. На-а-а, малкай!..

Һәм авыр газаплы юлдан соң шушы боерыкны гына көткән Нимес карлар уйнатып яткан урман юлыннан кушаяклап чабарга тотынды. Гүя тоткыннан ул шушындый чара белән генә котыла алачагын аңлаган иде.

— Сто-о-ой! — дип сөрән салдылар арттан.

Сәгъдәт артына борылып та карамады. Аның мондый Иваннарны күрәсе килмәде. Секундлар еллар кебек озак тоелды. Күпме чапкандыр, белми, чана койрыгында ниндидер авыр нәрсәнең өстерәлеп, сөйрәлеп баруын абайлап, борылса, ни күзләре белән күрсен, теге Кабантеш Иван зәңгәрләнгән бармаклары белән үрәчәгә ябешеп, артында карлар тузгыта-тузгыта өстерәлеп бара... Сәгъдәт, аны-моны уйламыйча, Җиренәнә тагын берне сыптырды. Ат тагын да тизрәк чабуга күчте.

— Оста-а-нови-и-и!.. — дип кычкыра иде Кабантеш Иван. — Не брос-са-а-ай!..

Акырып барыр-барыр да атылган йолдыз кебек ычкынып калыр әле. Сәгъдәт атына янадан селтәнде. Әмма аның тизлеге чикләнгән иде. Юл чокырларында, борылышларда уһылдап һәм кычкырып, сикерәнләп һәм ыңгырашып барган авыр гәүдәдән болай гына котыла алмаячагын аңлады. Ул дилбегәсен йомшарта биреп, тез очларында чанасының артынарак шуышты һәм кабантешнең кулларын чанадан ничек кенә булса да ычкындырырга теләп уң аягы белән типкәләнгәндә — кинәт! борылышта! — чаналары сикерде һәм дилбегәсенә уралган, кабантеш белән тәмам бер булып чатнап кавышкан Сәгъдәт үзе дә юл читенә очып төште. Дилбегәсе кинәт сулга тартылган ат, гырылдап һәм хырылдап, җәясендә сынган ук сыман кискен каерылып туктады. Инде сугышка әверелгән алыш җирдә дәвам итте. Алар бугазга-бугаз ябешеп, бер-берсен буарга тырышты, әүмәкләшә-әүмәкләшә, күз төпләрендә йодрык уйнатты. Иванның борыныннан кан китте. Көч һәм куәт унөч яшендә олылар белән печән чапкан, урман тарттырган, бөтерчек кебек тыгыз, туп кебек түгәрәк Сәгъдәт ягында иде. Шуңа күрә аның бар курыкканы бу, үз кочагындагы Иваннан түгел, ә борылышлар артында калган Иваннардан иде. Әгәр алар куып җитсә, Сәгъдәтнең хәле мөшкел булачак иде. Шуңа күрә ул моңардан тизрәк котылу ягын карады. Ул дилбегәсен кулыннан ычкындырды, Иванны биленнән алды, җан ачуы белән кысып күтәрде һәм башы аша җиргә орды. Иван урыныннан күтәрелеп, аңа типте, орды, бәрде, тагын типте. Ул Сәгъдәт кулланган ысулны кулланып, аны күтәреп бәрергә омтылды, әмма Сәгъдәт, күтәрелгән хәлендә, аяк-кулларын җәеп чайкалды, бар авырлыгын салды, Иван исә, әллә аяклары тайды, әллә икенче бер нәрсә булды, аны күтәрә алмыйча тайшанды һәм Сәгъдәтне күтәргән хәлендә артына ауды...

— О-о-о!

Акырып улаган тавыш урманны басты. Сәгъдәт чанасына сикерде һәм атын янә камчылады. Нимес хуҗасын тыңлап, бар җегәре белән алга омтылды. Кайчандыр тумыштан үзсүзле, кирегә беткән герман аты, Идел-Уралда никадәр арба-чана вата-вата тәртә арасына кертелгән булса, хәзер шул ук Идел-Урал карлары арасында шулкадәр тәртипле, шулкадәр намуслы, шулкадәр тырыш

жан иясе иде. Инде Сәгъдәтне, адәм баласын, икенче уй борчыды: карлы яланда ятып калган Иванга нәрсә булды? Аягын сындырдымы? Каймыктырдымы? Чыгардымы? Кем гаепле? Үземе, әллә Сәгъдәтме? Бу кадәр җан өзгеч тавыш юкка булмагандыр. Фаҗигале тавыш колак төбеннән китмәде. «Чыгаргандыр, — дип уйлады. — Сынсын өчен ул кискен хәрәкәт ясарга, һәрхалдә тибәргә, сугарга, көсәк белән тез капкачына кундырырга тиеш иде. Ул боларның берсен дә эшләмәде, бары тик котылырга гына теләп якланды гына...» Барган унайга ул вөҗдан тәмугында янды. Анарда ике фикер — ак һәм кара фикер көрәште. Син аягы сынган кешене, япа-ялanda калдырып киттең. Борылып та карамыйсың. Карарга мәллә? Юк, карама! Дөмексен! Алар синең атыңны әнә ничекләр итеп газаплады?! Ә-ә, син әле шулай кешегә үлем телисеңмени?! Юк, ул дошман түгел!.. Адәм заты!.. Хәзер үк артына борыл, кара!.. Бар!.. Тап!.. Чанана сыендыр!..

Ул ат караклары карашы белән кашын җимереп, артына борылды. Аны куа килүчеләр күренми, ә менә кар өстендә ихластан да кара керле чүпрәк булып сузылып яткан Иван кулларын күтәреп, нәрсәдер ялвара иде...

Үзенең ни эшләгәнен дә аңламыйча, үз кальбе белән үзе көрәшкән Сәгъдәт атын туктатып, кирегә борды һәм теге кара капчыкка таба китте. Авыз-борыны канаган, өсте-башы тузынган, бите-йөзе җимерелгән Иван әле генә канга-кан килеп сугышкан, инде хәзер янына килеп туктап, «утыр!» дигәндәй, чанасы канатларын китереп куйган татар үсмерен күреп, авыртынды, авызларын чалшайтты һәм, күккә ялварган кулларын төшереп, урыныннан күтәрелергә итте, әмма тагын да елаган тавышлар чыгарып урынына сеңде:

— Ай-яй-яй, не могу... Я, кажись, вывихнул ногу...

Сәгъдәт аның күзләренә карады. Алар котырган малныкы кебек куркыныч түгел иде.

— Утыр, әйдә... Как яво. Это самый...

Иван үз күзләренә үзе ышанмады. Ул бу татар сүзләренең мәгънәсен аңлаган, әмма, үз халәтеннән чыгып, мондый хәлнең була алуына ышана гына алмый иде бугай. Сәгъдәт чанасыннан очып төште, артыннан килеп, култык асларыннан күтәреп алды һәм тегенең «ай-вай-вай»лап ыңгырашуларына карамыйча, капчык кебек, чанасына таба өстерәде.

— Утыр. Утырып садись...

Иван исә һаман ышанмый иде.

— Не моһу...

Арттан куа килмиләр иде. Әле генә чырайсыз-ямьсез күренгән, житмәсә танавыннан каны саркыган кабантеш малай аны якын туган кебек чанага өстерәгән мәлендә мөлаем күренде. Хәзер аның кабан тешләре дә күзгә чалынмый, гүя алар күпшенгән иреннәре артына кереп качкан иде. Иван һәр сикәлтәдә йөзен чытып, ыңгырашты, ниләрдер мыгырданып ялварды. Телләрен белмәгәч, ул аларны да бөтенләй белми, илен белмәгән — тиле, дигәндәй, ул аларның, бабалары сөйләвенчә, бу җирләренә бары тик алтмыш-җитмеш ел элек кенә Херсон өлкәсеннән күчереп утыртылган колонистлар, фамилияләренең дә бик кызыклы Кнопкин, Втулкин, Подшипкин һәм Моторин икәнлекләреннән дә хәбәрдар түгел иде. Ул шунысын белә: бу мизгелдә Иван Сәгъдәткә мохтаҗ. Әйе, Сәгъдәт аның алдында бик көчле. Ул атлы, теге атсыз. Аның көтелмәгән юлдашын тынычландырасы, ни беләндер куандырасы, хәтта берәр ризык кәтрәсе биреп, тамагын ялгыйсы килеп, чана башына карады, андагы төенчекне күрмәгәч, исенә төшереп, үзе дә телен шартлатып куйды. Кесәсен капшады, аннан да ипи кыерчыгы түгел, җиңгәсенең алсу бармаклары ике алма чиккән кульяулык килеп чыкты. Ул аны Иванга сузды.

— Борыныңны сөрт.

Тегесе көтмәгәндә күз алдында ап-ак кульяулык күреп, югалып калды, алырга сузган кулын кире тартып алды:

— Не моһу. Ишь какой чистый.

Һәм нишләргә дә белмичә аптырап, канлы борынын җиң очы белән сөртте. Моны күреп Сәгъдәтнең күзләренә яшь типте. Анның чанасы янә дә тәмугтан оҗмахка әйләнгән иде. Күршедә яткан урыс авылы егетен утыртып ак карлар өстеннән ат чанасында очкан малай кульяулыгын бер тапланмас куаныч итеп кире кесәсенә салды.

— Как яво. Это.

Җир бер, әмма аларның телләре һәм җырлары төрле иде шул. Әмма бер-берсенең телләрен-җырларын белмичә дә бер-берсен аңлыйлар иде. Аларны уртак бәла якынайтты. Шунысы кызык: мәктәптә немес телен өйрәнгән, әмма «'эssen, trinken, schlaffen» («ашарга, эчәргә, йокларга»)дан башка бернәрсә белмәгән ике малайны татар авылына Прәгрис дигән немес аты җилдерә иде. Сәгъдәт, кәефе килеп, тирә-ягын күздән кичерде. Офыкка тәгәрәп барган кояшның нурлары «Түр» урманы эчләрендә караңгылык куертып, күк өстенә кат-кат булып түшәлгән каурый сыман болытларның эчләрен алсулык белән сугарган. Бу алсулыкны татлы су итеп эчәсе килеп китте. Сусаган икән. Иван исә туктаусыз сызлана, уфыра, чабатасына ыштыр урап киелгән аяклары исә күзгә күренеп юаная, күпереп шешә һәм ул аларны сыйпап, үзен түгел, гүя аягын юата иде...

Юл ачыклыкка килеп чыкты, аннан сыртка күтәрелде. Калын, урыны-урыны белән ерып чыга алмаслык кара урманга әверелгән «Түр» урманы шулай көтелмәгән алан ачыклыклары белән үзен яктыртып ала да аннан тагын төпкелгә чума. Бу урманнарда заманында баскынчыларга каршы Батырша яулары, Пугач качаклары, соңгы сугыш дизертирлары яткан дип сөйли риваятьләр. Исенә төшкән саен артына борылып карый — шөкер, куа килмиләр икән. Монда, бераз эчтә, Сөлекле күл бар. Кешегә түгел, атка сала торган эре сөлек. Сөлек салдырган атлар бозык каннан арынып савыга, баскан җирендә йоклый, йөкне ике тапкыр артыграк тарта.

Уң тарафта, аста, үзәнлектә, Кырыкнарат һәм Корманай авылларының үзләре күренмичә генә төтен саркыткан морҗаларының зәңгәрсу баганалары шәйләнеп калды. Җылынып куйгандай булды. Сул яктагы почмагына бер учма яшел печән белән аклы-каралы бозау бәйләнгән җылы өйләре, абзарлары, нәкъ шушы аклы-каралы бозау кебек аклы-каралы сыерлары күз алдына килде. Малай авыз чите белән генә көлемсерәп куйды. Көлемсерәрлек тә шул. Күптән түгел соңгы көннәренә җиткән буаз сыерлары югалды. Көпә-көндез. Бар авылның мең күзе алдында. Булган хәлме? Эзли торгач, аерып атлаган кушаяклы эзләр аларны Мендәрле Кул чишмәсе янындагы карагай урманына алып килде. Әнекәйгенәм, карагай төбендә, аның яшел энәле түшәгенә бер кушуч аклы-каралы җылы булып анасы карыныннан төшкән бозау, чак-чак буынлана биреп, әнисенең имчәген талкый, ә әнисе, күзләреннән шатлык яшьләре агызып, карагайлардан ботаклар сыдырып алып, ямь-яшел ылыс чәйни!.. Гүя әнисе баласын яшел бишектә тудырыр-тирбәтер өчен генә урман түшәгенә алып килгән дә, аны тудырып, ап-ак ай итеп ялаган. Гадәтенчә, хәтта салган күлмәк чүбен дә ашамаган, баласын исә гүя тоньяк кабиләләре кебек, чыныктырыр өчен кар өстенә ыргыткан, ә бала өшемәгән, аякланып, әнисен килеп табып, лач та лоч имә башлаган. Әнисенең ак тешле авызында яшел сөтле ылыс!.. Тансыклаган!.. Тансыклагач, ала сыер кадәр сыерның чыгып киткәнен авылның мең күзе дә күрми калган...

Иван мыш-мыш килеп сүзсез баруын дәвам итте. Сәгъдәт, сөйләшәсе, бик күп сораулар бирәсе килсә дә, чарасыздан бичара иде. Юлдашы, киресенчә, төртеп төшереп калдыра күрмәсен дигәндәй, үзенә-үзе кереп бикләнде, йомылды. Ул гадәттән тыш уяу

иде. Гүя ул чананың хәзер бернинди дошмансыз, дус яши торган галәмгә әйләнгәнен башына да китерә алмыйча исәнгерәгән иде. Чиксез яланда ике җан булып сөйләшми барудан җәфаланган Сәгъләтнең уйлары әллә кайларга китте. Бу юл — күпне күргән юл. Ата-бабалар, шул исәптән әткәсе дә, хәтта Иванның Хлеборобындагы шабралар да шушы юл белән яуга киткәннәр, исәннәре шушыннан кайтканнар. Үлем хәбәрләре, әткәсенең үлем хәбәре дә шушыннан килгән. Нигә еракка барырга? Хәтерендә, урактагы әнисе янына «Урман арты» басуына барганда, хат ташучы Суфия апа ана шушы юлда очрады бит. «Мә, әтиеңнән хат, әниеңә тапшыр. Мәтри, кысып тот, очып китмәсен!» — дип аның кулына өчпочмаклы хат тапшырды. Әй, йөгерде ул әнисе янына кош булып, әй, очты гына!.. Кысып тотудан бармак очларыннан каннары тама башлар кебек тоелды. Әнисе хатны укып чыгалмады, һушын югалтып егылды. Баксаң, әтисенең һәлак булганлыгын хәбәр иткән хат булган икән. Иванның әтисе бар микән? Ул да шундый хатны әнисенә илтмәде микән? Әллә аларның әтиләрен фронтка алмаганнармы? Әйе, бик мөмкин, бу якларга күптән түгел генә килгән Хлебороб шабраларына, шул ук бабайлар раславынча, татарларның иң яхшы җирсуларын, урманнарын, бихисап тормыш уңайлыкларын бүлеп биргәннәр. Ул хәтәр заманнарда җирле халыкның тарихи җирләре өчен килмешәкләр белән сәнәккә барып җиткән көннәре дә булган. Ничек инде бу? Аллаһтан кешеләр тигез, ә җирнең яхшысы — берсенә, начары — икенчесенә. Аның ни өчен шулай булганлыгының серләрен бәлки чанада барган Иван беләдер?

Алар сырт буеннан баруларын дәвам иттеләр. Менә озакламый утыртып үстерелгән тирәклеккә җиттеләр. Берәр чакрымнан Хлебороб та калкып чыгачак. Күп дигәндә аллы-гөлле балчык белән сыланган алтмыш-җитмеш йорттан торган һәм бер-берсен кысмыйча-кысылмыйча утырган бу авыл бик иркен итеп ике өлешкә бүленеп сибелгән. Миякә ягыннан килгәндәге кисәге Вознесенка аталып, утызынчы елларда чыккан яңгында көл булгач, икенче өлеше Сәгъләтләрнең Колтамагы ягын биләп, Воскресенка дип аталган. Әнә, тәреләре белән кара каргалар кебек караеп авыл зираты күренде. Сәгъләт ул уңайга бу юлы да карамаска тырышты. Әмма гаугa кузгатып, аннан тере кара каргалар үзләре күтәрелгәч, карарга мәҗбүр булганын сизми дә калды. Шул быелгы җылы кыш алдыннан китми калган каргалар инде алар. Әнә бер яна кабер — балчыгы да утырып бетмәгән. Бәлки бу кадәр карга мәетләр аһын ишетеп җыелгандыр? Сәгъләтнең шундый бер куркыныч риваятьне ишеткәне бар. Бәлки аның урыс зиратларына катнашы юктыр. Имеш, ләхет иясе булганнан соң, илле беренче көнендә, ит сөяктән аерыла һәм мәет бик нык кычкыра. Имеш, бу газаплы тавышка аның каршына бар тере табигать, беренче чиратта, ул асраган мал-туары җыела. Сыер малы зират коймасына ышкынып мөгрәр, ди. Аты исә, хуҗасына ярдәм итәргә тырышып, койма аша сикереп кереп кешнәр, ди...

Менә алар Вознесенкага керделәр. Сәгъләткә Иванны үз ихатасына илтергә, йортына кертеп куярга кирәк иде.

— Син авылның кайсы өлешендә яшисең? Сине кая илтим?

Иван, билгеле, төшенмәде. Сәгъләт бая юл башында үзеннән көч белән тартып алырга теләп бирмәгән дилбегәсен хәзер үз теләге белән юлдашына бирде.

— Мә, үзең алып барырсың.

Кулында дилбегәне күргәч, монысын Иван аңлады кебек. Ул башын кагып, дилбегәне тотты һәм чытык йөз белән елмайгандай итеп, атын үзе алып китте. Бу Сәгъләтнең күңелен күтәрде:

— Это самый. Того.

Иван Сәгъләтнең Колтамагы ягындагы Воскресенкасында яши икән. Озак та үтми алар кушкаен астындагы йорты-абзары кушылып салынган кечкенә, тәбәнәк куыш сыман җиргә сеңгән кура каршына килеп туктадылар. Барча каралтылар

берсе икенчесенә бертуган кебек охшаганлыктан, аларны бутавы җинел иде. Ярый, дилбегәсен Иванга биргән. Мәнге табалмаган булыр иде. Каяндыр колаксыз эт килеп чыгып, бер чанага, бер атка ыргылды да, Иван ачулы кычкырганнан соң, этләре дә куерып килгән көн караңгылыгына сеңде. Беравыкка Иван чанадан төшми дә, курадан бер кеше чыкмый да торды, кичкә каршы өйдә әле ут та алмаганнар иде. Сәгъдәт айнып китте: аның ярдәменнән башка Иван ничек төшә алсын?! Ул чанадан очып дигәндәй төште, Иванның ыңгыраша-ыңгыраша сузган кулын алып, башын аның култыгы астына кертте һәм тагын да газаплырак, үксеп диярлек елаган тавышлары астында гөбе кебек шешкән аяк табаннарын шудыра-шудыра, чанадан төшерде һәм титаклап сикертә-сикертә алып китте. Ул карашы белән татар йортларындагыча урта ишекне, болдырны эзләде. Ләкин таба алмады. Сикеренгән уңайга Иван аны озын кураның арткы ягына, теге очына таба алып китте. Ул биленнән кереп батарлык тирестә йөзгән мал абзары, дөресрәге, тегеннән-моннан мыркылдаган тавышлар ишетелгән дуңгыз сарае булып чыкты. Чучка дигәнне беренче тапкыр күргән, андагы әшәке, сасы исләр белән беренче тапкыр очрашкан Сәгъдәт күңеле уйнаудан чак косып җибәрмәде. Ләкин артка юл юк иде. Ул пималары белән тезенә кадәр тирес боламыгына батып, Иванны алда шәйләнгән якты ярыкка таба өстерәде. Ул ишек булырга тиеш иде. Ишек дигән кара тишек аша үтүгә, аны бугазыннан черегән бәрәңге, әчегән чөгендер исләре буып алды. Иванны ниндидер сәке сыман нәрсәгә утыртырга азапланган чакта чәче-башы тузгыган, башындагы яулыгы чачаклап бәйләнгән бер хатын килеп кереп, арт яктан Иванның янбашына шакшы көрәк белән тондырды:

— Ти һде шляешься, бесстыжий поросёнок?!

— Ма-ман-ня! — дип кычкырып җибәрде Иван. — Не бей! Сгину!!!

— Сһин һоть чичас, безродный!.. Ваня-вонючка!..

Ананың мондый кыйланышы Сәгъдәт өчен коточкыч фаҗига иде.

Әле дә аның әнисе болай кыйланмый. Тәүбә-тәүбә!.. Егет кызарынды, Иван алдында оялып, нишләргә белмичә, улы белән анасы арасына кереп, зиһененә килгән беренче сүзне кабатлады:

— Низ-зә, апа. Низзә.

Маржа аны ачулы караш белән күзеннән уткәзде. Аның йөзе үзгәрде. Улын китерүче егет чит кан, ят җан иде.

— Ти ещё мене разуму катишь? Иди, покедова, поһаный!..

Һәм тагын да нәрсәләр беләндер карганып, тирес көрәге белән Сәгъдәткә селтәнде.

Көне буе ала-коладан килеп, инде хәзер күзенә башка ак-кара күренмәгән Сәгъдәт дуңгыз боламыгында чаптыр-чоптыр килеп тышка чыгып йөгерде.

Тышта аны Нимесе һәм саф һава каршылады. Ул тулы сулыш алып, моңа кадәр кичермәгән сагыш белән атының ялларыннан сөйде: «Түз, малкай, түз. Ерак калмады». Прәгрис аның күзләренә карады. Бу күзләр күргән-кичергәннәренә ышанмый тонган иде. Әмма аларның бик тә, бик тә эчәсе килгән иде. Ике йорт аша кое сиртмәсе күренде. Ат үзе шуңа таба китте һәм Сәгъдәт туктатканны көтми килеп тә төртелде. Бу сәяхәттән бер башка үскән мосафир, инде егет булып җиткән үсмер, чылбыры белән доңгыр-доңгыр килеп чиләгендә су күтәрде һәм атын сугарды. Ат суны ялындырмый чүмерсә дә, сызгырган булды егет. Үзе бертуктаусыз, «Ваня»сы аңлашыла, «вонючка»сы, «поһаные» нәрсә була икән?» дип баш ватты.

Аннан үзе дә эчте.

Алар кайтыр юлга төштеләр.

Ырымбур далаларыннан Дим-Өязе-Ашкадар тарафларына кичке караңгылык савыла башлаган иде.

# ТӨРКИ СҮЗ СӘНГАТЕНӘ БЕР КАРАШ

**Бүгенге көндә берничә дистә халыкны, алты мөстәкыйль дәүләтне, 150 миллионнан артык кешене үз эченә алган төрки телле әдәбиятнын бай һәм озын-озак тарихы, жиһан рухи мирасында үзенә лаеклы урыны бар. Баласагуни (XI йөз) һәм Нәваи (1441-1501), Йуныс Әмрә (1250-1321) һәм Физули (1494-1556), Мәхтүмколый (1733-1798) һәм Абай (1845-1904), Тукай (1886-1913) һәм Айтматовлардан (1928-2008) башка дөнья әдәбиятын күз алдына да китереп булмый. Халыкка хезмәт итү, камил инсан тәрбияләү, гадел жәмгыять төзү, туган жиргә һәм илгә тугрылык, адәмнәр һәм кавемнәр арасында дуслыкны ныгыту — әдәбиятка йөкләнгән бу төр гуманистик, әхлакый һәм эстетик бурыч-вазифаларны төрки әдипләре һәрчак вөждани югарылыкта башкарырга омтылдылар, хәтта әлеге изге юлда гомерләрен дә кызганмадылар.**

*Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр*
*Шигыремдәге изге антына.*
*Бар жырымны илгә багышладым,*
*Гомеремне дә бирәм халкыма.*

Бөек шагыйрь Муса Жәлилнең (1906-1944) бу юллары авторнын шәхси язмышын гына түгел, ә йөзәрләгән каләмдәшләренең жан авазын ишеттерә.

Хәзерге төрки сүз сәнгате, мәһабәт имән кебек, үзенең тамырлары белән тарихның тирән катламнарына, төпкелләренә — борынгы мифологиягә һәм фольклорга, язма истәлекләргә, шулай ук башка кавемнәрнең дә рухи хәзиналәренә барып тоташа. Алфавит — язу графикасын уйлап табу жәмгыятьнең билгеле бер үсешен таләп итә һәм аны бик сирәк кавемнәр генә башкара. Бу яктан безнең борынгы әби-бабаларыбыз шактый бәхетле: алар өч төрле графика [туран (һун), рун, уйгур] уйлап тапканнар. Моннан тыш әле кытай, гарәп, латин, кирилл язуларын да кулланганнар. Болар арасында, әлбәттә, төп һәм хәлиткеч урынны гарәп графикасы били. Ислам дине белән бергә кергән бу язу бездә мең елдан артык гамәлдә булган. Элеккеге төрки язма истәлекләренең дүрттән өче, мөгаен, гарәп графикасындадыр. Бу язу һәм мөселман дине күп гасырлар буе төркиләрне берләштерүче төп фактор да булып торган.

Соңгы ике мең еллап вакыт эчендә әби-бабаларыбыз тудырган әдәби ядкярләр бихисап күп. Алар арасында аеруча аерылып торганнары, сүз сәнгате үсешендә гаять мөһим роль уйнаганнары да шактый. VI-X гасырларга мөнәсәбәтле рун истәлекләре борынгы чорлардагы яшәешебезне, гореф-гадәтләрне, башка илләр һәм кавемнәр белән бәйләнешләрне аңлауга ярдәм итәләр. Мәхмүд Кашгарыйның «Дивание лөгатет-төрк» (1072-1074) — мифология, фольклор, тел белеме, язма әдәбият, география һәм кайбер башка тармакларның синтезы, бәһаләп бетергесез хәзинә сандыгы. Шунысын да искәртик: халык авыз ижаты карыныннан чыккан язма әдәбият сабый чагында да, балигъ булгач та фольклор белән бәйләнешен өзмәде, алар даими аралашып, еш кына бер-берсе белән керешеп, кан алышып яшәделәр. Күп кенә авторлар үз әсәрләрен халык ижатындагы легенда-риваятьләргә, образ-мотивларга таянып яздылар. Үз чиратында фольклор да, гәрчә язма әдәбият белән бәйләнештә торса да, үзенең асылын жуймады, үсүен, яшәвен дәвам итте. Афористик жанрлар, бәет-жырлар белән бергә, «Манас» кебек биниһая зур һәм күләмле эпос-дастаннар да үз тереклекләрен дәвам иттерәләр.

1069 елда Йосыф Баласагунинын «Котадгу белек» әсәре барлыкка килә. 14 меңгә якын шигъри юлдан торган бу бөек поэма-дастан үзенең сәнгати камиллеге,

фикри байлыгы ягыннан Гомер һәм Вергилий, Фирдәүси һәм Низами әсәрләре белән янәшә торырлык. Юкка гына аны «шаһ китап», «төрки сүз сәнгатенең таҗы» дип йөртмиләр. «Котадгу белек» алга таба милли төрки әдәбиятлар үсешенә дә зур йогынты ясады. Аның тәэсире Нәваилар, Мөхәммәдьярлар (1497-1549) аша Абай, Тукайларга кадәр килеп җитте.

Үзәк Азия Баласагунилар, Әхмәд Ясәвиләр чорында гына түгел, аннан соңгы гасырларда да төрки дөньяның мөһим әдәби мәркәзе булып калуында дәвам итте. Лотфый (1366-1466), Нәваи (XV), Бабур (1483-1530) иҗатлары төрки сүз сәнгатен яна баскычка күтәрде. Төркестан, Урта Азия тарафлары белән бергә, Идел-йорт, Кавказ, Кече Азия дә төрки сүз сәнгатен үстерүгә үзләреннән зур өлеш кертте... Бу аеруча Алтын Урда (Котб, Харәзми, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи...) һәм Урта гасыр Госманлы (Әхмәди, Шәйхи, Хәмди...) мәмләкәтләрендә нәтиҗәле булды. Мәгълүм ки, әдәбият һәм сәнгать үсеше шактый дәрәҗәдә дәүләтчелек белән бәйле. Бу төрки сүз сәнгате язмышында да ачык күренә. Күп гасырлар буе төрле мәмләкәтләр тоткан безнең әби-бабаларыбыз XVI йөздә әкренләп бәйсезлекләрен югалта башлыйлар. Бер-бер артлы татар ханлыклары, бераздан Үзәк Азия һәм Кавказдагы дәүләтләр Рәсәй тарафыннан яулап алына. XIX гасыр ахырларына таба, Төркиядән кала, башка төрки кавемнәр колониаль коллыкка эләгәләр. Бу хәл, әлбәттә, аларның рухи, мәдәни үсешенә дә гаять тискәре йогынты ясый. Мәсәлән, иң беренчеләрдән булып бәйсезлеген җуйган татарларда әдәбият XVII-XVIII гасырларда чын мәгънәсендә торгынлык кичерә, элеккеге казанышларның шактые юкка чыга. Мөстәкыйльлеген саклаган Госманлы мәмләкәтендә исә әдәбият һәм сәнгать өзлексез рәвештә үсә, байый бара. Анда туган әдәби ядкярләр билгеле бер дәрәҗәдә башка төрки кавемнәрнең дә рухи ихтыяҗын канәгатьләндереп тора. Дәүләтчелеккә дәвамлы рәвештә ия булу аркасында төрек сүз сәнгате XX йөздә һәм яңа гасыр башында да төрки дөньяда әйдәп баручы ролен саклап килә. Бу чорда иҗат иткән Рәшид Нури Гюнтекин (1889-1956), Назыйм Хикмәт (1907-1963), Азиз Нәсин (1915-1993), Нихәт Атсыз (1905-1975) һ.б. бик күп авторларның әсәрләре бүтән халыкларга да яхшы мәгълүм. Орхан Памукның (1952 елгы) 2006 елда Нобель премиясенә лаек булуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Ч.Айтматов үзенең бер чыгышында Көньяк Америка һәм Төркия әдәбиятларын, аеруча хикәя-бәяннарын хәзерге дөнья сүз сәнгатенең иң матур үрнәкләре дип атаган иде.

Дәүләтчелегеннән мәхрүм ителгән төрки кавемнәр, әлбәттә, колониаль коллыкка каршы күп мәртәбәләр көрәшкә күтәреләләр. Әмма алар, гадәттәгечә, рәхимсез рәвештә бастырыла килә. XIX гасыр ахырларында, аеруча XX йөз башларында милли хокуклар, демократия өчен көрәш бигрәк тә көчәеп китә. Инкыйлаблар Рәсәй империясен дер селкетә. Шушы дулкында төрки сүз сәнгате дә ныклап үсә башлый. Шигъри сүз азатлык, демократия, милли барлык өчен көрәшнең көчле коралына әйләнә. Әдәбият мәйданына Г.Исхакый (1878-1954), Г.Тукай (1886-1913), Сабир (1862-1911), Ниязи (1889-1929), Токтогул Сатылганов (1864-1933), Н.Нариманов (1871-1925) һ.б. бик күп каләм әһелләре килә. Милли тәрәккыят, шәхес азатлыгы, белем-мәгърифәтне зурлау, яңалык өчен көрәш идеяләре бу әдипләрнең иҗатын ярып бара.

СССР таркалгач, совет чорын каралтып күрсәтү үзенә күрә бер модага әверелде. Дөрес, анда рәхимсез сугышлар, шәхес культының, тоталитар режимның миллионлаган корбаннары булды. Әмма, ничек кенә булмасын, бу чор — безнең тарихыбыз. Аны тәмам юкка чыгарырга омтылу һич тә дөрес түгел. СССР вакытында күп кенә халыклар, гәрчә шактый чикләнгән күләмдә булса да, үз дәүләтчелекләрен булдырдылар. Союздаш республика статусы алган төрки кавемнәр икътисад өлкәсендә генә түгел, әдәбият, сәнгать, мәгариф, фән тармакларында да зур үсешкә ирештеләр. Аеруча казакъ, азәрбайҗан әдәбиятлары алга китте. Моңа кадәр төп рухи ихтыяҗларын, нигездә, фольклор, башка халык ядкярләре белән канәгатьләндергән кыргыз, башкорт халыклары Чыңгыз Айтматов, Мостай Кәрим (1919-2005) кебек бөек әдипләре белән дөньяга танылды.

Төрки сүз сәнгате үзенең ике мең еллап яшәеш дәверендә искиткеч бай идея-эстетик хәзинә туплаган. Аның теләсә нинди уй-кичерешне бирә алырлык, кешене,

чынбарлыкны тулы гәүдәләндерерлек бай, сыгылмалы әдәби теле бар. Төрки әдипләре әдәбиятның барлык төр жанрларын иркен файдалана. Алар арасында фәрд-икеюллыклардан алып, роман-эпопеяларга кадәр әсәрләр бар. Төрки сүз сәнгатендә инсан һәм милләт яшәешенең, тормышның бик күп төрле мәсьәләләре чагылыш тапкан. Элегрәк чор әсәрләрендә дини-суфыйчыл карашлар да зур урынны били. Авторлар кеше гомеренең чикләнгәнлеге, яшәү мәгънәсе, игелек кылу, тәрбиялелек хакында да күпләп язалар. Абстрактлыктан, гомумилектән конкретлыкка күчә бару кешегә, аның күнел дөньясына ныграк якынаю, адәм баласын катлаулы иҗтимагый, социаль бәйләнешләрдә бирү, эстетик тәэсир чараларының көчәюе һәм төрлеләнүе — төрки сүз сәнгатенең эволюцион үсеш-үзгәрешенә хас төп сыйфатлар. Әдәбият иҗтимагый аңга, сәнгатьнең башка төрләренә көчле йогынты ясаучы факторга әверелде. Күп кенә рәсем, музыка, кино, театр сәнгате әсәрләренең нигезе, төп чыганагы әдәбият булу да бик мәгънәле.

Җиһанның башка кавемнәре кебек, төркиләр дә үз кысаларында гына бикләнеп яшәмәгәннәр, башка халыклар һәм илләр белән төрле мөнәсәбәтләргә кергәннәр, хезмәттәшлек кылганнар. Шуна нисбәтән аларның сүз сәнгате дә үзгәләрнең мәдәнияте белән теге яки бу дәрәҗәдә бәйланышта торган, рухи байлыкларын уртаклашканнар. Борынгырак чорда төркиләр һәм аларның әби-бабалары Кытай, Һиндстан белән ешрак аралашкан. Мифологиядә, фольклорда, рун истәлекләрендә бу төбәкләр һәм илләр белән бәйләнешле сюжет-мотивларның, факт-мәгълүматларның булуы әнә шул хакта сөйли. Генетик яктан Һиндстанга мөнәсәбәтле «Калилә вә Димнә», «Тутыйнамә», «1001 кичә» кебек мәшһүр җыентыклар турыдан-туры да, гарәп-фарсылар аркылы кереп тә төркиләрнең тәмам үз хәзинәләре кебек булып киткәннәр, күн санлы әдәби әсәрләр тууга сәбәпче булганнар.

Мәгълүм ки, Урта гасырларда гарәп-фарсы дөньясы, шул исәптән аның әдәбияты бик нык алга китә, җиһанның мөһим цивилизация үзәгенә әверелә. Аның Әл-Мөтәнәбби (915-965), Әл-Мәгарри (973-1057), Фирдәүси (935-1030), Ф.Гаттар (1119-1223), Ж.Руми (1207-1273), Сәгъди (1203-1292), Хафиз (1325-1389) һәм кайбер башка классиклары бөтен дөньяга таныла. Төрки әдипләре гарәп-фарсы рухы казанышларыннан мул һәм иҗади файдаланалар. Ул телләрдән күп санлы тәрҗемә-шәрехләр эшләнә. Гарәп теле аша безнең әби-бабаларыбыз антик Греция, Рим казанышларын, Сократ, Әфләтүн, Аристу карашларын да теге яки бу дәрәҗәдә кабул итәләр. Шунысын да искә төшерик: төркинең Фәраби (870-950), Низами (1141-1209) кебек бөек затлары үз әсәрләрен гарәп, фарсы телләрендә язганнар. Бу традиция өлешчә алга таба да дәвам иттерелә. Мәсәлән, XIX йөзнең олуг мәгърифәтчесе Ш.Мәрҗанинең (1818-1889) аерым хезмәтләре гарәп телендә.

XIX йөздә, аеруча Тәнзимат дип аталган чорда (30-70нче еллар), Госманлы мәмләкәтендә Аурупа казанышлары, бигрәк тә Франция мәдәнияте белән кызыксыну көчәя. Күпләгән төрек яшьләре Парижда укый, француз телен, әдәбиятын өйрәнә. Төрек теленә Аурупа классикларының әсәрләре тәрҗемә ителә. Еш кына алар Анатолия яшәешенә адаптацияләнә. Ибраһим Шинаси (1826-1871), Намык Кемал (1840-1888), Әхмәд Мидхәд (1844-1913) һәм кайбер башка авторлар Аурупа казанышларын файдаланып күпләгән роман-бәяннар, драмалар иҗат итәләр. Госманлы телендәге бу төр әсәрләр татар, азәрбайҗан укучыларына да ирешә. XIX йөзнең икенче яртысында рус әдәбияты белән кызыксыну да көчәя. Рус, Аурупа рухи казанышларын төрки укучыларга җиткерүдә аеруча Исмәгыйль Гаспралы (1851-1914), Абай (1845-1904), Мирза Фатали Ахундов (1812-1878), Гаяз Исхакый, Тукай нәтиҗәле эшлиләр.

Тышкы бәйләнешләрдән кала, төрки халыкларының, шуна мөнәсәбәттә сүз сәнгатенең дә үз эчендә күп төрле бәйләнышлар яши. Борынгы, ягъни төрки кавемнәренең халык буларак формалашмаган чорга кадәрге әдәбият (якынча XIII йөзләргә кадәр) уртак мирас, гомумтөрки сүз сәнгате рәвешендә карала. Ул милли, төбәк (региональ) әдәбиятларның нигезе, чишмә башы вазифасын үти. XIII-XIV гасырларда төрек (госманлы), татар, бераздан үзбәк, азәрбайҗан, төрекмән, казакъ һәм кайбер башка кавемнәр оеша башлый. Бу дәвердә дә төрки кавемнәр арасында кискен чикләр юк: үзара керешү, күчешләр дәвам итә. Бер үк дәүләтләр составында яшәү дә мөһим роль уйный. Алтын Урда шагыйрьләре Харәзми (XIV),

Лотфый һәм үзбәк, һәм татар әдәбияты кысаларында карала. XV йөз авторы Өмми Кәмал Идел буенда, Кавказда, Кырымда да яши, гомеренең ахырын Кече Азиядә уздыра. Чыгышы белән Әстерхан «нугае» булган Суфый Аллаяр (1616-1713) Сәмәрканд төбәгендә яши, Идел буена да килеп-китеп йөри. Ул һәм үзбәк, һәм татар әдәбиятларының үсешенә сизелерлек өлеш кертә. Акмулла (1831-1895) – бер үк вакытта татар, казакъ, башкорт халыкларының уртак шагыйре. Чыгышы белән татар булган күренекле тюрколог Рәшит Рәхмәти Арат (1900-1964) һәм төреккә, һәм татарга хезмәт итә. Тарихтан мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Этник якынлык, телләрнең охшашлыгы, дини уртаклык һәм гарәп графикасы да төркиләрне якынайтуда мөһим роль уйнаган. Элек мөселман төркиләре бер-берләренең әсәрләрен, нигездә, оригиналда укыганнар. Истанбул, Казан басмалары бөтен төрки дөньяда киң таралыш тапкан. Төрки телләрдә күпләгән гарәп-фарсы сүзләренең һәм шәкелләренең урын алуы да аларны якынайта төшкән. Кызганыч ки, төрекләр узган гасырның 20-30нчы елларында «тел реформасы» вакытында күпләгән гарәп-фарсы алынмаларын чыгарып ташлап, аларны үз сүзләре белән алыштырдылар. Шуның нәтиҗәсендә төрек теле башка төрки телләрдән шактый аерымланды. Үз чиратында СССРдагы төрки телләргә күпләгән рус, Аурупа алынмалары кертелде. Гарәп графикасы урынына кирилл язуының төрле вариантлары кабул ителүе дә үзара аңлашуны өлешчә кыенлаштырды.

Төрки сүз сәнгатенең үз эчендә бер үк яисә охшаш сюжетка язылган әсәрләр дә шактый. Уртак образлар, детальләр дә күп. Әдәби жанрлар, шигъри үлчәмнәр дә бер үк диярлек. Төрки авторларының бер-беренә нәзыйрә язулары да аларны якынайта. Охшаш шартлар, совет чынбарлыгы да төрки әдәбиятлар арасындагы якынлыкны арттырды. Милли төрки әдәбиятларда тугандаш кавемнәрнең кешеләрен, тормыш-көнкүрешен чагылдырган әсәрләр дә шактый. Г.Ибраһимовның (1887-1938) «Казакъ кызы» романы — шуның күркәм бер мисалы.

Совет чорында без Төркия тормышын, әдәбиятын юньләп белмәдек. Хәзер вазгыять башка. Төрек теленә һәм аннан күп тәрҗемәләр эшләнә. Бу юнәлештә аеруча Фатма Өзкан, Мостафа Өнәр, Фатих Кутлу нәтиҗәле гамәлләр кылалар. Фатих Кутлу Тукай, А.Гыйләҗев, Ә.Еники һ.б. бик күп кенә татар әдипләренең әсәрләрен төрек телендә бастырып чыгарды. Үз чиратында ул төрек авторларының китапларын татар укучыларына ирештереп бара. Төрек теле башка төрки әдәбиятлар белән танышуда, бер-береңне ныграк аңлауда, киңрәк дөньяга чыгуда да мөһим фактор булып тора.

СССР таркалгач, аның составындагы төрки әдәбиятлар арасында үзара бәйләнешләр шактый йомшарган иде. Соңгы берничә елда бу кимчелекне бетерү юнәлешендә житди генә чаралар (фестивальләр, конкурслар, форумнар, уртак проектларны гамәлгә ашыру һ.б.) үткәрелә. Электрон мәгълүматлар туплана. Бер телдән турыдан-туры икенче телгә тәрҗемәләр күбәеп бара. Мәсәлән, Рәдиф Гаташ үзбәк шагыйре Чулпан, казакъ әдибе Магҗан Җомабаевның шигырьләрен татар телендә аерым китап итеп чыгарды. Тугандаш төрки телләрдән татарчага тәрҗемә итүдә А.Хәмидуллин, Ф.Тарханова, М.Галиев, Р.Корбан һ.б. уңышлы гына эшләп килөләр. Тургай һәм Р.Харис тырышлыгы белән татар һәм чуваш шагыйрьләренең аерым әсәрләре тәрҗемә ителеп, Казанда һәм Чебоксарда дөнья күрде. Искешәһәр, Казан, Мары калаларының төрки мәдәни үзәкләре булып торулары да файдага. Төрки театрларының Казанда уздырыла торган Халыкара «Нәүрүз» фестивале дә үз тамашачыларын тапты. Төрки әдәбиятларын үзара якынайтуда, алардагы казанышларны пропагандалауда һәм үстерүдә халыкара ТЮРКСОЙ оешмасы да бик нәтиҗәле эшли.

Бөек Гаспралының төркиләргә карата моннан йөз еллар элек әйткән «телдә, уй-фикердә, эш-гамәлдә бердәмлек» лозунг-шигаре бүген дә заманча, актуаль яңгырый. Аның эзлекле рәвештә гамәлгә ашырылуы төркиләр өчен генә түгел, ә башка кавемнәр өчен дә файдалы, игелекле булачак.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

# ТӨРКИЛЕКТӘ ТӨРЛЕ БУЛСАК ТА, БЕРГӘ БЕЗ

«Гөроглы / Көроглу / Гүроглы» дастаны турында университеттагы студент елларында ук Резеда Кадыйр кызы Ганиеваның безгә дәртләнеп-илһамланып сөйләве һаман хәтердә, әле дә колакта янгырый әле...

Ин элек бу гаҗәеп әсәр Якын Көнчыгышта һәм Урта Азиядә яшәүче бик күп халыкларның уртак мирасы булуы белән сокландыра. Ул бер үк вакытта азәрбайҗан һәм төрек, казакъ һәм төрекмән, үзбәк һәм каракалпак, кумык һәм көрд, ажар һәм дагыстанлыларга гына түгел, хәтта төрки дөньядан ераграк торган грузин, абхаз, әрмән, таҗик, гарәп, болгар телләрендә дә һәркайсына газиз, кабатланмас аһәңле, үз, табигый булып янгырый. Тянь-Шаньнан алып Балкангача, Каспий буеннан Себер кинлекләренә кадәр күнелләрне әсир иткән әлеге дастан, сюжет сызыкларында күп кенә уртаклык булуына карамастан, төп каһарманның исеме төрлечә әйтелеше белән генә түгел (Көр-оглы, Гёр-оглы, Гороглы, Гургули, Гуругли, Курулли, Күр-оглы...), һәр халыкның тарихи-иҗтимагый тормыш үзенчәлеге, рухи-мәдәни традицияләре, фикер үсеше белән аерыла.

Сүз уңаенда, Гөроглының барлык версияләрдә дә милләте белән төрекмән (түркмен) икәнлеген, ә исеменең «күрмәс кеше (сукыр)» яки «гүр (үлгән кеше)» баласы дигән ике мәгънәсе булуын искә төшерик. «Күрмәс» — явыз хан сукырайткан атасы (төрекмән версиясендә — бабасы) язмышы аша аңлатыла. Икенче вариантта исә (үзбәк, таҗик, хәер, шул ук төрекмән мифологиясендә дә) ул әнисе гүр иясе булгач кына туган малай буларак тасвирлана. Каһарманның Гыр (Кыр) аты да (гыр — төрекмәнчә дала мәгънәсендә) — Аллаһ бүләге — тылсымлы көчкә ия.

Риваятьләргә, могҗиза-сихергә, әкияти-хыялый хәлләргә уралып, сюжеты һәм каһарманнары маҗаралар рухы белән өретелүенә карамастан, галимнәр Гөроглыны тарихи шәхес — халык мәнфәгатен яклап көрәшкә күтәрелгән һәм үзенә күпләрне ияртә алган әйдәман, җыр-сүз остасы дип саныйлар. Гөроглы гайре табигый көчкә ия, аның күкләрдән иңгән кылычы, канатлы аты бар. Аның көрәштәшләре белән бергә төзегән кальга-ныгытма-иләндә (Чандыбил, Чамбел, Шамлыбел, Шимлибил, Җамбилбел...) халык үз хыялындагы бәйсезлек, хөрлек, гаделлек утравындагы сыман көн күргән. Бу шаһ-әсәрнең төрекмән версиясе гали кешеләрнең шатлыгын һәм аһ-зарын, югалту-табышларын, мәхәббәтен һәм нәфрәтен чын, тормышчан итеп тасвирлавы белән аеруча кызыклы.

«Гөроглы»ның төрле телләргә тәрҗемәсе билгеле. Мәсәлән, рус дипломаты Александр Ходзько аның үзе язып алган тулы текстын беренче буларак инглиз теленә тәрҗемә итеп, 1842 елда Лондонда бастырып чыгара. 1889 елда Казанда «Хикаяти Гөроглы солтан» җыентыгы нәшер ителә. Әмма бу — дастанның азәрбайҗан версиясе. Кызганыч, аерым галимнәребезнең «Гөроглы» турында шактый тирән, әтрафлы хезмәтләре булса да, әлегәчә бу әсәрнең татар теленә тулы тәрҗемәсе юк. Ә бит «төркилектә бөек без» дип күкрәк киереп расләр өчен, аның турында мәгълүмат, хәтта аерым өзекләренең мәктәп программасына һәм дәреслекләргә керүе дә бик урынлы булыр иде. Үз чиратында татар халкының «Идегәй», «Чура батыр» кебек җәүһәрләре төрки кардәшләребезнең шундый ук игътибарына лаек дип уйлыйм.

Заманында Мостай ага Кәрим язганча, һәр милләт бүген дә миф һәм каһарманнар рухы белән тереклек итүгә мохтаҗ. Гөроглы халыклар хәтерендә «әйбәт» юлбасар түгел, ә юксылларның юлбашчысы буларак яши. Шуңа күрә аның Төрекмәнстанда милли байлык һәм горурлык билгесе булып саналуы табигый. Тикмәгә генә мени Гөроглының сурәте акчага (төрекмән манатына) төшерелгән, башкалада аңа һәйкәлләр куелган?!

Журналыбызның бу санында дастаннан кечкенә бер өзек татарчага тәрҗемәдә тәкъдим ителә.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**

# ГӨРОГЛЫ

ДАСТАННАН ӨЗЕК

Гөроглы, яраларыннан арынып, Өвез җанны (асрамага алган улын) үз янына чакырды һәм, элеккечә үк, дошманнарының астына ут яга башлады. Ел буе сугышты Гөроглы — һаман да шул Нишапур белән инде. Барганда да башларын чапты, кайтканда да.

Әлеге заманда Нишапур белән Балы-бәк падишаһ идарә итә иде. Беркөнне ул яраннарын үз хозурына дәшеп алды һәм әйтте:

— Егетләр, киңәш бирегез әле, инде нишләргә. Бу әшәке ишәк карагы, башкисәр, илгә тынычлык бирми бит...

Яраннары болай җавап бирде:

— Сез аны, тәкъсир, яныгызга чакырыгыз, зур бүләкләр бирегез, ат, затлы киемнәр бүләк итегез. Аның белән солых төзегез, тәкъсир!

Падишаһның карт вәзире бар иде. Аны чакырды да әйтте падишаһ:

— И зирәк вәзирем! Миңа яраннарым шундый-шундый киңәшләр бирә. Син моңа ни әйтерсең?

— Акылсыз киңәш бирәләр сиңа, тәкъсир. Юлбасар бүләкләренне алыр, син биргән чапаннарны кияр, атыннан да баш тартмас, ә кайтыр юлында иленне талар, шуннан соң аннан җилләр искән булыр. Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманына карый, дип юкка гына әйтмиләр инде. Башкисәр-каракка ярарга тырышып яшәү килешмәс, тәкъсир!

— Син нинди киңәш бирәсең соң, вәзир?

— Минем киңәшем шул, тәкъсир... Юлбасарның Мәҗнүн Дәли дигән кушаматлы Гыр аты бар, дип сөйлиләр. Менә шул аты аркасында гына ул ишәк карагы Гөроглы каһарман булып танылган, имеш. Шул Гыр атына атланмаган чакта ул ун кадак таш та күтәрә алмый, диләр.

— Ә без ул Гыр атны ничек кулга төшерербез соң, вәзирем?

— Аны көч белән алып булмас. Акчага да сатылмас. Шулай да бүләккә саран булмасаң, безнең кальгада синә Гыр атны тотып кайтучы хәйләкәр адәмнәр табылыр. Хәйлә сиңа атны алырга булышыр, тәкъсир!

Падишаһка бу киңәш ошады һәм ул шунда ук кальгада хәбәр таратырга боерды: «Кем дә кем миңа Гыр атны — юлбасар Гөроглының атын тотып китерергә алына, ул адәмгә мин шунда ук биш йөз алтын бирәм, ә атны алып килүе белән — аны арыктагы суны бүлүче итеп куям, гомере буена казна исәбенә нужа күрми тереклек итәр!»

Кальгада бер ир белән хатын яшәп ята иде. Аларга йөз сиксәнешәр яшь иде. Ирнең исеме Ләнгер карт, ә карчыгыныкы — Шаһмамаи-Зүлман. Аны Хирс-биби дип тә йөртәләр иде. Карчык иренә әйтте:

— Карале, карт Ләнгер! Ә бәлки ул атны мин алып кайтып бирә алырмын?

— Әй син, юньсез карчык! Мин бит син тукыган алача бәзен сатып кына тереклек итәм. Әгәр син китсәң, ачтан үләргәмени миңа?

— Юк инде, юк! Падишаһ биш йөз алтын вәгъдә иткән, диләр ләбаса. Шуларны мин сиңа калдырам. Үлсәң дә, тук булып үлерсең.

— Ярар соң, кортка, алайса, бар, бәлки, нәрсә дә булса майтарып чыгарсың, — дип җаваплады карт.

Карчык падишаһ хозурына китте. Бил бөкте, аннары тураеп, хөрмәт йөзеннән кулларын күкрәгенә куйды.

— Сөйлә, әби, ник минем янга килдең.

— Нәрсәсен сөйләп торасы: сиңа Гыр ат кирәк — биш йөз алтыныңны санап бир, тәкъсир!

— Син, бетәшкән, хәлсез карчык, ничекләр ат тотып килмәкче буласың соң?

— Ни әйтим сиңа, тәкъсир? Ул атны берәүгә дә тотарга язмаган. Аны бары тик мин — хәйлә-мәкер һәм сихер остасы гына алып килә алам.

Карчыкны барысы да белә иде. Вәзирләр дә җөпләде:

— Шулай, тәкъсир, бу дөньяда кем дә булса ул атны тотып китерәм дисә, моны шул карчык кына булдыра ала. Хәйлә һәм сихердә аңа тиңнәр табылмас, тәкъсир! Ул җир астында елан шуышканын да ишетә.

Падишаһ болар белән килеште дә биш йөз алтынны бирергә боерды. Алтын тулы капчыкны карчыкның өенә үк илттеләр. Акчаны ул Ләнгер картка тоттырды, үзе биш алтынга ишәк сатып алды һәм Гүрҗустанга юл алучы кәрванга кушылды...

Юл озын, ә сүз кыска. Көннәрнен берендә, карангы төшәр алдыннан, кәрванчылар шомлана башладылар һәм колактан-колакка ирештерделәр: «Дөянне ныклабрак тот, шыпыртрак сөйлә!» Карчык монын юкка гына түгеллеген анлады, ишәген кәрван башына таба куды.

— Әй, кәрван башы! Сез нишләптер кабаланасыз әле бүген! Бер-бер хәл булмагандыр бит?

— Әбекәем жаным, без Чардаглы (Дүрт таулы) Чандыбил янынннан узабыз. Анда Гөроглы бәк хакимлек итә. Кояш чыкканчы бу жирләрне узып өлгермәсәк, ул безне ясак түләтеп бөлгенлеккә төшерер. Шуна бик зур салымнан котыласыбыз килә.

Чандыбилләге Гөроглы исемен ишетү белән, карчык, кәрваннан аерылып калыр өчен, ишәген тыя башлады.

«Алла кушып, Гөроглы кәрван юлын карарга чыгар әле: минем эземне күрер дә, бәлки, мин аны тозакка эләктерә алырмын».

Шулай дип уйлады ул, ишәгеннән төшеп, күлмәген салды да жиргә утырып шуыша башлады.

...Икенче көнне Гөроглы әйтә:

— Көсе (егетләрнен берсе), безнен акча бетте, тиздән ашарга берни дә булмаячак. Кәрван юлын барып карыйк әле — кемнәр узды икән!

— Һай, Гөроглы! Үзен бар да үзен кара. Син анда нәрсәдер табарсын дип уйламыйм...

— Ярар сон, — дип жавап бирде Гөроглы һәм үзе генә барырга булды.

Зур кәрван эзен күрде ул. Эз буйлап куа киткән иде, шунда бер читкә борылган ишәк эзләренә тап булды. Анда әле тагын ниндидер сәер эзләр бар иде.

Ул бу эзгә басты. Таугa бер күтәрелде, бер аска төште. Калкулыкка менгән иде, күрә: ишәк басып тора, ә анын аяклары астында ниндидер карчык ята. Карчыкнын авызы кара учак сыман, тешләре — казык кебек, муен тамырлары арба читәне диярсен, иске тимерче күреге сыман гел жыерчыктан гына тора.

— Әй, әби жаным, син монда нишләпләр ятасын?

— И, улым! Кәрванга ияреп юлга чыккан идем, тик түзә алмадым, арыдым да аерылып калдым. Ташлап киттеләр алар мине. Сүзеннән таныйм — изге мөселман син. Озаклмый үләрмен дә инде. Күмәрсен мине, улым, бер-ике уч туфрак ташларсын, зинһар.

— Әй, әби жаным, без сина үләргә бирмәбез. Атлан әле ишәгенә, сине кальгага алып китәм.

— Ишәккә менеп утырырлык халем юк. Ипи кисәгеп булса, мина ташласан иде.

— Ишәккә утыра алмасан, үземнен артыма утыртам. Кулынны бир әле!

— Жирдән тора алмыйм шул, — диде дә карчык, кулын сузды.

Гөроглы аны үзенә таба тартты, һәм ябык карчык атнын арт санына жинел генә менеп кунаклады. Ишәкне алдыннан куалап, Гөроглы кальгага юл тотты.

Гөроглы кайчан гына кайтса да, Ага-юнус («пәри кызы», халал жефете) ана каршы чыга иде; ни улы, ни кызы булмавын исенә төшермәсен өчен, атыннан төшү белән, ул аны кочагына ала. Менә әле дә Ага-юнус аны каршыларга чыкты да туктап калды, — Гөроглынын артында килбәтсез бер карчык утыра, карт маймыл диярсен.

— Һай, Гөроглы, болай кемне алып кайттын син?

— Әй, Ага-юнус, мин сина ярдәмче-әбине алып кайттым.

— Жәһәннәмгә олаксын бу әби, анын белән син дә олак. Карчыкны кайдан алдын, шунда илтеп куй. Тугыз көн ераклыгына илт тә шунда ташла! Йә тагын да ераграк — зур тау артына һәм шул тау артында калдырып кайт! Киеменә таш тутырып, дингезгә ташла. Бу карчыкнын йөзе кабахәт, Гөроглы. Ул синен яисә Гыр атыннын башына житәчәк...

— Әй, хатыннарнын чәче озын, акылы кыска дип, күрәсен, юкка гына сөйләмиләр инде. Йә, нинди зыян сала алсын бу карчык!

— Үзен белгәнчә эш ит, тик хатын-кыз ягына мин аны кертмим. Кая телисен, шунда куй аны, Гөроглы!

Гөроглынын ачуы килде.

— Ярар, син аны карый алмыйсын икән, үзебез кайгыртырбыз, — диде дә карчыкны үзе белән алып китте, аны Мәйханәдәге чоланга урнаштырды, шунда ук калдык-постык ризыкны жибәрде.

Гөроглы егетләр белән пирәшлек иткәндә, аннары исереп йоклап киткәч, карчык вакытны бушка уздырмады — далага барыр, бер кочак сусыл үлән алып

кайтыр, атның алдына ташлар да үзе күздән югалыр иде. Ай үтте — ул инде бер дә курыкмыйча ат авызына үлән сала; ике ай узды — ат аңардан үзен сыйпата; өч ай дигәндә, карчык атны тәмам кулына ияләштерде.

Бервакыт карчык атның иярен салдырып карады, аннары кабат иярләде. Кыюланып китеп, ияргә сикереп менде дә, убырлы карчык кебек, ат сарае буйлап чаптырып йөрде... Атны бәйләп куйгач, үзенең чоланына кайтты һәм болай фикер йөртте: «Менә бит, мин инде атка атланып йөри алам. Шулай да берәр хәйлә уйлап тапмасам, аны алып китә алмам». Шуннан соң үзенең әфсен-төфсеннәрен мыгырдарга кереште...

Кинәт Гөроглы, аның белән бергә егетләре дә хәлсезләнеп китте. Өченче, дүртенче көннәрне дә чир аларны тынычлыкта калдырмады.

— Әй, егетләр! Карчыкны чакырыгыз, — дип кушты Гөроглы. — Күнелем сизә, ул им-томга һәвәс — аның сихер букчасы бар иде.

Карчыкны дәштеләр.

— Һай, әби, безнең хәл китте бит әле. Баш авырта. Чиребез узмый. Син им-том итә белмисеңме?

— Әй углым! Минем ни генә белмәгәнемне әйт син. Сез мине салкын чоланда калдырдыгыз бит.

— Безне тизрәк дәвала инде, әбекәй!

— Хәзер мин сезнең язмышыгызны укыйм, углым, — дип җавап бирде дә карчык, җилкәсеннән сихер букчасын салды. Нидер пышылдаган булды, багу китабының битләрен актарды, шуннан соң сорый инде:

— Теге айда сезгә зират аша узарга туры килмәдеме, углым?

Ә Гөроглы һәрвакыт каберстан аша үтеп йөри иде.

— Уздым, — диде ул.

— Менә шул чакта сезнең башларыгызга гайсар чире йоккан да инде. Баштан ук дәваларга керешсәгез — савыгырсыз, углым, ә керешмәсәгез — харап булырсыз.

— Чирне белүен белден син, әби. Ә безне дәваларга көчеңнән килерме?

— Чирне кем белә, шул дәвалый да инде. Минем бер даруым бар. Шуны эчү белән, савыгырсыз.

Юлга чыкканда, карчык киеме эченә йокы төнәтмәсе белән кечкенә шешә яшергән иде. Менә шул агулы эчемлекнең ярты касәсен башта Гөроглыга, аннары Өвез җанга һәм Сәпәр-Көсе кул астындагы кырык егеткә бирде. Төнәтмә иреннәренә тию белән, һәркайсы һушсыз калып егылды. Инде менә барысы да тәгәрәп яталар.

Карчык Ага-юнус янына килде.

— Ага-юнус, балакаем! Үземнең даруым белән Гөроглыны, аның кырык егетен дәваладым. Син дә эчмисеңме соң?

— Башта үзең эчеп күрсәт, әби, аннары сыйларсың.

— Ярар, — дип килеште карчык, касәне алды һәм, эчкән булып, сыекчаны букчасы эченә түкте.

Ага-юнус та аңа ышанып эчте һәм шунда ук һушын җуйды. Карчык касәне Гүл-Ширинга биргән иде — анысы да аңын югалтты. Инде карчык үзе генә калды. Бер дә курыкмыйча, Ага-юнусның башыннан алтын калфагын алды, аны үз чәченә беркетеп куйды, Гыр атка исә алтын йөгертелгән дирбиясен кигезде, иярләде, аңа менеп атланды да мәйханә янына барды.

— Йә Гөроглы! Ат өчен мин сиңа ишәк калдырам. Әйтәләр бит: «Берсен алсаң — бүтәнне бир, кем бирми, ояты шуңар».

Шулай дип әйтте дә атны Нишапурга куалады.

Йоклата торган төнәтмәнең көче өч көнгә житте — Гөроглы өч көн ятты. Дүртенчесендә аңына килде, торды, чәй эчте, кальян тартып алды.

— Әй, Мәтер! Баш төзәлде, ауга барабыз, — дип дәште Гөроглы.

Мәтер ат сараена йөгереп барды — Гыр ат юк. Кире чапты.

— Һай, Гөроглы, Гыр ат юк бит!..

— Ә дирбиясе?

— Дирбия дә юк.

Дирбиянең юклыгын ишетү белән, Гөроглы Ага-юнусның теге чактагы кисәтүен исенә төшерде. Күнеленнән тынычлык качты.

— Ә карчык урынындамы? Барып кара әле!

Карчыкның чоланына китте Мәтер, ә тегенең эзе дә суынган. Читекләре, бүтән вак-төяк

киемнәре аунап ята. Колакларын торгызып, инде өч көн ашамаган ишәк пошкырына...

— Карчыгын да, Гыр атың да юк, Гөроглы. Алмашка ул үзенең ишәген калдырган, рәхим итеп алсаң...

Гөроглы кычкырып җибәрде, һушсыз калды. Өч сәгатьтән соң гына ул аңына килде, утырды һәм хәсрәтле тавыш белән еларга кереште.

— Кайгырма, Гөроглы, — дип тынычландырды аны Көсе. — Гыр ат югалса ни, безнең бит әле тагын Ховали гыр бар. Өстәвенә Боз Думан да!

— Әй дивана баш! Нәрсә аңлыйсың соң син, Көсе! Йөз мең ат та Гыр ат дагасының бер калагына тормый, — дип җаваплады Гөроглы һәм Ага-юнус янына китте.

— И Ага-юнус! Гыр ат юк бит...

— Бетә белмәдең инде! Бу мәкерле убырлы карчык үзеңне яисә атыңны харап итәр дип әйтмәдеммени мин сиңа?

— Хәзер үкенүдән ни файда? Ин яхшысы, Ага-юнус, миңа бирәр киңәш бир.

— Сиңа нинди киңәш бирергә дә белмим инде.

— Ачуланма миңа, «белмим» дип җавап бирмә. Ичмасам, атны кая алып киткәнен булса да бел.

Бу икейөзле дөньяда ни генә булмасын, Ага-юнус белеп тора иде: моның өчен аңа тик әфсен-төфсенен әйтергә дә үзенең тырнакларына карарга гына кирәк. Ул тәһарәт алды, ике рәкәгать намаз укыды, әфсен-төфсенен әйтте һәм тырнакларына карады.

— Ул карчык, Гөроглы, Нишапурдан булган. Гыр атны Нишапурга алып киткәннәр.

Шулай диде дә Ага-юнус Гөроглыны мыскыллып көлде.

— Син бит, Гөроглы, Гыр атка атлангач кына баһадир икәнсең. Гыр атың булмаса, эттән дә артык түгелсең!

«Нәрсәгәдер сөенә бу, — дип уйлады Гөроглы. — Атны эзләргә китсәм, исән кайтырмынмы — кем белә. Минем турыда яман хәбәрне ничек кабул итәр — «ир-егетне җиде ел көтәләр» дигәнне онытмасмы? Бәлки хәзер үк башканы, калын муенлыны эзли башлар?»

— Ага-юнус, мин менә ат артыннан китәм, Нишапурга барып җитәм, ә анда минем Гөроглы икәнемне белеп алалар да үтерәләр ди. Үлсәм, син минем өчен ничек еларсың? Сөйлә, мин тыңлыйм, аннары юлга кузгалам, — диде Гөроглы Ага-юнуска һәм чапанын ябынып ятты.

Ага-юнус Гөроглы янына утырып җырлый башлады:

*Көчең бетсә – хәлең яман, дустым,*
*Корыч көбәле кыю егет – Гөроглы.*
*Дошманың күп, алар синең канга сусый,*
*Корыч көбәле кыю егет – Гөроглы.*

*Синең кебек җәя тарта алмый беркем,*
*Атың – җиргә тими оча торган бөркет.*
*Сиңа тиң юк. Тик син ялгыз гына булдың,*
*Корыч көбәле кыю егет – Гөроглы.*

*Улларың юк – яуда биргә үләр өчен,*
*Кызларың юк – кабереңдә иңрәр өчен.*
*Синнән башка яшь алмам, синсез үләм,*
*Корыч көбәле кыю егет – Гөроглы.*

*Яшем эретер таулардагы ак карларны,*
*Тегермән ташын әйләндерер агымнары.*
*Шулай җырлап озатам мин – Ага-юнус,*
*Лачын күзле арысланым – Гөроглыны.*

Ага-юнус җырлап бетерде исә Гөроглы урыныннан кузгалды.

— Күңелемне күрдең, Ага-юнус, рәхмәт яусын сиңа. Үләргә язганмы, исән калыргамы, мин инде хәзер язмышыма үкенмим...

— Гөроглы, дәрвиш сыйфатына кереп, Гыр атны эзләргә бар. Маңгаең тир белән юылсын, аягың кабырчыклар белән капласын. Атың хакына азап чиксәң генә, ул сиңа файда китерер. Сиңа Гыр атны Аллаһ бүләк иткән иде, аны җинел генә кулыңа төшерден. Ә җиңел килгән малдан май язып булмый, Гөроглы.

Ул Гөроглының кыйммәтле чапанын, камчат бүреген, сафьян итекләрен салдырды, ефәк кушагын, үткен хәнҗәрен алды. Гөроглының бөтен затлы әйберләрен алып, аннан чын дәрвиш ясады. Башына тишек бүрек кигезде, иннәренә салэмә-сәләмә ташлады, кулына таяк тоттырды, җилкәсенә хәерче капчыгы асты да болай диде:

— Йә, бар! Аллаһ сиңа ярдәмче булсын!..

*Басмага* **Мөдәррис ВӘЛИЕВ** *әзерләде.*



## Омор Солтанов

# МИЗГЕЛЛӘР АГА ТИЗ СЫЗЫП

## Ватан

И, Ватаным, сөю түккән анам да син,
Фанилыкны якын иткән атам дисәм?
И, Ватаным, тәрбияләп, кеше иттең,
Синең җылы куеныңнан сөю көтәм.

Айлар үтеп, мизгел елга киткән саен
Төшенеп киләм Ватанымның асылына.
Туганнан ук ак-караны таныткан син,
Түзә алмыйм күңелемнең ярсуына.

Ватанымны мин дә сөям, син тагы сөй,
Чөнки ул минем дә өем, синең дә өй.
Кирәк булса, зур горурлык хисе белән
Йөрәгеңне Данко кебек яндыр һәм көй.

Көннәр үтеп, заман алга барган саен
Төшенеп киләм Ватанымның мәгънәсенә.
Керем юып, кендек каным тамган җир син,
Шуңа газиз илемнең һәр бәндәсенә.

## Китапка

Мин дөньяны синең белән таныдым,
Синнән алдым акылымның ярымын.
Тормышымда кыйммәт күреп барыннан,
Иң кадерле бүләк итеп алырмын.

Бу тормышны синең белән белгәнмен,
Синең аша ак, караны аердым.
Кыю, дәртле йөрәгемә тын биреп,
Бәхет көткән иртәгәмә бар, дидең.

---

Омор СОЛТАНОВ (1935) — *совет һәм төрки әдәбиятлар классигы, Кыргызстанның халык шагыйре. Кыргызстан Язучылар берлеге рәисе, Кыргызстан Республикасының Бишкәк шәһәрендә яши.*

Акылыннан өлеш биргән якыным,
Әйткәненә жан дустымдай инандым.
Табалмасан,
яхшы китап күрсәтер
Язмыш, бәхет кай тарафта булганын.

* * *

Нарасый чая кызлардай
Яз көне гөлләр ясана.
Көнелсез булыр яшәеш,
Тормышта хезмәт булмаса.

Көләч күз — яшьлек булмаса,
Танылу алмас сылулар.

Килмәс иде гөлле заман[1],
Әгәр булмаса олылар.

Гомернен йомгагын сүтеп,
Мизгелләр ага тиз сызып.
Укы, хозурлан, хезмәт кыл,
Тормышнын юлы бик кызык!

## Сагынганда

Алыста калган мизгелне
Хәйләсез очыр төш кебек.
Әйткәнен торды исемдә
Әйләнеп очкан кош кебек.

Иртә дә таңдай яктыра,
Ислэп кал, ди ул, күрәсен.
Текәлеп карап калуын
Исемнән китми, беләсен.

Көнелнен серен яшердем
Юка пәрдә артларына.
Ышанам: йөрәгем серен
Күл буйлары сакларына.

Язмышымда бәхет булып
Калдың сенелкәш — авылдаш.
Сагынасың, тик бирәү дә
Сине миндәй һич сагынмас.

* * *

Төн...
Тып-тын...
Сәгать: келт-келт... келт-келт...
Уйлап ятам...
Колак тонып, уйга батам.
Очкындай алыс-еракта йолдызга охшап,
Бер өмет чырт-чырт яна уйда, һич калмый.
Шушы уйны мизгелендә әйтәламмы?!
Сызылып секунд йөгерә, кабатланмый.

## Иссык–Күл[2]

Хәтеремә Иссык-Күлем сенеп калды,
Сулыш биреп, сагынганда сагыш булып.
Мондагыдай акбүзаттай таулар бармы?!
Аккошлар күл өсләрендә оча кунып.

Кыш белән күл буенда син утыр әле,
Бер карасан, ул әнинен матур чагы.
Ярга бәрде ап-ак яллы дулкыннарын,
Гүя җәйләүнен баш бирмәс кыргый аты.

[1] Гөлле заман — яхшы заман мәгънәсендә.
[2] Иссык-Күл — кыргызча «Ысык-Көл» дип әйтелә, татарча «Кайнар-Күл», «Эссе-Күл» мәгънәсенә туры килә.

Бу ягымлы күлнең сылу кызларыдай
Үрдәкләре назланалар канат тарап.
Кояш кичен суга чумып баткан чакта
Күл өстендә кызыл җәен канап кала.

Йолдызлары алтын керфек сирпеп ята,
Күк йөзеннән ак болытны ачып карап.
Иссык-Күлем табигатьнең көзгеседәй –
Ай килә күл төбенә чәчен тарап.

* * *

Алда көткән максатларны күзаллап,
Гел ашкынам өметемне яндырып.
Максатыма көн батканда барырмын,
Күгәрчендәй
очып, канат талдырып.

Шашып көткән максатларны күзаллап,
Кучмә кошлар килә илләр калдырып.
Максатыма көзге кичтә кунармын,
Торна кебек
очып, канат талдырып.

* * *

Киләм дип, килер җиргә син килмәдең,
Яшь баладай як-ягыма карандым.
Җәй көне ак кыш төшеп хыялыма,
Әйләнәмне чолгап алды караңгы.

Син миңа шик саклама җәй дә, кыш та.
Көн булып чыккан идең тормышыма.
Өшедем, болыт каплап, калтырандым,
Кояш барын белмичә җылысында.

Син миңа шик саклама бәйрәмнәрдә,
Җыелып күңел ачкан бу җайларда[1],
Балкып эчерерлек шәраб булып,
Кыстаудан кызуланган башкайларга.

Син миңа шик саклама гомер буе,
Хөкемеңә тапшырамын күңел, уйны.
Хәйләгә юк теләгем бер тамчы да,
Алдымда менгән атым аксак булды.

Киләм дип, килер җиргә син килмәдең,
Яшь баладай як-ягыма карандым.
Җәй көне ак кыш төшеп хыялыма,
Дерелдәп, өшеп торды бар караңгы.

*Кыргыз теленнән* **Ленар ШӘЕХ** *тәрҗемәләре*

[1] Җай — бу очракта урын мәгънәсендә.



Якуп Өмәруглы

# ХИКӘЯЛӘР

## Озату сые

Кеше якыннарыннан, әйтик, атасыннан озакка аерылганда шатлана диме? Ә мин шатланган идем. Хәзер уйланам да, «балалык инде» дип кенә аңлатып та булмый кебек. Шатланыр өчен сәбәпләре бар иде чөнки.

Бер дә исемнән чыкмый: ул көнне әтине авыл янындагы клевер басуына су сиптерергә киткән жиреннән чакыртып кайтардылар. Район үзәгеннән чакыру кәгазе килгән, гаскәргә китәргә тиеш икән. Чакыру кәгазе алданрак килгән булып та, ул көн — китәргә тиешле соңгы көне идеме, әллә кәгазь шул көнне килеп, ашыгыч рәвештә барып житәргә кирәк идеме, аларын белмим. Аннан соңгы елларны Мәрьям анамнан сорарга да башыма килмәгән. Ни булса да булган, шулай итеп, әтием басудан кайтты, аның өчен хәзерләнгән табын түренә утырды.

Әтием урта буйлы, авыр эш эшләүдән мускуллары тыгызланып киерелгән, Анадолуда «караягыз» дип йөртелә торган ялтыр кара тәнле кеше, галәттә үзенә нык ышанып сөйләшә, тавышы кырыс чыга торган иде. Әмма ул көнне бар кешегә дә йомшак итеп эндәште, бигрәк тә минем белән, әнием һәм Мәрьям анам белән дә бик ягымлы сөйләште.

— Улыма чалбар кидерегез дә, бер карыйм әле үзенә, — диде бераздан.

Дөресен әйткәндә, ул вакытларда чалбар сүзен бик белмибез, ыштан, ирләр ыштаны, дия идек. Ыштан кию — малай кеше өчен зур үсәнлекнен билгесе, ир-егет булдым дигән сүз иде. Минем дә ул көнгә кадәр озын балаклы ирләр ыштаны кигәнем булмады, дүрт яшемә житә язсам да, бер генә чалбарым да юк иде. Кечкенә ир балалар да, кыз балалар кебек, «әнтари» дип йөртелгән озын кин күлмәк кияләр иде.

Мин генә белмәгәнмен, Мәрьям анам белән әнием инде күптән миңа дип күк бөздән чалбар тегеп, сандыкка салып куйганнар икән. Күк бөз дигән тупас калын бер тукыма бар иде ул заманнарда. Шунда ук чалбарны китереп миңа кидерделәр.

Шатлыгымнан нишләргә белмәдем.

Әтием, идәндәге тәбәнәк сәкегә корылган табын янында утырган килеш башын миңа таба боруга, күкрәген киереп жибәрде дә берничә тапкыр баштан-аяк миңа күз йөртеп алды. Чалбар кигән улын күреп, билгеле инде, бик горурланган иде. Аның карашыннан мин дә горурландым. Шатлыктан һәм горурланудан башым түшәмгә тиярлек булды: мин дә чалбар кидем!

Өебезнең ишегалдына бераздан туган-тумача, дус-иш жыела башлады.

Әтием, үзен озату сые итеп әзерләнгән ризыкларга кагылмыйча да диярлек,

---

Якуп ӨМӘРУГЛЫ (1966) – *прозаик; Евразия Язучылар берлеге рәисе, «Кардәш Каләмнәр» әдәби журналы баш мөхәррире һәм Тел өйрәнү фонды журналлары берлеге рәисе. Күпсанлы әдәби премияләр, шул исәптән ТЮРКСОЙ (2010) премиясе лауреаты. Төркиянең Анкара шәһәрендә яши.*

урыныннан купты. Табында йөзем кайнатмасы да, йомырка тәбәсе дә бар иде: башка тәгам турында инде әйткән дә юк, боларын да ашап бетермәде.

Тамагы туйган идеме, юкмы, бик ашыгыч эше бар шикелле кабаланып, ишегалдына чыгып китте. Анданиләр булды, анысын мин күрмәдем, чөнки мин бик теләп әтиемә табын әзерләнгән бүлмәдә калдым.

Мәрьям анам чакырганнан соң гына өйдән чыктым. Әтием мине, күтәреп, маңгаемнан үпте, кире җиргә бастырды да китеп барды. Мәрьям анам, әнием, дәү бабам Исмаиль — барысы бергә елый-елый артыннан дога укып калдылар. Әтиемнең авылны чыкканын, күренми башлаганга кадәр олы юлдан атлавын бөтен гаиләбез белән карап тордык. Мәрьям анам — мине, дәү бабам энем Йосыфны кочагына кысып нидер такмаклыйлар. Әниемнең кочагында исә — биләүдә яткан сеңлебез Фатыйма. Мәрьям анам бу аерылуны иң авыр кичергән кеше дәү бабам Исмаиль булганын сөйли иде.

Исмаиль бабам Мәрьям анамның каенатасы иде. Ул көннәрдә алтмыш яшен узган булырга тиеш. Тик үз яшеннән күпкә олырак күренә торган ябык гәүдәле карт иде. Мин Мәрьям анам дип атаган кеше исә — минем әбием — әтиемнең әнисе. Буе озын, адымнары нык, хатыннар белән дә, ирләр белән дә кыю сөйләшә торган, аз сүзле, үзе дә, сүзе дә абруйлы хатын иде. Инде картаеп бара торган дәү бабамнан кала өйдә башка ир заты юк. Шулай булса да, Мәрьям хатын (авылда аны шулай дип атап йөртәләр иде) безне мохтаҗлыкта яшәтмәде. Истикълял сугышы[1] елларында да Мәрьям анам ничек кенә булса да безгә авырлык китермәскә тырышты. Авылда кайберәүләрнең амбарында оны бетә, ашарга икмәкләре калмый торган иде, тик безнеке беркайчан да бетмәде.

Бары тик истикълял сугышы гынамы соң? Чанаккалә, Балканнар, тагын әллә нинди сугышлар... Ирләр китәләр дә китәләр, кире кайтмыйлар иде. Иң әүвәл Исмаиль дәү бабамның атасы киткән, кайтмаган. Аннан соң ул үзе унбиш ел гаскәри хезмәттә булган. Ул кайтып керер-кермәс, улы Хәсән — Мәрьям анамның ире гаскәргә алынган. Аның турында, Балкан сугышында шәһит булды, диләр иде. Инде менә дәү бабамның оныгы Мостафа чыгып китте. Бу авыр елларда гаиләне җыеп тотучылар хатыннар булды. Хәзер уйланам да: сугыштагы ирләрнең каһарманлыгы олырак идеме, әллә бу хатыннарныкымы, белмәссең.

Соңгы вакытларда яшьләрне, бик иртә дип, 13-15 яшьтә өйләндерү яки кияүгә бирүгә каршы чыгалар. Ләкин мин тәнкыйтьләргә ашыкмас идем. Әлбәттә, заман үз хөкемен чыгарачак. Тик без иртә өйләнү дигән мондый өйләнүләр ул заманнарда да булмаган булса?! 13-15 яшендә егет өйләнә, бер-ике баласы дөньяга килә, 20 яшен тутыруга, гаскәргә алына да кире кайтмый. Ятимнәр дә ата-аналары башлыкүзле булган яшькә җитүгә өйләнәләр, бер-ике балалары туа, яшь ата сугышка китә дә әйләнеп кайтмый. Безнең гаиләдә дә ничә буын нәкъ шул рәвешле дәвам итеп килгән. Иртә өйләнмәгән булсалар, буыннар дип сөйли алыр идекме?!

Сугыш беткәнгә берничә ай булды дигәндә, әтиемнән беренче тапкыр хәбәр алдык. Авырып, Анкарадагы Җәбәче гаскәре хастаханәсендә ята икән. Шәһит булды, дигән хәбәр түгел әле, дидек, шуңа да шатландык. Мәрьям анам Анкарага, әтием янына барырга җыена башлады. «Сиңа Анкарадан уенчык алып кайтырбыз», — дип башымнан сыйпап ала, шатлыгым эчемә сыймый.

Шул көнне үк бер тавык суйдылар, Мәрьям анам күп итеп йомырка пешерде, бер савытка йөзем кайнатмасы тутырды. Безнең авылның йөземе һәм йөзем кайнатмасы бик тәмле була торган иде. Әнием белән күп итеп юка, берничә тәбикмәк пешерделәр, шулар янына суган куйдылар.

«Тәбикмәк белән суган — юлда ашарга. Юка белән йөзем кайнатмасы

[1] Истикълял сугышы — Госманлы дәүләтендә 1919-1923 еллар арасында чит дәүләтләрнең тыкшынуына каршы илнең бәйсезлеге өчен барган сугыш. *(Тәрҗ. иск.)*

— Мостафага, ул аларны бик ярата», — диде Мәрьям анам.

Тик Анкарага кем белән барырга соң? Мона кадәр бер дә барганы булмады. Бара белсә дә, жәяүле өчен ике көнлек юлга хатын кеше бер ялгызы ничек чыксын? Тиз генә уйлап алды да Һидаять ага[2] өенә йөгерде. Ялынып-ялварып, аны бергә Анкарага барырга күндерде. Һидаять ага безгә туган тиешле, Анкараны да бик яхшы белә иде.

Мин инде биш яшемне тутыра язганга, ул көннәрне әтиемне гаскәргә озаткан көннәрдән яхшырак хәтерлим.

Без түземсезлек белән көтәбез. Сөенечтән әниемнен аяк атлаулары ук үзгәрде. Исмаиль дәү бабам да шатлыгыннан яшәреп киткәндәй булды. Ул көннәрдә, әгәр Фатыйма да авырып тормаган булса, бәхетебез түгәрәкләнер иде. Сеңлемнең тән кызуы бик көчәйгән күрәсен, әниемнен аны серкә белән уганын хәтерлим. «Ашына серкә кулланмаган кешедә кырык еллык серкә булыр», — ди иде Мәрьям анам. Безнен өйдә дә һәрвакыт бик сыйфатлы серкә була торган иде. Әнием Фатыйманың тәненә серкәне сөртә дә сөртә, исе белән бөтен өй эче тулды. Ул мизгелләр, бәлки нәкъ менә шул борынны ярып керә торган серкә исе аркасындадыр, аермачык исемдә.

Мәрьям анамнын Анкарага киткәненә биш көн булды дигәндә, кайтып килүләрен иң беренче булып мин күреп алдым. Барып аны кочаклап алыргамы, әллә йөгереп кайтып, өйдәгеләргә хәбәр итәргәме икәнен белмичә аптырадым. Вәгъдә ителгән уенчык исемә төшүгә, йөгереп барып, Мәрьям анама сарылдым.

Ул миңа бик йончыган, бетеренгән булып күренде. Эндәшми-нитми, сабыр гына кочаклап, башымнан үпте. Һидаять агадан да бер сүз дә чыкмады. Мәрьям анам кулымнан житәкләде дә, өчәүләшеп безнең өйгә юналлек. Башымны горурлык белән югары тотып эре-эре атлыйм: кайтучыларны иң беренче булып мин күрдем!

Әнием безне ишегалдына кергәч абайлап алды да йөгерә-атлый янныбызга килде. Шул вакытка кадәр тавыш-тынсыз атлаган Мәрьям анам инде үзен тотып тора алмады, елап жибәрде. Әнием дә елый башлады. Бу тавышны ишетеп, янныбызга энем Йосыф килде. Без ни булганын белмәсәк тә, алар елый дип, икәүләшеп шыңшырга тотындык. Һидаять ага аяк басып атка атлана торган таш өстендә, иелгән башын куллары белән кысып тоткан килеш тын гына утыра.

Күп тә үтмәде, ишегалды кеше белән тула башлады. Туганнар, дуслар, хәбәрне ишеткән бөтен авыл кешесе безгә агыла иде. Килгән берсе мине һәм Йосыфны кочагына алып, башыбыздан сыйпап елый.

Аннан соңгы елларда Мәрьям анам Анкара сәфәре турында берни дә сөйләмәде. Һидаять агадан ишетеп белгәнемчә, ике көнлек юлны алар көн ярымда узганнар. Мәрьям хатын атка да кайбер ирләргә караганда остарак атланып йөри ала икән. Анкарага килеп кергәч, туктап ял да итмичә, туры Җәбәче хастаханәсенә барганнар. Аларга әтиемнең әле бер сәгать элек кенә жан биргәнен хәбәр иткәннәр. Әле палатадан да чыгармаган булганнар. Мәрьям анамны әтиемнең мәете яткан караватт янына китергәннәр. Шуңа кадәр үзен нык тоткан ана улына сарылып елый башлаган. Шулкадәр ачыргаланып, такмаклый-такмаклый елый икән, табибларның берсе: «Чыгарып жибәрегез бу хатынны тизрәк моннан, бөтен хастаханәне аякка бастырды», — дип ачулангач, Мәрьям анам белән Һидаять аганы чыгарга мәжбүр иткәннәр. Шул ук көнне өйләдән соң әтиемне Гасрый зиратына күмгәннәр дә безнекеләр кайтыр юлга чыккан.

Бик ачык исемдә: ул көнне Исмаиль дәү бабам һич еламады, йөзендә ник бер тамыры селкенсен, таш булып каткан диярсең. Килгән кешеләр, «башын сау

[2] Ага — Госманлы Төркиясендә авылларда басу жирләре күп булган, иң дәрәжәле, сүзе үтә торган, хөкүмәт тарафыннан да танылган бай кеше. *(Тәрҗ. иск.)*

булсын» дип, аның кулын үбәләр, ул бер сүз дәшми утыра. Кулын үпкәннәрен сизә идеме, килгән кешеләрне таный идеме, белмим. Әллә үлем хәбәрләренә инде тәмам күнеккән идеме? Башта атасы, аннары улы, инде менә оныгы. Унбиш еллык гаскәр хезмәтендә ничә тапкыр үлем хәбәре ишеткәндер, кем белә? Карт берни дәшмичә, сөйләшмичә, кыя ташы кебек тора иде.

Әтиемнең матәме ничә көн дәвам иткәнен хәтерләмим. Ул көннәрдә яши идекме, сулый идекме, йоклап уяна идекме — аңламыйча аңкы-миңке йөри идек. Төнлә елый-елый шешенеп бетәбез, утырган йә яткан җиребездә йоклап китәбез. Уянып киткән саен, берәребезнең сулкылдавы ишетелә торган иде дә, тагын елаша башлый идек.

Бу кайгы гаиләбезне шактый какшатты. Шуның аркасында тиешле игътибар кимегән идеме, әллә авыруы көчәйдеме, белмим, беркөнне иртән иртүк әниемнең үксеп елавына уянып, сикереп тордык: Фатыйма да үлгән иде.

Ул көнгә кадәр һәрвакыт каядыр еракларга карап, селкенмичә дә утырган дәү бабам урынына утырып тормас булды. Үзалдына нәрсәләрдер сөйләнеп, гел арлы-бирле йөри иде. Кайчак үзенең гаскәрдә хезмәт иткән елларын, кайчак балачак хатирәләрен искә төшереп сөйли. Тавышы бик көчле түгел, сөйләгәннәрен, янына якынрак килсәң генә, аңлап була иде. Берәр хәл турында кабаттан сөйләвен сорасаң, һич исенә төшерә алмый. Шуның белән бергә инде ачы кайгыларны да хәтерләмәс булды.

Ах, минем Мәрьям анам! Фатыйманы җирләгәннән соң, ничектер ана рух ныклыгы кире кайткан кебек булды. Елау-сыктауны да онытты, гаиләне тупларга тырыша иде. Чөй чөйне кагып чыгара, диләрме әле? Нәкъ шулай кайгы кайгыны юып төшергән иде, ахрысы. Тик шул көннән башлап аның көлгәнен дә бик аз күрдек. Бары тик кайчакларда, авыл хатыннары җыелышып, юк-бар сөйләшеп, шаярышканда гына беразга йөзе яктыра торган иде. Хәсән бабамның шәһит булу хәбәре генә килгән, рәсми кәгазе юк иде. Авылдаш хатыннар кайчак шаярып: «Мәрьям хатын, Хәсән ага Истанбулда икән лә. Күрүчеләр булган», — дигәндә, «Чынлапмы?!» — ди, күзләре нурланып китә иде. Хатыннарның бу сүзгә нинди мәгънә салганнарын аңласа да, һәр ишеткәнендә йөзенә ниндидер бер моңсу куаныч җәелә иде.

Әтием сугыштан кайтмагач, әнием башка берәүгә кияүгә китте. Безгә әти дә, әни дә булып Мәрьям анам калды. Улының ятимнәрен генә түгел, гаскәрдән кайтмаган энесенең ятимнәрен дә янына алдырды, барыбызны бергә үстерә, тәрбия итә башлады. Әнием кайбер көннәрне килеп безне караша, тик төн кунарга калмавы эчемә сызлау булып төшә. Мәрьям анам әниемне дә аңлый иде, тәгаен.

Әтием турында берни дә сөйләмәде. Шуна күрә әтиемне гаскәргә озату белән бәйле үз хатирәләрем мина бик кадерле. Чалбар кидерттерүен һәм «егет булдың» дип, горурланып мина карап торуын искә төшерсәм, әле бүген дә үземне ниндидер сихри көч иңгәндәй хис итәм. Тагын бер нәрсә бар: ризыкларын ашамыйча, ул калдырып киткән табын. Әтием ашамады, тәбә белән йөзем кайнатмасы мина калды, дип бик сөенгән һәм аларны тәмләп ашаган идем.

Мәрьям анам Анкарадан әтиемнең үлем хәбәрен алып кайткан көннән бирле бер генә тапкыр да йомырка тәбәсе дә, йөзем кайнатмасы да ашамадым. Мин инде зур үстем дип, аларны әтием өчен калдыра идем. Ул елны, аннан соңгы елларны да һаман шулай булды, бүген дә бу ризыкларны әтиемә калдырам.

## Агылый белән тагылый

Бик эссе җәйге көн. Тавыклар койма буендагы корыган агач ботаклары өстенә тезелешкән, томшыклары ачык, кымшанмыйлар да. Авырдан сулыш алганнары ун-унбиш адымнан да бик ачык күренә. Песиләр дә аяк астында сырпаланып йөрми, этләр дә, кайда бераз күләгәле җир тапсалар, шунда сузылып, йокымсырагандай

изрәп ята. Вәйсәл белән без дә тут агачы күләгәсендә өч таш уйнап туйдык. Мин ничә тапкыр жиндем, ничә уенда Вәйсәл жинде — икебездән беребез ник хәтерләсен.

Кинәт жил исеп куйгандай булды. Тәннәребезне йомшак кына сыйпап үткән бу һава агымы тынны буа торган көндезге эссенең бераз кимисен хәбәр итте.

Вәйсәл, нигез буена өелгән печән чүмәләсенә күрсәтеп:

— Әйдә, сикереп уйныйбызмы? — диде.

Мин каршы киләмме соң инде:

— Әйдә! — дидем.

Без — ике дус, агылый белән тагылый, бераз читтәрәк сөяп куелган агач баскыч буйлап өйнең сәзәк түбәсенә менеп тә бастык. Икәү янәшә аска карап торабыз. Уенны Вәйсәл уйлап чыгарды, димәк, беренче булып сикерү хокукы да аңа бирелә. Шулай фикер йөрткәнгә, мин көтәм. Кулларын очкыч канаты кебек ике якка ачып, беренче булып сикерүче — дөрестән дә, Вәйсәл булды. Ул аякларын тездән аз гына бөкте дә гәүдәсен аска ташлады. Өй түбәсеннән аерылып, печән өстенә килеп төшкәнгә кадәр «Һоооооп!» дип кычкырганы ишетелеп торды. Кибәннән шуып төшеп, жиргә баскач, мина күтәрелеп каравы белән мин дә, ул ясаган хәрәкәтләрне кабатлап, түбәдән сикердем.

Тут агачы астында шактый озак утырып оеган гәүдәләр язылып киткәндәй булды. Шунда ук кабат баскычка таба йөгердек, тагын түбәгә менеп бастык.

Сикергәндә, кызган һава бераз жилләнеп, безгә азрак рәхәтлек биргәндәй була. Бушлыкка ташланганда, кулларыбызны жәеп, бик аз вакытка гына булса да үзебезне кошлар кебек очкандай хис итәбез.

Тагын бер сикердек, шуннан тагын...

Башта санап барган идек, аннары санаудан да туктадык. «Егерме бе-ее-р» дип кычкырып сикергәнем генә исемдә.

Бу уен да бераздан туйдыра башлады. Түбә читенә килеп бастык, сүлпән генә тагын сикерергә әзерләнә идек, Вәйсәл кинәт:

— Мостафа, берәр тапкыр баштүбән сикереп карыйбызмы? — диде.

— Ничек итеп? — дим гаҗәпләнеп. Моңа кадәр өй түбәсеннән баштүбән сикергән кешене күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Тик болай сикереп төшү дә туйдыра башлаган иде шул. Икеләнеп кенә:

— Ярый, тик башта син сикер, — дидем. Вәйсәл, әлбәттә, моңа әзер иде.

— Ярый, — диде дә түбә читенә үк килде, аска карап, ничегрәк сикерергә кирәклеге турында уйланып торды, бераз курыкканы сизелә иде сизелүен. Тик, бу уенны үзе тәкъдим иткәнгә, сүзеннән кире кайта алмый иде, билгеле. Иелде дә, чүмәлә өстенә төшкәндә, башы аста калсын өчен, гәүдәсен ничек тотарга, нинди хәрәкәт ясарга икәнен чамалап, түбәнгә мәтәлде.

Чынлап та, печән өстенә иң әүвәл башы белән төште, аннары жилкәсе тиде, йомшап калган гәүдәсе бер якка кыйшайды да чүмәлә төбенә таба, жиргә кадәр тәгәрәде.

Аягына бераз авырлык белән торып басты кебек. Башын боргалап, өстенә-башына ябышкан печәннәрне каккалаганда, мин аның йөзен күрергә тырыштым. Бу сикерүдән әллә ни кызык тапканы сизелми, ләкин еламый да.

— Авырттымы? — дип кычкырдым.

Күлмәк-ыштанын печәннән чистарта-чистарта, «юк» дигән мәгънә белдереп, башын артка чөеп алды:

— Авыртмады.

Болай сикерүдән әллә ни кызык тапмаганы аңлашылды, ләкин шул ук вакытта бер жире дә авыртмаган. Миңа да сикерергә кирәк.

Түбә читенә килдем дә икеләнебрәк торам. Баштүбән сикерергә бераз шүрләгәнгәме, әллә Вәйсәл, авыртуга түзә алмыйча елап жибәрсә, ваз кичәргә сәбәп булыр иде, дип уйлагангамы — бер карарга килә алмыйм.

Вәйсәл миңа текәлеп тора, һаман еламый да еламый.

Моннан да артык көтеп торып булмас. Мин дә печән эченә баш белән чумар өчен әзерләндем дә аска томырылдым.

Аяк өсте төшәрлек итеп сикергәнгә караганда, күпкә күңеллерәк иде, әлбәттә. Әгәр чынлап та бер җир дә авыртмаса, бераз бу рәвешле сикерергә дә була икән.

Вәйсәл кебек мин дә, башым белән төшкәннән соң, бер мизгелгә гәүдәм үземә буйсынмаганга, читкә тәгәрәдем.

Бераз авырлык белән булса да, бар да яхшы, дигән кыяфәт чыгарып, тураеп бастым.

Вәйсәл миңа карап тора. Карлыгыбрак киткән тавыш белән:

— Йә, ничек? — ди.

Бөтен җирем авырта, үземне көчкә генә тотып торам.

— Минеке бераз авырта, — диюем булды, кулым шунда ук ачытып сызлаган билемә таба шуды. Вәйсәл:

— Минеке дә бераз авыртты, — дип әйтеп бетерер-бетермәс, бер-беребезне кочаклагандай итеп тотыныштык та кычкырып елап җибәрдек.

## Ике чынар

Башта, кәүсәсенә колагын куеп, агачның эченнән ишетелгән чытырдау тавышларын тыңлады. Аннары, кулларына таянып, эре гәүдәсен агачтан этеп тураеп басканда, үзен әйләндереп алган һәм бик дикъкать белән күзәтеп торган кешеләргә:

— Авар бу агач, — диде.

Берничә адым артка чигенеп, башта агачның буар елан кебек юан ботакларына, аннан соң түбәнә якынрак урыннарда тибеп чыккан кара-кучкыл тапларга беравык карап торды. Үзенә бик нык ышанган кыяфәт белән башын кагып, тагын: «Авар бу!» — дип кабатлады.

Районның мәдәният идарәсе хезмәткәре иде бу кеше: ул белмичә, кем белсен! Шул арада янындагы яшь хезмәткәрләргә, йөзьяшәр агачларның да мәдәни кыйммәте барлыгы, мондый карашның тарихта ни рәвешле барлыкка килеп, ни рәвешле урнашуы турында да сөйләп алды. Европада мондый эшләргә никадәр зур әһәмият бирелүен мисаллар китерә-китерә аңлатты. Шуннан соң барысы бергә сөйләшә-сөйләшә, акрын гына агач яныннан кузгалып киттеләр. Бераз читтәрәк үзләрен күзәтеп, сүзләренә колак салып торган каравылчы Хәмди белән, араларындагы әңгәмәне бүлмичә генә, баш кагып саубуллаштылар да китеп бардылар.

Көллиянең[3] өлкән яшьтәге каравылчысы, хезмәткәр һәм аның юлдашлары артыннан, иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кыйшайтып, көлемсерәп карап калды. Моннан берничә көн элек кенә әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсеннән дә белгечләр килеп киткән иде.

Морадия көллиясенең ишегалдында үсеп утырган, кәүсә диаметры өч метрга җитә язган чынар агачын яшен сугу вакыйгасы Бурса шәһәрендә бик көчле шау-шу кубарган иде. Беренчедән, яшен утының Бурсадагы иң затлы район Чәкиргәгә төшүе, икенчедән, аның Госманлы солтаннары династиясе каберлегенә туры килүе көннәр генә түгел, атналар буе телләрдән төшмәде.

Кәүсәсен яшен суккан карттан да өлкәнрәк чынар агачының исә җәрәхәтле тәне сызланадыр, ул гаҗәеп юан ботакларын бик авырлык белән генә күтәреп торадыр кебек иде. Төз гәүдәсен горур тотып, гасырларны кичкән пәһлеван агачның кәүсәсе эченнән ишетелгән чытырдау тавышларын инде аның яныннан үтүчеләр дә ишетә башлады.

[3] Көллия — Госманлы дәүләте заманында мәчете һәм мәдрәсәсе, аш пешереп, мәдрәсә укучыларына һәм ярлы кешеләргә таратыла торган ашханәсе, шундый ук чишмәсе, хастаханәсе булган зур комплекс. Бүгенге көндә бу биналарда музейлар ачылган. *(Тәрҗ. иск.)*

Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсеннән килгән белгеч тә, бу тавышларга колак салып торгач, бик каттый итеп: «Авачак бу агач!» — дигән иде.

Чынар агачының яшен билгеләргә тырышучылар аны жирдә биш-алты йөз еллар чамасы үсәдер, дип фараз итәләр.

Делегациянең кайбер вәкилләре агачка терәүләр куярга, икенче берләре аны ботап, кәүсәсенә төшкән авырлыкны бераз булса да киметергә кирәк, диделәр; Көнбатыш илләрендә «яралы» агачларны савыктыру өчен төрле техник чаралар житештерелә, тиз арада шуларның берәрсен китертергә, шуның ярдәмендә агачны коткарып калырга кирәк дигән фикерне алга сөрүчеләр дә булды. Вазифасы таләп иткәнчә, һәрвакыт ишегалды тирәсендә йөренгән каравылчы Хәмди, агачны яшен сукканнан соң үткән өч ел эчендә ана ярдәм итүнен ничә төрле чарасы, ничә төрле юлы булса, шуларның һәммәсе турында да килгән-киткән вәкилләр авызыннан ишетә торды.

Шәһәр идарәсеннән хезмәткәрләр килде, губерна идарәсеннән, хәтта министрлыктан килүчеләр дә булды. Һәммәсе бер авыздан, әгәр дә мәгәр берәр төрле чара күрелмәсә, бу карт чынар, һичшиксез, авачак, диделәр.

Каравылчы Хәмдинең өе Морадия көллиясенә бик якын, аның янында ук тора. Өенең тәрәзәләреннән көллия ишегалды ана бик яхшы күренә. Шуна күрә менә күп еллар инде Морадия көллиясенә башка каравылчы билгеләмиләр дә. Хәмди абзыйга көндезге каравылы өчен бер хезмәт хакы бирсәләр, хатыны һәм балалары ярдәме белән төнге каравылда торганы өчен тагын акча түлиләр иде.

Бер төнне көллия ишегалдыннан гөрелтө ишетелде, жир селкенгәндәй булды. Гаиләдә ничә кеше булса, барысы да тәрәзәләргә барып капланды. Ә анда... Башка түзәрлеге калмаган карт чынар ауган иде.

Хәмди, хатыны белән күзгә-күз карашып, берара сүзсез торганнан соң:

— Әле дә яхшы төнлә ауган, көндез авып, кешеләр өстенә төшсә, фажига буласы икән, — диде, эче пошып, йөзе карангыланып китте.

Иртәгесен беренче булып шәһәр идарәсеннән белгечләр килде.

— Әле дә ярый төнлә ауган, — диделәр. Араларыннан берсе, яшь үсенте китертеп, моның урынына тагын чынар утыртырга кирәк, дигән фикер әйтте. Башкалар да аның сүзен хупладылар.

Шәһәр идарәсе белгечләре көллия ишегалдыннан чыгып китәргә дә өлгермәделәр, вакыйга булган жиргә мәдәният идарәсеннән бер төркем вәкил килеп житте. Чынарның төнлә авуына алар да шатланган иде.

Бу урынга яңадан чынар агачы утыртырга кирәк дигән фикерне әйткән шәһәр идарәсе хезмәткәре аны мәдәният идарәсе белгечләренә дә житкерде. Бу ниятне алар да бик ошатты, араларыннан берсе хәтта:

— Әйе-әйе, бик күркәм гамәл! Агачның тамырлары — Госманлы мәмләкәтенең, яшь үсенте исә дәүләтебезнең символы булыр. Искиткеч булачак бу! — дип өстәп куйды.

Моннан соң да эзне суытмадылар. Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсеннән дә килделәр. Вакыфлар вәкилләреннән торган, өлкә башлыгы житәкчелегендәге тагын бер төркем килеп китте. Тарих белән бик кызыксынучы губернатор ярдәмчесе дә ауган чынарны килеп күрүдән читтә калмады.

Ул арада шәһәр идарәсе жибәргән эшчеләр бригадасы чынарның ботакларын кистеләр, ботадылар — бары кәүсәсе генә жирдә ятып калды.

Фикер чынлап та акыллы, дөрес: ауган чынар урынына яшь үсенте утыртырга кирәк.

Каравылчы Хәмди бу фикерне чынар ауганнан соң үткән ике ел буе көллияне карарга килгән идарә хезмәткәрләреннән дә, туристлардан да, башкалардан да ничәмә-ничә тапкырлар ишетте.

...Шулай шул, урыны буш тормасын... Тормаска тиеш.

Көннәрдән бер көнне Хәмди абзый, көллия ишегалдын себереп тәртипкә салганнан соң, бераз хәл алырга утырган иде, туристлар тәялгән бер автобус килеп туктады. Туристлар төркеменең житәкчесе — яшь кенә егет, каравылчы Хәмди аны яхшы таный. Төркем көллия ишегалдына кергәч, яшь егет:

— Хәмди абзый, Мари ханымның сезгә берничә соравы бар, килегезче, — дип аны үз яннарына чакырды. Бу егет көллиянең бөтен тарихын бик яхшы белә, туристларның бөтен соравына җавап бирә ала. Шуңа күрә каравылчы үзен ник чакыруларын берничек тә аңлый алмаса да, егеткә таба китте. Ул якынлашуга, егет:

— Хәмди абзый, бу тирәдә чынар үсентесе табарга мөмкинме, дип сорый Мари ханым, — диде.

— Без Бурсада түгелмени? Ничек чынар үсентесе табылмасын ди инде! Меринос базарында сатыла.

— Бәяләре ничегрәк икән?

Егет ике арадагы сөйләшүне бер үк вакытта Канададан килгән турист Мари ханымга тәрҗемә итеп тә бара иде.

— Бәяләре үсентенең яшенә күрә төрле,— диде каравылчы Хәмди. — Бик кечкенә, бик нечкәләре — 50 долларга, аннан бераз зурраклары — 100, агач рәвеше керә башлаганнары 150 долларга сатыла.

Бәяләр турында сорашып белгәннән соң, Мари егеткә Мериносның моннан еракмы икәнен сорарга кушты.

— Юк, — диде Хәмди абзый. — Такси белән ун минутлык юл.

Җавапны ишеткәч, Мари кесәсеннән 200 доллар акча чыгарып, Хәмди абзыйга сузды. 150 доллар — үсенте алырга, 50 доллар — таксига түләргә. Егет тәрҗемә итте: каравылчыдан бер чинар үсентесе алып килүен үтенә икән.

Каравылчы Хәмди ун минут эчендә Меринос базарында иде инде. Чынар үсентеләренең иң яхшысын сайлап алу өчен дә ун минутлап вакыт җитте. Тагын ун минут үтүгә, такси белән кире кайтып, көллия ишегалдына килеп тә керде.

Хатынына әйтеп, китмән белән көрәк китертте. Ун минут эчендә элеккеге чынар урынына яшь үсенте утырттылар.

— Бу чынар Канаданың символы булсын, — диде Мари.

Аннары Хәмди абзыйга тагын 100 доллар сузды. Егет тәрҗемә итте: ханым бу акчаны чынар агачын карап, су сибеп тору өчен бирә икән.

Бу хәлләрдән соң биш ел үтте. Мари ханым һәр ел каравылчы Хәмдигә 100 доллар җибәреп тора. Егет белән телефоннан сөйләшеп, чынар агачының ничек үсүен сораша.

Мәдәният идарәсеннән, шәһәр идарәсеннән, вакыфлардан да белгечләр, көллиягә юллары төшкәндә, килеп чынарны карыйлар, кызыксыналар. Тиешенчә карап үстерелсә, инде бу чынар аумас, диләр, юлдашларына һаман шулай сөйләүләрен дәвам итәләр.

## Ун доллар

Кояшның беренче нурлары җир өстенә килеп ирешкәндә, ул утырып килгән очкыч аэропортның куныш юлына төшеп, бераз «йөгергәннән» соң, «йөренүгә» күчкән иде инде.

Барасы җиренә ул әле барып җитмәгән иде, моннан соң юлын таксига утырып дәвам итәчәк. Аэропорт тамгаханәсендә — таможняда документларын рәсмиләштереп, транзит визасы белән чик аша күрше илгә чыгачак.

Хезмәт күрсәтү тәртипкә салынган, икътисади дәрәҗәсе югары илнең аэропортында бер-берләренең хокукларын танып, аэропорт һәм очыш кагыйдәләренең һәммәсен

бернинди кисәтүләргә урын калдырмаслык итеп, чын күнелдән үтәгән кешеләр, кода-кодагыйлык чәчәк аткан, икътисади яктан беркадәр артта калган илнең аэропортына төшеп утырмас борын, әле очкычның эчендә үк, бер-берсен эткали-төрткәли, үталергә тиешле кагыйдәләрне дә үтәми башлыйлар. Әле бер сәгатьләп элек кенә бер-беренә нәзакәтле мөгамәләдә булган кешеләр, «бу ул түгелдер лә!» диярдәрәжәдә алышынып, гүя ки илдән илгә генә түгел, бер холыктан икенче холыкка күчәләр.

Ул килгән илдә дә нәкъ шулай: аэропорт хезмәткәрләренең ягымлылыкның әсәре дә булмаган йөзләре, «бу илдә күзең ачык, колагың сак булсын» дигән кисәтүле салкын күз карашлары яна килүчеләргә шактый нәрсә аңлата иде. Монда барып башларын тыгарлык берәр хакимият оешмасы яки сыенып кешесе булмаганнар, бераз шүрләп калган кыяфәттә, мөмкин кадәр тизрәк таможняны узасы иде дип, ашыга-кабалана документларын рәсмиләштерергә азапланалар.

Аэропорт капкасында Кадыйрның виза рәсмиләштерүе озакка сузылмады. Хезмәткәр, күрше илнең визасын һәм эшкә рөхсәт кәгазен игътибар белән карагач, абруен күрсәтергә теләгәндәй, паспортка шапылдатып мөһер сукты да кискен хәрәкәт белән кире сузды. Ана сиздермичә генә, Кадыйр эченнән «у-у-ф» диде: беренче капканы үтте.

Тик киеренкелектән бушанырга иртәрәк, таксига утырып, әле тагын бер таможня узасы бар. Аэропортта такси алып, Кадыйр башта күрше ил таможнясына якынрак урнашкан тукталышка барачак, анда икенче такси тотып, тагын юлын дәвам итәчәк. Башка илгә чыгу өчен ялланган таксиның шул ил тамгасы һәм номеры булуы яхшы. Әгәр таксиның тамгасы һәм номеры керәсе илнең тәртипләренә туры килми икән, юлдагы һәр полиция хезмәткәре туктатып, тикшерү сылтавы белән ришвәт сорый.

Тик шунысы бар: Кадыйр, әллә гаиләдә алган тәрбиясе, әллә инде белем дәрәҗәсе югары булу сәбәпле, ришвәт бирүне кешене мыскыллау дип кабул итә һәм мондый очракларда бик кыенсына. Ул төрткән акчаны берәү алып үз кесәсенә салганда, Кадыйрның йөзе кызара, йөрәге еш-еш тибә башлый иде.

Аэропорт ишегеннән чыкканчы ук, ике кеше: «Такси кирәк буламы, абый?» — дип, Кадыйр артыннан иярде. Ул исә, бер сүз дә әйтмичә, каш астыннан гына боларны күзәтә: таң беленә генә башлаган караңгылыкта үзе утырачак машинаны йөртүченең ышанычлырагын, аның өстенә-башына һәм йөз-кыяфәтенә карап сайларга тырыша иде.

Ишектән чыгуга: «Такси кирәкме?» — диючеләрнең саны бермә-бер артты. Күз чите белән генә такси шоферларын тикшереп, араларындагы таза гәүдәле, урта яшьләрдәге, тыныч, сабыр холыклы булып тоелган берсенә, әйе, кирәк, дигән мәгънәне ишарәләде.

Такси шоферы Кадыйрның чемоданнарына үрелде һәм:

— Машина менә монда, рәхим итегез! — диде.

Башкалар бертуктаусыз ишектән чыгучы юлчыларга: «Такси кирәкме?» — диярга дә, шул ук вакытта күз читләре белән генә карап, Кадыйрның юл хакын килешүенә колак салырга да өлгерәләр: килешә алмасалар, шунда ук клиентны каптырырга әзер торалар.

— Кая кадәр барабыз, абый?

Таксичыларның хак килешүне мөмкин кадәр тизрәк һәм үз файдаларына хәл итү өчен куллана торган алымы иде бу.

— Ханчаерыга, — диде Кадыйр.

— Йөз булыр бәясе.

— Кырык та житәр.

— Ничек инде, абый, әле төн үтмәгән, төнге бәяләр буенча — йөз.

Кадыйр күккә, тәртә буе күтәрелгән кояшка карады:

— Белмим-белмим, синең өчен махсус башка кояш чыкса гына инде. Таң күптән атты, кояш чыга әнә. Кырык житәр.

— Ярый алайса, абый, 50 булсын, — диде таксичы. Кадыйр, яхшы, килештек, дигән мәгънә белдереп баш какты да машинага таба киттеләр.

Машина иске «Мерседес» иде, Европадан ул монда ничек чыгарылгандыр, анысы билгесез. Талчыккан мотор хәтәр көчле тавыш чыгарып эшли башлады.

— Күршеләргә юл тоттыңмы, абый? — диде шофёр. Ханчаеры дигән жир — ике ил арасында, тәжрибәле таксичыга юлчысының әле ары китәчәген чамалау авыр түгел иде, күрәсең.

— Әйе, — диде Кадыйр.

Юлда ике тикшерү пунктын үттеләр. Полиция машинасы күргән саен борсаланып, такси йөртүче үз телендә ришвәтчеләр-фәләннәр дип сүгенеп алды.

— Бары тик алар гынамы? — диде Кадыйр, көлеп.

— Белмәссең инде, абый. Без болардан күрәбез лә күрмәгәнне, шуңа да аларны сүгәбез дә инде, — дип жавап бирде таксичы. Аннары сүз гаиләгә, балаларга күчте.

Күрше илнең таможнясына бик тиз барып життеләр. Таможня шау-шусыз, ыгы-зыгысыз, шактый тыныч булып күренде. Шофёр:

— Мин чик чыгу өчен машина кәгазьләрен рәсмиләштерим, син паспорт-виза мәсьәләләреңне хәл ит, каршы якта очрашырбыз, — дип, Кадыйрны машинадан төшереп калдырды.

Кадыйр яңа гына салынган таможня бинасына килеп керде. Күз йөгертеп кенә паспорт тикшерә торган кабиналарны эзләп тапты. Таможня залы буш диярлек иде. Эш көнен бик иртә башлаган хезмәткәрләр жентекләп тирә-якны күзәтә. Кабина тәрәзәсендә күренгән яшь кенә хезмәткәр егет белән күзгә-күз очрашкач, ул Кадыйрга: «Бирегә кил», — дигән ишарә ясады. Кадыйр, кабина янына килеп, аңа паспортын сузды.

Күнегелгән баш, күз, кул хәрәкәтләре белән паспортның битләрен актара-актара, хезмәткәр башта фоторәсемле битне эзләп тапты. Бер фоторәсемгә, бер Кадыйрның йөзенә карады. Паспорт тикшерүе үтүнең иң эчпошыргыч мизгелләреннән берсе менә шушы инде. Хезмәткәр шөбһәләнгән кыяфәт чыгарып, кабат фоторәсемгә, аннан соң бик игътибар белән Кадыйрның йөзенә карады. Ул бу мизгелне мөмкин кадәр сузарга телидер кебек тоелды Кадыйрга. Фоторәсемнең шик тудырмавына ышангач, үз иленең визасы куелган битне эзли башлады.

Кадыйр селкенми дә, хезмәткәрне күзәтә. Ниһаять, визалы бит табылды. Егет бик сабыр, салмак хәрәкәтләр белән визаны тикшерде. Алдында торган компьютерның төймәләренә үрелеп:

— Эшләргә киләсеңме? — дип сорады.

— Әйе, — диде Кадыйр. — Мин бер төзелеш фирмасында житәкче.

Барыбер сораячагын белгәнгә, шунда ук үзе эшләгән бүлек, фирма эшчәнлегендә тоткан урыны турында да мәгълүмат бирде.

— Директормы?

— Юк, директор ярдәмчесе.

Хезмәткәр ул арада компьютерда Кадыйрның исем-фамилиясен яза башлаган иде:

— 100 доллар бир, алайса, — диде.

— Яхшы икән... Минем бөтен документларым әзер, тәртиптә. Нәрсә дип бирим 100 доллар?

Тегесе Кадыйрның әйткәннәрен ишетмәмешкә салынды, төймәләргә баскалап, паспорт номерын язуын дәвам итте.

— Ничә ел эшлисең бу илдә?

— Дүрт, — диде Кадыйр.

— Телебезне яхшы өйрәнгәнсең.

— Яхшы дип әйтергә була.

Кадыйрның чит ил кешесе икәнен белмәгәннәр, акцентсыз сөйләшүеннән чыгып, аны жирле халык вәкиле дип уйлый иде хәтта.

— Тел өйрәнү курсларына йөрдеңме?

— Әйе, килгән елны ук, алты ай тел үзләштерү дәресләре алдым.

Хезмәткәр, башын күтәрмичә генә:

— 50 доллар бир алайса, — диде.

Туган телен Кадыйрның яхшы белүеннән бик канәгать калган да, әйтерсең, ташлама ясый.

— Шулай да, ни өчен бирергә тиеш ди инде мин ул акчаны? Ярдәмегез кирәк булган бер мәсьәлә дә юк. Бөтен документларым тәртиптә.

Егет тагын берни ишетмәгән кебек, язуын дәвам итте.

— Эшләргә рөхсәт алынганмы?

— Алынган.

— Рөхсәт язуы янындамы?

— Янымда, — дип, кәгазьне сузды Кадыйр.

Документны тикшергәннән соң, хезмәткәр аны паспорт янына куйды да алдындагы тар өстәл өстеннән мөһер эзли башлады. Башын күтәреп карамыйча гына, тагын:

— Ярый, 25 доллар бир алайса, — диде.

Көләргәме, ачуланыргамы — Кадыйр әлегә моны аңлый алмый иде.

— Ни өчен бирергә тиеш инде мин, шуны әйт тә бирим, һич булмаса.

Хезмәткәр мөһерне табып, кискен хәрәкәт белән баштаа штамп тартмачыгына, аннары Кадыйрның паспортына басты. Такта өстәл, галәттәгечә, шыгырдап куйды. Эшләргә рөхсәт кәгазен паспорт эченә тыгып, Кадыйрга:

— Кил әйдә, чәй эчәбез, — диде. Тәкъдимнән баш тарту мөмкин түгел иде, егет урыныннан торып чыкты да, кулы белән ишарә: «Әйдә минем арттан», — дигәндәй итте.

Бүлмә арткы коридорда урнашкан. Сөйләшү һаман да Кадыйрның телне яхшы белүе, фирмаларының эшчәнлеге турында дәвам итте. Чәй китерделәр. Хезмәткәр чәен уртлап куйды да:

— Йә, ярый, алайса 10 доллар бирерсең, — диде.

Кадыйр инде аптырауның чигенә житкән иде. Тикшерү беткән, паспорты кесәсенә кереп урнашкан. Инде килеп, бу кешенең «алайса ун доллар»ы нәрсә дигән сүз соң ул?

— Бирәм, валлаһи, бирәм. Тик ни өчен бирергә тиешлегемне генә әйт. 10 доллар бирәм.

Хезмәткәр, Кадыйрның йөзенә туры карап:

— Ай-һай, Кадыйр бәй, син дә бирмә, башкасы да бирмәсен. Мин бу эшкә урнашыр өчен түгкән акчамны кемнән чыгарырга тиеш булам инде алайса, йә?!

Кадыйр, ләм-мим дәшмичә, акча янчыгыннан 10 доллар алып бирде һәм, чәен дә эчеп бетермичә, бүлмәдән чыгып китте.

Хезмәткәр аны ишеккә кадәр озата килде. Күптәнге танышлар кебек саубуллаштылар.

Ул үзен көтеп торган такси йөртүчене эзләп тапты.

Тикшерү пунктларында туктата калсалар, ун долларны мин түләргә тиеш микән, әллә такси шоферы микән, дип уйлана-уйлана, Кадыйр юлын дәвам итте.

*Төрек теленнән* **Асия РӘХИМОВА** *тәрҗемәләре*



Әскәр
Додуев

# ҺӘРБЕР КЕШЕ ҮЗ ЮЛЫННАН БАРА

## Йолдызларда тормыш юк

Әйт дөресен: сиңа бар да дусмы?
Акылы сайның бармы байлыгы?
Тормыш юк айда, йолдыз, күкләрдә,
Хәтта җирдә яшәү тарлыгы.

Үтерешеп, бүре күзе белән
Йотып яшәү — яшәүмени ул?
Җанында — үч, эзең мишень булса,
Сиңа дошман буламыни ул?

Юк, диләр шул, йолдызларда тормыш,
Җирнекен киләбез бетереп.
Эчәр суны хәтта боз итәбез,
Туң йөрәкле җаннарга төреп.

Әйтәләр бит, йолдызлар үле, дип,
Җир дә бетәр, иман югалса.
Текә тау бозыннан шуып торсак,
Ышанычка кар һәм боз ката.

Йолдызларга һаман үреләбез —
Ерактан бит кайнар тоелмый.
Кагылуга, ялкын булып янгач,
Хыял, язмыш аннан уелмый.

Әйтерсең лә җирдә беркем дә юк,
Җансыз күккә сузылу кирәкме?
Үз йолдызың янда балкып торса,
Янып-көю бәйли йөрәкне.

---

*Әскәр ДОДУЕВ (1953) — Карачай-Черкес Республикасының халык шагыйре, Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының IV чакырылыш депутаты, «Минги-Тау» журналының баш мөхәррире. Нальчик шәһәрендә яши.*

## Юлны күрмим

Көнләшмә син миннән, Ходай өчен,
Мин болай да очмыйм хәйлә корып.
Минем өчен яшәмә дә куркып:
Дошманыма булмам табыш кыры.
Дуслар, якыннарым биздерсә дә,
Капланнарны тормам тукландырып.

Тик бер нәрсә калсын хәтереңдә:
Мин беркайчан уйга батып йөрмим.
Төндә чакыру ишетеп чыга калсам,
Кая барганымны хәтта белмим —
Озын төннән таңга кадәр ерак,
Өмет чаткылары гына сүнми,
Алары да әле ышаныч бирми.

Тиз барганмын — алда нәтиҗәсе:
Бозлык арасына килеп кердем.
Шулчак минем тыйнак, тын хыялым
Синекеннән аерылып йөрде.
Монда да син ашыгып узып китмә:
Үтәр юлны караңгылык төрде...

Сагыну-сагыш миннән читтә йөри,
Онытылды — алар дус түгел.
Һәрбер кеше үз юлыннан бара —
Берсенең дә юлы хуш түгел.
Бер Аллаһ та безгә берни бирми:
Табынмасаң, тулмый уч төбе.

Ачылып киткән ярам канда әрни,
Элеккесен дә бит җуймадым.
Килер төннәр хыял, утсыз үтәр:
Ачы язмыш миннән туймады.
Шулай да ул мина дәрман өсти,
Булып калсам да мин бүген көчле,
Кичерүләргә нокта куймады.

## Синең күзләр

Алдый алмыйсың син бер дә:
Күзләрең — сатлыкҗаннар —
Хакыйкать белән янар.
Син үзең: «Кит!» — дигәндә дә,
«Кал, зинһар!» — диләр алар.

Күзләрең — сагыш оясы,
Минекеләр — зәңгәр күк.
Синең күзләр — минем байлык,
Соңгы көнемдә аларны
Югалтып китәрмен күк.

Күзләрең — минем җырымның
Булыр соңгы сулышы.

Сөйлиләр (сөйләсеннәр лә),
Күзең үзеңне сата, дип.
Бер-берләрен күрмәгәнгә,
Һәлакәтем, тормышым.

## Ике дулкын

Язмышым борма булганда,
Мин аны нык битәрлим.
Тәмле бәлеш ашатса да,
Битәрләми киталмыйм.

Дөньяда миңа ни кирәк?!
Пәйгамбәр дә әйталмас.
Сөеклем бар, тик ул миңа
Карап, күзләре талмас.

Ике дулкын очрашканда,
Бер-берен китә күмеп,
Эзләмим шуңа назларны —
Тормасын мине сөеп.

Дәрьяга охшаш дөньяда
Ул — алдан йөзгән дулкын.
Бер үк ярга ашыгабыз,
Тик мин иярчен дулкын.

***

Язың инде сиңа күптән килде,
Тик, нигәдер, карлар эреми.
Элеккечә бәхет тәрәз чиртми,
Булганыннан артык күренми.

Язмышың да сине җәлләп тормый,
Ялваруыңны да ишетми.
Ышанычың күрсәт бер мәртәбә —
Меңләп ялган кагар ишекне.

Яңгыр үтте, ә син аннан калмый
Чикмәнеңне киеп чабасың.
Атны камчылаудан бер мәгънә юк —
Күбеген генә чәчә чамасыз.

Язмышыңнан күпме файда көттең,
Бурычка да чумдың бит инде.
Мондыйларны язмыш ярлыкамый:
Әгәр атың китсә сине ташлап,
Ияртер дә китәр этеңне.

*Балкар телennән* **Флёра ТАРХАНОВА** *тәрҗемәләре*

## Мөхәммәт Әхмәтов



# ТӘСБИХ

**1**

Ишетерме минем тавышымны
Шайтан утырган зат эчендә,
Карангылык белән төренгән һәм
Ишетмәүче күкләр өнен дә?!

Йөрәгендә елан асраучы,
Ә Аллаһны, Аны оныткан
Бәндәләргә, бер могжиза булып
Барып ирешерме бу догам?

**2**

Дөнья, мәгълүм, тора гел ялганнан
Һәм үзеннән һәрчак канәгать.
Ул кайгырмас минем турында һич,
Исән чагымда да, җәмәгать.

Ләкин үлү безнең өчен — гөнаһ,
Ике икән күк бу ап-ачык:
Армас кулым тәсбих тартудан һич
Һәм җыр мәңге исән калачак.

**3**

Йә төрмәгә тыга, йә бөлдерә —
Рәхимсез чор безгә бирә җәза.
Бәндә, мескен, белми ни кылырга,
Акрын гына акылыннан яза.

Таладылар ярты илнең малын,
Җимерделәр яши торган йортын.
Ә мазарда һәммәбез дә тигез,
Кайчан гына шуны аңларбыз соң?!

**4**

Мин тәмугка әгәр керә калсам,
Мине эзләп һәрчак килерләр,
Ярдәм кулын миңа сузар өчен,
Җирдә яшәп киткән шагыйрьләр.

Шул чагында әйтә алырмын мин,
Каләмемне манып карага:
Изге булды һәрчак язган сүзем,
Кара кертмәдем, дип, арага.

**5**

Илаһи Сүз түгел, буш сүзләрдән
Тулган чакта дала, калалар,
Күселәр дә арысланны җиңә,
Тәсбихлар да өзелеп тарала.

Шигырь — түгел шайтан вәсвәсәсе,
Чорлар уйлап тапкан уйдырма.
Ул намазга басып укыр өчен
Илаһиның Сүзен сыйдырган!

**6**

Кичүдә дә елга кичә алмас
Оныткан зат Аллаһ барлыгын.
Халкым минем, берүк, тот исеңдә
Дәрт-дәрманың һәм горурлыгың!

Ләгънәт тулы труба тавышын мин
Еш ишетәм соңгы арада.
Текәрәктер, белмим, кем язмышы —
Таулыдамы, әллә тауларда?

**7**

Юк, бу минем сүзем түгел,
Халык әйткән, ди, бу хакта.
«Ышаныргамы патшага?»
«Ышан, ләкин үле чакта».

Тик ник халык угрыларның
Шәфкатенә өмет тота?
Аллаһыга юллар ябык.
Туган йорты яна утта.

Мөхәммәт ӘХМӘТОВ (1955) — *Дагыстанның халык шагыйре. Дагыстан Язучылар берлеге рәисе. Россиянең Зур Әдәби премиясе лауреаты.*

**8**

Һәрвакыт рәхәт козгынга
Бөркет корган ояда.
Рәхәт аңа явызлык
Белән тулы дөньяда.

Ул — сандугач бакчасында,
Мәетләр арасында.
Рәхәтләнеп яши козгын,
Кай якка карасаң да.

**9**

Телисеңме бәхетне тик үзеңә?
Яшә, әйдә, күрми кайгы, бәласез.
Тик күңелсез булыр яшәү ялгызын,
Дус-ишләрсез, хатынсыз һәм баласыз.

Бәхет шунда: бүген яки иртәгә
Яшәвеңнән канәгатьлек алалсаң;
Үз вакытың җитеп, гүргә кергәч тә
Хәтерләрдә исән булып калалсаң.

**10**

Кем ваз кичә Аллаһ биргән бүләктән,
Кирәк түгел шуңа Аллаһ үзе дә.
Ул картайган була сабый чагыннан,
Чытык була күңеле дә, йөзе дә.

Һәм бердәнбер иң югары дәрәҗә
Кеше булу. Ләкин шуны уйлыйсың:
Нигә әле ирләр кайчак әйләнеп
Матрёшкага, әйлән-бәйлән уйный соң?!

**11**

Юк, тумаган кеше михнәт чигеп,
Сыер абзарында яшәргә.
Ул яңгыр йә илбаш була ала,
Шагыйрь булып мөмкин яшьнәргә!

Тик мәңгелек тегермәне ташын
Бора алам дип алданма.
Бил бөгәргә әгәр туры килсә,
Патша түгел, иел Аллага.

**12**

Кем ул саткан ата-баба рухын?
Изге ни бар андый затка соң?!
Андый хәсис адәм актыгыннан
Газиз Аллам үзе сакласын!

Кояш чыга таңда тауны назлап,
Тау елгасы ага чылтырап.
Тууым да, үлемем дә Синдә,
Синдә туды җырым җан сорап.

**13**

Тизрәк шөһрәт килсен дисеңме син?
Тормыш гади, үзең күрерсең.
Горур тотсаң башың, син булырсың
Патшалардан бермә бер өстен.

Акрын барма, артык ашыкма да,
Барып җитмәс җиргә юл тотма.
Менә калсаң тауның түбәсенә,
Аста дала барын онытма.

**14**

Яшәгәндә берни уйламыйсың,
Курыкмыйсың хәтта Алладан.
Явызлык ул балыкка да житә,
Яхшылык күренә таулардан.

Тормыш чиста, гөлчәчәге кебек,
Чишмә кебек үтә күренә.
Шәрык әле һаман яшәсә дә,
Ия юк тик зирәклегенә.

**15**

Сәер нәрсә Ходай биргән сәләт!
Сәеррәк ләкин тагын да,
Сәләтеңә бәһа бирә берәү,
Син картаеп каткан чагында.

Шундый бәһа: синең өскә басып,
Тау өстенә үзен күтәрә.
Һәм үлемсез данга күмә үзен.
Синнән кала бары күләгә.

**16**

Мин аңлыйм һәм якын итәм
Намусы саф булганны.
Хәтта чит илгә китеп тә
Табыла аның туганы.

Кем бары малга табына,
Кем бары акча колы —
Аннан иң якыннары да
Селтәгән була кулын.

**17**

Мәңгелекнең явыз җебен кулдан
Җибәрмәскә теләп озакка,
Мәхәббәтне саклап калыр өчен
Утыртканнар аны тозакка.

И, кешеләр, кылмагыз явызлык,
Хыянәткә сукмак сапмагыз.
Мәхәббәтне йөрәк түрегездә
Күз карасы кебек саклагыз.

18

Үз үлчәме сүзнең — бәхетне дә,
Күз яшен дә йөрәк үткәрә.
Бирсә дә бу зарлы җирдә түгел,
Бөтенесен күкләр күтәрә.

Син мәңгелек белән үлчә бары
Йөрәгеннең һәрбер кагышын.
Шунда гына, ышан, мәңгелектә,
Гасырларда калыр тавышың.

19

Әйтсәң кемгә табынганыңны,
Белерсең син хаклыгың
Кылганыңның, бу дөньяда
Зурлыгың йә ваклыгың.

Кылтырамасын йөрәгең,
Син бары үлмә генә.
Тәмуг белән җәннәтне тик
Белерсең гүрдә генә.

20

Сылтама барсын Аллага!
Иленне саткан чакта,
Үзелер дип күңел кылын,
Уйладыңмы шул хакта.

Рәхимсез дисеңме чорны,
Күз текәп стаканга?
Кеше дисеңме? Мин сине
Охшатам тараканга!

21

Җинелме сиңа кыек юлларда?
Ник кирәк безгә бу язмыш, Ватан?
Аяк астында бөтен мөлкәте
Хакимнәреннең, иманын саткан.

Ә фәкыйрь халкың тормыш төбендә
Дөрес юлларның табалмый очын.
Ни ул дингезгә киталмый йөзеп,
Ни фәрештәләр янына очып.

22

Җырмыни соң булсын күңелеңдә?
Фәкыйрь халык бүген кәефсез.
Байлар бүген кәеф-сафа кора,
Илне талап яши, хәерсез.

Аш дигәнең, ул да ачы бүген:
Сабый алдындагы табактан,
Картлар авызыннан өзелгән аш
Ничек итеп үтсен тамактан?!

23

Белмиләр ни кылганнарын,
Җырлауларын кем җырын:
Ватан турында лаф орып,
Саталар Ватаннарын.

Һәм шушы буш сафсатада
Бер гамь бар сүзгә лаек:
Бай өчен фәкыйрьнең малы
Нибары бер уч байлык.

24

Чәчеп бөтен ачу-үчен,
Өскә килә угры-затсыз.
Кайчан әле җайдак иде,
Калган торып кинәт атсыз.

Тик асылда бар хакыйкать,
Шушы хакта алар белсен:
Ялган юлы рәхәттер дә,
Алда көтә гадел хөкем!

25

Ялтырамый хәзер намус,
Алтын, көмеш ялт-йолт килә.
Тик кешеләр оят барын
Һәм изгелек барын белә.

Ничә еллар инде шайтан
Яздырмакча мине юлдан.
«Алла сират күпере!» — дип,
Тәсбих тота мине кулдан.

26

Яшәмә үткәнгә үпкәләп,
Эзләмә дә аннан гел хата.
Хәерле килсен һәр туар таң,
Уйла син бары тик шул хакта.

Тормыш ул болай да бик матур,
Ләззәт ал  көлеп таң атудан.
Йөз тапкыр егылу хәерле,
Бер тапкыр иленне сатудан.

28

Гомер үтә комга сеңгән судай,
Өстен күрмә җирдә берсен дә.
Мәңгелектән без йолдыз күк ерак,
Ә үлемнән — тик кыл өстендә.

Җыр — оясын ут ялмаган кош ул.
Коткарырга аны юк чара.
Елый кошчык: «Ни эшләргә миңа,
Ватаным юк, ди, мин — бичара?!»

**29**

Һәрбер яңа тәңре
Туган көннән туңган.
Язмыш аны яшьли
Туган илдән куган.

Тәңре була алмый,
Имеш, туган илдә.
Буламы соң читтә?
Йә, кем җавап бирә?

**30**

Карангылык баскан илдә ирек
Әверелә икән зинданга.
Сагышыннан анда мәңгелек тә
Акылын җуеп була дивана.

Җаннар кара канга баткан илдә,
Азатлык һәм сөю хакында,
Кайчандыр мин төшләр күрә идем...
Иле дә юк хәзер, язы да.

**31**

Сәгатьләр дә кайчак дөрес сукмый.
Акмый сулар кайчак тиешенчә.
Аллаһ кайчак колак салмый кала
Янган йөрәкләрнең тибешенә.

Шигырь кайчак гөнаһ белән туа,
Тауны кайчак туган күрәсең...
Мәхәббәтсез бар дөньясы бушлык.
Мәхәббәтсез хәтта үләсең.

**32**

Үз илемдә килмешәктәй яшим,
Сагыш аша багам дөньяга.
Уйлыйсым да килми, укыйсым да,
Тынгы табам җанга догада.

Исем китми иде беркөн җирдә
Минсез генә таннар атар дип.
Башыма да китермәгән идем
Беркөн Илем мине сатар дип.

**33**

Мин күп төрле вакытларны беләм,
Һәм беләм шул чакны — менә да
Әзер булып тору кирәк шуңа:
Мин дә булмам беркөн дөньяда.

Дөнья ел да яманлана бара,
Аһ, нигә ул шундый икән соң?
Мин киткәндә, белмим, нинди булыр,
Матур булсын иде миннән соң.

**34**

Кешеләр, имеш, бер ярда,
Ә тормыш — икенчедә.
Ни булганын күрмиләр һәм
Ишетми икесе дә.

Алла хакы өчен, калсын
Үз ролендә һәрберсе:
Моцарт — Моцарт, ә Сальери
Сальери булып йөрсен.

**35**

Кылын чиртсәң сазның —
кул калтырый,
Тәсбих тартсаң — йөрәк авырта.
Кемгә нәрсә кадерле дә түгел,
Сүз — тормыш кадере хакында.

Чик юк дога һәм җыр арасында,
Син дә моны беләсең күптән:
Кыл чирттерсәң — түбән капланасың,
Тәсбих тартсаң — ашасың күккә.

**36**

Тауда үскән гөл турында бер җыр яши:
Имеш, язын шаулап чәчәк аткан чакта,
Тыйнаклыкмы, куркуданмы,
өзәрләр дип,
Чәчәгемне, ул таш арасына кача.

Шагыйрь дә шул гөлгә охшаш:
иҗатының
Шаулап чәчәк аткан матур бер
мәлендә,
Күренмәскә тырыша гел кешеләргә,
Ялгыз калып яши иҗат мөнбәрендә.

**37**

Шигырьләрне дә, чәчәк күк,
Саклавы кыен була.
Гөлләрнең гүзәл таҗлары,
Су эчермәсәң, сула.

Мәхмүтнең кайнар сулышы,
Пушкинның татлы теле,
Чорлар тузанын тидерми,
Саклый мәхәббәт гөлен.

**38**

Мәхәббәт төшләре сихерле,
Очасың күкләрдә ак атта,
Якты фәрештәләр катында
Юк тынгы сиңа да, миңа да.

Тын ал, дус, сулышын, күрәмсен:
Йолдызлар назлана төшендә.
Хисеннен син биек исемен
Йолдыздан түбәнгә төшермә.

**39**

Безгә Аллаһ биргән бөтен нәрсә
Юкка чыкты еллар катында.
Үз урынын табалмыйча, аннан
Ватан китте алар артыннан.

Тигез тормыш төзү тәгълиматын
Качкан оят искә төшермәс.
Һәм халкына хыянәт иткәннәрне
Беркайчан да Аллаһ кичермәс.

**40**

Мәхәббәт барын оныткан,
Ач, шаян, матур кеше...
Егерме беренче гасыр —
Шул анын бөтен эше!

Аһ, кайда сон ул татлы төш,
Аһ, ул хатын-кыз кайда?
Калыр идем шул гасырда,
Тик кайда мин, сез кайда?!

**41**

Туйдырды, бөлгенлек, төрмә —
Бугаздан булдым гарык.
Бурычка биреп торыгыз,
Калыйк илне коткарып.

Кредит итеп бирегез,
Кайтарырмын өлешләп.
Аллаһы кичермәсә дә,
Алай да бирер бүләк.

**42**

Дошман да кайчак үз була,
Дус та бөергә суга.
Горур кыр чәчәген тормыш
Ташлый бер заман суга.

Шулай — минем дә хыяллар
Сындылар давылларда.
Шул кыр чәчәкләре сыман,
Акты ярсу суларда.

**43**

Ниндидер сәер як,
Аллаһмы шат шуна?
Җәннәт жанны телә,
Тәмуг кулга суга.

Яшәсенме шунда,
Жан, кылсынмы тәслим?
Фәрештә һәм шайтан
Арасында яшим.

**44**

Ни сөйлисен һәм ни хакка —
Сүз әйтүен тин ижатка.
Үлгәннән сон, әйт син шуны,
Сөйләшербез без на хакта?

Бетермибез ник сон анлап:
Гомерне бит безгә Аллаһ
Әҗәт итеп биргән бары.
Без түләргә тиеш аны.

**45**

Хатирәләр, ялтырап,
Таудан төшкән су кебек,
Өркетеп үткән белән,
Туфракка бетә сенеп.

Күнелдә кала торып
Бик азлары, яктырып,
Женазада тотылган
Ин сонгы нотык булып.

**46**

Карангылык һәм явызлык изгән
Бөтен фәкыйрьләрен жиһаннын,
Мин бәхетле бәндәләре итеп,
Кайтырмын дип илгә инандым.

Кайттым илгә. Ә бәхетем кайда?
Хуржиным буш, шулмы тәкъдирем?
Ә Ватаным хәйрестәргә калган.
Мин дә анын сансыз фәкыйре.

**47**

Шигырьләр киткәндә, дөньяга
Вак-төяк һәм чүп-чар тулачак.
Мин китсәм, дөньяны тутырып,
Бары тик шигырьләр калачак.

Таулылар елый тик — күмгәндә,
Ә шигырь — жан тәслим кылганда.
Шигырем жанымда ярала,
Чал дәрвиш догасын кылганда.

*Авар теленнән* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәсе*



Тамара
Ганиева

# МОҢАЮ БАР КҮКНЕҢ ҮЗЕНДӘ ДӘ

## Минем кыйблам

Жиде ыру — җиде ак тамырым.
Җитмеш жиде үлеп терелгән.
Ятим калам диеп курыкканда,
Ныклы өмет алам күзеңнән.
Биш тарафым: көньяк, көнчыгышым,
Төньяк, көнбатышым, җиһаным.
Биш бармагым кебек биш дәрманым —
Дәрт, кодрәтләр алып торганым.
Өч таган[1] да кебек өч туганым,
Мин дүртенче — кисәү булыймчы.
Янган чакта, көлгән, елаганда,
Өзелеп сезгә бәхет юрыймчы.
Берәү генә, бер-бер бөртек кенә
Газизләрдән газиз кыз балам.
Шул җидәүдән, биштән, өч, берәүдән
Сабырлык, уй, гайрәт, моң алам.

***

Әнкәемнең кулы нык арыган...
Каләм тоткан кулы, урак урган,
Ризык сузган,
Безне назлый торган —
Бәп-бәләкәй кулы нык арыган —
Күкрәгенә шуңа ул сыенган.

Әнкәемнең күзе нык арыган...
Нур бөркегән күзе, гыйлем җыйган,
Шатлык күргән күзе,
Күп яшь койган,
Әнкәемнең күзе нык арыган —
Мәңгелеккә ялга йомдырылган.

[1] Таган — очаяк мәгънәсендә.

Тамара ГАНИЕВА — *башкорт шагыйрәсе. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Р.Гарипов, Ф.Кәрим, Б.Бикбай исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Уфада яши.*

Әнкәемнең аяклары талган,
Дөнья көтә торгач сызлау алган,
Бер ял итсен дипме сузып салган...
Әнкәемнең аяклары талган,
Читек, оеклары салдырылган.

Әнкәемнен жаны нык арыган...
Аяулардан безне, яратудан.
Куану һәм чиксез сагынудан,
Әнкәемнен жаны нык арыган...
Көне бетте микән, жирдән узган...

***

Ачыла-ачыла инде асыл чәчкә,
Түгелә-түгелә инде мөлдер чишмә,
Өзелә-өзелә генә бер сандугач –
Унсигезем тулган мәлләргә хас.

Алсу-зәнгәр генә күк төсләре,
Иләс-миләс кенә жил искәне,
Узыша-куыша вакыт колынчагы –
Бер егеткә үлеп гашыйк чагым.

Сак-сак кына болан тояклары,
Тәлгәш-тәлгәш миләш ботаклары,
Каерып-каерып чабар печән өсте –
Бала гына көткән мәлем төсле.

***

Урман уйчан. Имән кәүсәләре
Көннең кызуыннан йончыган.
Инәнә хәсрәт яткан карурманның
Уфтануын тыңлап төн чыгам.

Моңаю бар күкнең үзендә дә,
Жир дымлана шомлы хәвефтә.
Әйләнә дә тирәм кисәтүме
Өмет тулы минем кәефкә.

Өметләнәм. Менә Алла бирсә,
Яхшырачак минем дөньялар.
Куйчы, сулма,
Диган сулыш өреп,
Жангынама тынгы оялар.

Карурманның тылсым чаршауларын
Көн кодрәте тартыр бик тиздән.
Керфек талдырыплар таңны көтәм,
Урман арыналмый елак көйдән,
Үрсәләнә.
Мин бит... мин бит түзәм...

## Янә туган як хакында

Уйсуында уем уелып калды,
Чагылында[1] күнелем чагылды.
Түздермичә генә әсир итте
Яратуым туган ягымны.

Яшермим лә яшем узганны да,
Кыланулар монда ят кебек.
Чумар идем туган төбәгемә
Су төбенә төшкән таш булып.

Казарманы[2] әйләнепләр чыксам,
Тәрәз чиртер төсле бер туган:
«Яныбызда бары син җитмисең,
Касәләргә кымыз коелган».

Кадер күргән бар ул,
Тик шушында
Җәйлиселәр килә бу җәйне.
Онытканмы әллә туганнарым
Каршы чыгып атлар бәйләүне.

Үксезлектән җаным үксеп елый,
Мине болай ятим итмәгез.
Сез кешегә санамаудамыни,
Күнелемә якын һәммәгез.

Түбән очтан килгән энекәшнең
Рәхмәт төшкер,
Йөзе яктыра:
«Нихәл, апа,
Баш авырта яман,
Күчтәнәчең юкмы чак кына?»

...Үзәгемә рухың уелган жир,
Озынайган урам,
Хыял — тар.
Үзгәрмәгән кебек бу мәлләр...
Суындыра никтер мәхрүм итеп,
Күнел тартмый торган гамәлләр.

**Ленар ШӘЕХ** *тәрҗемәләре*

[1] Чагыл (башк.) — тау бите.

[2] Казарма — Башкортстандагы авыл.



Сәйран
Сөләйман

# БЕРЛӘШИК ВАТАНДА

## Байрагым

Рәхимсез бу дөнья, аямый һичкемне,
Кодрәте киң анын, алалмый тик сине.
Кырымым, бәйсезлек күрәм мин тамганда,
Халкымның үткәнен хәтергә алганда.
Кирәкми, кирәкми, башка бер байрак та,
Берсе дә үз түгел — уемнан еракта.
Үтенеп, гозерләп ялварам Аллалан:
Ил-йортым, байрагым жанлансын яналан!
Байрагым... Ярым ай... сезсез мин — кол-әсир,
Кулымнан төшерсәм, варислар ни әйтер?
«Татарлык» дигәндә, син уйга киләсен,
Байрагын сөймәгән — акылсыз, күрәсен.
Күк байрак иясе — милләтем һәм халкым,
Байрагым дип яшә — хакла син ир хакын.
«Бал тамчыдан жыелыр» — берләшик Ватанда,
Яңа дәүләт корганын күрәм мин тамганда.

## Бушлык

Бу чиксез дөньяны соңгы вакытта
Кайдан урап алды шулкадәр бушлык? —
Өстән һәм астан, сулдан һәм уңнан
Кабып йотар күк бу вәхши бушлык.

Күзгә күренми, тик сизә йөрәк —
Кая карама — һәр жирдә бушлык.
Бушлык арабызда туктаусыз гизә:
Жырларда, көйләрдә, фикердә бушлык.

Чаларган дөньяны изә бу бушлык,
Инсанның инсафын юк иткән бушлык,
Чиксез үч-нәфрәт тудыра бушлык,
Жандагы ташны кабарткан бушлык.

---

Сәйран СӨЛӘЙМАН (1979) — *шагыйрь һәм прозаик; Кырым-татар һәм Евразия Язучылар берлеге әгъзасы. М.Кашгари исемендәге (Төркия) I Халыкара әдәби конкурс лауреаты. Симферополь шәһәрендә яши.*

## Кырымга

Ватаным, балаларың
Кайчан берләшер?
Уртак нияткә
Бердәм ирешер?
Дан-кадереңне
Кем белә, әйтче?
Уелган бәгъренә
Бу кемнең Хачы?
Җаным, улың сине
Үлсә дә сатмас,
Ватанын күңеленнән
Чыгарып атмас.
Карама, Кырымым,
Күз яшең тыеп.
Ил-йортым, син барда
Булмабыз гаип.
Күчкән бит беләккә
Атилладан көч.
Калсак та элгәрге
Җәмгыдән — бер уч.

## Хатын–кызларга багышлау

Хатын-кызлар теләмәсә — Җир әйләнмәс,
Кайсы ир-ат анасын һәм ярын сөймәс?
Хатын өчен корбан чалу кирәк түгел,
Сагышланган чакларында юата бел.
Зифа буй-сын, кара кашлар, коңгырт күзләр,
Ычкындырмыйк бу байлыкны ялгыш безләр.
Авыз ачып торсак, дошман кызык итәр:
Җилләр исәр — татар кызын урлап китәр.
Бу җиһанга елга тик бер килә язлар,
Ямьле язны яз иткән тик хатын-кызлар.
Кемгә — яулык, кемгә калфак килешеп тора,
Кемдер ялгыз, кемдер парлы — гаилә кора.
Иске гадәт — хатын-кызның кулын үпмәк,
Изге алар: хатын-кыздыр һәм дә икмәк.
Хатын-кызсыз нишләр иде ир-егетләр? —
Алар җирдә нур өстенә нур кебекләр.
Бала йөртә йөрәгенең нәкъ янында,
Кемнәр багар бу ананы картлыгында?
Без рәнҗетсәк, әйтеп әгәр ялгыш сүзләр,
Кичерегез, кичерегез, хатын-кызлар...
Җир әйләнсен, әйләнсен Җир... Хаклык шулдыр:
Сез булсагыз, җирдә яшәү мәңге булыр.

## Раббым

Раббым, сакла безләрне
Утка салган сүзләрдән,
Ялгыш-кыек юллардан,
Каты-яман күзләрдән.

Тагын сакла безләрне
Зәһәр телле затлардан,
Һәлакәткә юл тоткан
Аксак-сукыр атлардан.

## Синең күзләреңдә

Синен күзләреңдә
Йолдызлар күрдем,
Дингезләр күрдем,
Болытлар күрдем,
Яшел-яшел урманнар,
Гүзәл балкышлар күрдем.
Күрмәгән булсам әгәр,
Яшәмәс идем,
Куанмас идем,
Язалмас идем...

Синен күзләреңдә
Хәсрәтләр күрдем,
Тамчы-тамчы күз яшьләре,
Сорау-ялвару күрдем.
Тагын — Кояшны,
Тагын мин Айны күрдем.
Күрмәгән булсам,
Еламас идем,
Кояшка, Айга
Куанмас идем.


Синен күзләреңдә
Сине күрәм, Ана.
Кирәк түгел сүзләр,
Күзләрең булганда.

## Ышанды

Ышанды ул тирәккә,
Тирәк янды — көл булды.
Ышанды ул гөлләргә,
Гөлләр саргаеп сулды.
Ышанды ул җилләргә,
Җилләр үтте дә китте.
Ышанды сөйгәненә,
Ул башканы үз итте.
Ышанды дус сүзенә,
Ни дусты юк, ни сүзе...
Инде ышанмый егет
Хәтта үзенә үзе.

*Кырым-татар теленнән* **Сания ӘХМӘТҖАНОВА** *тәрҗемәләре*

# ИКЕ БОМБА, ТЕШ ҺӘМ ИЗОЛЬДА



Сугышта авырлыклар да, хәтәр хәлләр дә баштан күп кичте. Ләкин беркайчан да күңелемнән чыкмаган иң җете хатирәм бөтенләй бүтән төрле.

1943 елның җәе бу. Безнең 77нче дивизия көне-төне алга, көнбатышка таба хәрәкәт итә. Ә минем бертуктаусыз теш сызлый. Украинадагы Мена дигән местечко, ягъни шәһәр тибындагы авылга кергәч, дивизион командирыннан рөхсәт алдым да (мин ул чакта дивизионның разведка башлыгы идем), больницаны эзләп киттем. Больница да, теш врачы кабинеты да бар икән бит, табибы да кабинетта утыра! Табиб та түгел, табибә! Чибәрлеген күреп телсез калырлык бер кыз! Күктән иңгән фәрештәмени! Елмаеп кына каршы алды... Авызымны ачтырып карады да:

– Алырга иртә, дәваларга кирәк тешегезне, – ди.

– Зинһар өчен, йолкып ташлагыз, – минәйтәм. – Мин сугыштагы кеше бит.

– Бер тамчы да новокаиным юк шул. Уколсыз гына алсам, чыдарсызмы соң?

– Чыдый алмасам, ичмасам, матур исемегезне белеп үләр идем, –дим.

– Изольда, – диде кыз, елмаеп... Ул минем тешне йолкый башлауга, янәшәдә бомба төшеп ярылмасынмы! Больница бинасының тәрәзә пыялалары чәлпәрәмә килеп коелып төште...

– Ятыгыз! – дип ишарәләп, кулым белән идәнгә күрсәттем. Тел белән әйтер идем дә, авызым буш түгел. Ул да булмады, икенче бомба төшеп ярылды. Бусы бинаның икенче ягында шартлады. Кыз мине калдырып йөгереп китте дә, ишеккә барып җиткәч, кире борылды. Кулында кыскычы, анда минем канлы азау тешем... Больница бинасына төзәп ташланган ике бомба арасында бу кыю кыз үзенең вазифасын башкарып та өлгергән бит!..

Шуннан соң без хат алыша башладык... Изольда бер тапкыр болай дип тә язды: «Һәр хатыгызны түземсезлек белән көтеп алам. Сездән хат килми башласа, нәрсә буласын да күз алдына китерә алмыйм...»

1945 елның 18 гыйнварында мин, каты яраланып, госпитальгә озатылдым. Изольдадан хатлар өзелде... Аны эзләп теге больницага да, газета-журналларга да язып карадым, ләкин таба алмадым... Күп еллар үткәч, XX-XXI гасырларның атна көннәре календарен төзеп, икенче ягына кызның фоторәсемен куеп, типографиядән ике мең данә бастырып чыгардым. «Хур кызы»ның гомерем буе карап туймаган нурлы йөзе миндә генә түгел, бүтәннәрдә дә иң гүзәл хисләр уятсын дидем.

**Маннур САТТАРОВ**

***Редакциядән:***

*Юморист язучы Маннур Саттаровка 18 сентябрьдә 95 яшь тула. Туксанны узгач та каләмен ташламады ул, сугышта исә аның башыннан ук катнашкан. Мөхтәрәм язучыбызга саулык-сәламәтлек, иминлек телибез!*

# ӘСӘРЛӘРЕНДӘ БУЫННАР ЯЗМЫШЫ

МӘДИНӘ МАЛИКОВАГА 80 ЯШЬ

Мәдинә Маликова XX гасырның җитмешенче елларында татар әдәбияты мәйданына чыга. Ул нигездә чорның шәхес белән җәмгыять арасында барган каршылыкларны тасвирлый. Проза, драматургия, публицистика жанрларында социаль-әхлакый яңгырашлы әсәрләр иҗат итә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне, милли фикер үсешен, сәясәт торышын үзәккә куеп яза.

М.Маликованың әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары көндәлек матбугат өчен хәбәрләр, документаль очерклар, мәкаләләр язудан башлана. Журналист буларак, ул күп йөри, төрле һөнәр ияләре белән очраша, тормыш материалын тырышып өйрәнә.

1967 елда М.Маликованың «Юлдашлар» исемле беренче хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Хикәяләрендә автор тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы белән игътибарны җәлеп итә. Язучы күзәтә белә, тормышчан детальләрне тотып ала. Аның һәр хикәясендә истә калырлык образлар, матур эпизодлар очрый.

Язучының беренче күләмле һәм җитди әсәре — «Казан каласы — таш кала» повесте. Ул 1968 елны «Казан утлары» журналында басылып чыга һәм укучылар арасында зур кызыксыну, төрле фикерләр уята. Әсәрдә төп герой — архитектор Мәрьям. Эчтәлекнең шактый өлеше аның беренче мәхәббәте, сөйгәне белән кавыша алмыйча, икенче кешегә кияүгә чыгуы турындагы искә алулар рәвешендә бирелгән. Героиняның шәхси тормышындагы йөрәк яралары өстенә иҗади хезмәтендәге кыенлыклар килеп өстәлә.

Мәрьямнең уйлануларына ияртеп, автор безне дә янадан-яна вакыйгалар эченә алып керә. Әсәрнең сюжеты оста корылган, күтәрелгән мәсьәләләрне ачу өчен автор отышлы һәм күп сыйдырышлы әдәби форма тапкан.

Язучы үзе күтәргән мәсьәләләр, кешеләр тормышы, бүгенге дөнья турында югарыдан торып, заманча фикер йөртә. Әсәр яшь язучының үз йөзе, үз стиле формалашып килүе турында да сөйли. Ул кычкырып, ялтырап торган буяуларны яратмый, гади, тыйнак язарга омтыла. Тормышның үзеннән, классикларыбыздан үк килә торган гадилек, табигыйлек аның иҗатында елдан-ел калыплаша, ныгый бара.

Мәдинә Маликова — ана телебездә беренче роман язган хатын-кыз. Бу роман «Казан утлары» журналында «Ак давылда тал бөресе» исеме астында чыккан иде, китапта исә «Шәфкать» исеме белән дөнья күрде.

Журналда басылуга, аны дикъкать белән укып чыккан әдәбият галиме Фоат Галимуллин: «Әсәрнең исеме үк аның битләрендә нинди давыллар уйнап аласына ишарәләп тора: «Ак давылда тал бөресе» — мәгънәле исем. Әле әсәрне укыганчы ук, конфликтның шактый җитди булып, аның агач бөресе кебек көчсез берәүгә кагылып узасы күңелгә килеп куя. Ул шулай булып чыга да», — дип язып чыкты.

М.Маликова иҗатының башлангыч чорында ук детектив жанрда да уңышлы эшли. Аның «Хөкем» (1969), «Августның бер кичендә» (1970), «Адашканга юл кайда?» (1971) исемле мажаралы повестьлары, жанр хасияте таләп иткәнчә, киеренке вакыйга-сюжетка корылган һәм укучылар тарафыннан яратып укыла. Детектив әсәрләр һәм аларны иҗат итүчеләр турында Ф.Мусин: «Профессиональ язучылар, гомумән, бу жанрның максатын һич тә теге яки бу җинаятьне ачуга гына кайтарып калдырмыйлар. Алар үз алларына социаль-әхлакый яңгырашлы бурычлар куялар. Ә кайчак хәтта детектив форма авторларның шушындый омтылышларын тормышка ашыру чарасына әверелә», — дигән фикер яза. Бу уңайдан әдибәнең детектив жанрда



язылган «Хөкем» повестенда ук, әдәбият белгече әйткәнчә, детектив форма кешеләргә хас сыйфатларны ачу өчен бирелә.

Әсәр: «Без барыбыз да — хөкемдарлар. Кешеләр турында үз хөкемебезне чыгарабыз, хәтта күп очракларда аларга лаек дип тапкан җәзаны да бирәбез», — дигән фәлсәфи фикер белән башлана. Беренче карашка, повестьта яшь тикшерүче Вәлидәнең үз эшенең остасы Җәүдәт Харисович белән бер җинаятьне ачу вакыйгасы сурәтләнә. Әсәрнең эчтәлеге бик гади. Ике тикшерүче җинаять булган җиргә киләләр. Мәетне, ул яткан урынны карап, барлык шаһитларны чакырып сораштыралар. Тикшерү эше шактый җайлы бара, күрше-күлән авыл советы председателе — фәкыйрь тормышлы Гадел Мөгыйнне гаепли. Вәлидә үзе дә моңа ышана, чөнки барлык күрсәтүләр, дәлилләр фаразны раслый. Инде эшне ябар вакыт та житте, гаепле дә табылды шикелле. Тик Җәүдәт Харисович эшне бөтенләй башка юнәлешкә бора һәм Мөгыйн Саттаровның монда катнашы юклыгын, үтерүченең күрше авылдагы Семёнов булуын дәлилли. Автор әсәрне шулай ук фәлсәфи фикерләр белән тәмамлый: «Хәтәр нәрсә ул — нахак шик. Бераүләргә йөз каралыгы, икенчеләргә йөз кызыллыгы китерә». Әсәр буена тикшерү эшләрен кызыксынып укыган укучы, үзе дә сизмәстән, белмичә, тәгаен дәлилләмичә кешене гаепләргә, ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ярамый, дигән фикергә килә. Гомумән, әсәрнең буеннан буена тикшерү эше ярдәмчел сюжет сызыгы ролен генә үти, төптәнрәк караганда, повестьның идея-эчтәлеге бөтенләй башкада булуы күренә. Әдибәнең бу отышлы алымы бөтен иҗаты буенча дәвам итә.

Гасырлар алышынган елларда, илдәге кискен үзгәрешләргә нисбәтле, Мәдинә Маликованың иҗаты да зур борылыш кичерде. Ул берничә елга каләмен куеп торып, «Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыяте»н оештырды һәм, аның җитәкчесе буларак, бар көчен авыр чорда мохтаҗлыкка дучар ителгән кешеләргә ярдәм итүгә багышлады. Бу игелекле эшчәнлек әдибәнең матбугатта басылып чыккан мәкаләләрендә ачык чагылыш тапты.

Шул рәвешле, М.Маликова иҗатының икенче чорын да, нәкъ беренче чоры кебек үк, публицистикадан башлады. 2001 елда дөнья күргән «Алтын ятьмә» китабына кертелгән «Кыргый дивизия» исемле юл хикәяләрендә безнең каршыбызда киң тормыш панорамасы ачыла. Анда без юлларның көйсезлегеннән, машиналарның туктаусыз ватылуыннан интеккән шофёрларның бик ачык образларын күрәбез. Җәмгыятьтәге тәртипсезлекләрнең шәхесне түбәнәйтүе, адәм баласының холкын-табигатен бозуы бирелә бик ачык күрсәтелгән. Бу «Берәгәйле бәрәңге» исемле хикәядә аеруча үтемле тасвирлана. Акча җитмәүдән тилмергән студент егетнең бәрәңге алып-сатып кесә калынайту турындагы хыяллары, моның өчен очраклы шофёрлар белән берләшүе, авылдан бурычка бәрәңге җыеп, машинага төяп озатуы һәм шофёрларның акча кайтарып бирүен көтеп утыруы кызганулы да, шаян да каләм белән язылган. Бу гыйбрәтле кыйссаны күз яшьләре аша елмаю белән укыйсың.

Шаян елмаю, нечкә юмор Мәдинә Маликова иҗатының икенче чорында язылган әсәрләрендә еш очрый һәм күңелне үзенчә жылыта. Шул ук китапка исем биргән «Алтын ятьмә» повесте ачы көлемсерәү аша язылган. Әсәрдә XX гасыр ахырында илдә барган кискен үзгәрешләрнең кеше язмышларын ничек имгәткәне тасвирлана. Аның төп герое Тәслимә — сәнгать кешесе, мәдәният йортындагы бию түгәрәгенең җитәкчесе. Илдә тәртип беткәч, мәдәният йорты бушап, анда эшләүчеләр иписез кала. Тәслимәнең ире Инсаф эшли торган завод та ябыла. Нишләргә? Ике баланың

тамагын ничек туйдырырга? Совет тәрбиясен нык сеңдергән, алып-сату шөгылен жинаятькә тин «спекуляция» дип санаган Инсаф бу мәсьәләне хәл итәргә сәләтсез. Гаилә өчен бөтен җаваплылык Тәслимә җилкәсенә төшә. Төркиядән кием-салым алып кайтып сату эшенә керешә ул. Морадына ирешә — гаилә мохтаҗлыктан чыга. Әмма авыр юллар, сәнгать кешесенең табигатенә каршы килә торган шөгыль анын тәнен дә, күңелен дә керләндерә. Нәтиҗәдә, гаилә таркала... Әсәр: «Эше бик тыгыз, тын алырга да вакыты юк, башы саннар, товарлар, планнар, хәйләләр белән тулы Тәслимәнең. Барысы да әйбәт. Төннәрен генә нигәдер бәгырьне сагыш талый. Яшьли сөйгән ярынын татлы сулышыннан эрегән чаклары исенә төшә. Нурга күмелгән сәхнә, биюче балалар төшенә кереп, үзәген өзә», — дип тәмамлана. Җәмгыять белән шәхес каршылыгы биредә менә шушындый төсмер ала. Шул чордагы күпме кешеләр башыннан кичте мондый хәлләр!

Бу елларда иҗат ителгән «Өермә» романынын башында: «...әсәрдә тасвирланган һәммә вакыйгалар һәм образлар баштанаяк уйлап чыгарылган», — дип куелган булса да, без анын автобиографик рухта язылганлыгын беләбез. Анда хәйрия җәмгыятенең төзелү тарихы, эшендәге авырлыклар һәм куанычлар бик тәфсилләп сурәтләнә.

Әсәр ташландык бер бинада шагыйрә Җәүһәриянең үле гәүдәсе табылудан башлана. Матбугатта Жанна Баянова тәхәллүсе астында русча шигырьләре чыгып килгән бу хатында кемнең үче бар да, анын үлеменнән ни файда?

Романда ике төп сюжет сызыгы бар. Беренчесе — үтерүчене эзләү, ягъни традицион детектив сюжет, икенчесе — хәйрия җәмгыятенең эшчәнлеге, мохтаҗларга ярдәм итү һәм үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучылар белән конфликт. Вакыйгалар төп өч персонаж — Җәүһәрия, Харис һәм Даниф тирәсендә кайный.

Харис белән Җәүһәрия арасында бик зур уртаклык бар: икесе дә сизгер күңелле, кешелекле, ихлас, максатчан, эшлекле. Шул ук вакытта аерма да зур: Җәүһәрия артык беркатлы, хыялый, ышанучан. Харис исә, төзелеш инженеры буларак, һәрнәрсәнен нигезенә карарга, тамырын актарырга, салкын акыл белән эш итәргә күнеккән. Монда ир-ат белән хатын-кыз арасындагы аермалык та сизелә.

Анын каравы, язучы Данифны каршылыклы итеп сурәтли. Бу образ аша М.Маликова чорга, заманга тәфсилле характеристика бирә. «Ул чакта «бизнес-план»нарны белен урынына пешерде Даниф. Анын «бөтенесе исәпләнгән-саналган» кооперативлары берничә иде. Кайдадыр ат үрчетеп, кымыз цехы ачып яталар. Кайдадыр умартачылык белән шөгыльләнәләр. Һәммәсенең планы расланган, барысына да кредит алынган. «Бизнесмен» исә үзенең кара «Тойота»сында, өч таза егет белән бергә, тегендә-монда ут капкандай чаба, машина эчендә әледән-әле телефон зынгылдый».

Әсәрдә М.Маликова илдә тәртипнең какшавы, әхлакый кыйммәтләрнең югалуы кешеләргә никадәр начар йогынты ясаганны ачып сала. Мохтаҗлык кешене яхшыртмый. Мисалга, ире ташлап чыгып киткән, тулай торакта өч баласы белән ялгыз калган Насибәне әйтергә мөмкин. Бер җыештыручынын хезмәт хакына дүрт тамакны ничек туйдырырга? Житмәүчелек шулхәтле үзәгенә үткән, кеше кулында акча күрсә, күзе кыза, тартып алудан чак тыелып кала Насибә. Анын үсмер кызы Лиананын үз фаҗигасе: тизрәк унсигезен тутырып, төнге клубта стриптизёрша булу турында хыялланып йөргән кызны хур иткәннәр, ул авырга узган...

Буыннар арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасы Насибә белән кызы Лиана каршылыгында ачыла.

Әмма заман нинди генә болгавыр, тормыш ничек кенә авыр булмасын, әсәр якты хис белән сугарылган: «Эссе көндә дә җиләс, иркен, тыныч, Кремль буйлап зәңгәрсу чыршылар ышыгыннан Спас капкасына таба барганда, туктап борылды да, каерылып, Сөембикә манарасына, анын очында очкынланып балкыган айга карады Харис. Аннары карашын президент сараенын түбәсе өстендә җилпенгән әләмгә төбәде. Ничә гасырлардан сон калыкты бу ай!.. Күпме гомерләрдән соң татарнын үз байрагы күтәрелде».

«Өермә» романы турында әдәбият галимәсе Д.Заһидуллина: «Гасырлар чигендә детектив әсәрләр язучылар күбәйде. Шулай да әлеге жанрда ин оста каләм иясе булып М.Маликова кала. Бу өлкәдә уңышлы булган «Өермә» романы үтерүчене эзләү

белән бәйле мавыктыргыч сюжеты, талантлы һәм саф күңелле романтик геройлары белән сокландыра. Шул ук вакытта постсовет чорына хас күп кенә сыйфатлар: матди байлыкларның рухи кыйммәтләрдән дә, кеше гомереннән дә өстен куелуы, хакыйкатьнең хәерчелек, җинаятьчелек, наркотиклар белән агулау шартларында яшәргә мәҗбүр ителүе, моның кемнәрнедер баету хисабына булуы һ.б. калку, язучының тәнкыйди мөнәсәбәтен күрсәтеп билгеләнә», — дигән фикерне әйтә.

Соңгы елларда язылган «Кызыл гөл» романында ике чор: бүгенге заман һәм шәхес культы чоры параллель сурәтләнә. Төп геройлар — Заһидә белән аның улы Мортаза аша ике буынның омтылышлары, күзаллаулары, максатлары чагыштырыла.

Заһидә — үз чорына хас булганча, комсомол тәрбиясе алган, бик тә дөрес әхлакый кануннарны сеңдергән хатын-кыз. Һәрвакыт намуслы булырга, нахакка рәнҗетелгәннәрне якларга, коллектив мәнфәгатьләрен үз гамьнәреннән өстен куярга омтыла. Болар бик яхшы, әлбәттә. Әмма тәрбия бер, совет җәмгыяте исә бөтенләй бүтән әхлакый нигезләргә корылган. Анда бер-берең артыннан шымчылык итү, икейөзлеләнү, дәүләт органнарына әләк язып, кешедән үч алу киң таралган. Студент кыз Заһидә боларны белми, белергә дә теләми. Нәтиҗәдә, беркатлылыгы, уйлап-уйлап тормыйча, фикерен ярып салуы аркасында очраклы рәвештә төрмәгә эләгә. Анда исә яшерен тикшерүләр алып баручы галимнәр, буталчыклык килеп чыгу аркасында, кызда яңа төр агу сыныйлар. Үлемнән аны яшь галим Вилен коткарып кала. Алар арасында мәхәббәт хисе кабына. Бу хис Заһидәнең бәхетсезлегенә китерә, сөйгәненнән ераклаштыру максатыннан, аны сөргенгә җибәрәләр. Фаҗига моның белән генә бетми, ана канына кергән агу тәнендә еллар буе саклана, баласына йогынты ясый — улы Мортазаның сәламәтлегенә зыян сала.

Мортаза әнисенең башыннан үткән хәлләрне, үзенең кимчелегенә китергән сәбәпләрне ачыкларга керешә. Күп кешеләр белән очрашып сөйләшә. Асылда алар берсе дә кеше газаплаудан тәм таба торган адәм актыклары түгел икән, бары тик дәүләт системасына хезмәт итәләр. Халык белән санашмыйча, аны фәкать үз мәнфәгатенә генә файдалануга корылган системаның аяусызлыгы, куркынычлыгы романда бөтен тирәнлеге белән ачылган. Дәүләт шәхес өченме, әллә кеше дәүләт өченме? Гасырлар буе күтәрелгән бу сораулар романда яңача яңгыраш ала. Система дигән олуг машинаны кинәт туктатып, яңасын кору җиңел түгел. Бу хакта тикшерүче Антон Никитич болай ди: «Әйе, шәхес культы фаш ителгән, Сталинны, Берияне хурлап күп сүзләр сөйләнгән. Ләкин системасы калган! Система шул ук, аңлыйсыңмы?! Системага берничек тә каршы торып булмый! Аннан гаделлек таләп итү карцерның бетон стенасын маңгаең белән ватарга маташу кебек ул!»

Романның геройлары бу каршылыкның серен ачарга тырышалар. «Адәм балалары булдырган система, аларның кулы белән ясалган һәм хәрәкәткә китерелә торган машина. Тик нишләп соң кешеләр файдасына гына эшләми? Нилектән ул Мортазаның әнисе кебекләрне эләктереп ала да изеп ыргыта?»

Әсәр җәмгыятьнең төзелешен кешелекле итеп үзгәртеп корырга өнди. Фаҗигале вакыйгалар тасвирлануга карамастан, ул бик якты тәмамлана: Мортаза үзенә пар ярны таба, сәламәтләнүенә дә ышаныч туа. Романның азагында мондый күренеш тасвирланган: «Ә мәхәббәт алласы, көлеп-шаярып, алтын угын төби, фонтан рәшәсендә салават күпере балкый, түтәлләрдә кызыл гөлләр керфекләрен ачкан, кояш гөлбакчаны, тынгысыз урамнарны — Иске шәһәрне дә, Яңа шәһәрне дә җылы нурга күмгән иде».

М.Маликованың күп әсәрләре безнең әдәбиятыбызга тема яңалыгы алып килгәнлеге алдарак әйтелгән иде инде. «Тылсым» романы да әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан яңалык буларак кабул ителде. Бу әсәрдә бүгенге көн өчен аерата мөһим, киләчәгебезнең ничек булачагын билгели торган мәсьәлә — шәхеснең рухи таянычы булуның зарурлыгы бик ачык мисалларда күрсәтелә. Барысына да ирешеп була: белем дә алырсың, һөнәргә дә ия булырсың, гаилә дә корырсың, балаң да туар. Әмма җаның тыныч булсын өчен, болар гына җитми — рухи таяныч, иман кирәк адәм баласына. Шул булмаса, бал-майда йөзеп яшәсәң дә, күңелең тынгы тапмас, ул булса — кайгы-хәсрәтләрне дә җинелрәк кичерерсең. Бу хакыйкать яшь пар — Лениза белән Мидхәтнең кавышу һәм аерылышу кыйссасы мисалында ачыла.



*Туфан Миңнуллин белән. 1986 ел.*

Лениза комсомолка әбисе кулында үскән. Аның рухын баетуны кайгыртучы булмаган. Институтта укыганда, ул Мидхәт белән таныша. Диплом алгач, алар Ерак Себергә китәләр, нәни кызлары Рамиләне (бу исем «тылсым, тылсымчы» дигән мәгънәне анлата) үстерәләр. Һәммәсе көйләнгән кебек. Әмма Ленизаның жаны тынгы тапмый. Бар уйлары ире Мидхәттә, аны югалтудан курка, һәр адымын күзәтә, юк-бардан көнләшә. Өйнен яме китә, Мидхәтнең кайтасы килми башлый. Ирне генә уйлап, аның ягыннан да шундый ук мөнәсәбәт таләп итеп яшәүнең читенлеген Лениза үзе дә аңлый, рухи таяныч эзләргә керешә. Мәчеткә барып карый — күнеле ятмый. Чиркәүгә керә — андагы мохит, андагы гамәлләр шулай ук ят тоела. Баштанаяк эшкә чумган Мидхәт хатынының уй-кичерешләрен аңламый, холыксызлануын авыр кичерә. Шул чакта Лениза сектантларга юлыга, алар исә, кеше жанын ауларга оста, бер килеп капканны ычкындырмыйлар. Тәмам башы әйләнгән Лениза кызын алып еракка, алар төзегән авылга китә. Моның ахыры зур фажига — Рамиләнең үлеме белән тәмамлана.

Газиз баласының каберенә килгәч, Мидхәт авыр уйларга чума. «Бу сабыйны дөньяга чакырганда, ул үз жаваплылыгын тоя идеме? Мидхәтнең күз алдыннан Рамиләнең бөтен гомере чагылып узды. Бу гомер анадан туган минуттан түгел, аннан шактый элегрәк башланды бит. Тулай торакта Лениза белән бергә үткәргән төннән... Юк, аннан да элегрәк, ул кызны үзенә артык якын китереп, анда яшерен өметләр уяткан айлардан... Уйладымы соң ул шул чакларда дөньяга киләчәк яңа жан турында?»

Бу әсәр өч яше дә тулмыйча дөнья куйган сабый турында, сюжет аның гомер жебе буйлап сузыла. Дөрес, ул әлегә мавыктыргыч вакыйгаларда катнаша алмый, аның яшәешен өлкәннәр хәл итә. Ә ничек яшәтteләр аны Мидхәт белән Лениза?.. «Нишләргә? Бәгырьне баскан бозлы кантарны ничек эретеп, сулышны ничек жиңеләйтергә? Бармы андый жылы сүзләр? Менә кайчан кирәк икән Аллага ышану, догалар белү... Мондый чакларда адәм баласына башка беркем дә ярдәм итә алмый, дога укудан башка бернинди гамәл дә жиңеллек китерә алмый...»

Алда аталган романнарда тормышыбызның һәркем өчен мөһим каршылыклары бөтен житдилеге белән куела, яшәешнең тирән тамырлары актарыла. Әдибәнең «Юкә чәчәк аткан чак иде» исемле романы алардан аерылып тора.

Романның беренче битләрендә «Шәфкать» романы белән аваздашлык бар: тегесендә дә, монысында да әле генә укуларын тәмамлаган яшьләр ант бирәләр. Әмма беренчесендә бу рәсми шартларда, үтә дә житди һәм тантаналы рәвештә башкарыла. Бусында исә дүрт егет — ике рәссам, бер шагыйрь һәм бер жырчы — әлеге гамәлне ярым шаярган кебек кылалар. Булган талантны, бар көчне сәнгатькә хезмәт итүгә, дөньяның матурлыгын башкаларга күрсәтүгә багышларга ант итәләр алар. «Матурлык яки үлем!.. Кешегә бирелгән талант — халык байлыгы ул. Хыянәтче яшәмәсен!»

Әсәр, гомумән, шаяруга корылган, аны «шаян роман» дип атарга булыр иде. Беренче жөмләләре үк шуны искәртә: «Дөнья шулай корылган инде ул: уены-чыны бергә. Бу очракта да һәммәсе яшьлек шаяруыннан башланды».

Егетләр ун елдан соң бергә жыелып, кемнең антына тугры калганын, кемнең сәнгатькә хыянәт итеп, дөнья малы артыннан чапканын ачыкларга сүз бирешәләр.



*Гаиләсе белән*

Төп вакыйгалар нәкъ менә шул антның үтәлешен тикшерер чак житкәч башлана да инде. Кемдер якты хыялларына тугры калган, кемдер читкә тайпылган. Берәү ижаты белән танылган, икенчесе тирә-якта яманаты чыккан «олигарх»ның йомышчысына әверелгән.

Әсәр үз эченә бик күпне сыйдырган: анда детектив сюжет сызыгы да, лирик күренешләр, мәхәббәт мажаралары да, фәлсәфи уйланулар да бар. Һәммәсе төп идеяне ачуга хезмәт итә: «дөнья матур — күрә белгәннәргә, яшәү рәхәт — тәмен белгәннәргә, хатын-кыз гүзәл — сөя белгәннәргә». Шигырьләр, кичәләр, рәссамнарның картиналары кешеләргә менә шуны аңлата.

Әсәр жанрлар кисешкән ноктадан торып ижат ителгән. Сюжеты кискен һәм төгәл, теле бай, рухы күтәренке. Ул гүяки рәссам палитрасындагы ачык буяулар белән язылган, аны ижат иткәндә, авторның йөзеннән елмаю китмәгәндер кебек тоела.

Әдибәнең соңгы елларда дөнья күргән «Арыш тәме» һәм «Көмеш билбау» романнары яратып кабул ителде. Татар әдәбиятында кешеләрнең авыр язмышка дучар ителүе турында күп язылды һәм языла, әмма талантларны үстермәү һәм юкка чыгару проблемасы күтәрелгән әсәрләр моңарчы булдымы? «Арыш тәме» романында халкының язмышын, аның бүгенгесен һәм киләчәген талантлы уллары һәм кызлары билгеләве ассызыклана.

«Көмеш билбау» романында мәхәббәт тарихының йомгагын сүтү криминаль вакыйгаларны ачыклау белән үрелеп бара. Бәхетле гаилә кору өчен гашыйк булу гына житәме?.. Хәзерге заман кешесе үзенә тиң пар табып, кавышып, гаиләсенә йомылып кына яши аламы? М.Маликова укучылары белән шушы фәлсәфи сорауларга жавап эзли. Кеше үз йортына гына бикләнеп яши алмый. Телиме-теләмиме, ул барыбер башкаларның язмышына, илнең киләчәгенә йогынты ясый. Без бер-беребезгә бик күп жепләр белән бәйләнгән. Жәмгыятьнең нинди булуы да беренче чиратта үзебездән тора. Романда бу фикер үз халкының иң изге омтылышлары дулкынында күтәрелеп, үз мәнфәгатен кайгыртып, исем казанучы кеше һәм милләтнең киләчәге өчен үзен корбан итәргә әзер фидакарь шәхеснең каршылыгы тасвирлану аша бик ачык әйтелә.

Әдибәнең XXI гасыр башында язылган повестьлары арасында иң киң яңгыраш тапканнары, мөгаен, «Югалган якутлар», «Мендем биек тауларга», «Чәчкә балы»дыр. Аларның беренчесе мажаралы жанрда язылган, шул ук вакытта бик житди проблеманы үзәккә куя — үз халкынның тамырларын белмәүнең, аларга битараф булуның шәхси фажигагә китерүен дәлилли.

«Мендем биек тауларга» исемле лирик повесть туган туфрагыннан аерылуның, үз нәсел агачыннан өзелеп төшеп, ялгыз калуның кеше шәхесен ваклавы, кечерәйтүе, изүе турында. Әсәрнең төп герое Рәшидә үсмер яшеннән шәһәргә укырга китә, шуннан әйләнеп кайтмый. Якында барып сыенырлык туган-тумачасы, кардәшыруы юк, чит-ят арасында житлегә, мәхәббәт хисе белән мавыгып кияүгә чыга. Әсәрдә халкының бер ятимәсе кебек яшәгән Рәшидәгә үз жирлегенә нык береккән, кардәшләренең кайгыртуын һәрдаим тоеп яшәүче, үз халкы белән горурланучы әрмән кызы Зара каршы куела. Бу проблемалар Рәшидәгә сонлап килгән көйдергеч мәхәббәт кыйссасы фонында күтәрелә.

«Чәчкә балы» повестенда хәзерге заман өчен аерата мөһим булган ата-аналар һәм үсмерләр проблемасы үзәккә куелган. Беренче карашка сюжет оеткысы татар әдәбияты өчен бөтенләй үк яңа түгел: бала тудыру йортында бер хатынның хәле начараеп китеп, ыгы-зыгы куба да, яңа туган ике сабыйны ялгыш буташтырып куялар. Әмма Мәдинә Маликова бу чуалган йомгакны үзенчә чишә. Рус кешесенә кияүгә чыккан Эльзаны бала белән Казан хастаханәсенә озаталар, Сәгъдиягә исә аның улын бирәп чыгаралар. Бу хата малайлар үсмер яшькә җиткәч кенә ачыклана.

Эльза белән Геннадийның улы бик зәгыйфь булып дөньяга килә. Анда тугач ук махмыр башлана, ул — эчүчелек корбаны. Малай нык булып үссен өчен, Сәгъдия белән Гамилгә бик күп тырышлык куярга туры килә. Автор бу әсәрдә эчүчелекнең бер гөнаһсыз балага никадәр зыян салуын ачык күрсәтә. Эчүче гаиләсендә үскән баланың психикасы бозылуын, аның бик тиз начар юлга кереп китүен, бер кергәч, тиз генә чыга алмавын, Геннадий гаиләсендә үскән Макар (Мохтар) мисалында тасвирлый. Малай, өендәге исерек әтисеннән туеп, урамда дуслар эзли, наркотиклар куллана башлый, хәтта кеше талауга кадәр барып җитә. Малайның үз гаиләсе табылып, ул шунда яши башлагач кына тормышы көйләнә. М.Маликова бер-беренә ихлас мөнәсәбәт, чын мәхәббәт нигезендә төзелгән, әхлак нормаларына буйсынган гаиләдә сәламәт яшь буынның үсеп җитлегүен исбат итә.

Балаларның алышынганлыгы беленгәч, ике гаилә дә хафага төшә. Нишләргә? Малайларны кире ничек алыштырырга? Үз канынны бөтенләй ят кулларда калдырып булмый бит инде. Бигрәк тә Сәгъдия белән Гамил өчен бу һич мөмкин түгел! Ярый, алып та кайттың, ди. Аны ничек игә китереп, тәртипкә өйрәтергә, яман гадәтеннән ничек биздерергә? Җәмилне дә эчүче кулына биреп җибәреп булмый, ул да бәгырь пәрәсе, Сәгъдиянең күкрәк сөтен имгән бала...

Авыр хәлдән чыгу юлларын ахырда үсмер малайлар үзләре таба. Балаларны мондый ситуациядә үзәккә кую — язучының зур табышы булып тора.

М.Маликова әсәрләрендә күп төрле темалар күтәрелә. Ул замандашларыбызны рухи яктан ачып, хисләр каршылыгын, югалту һәм табуларын үз күңеле, үз җаны аша үткәреп иҗат итә. Әдибә әсәрләрендә шәхес белән җәмгыять арасында булган һәм яңа туган каршылыкларны күрсәтә, җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең шәхескә йогынтысын ачып сала. Кешелек дөньясындагы мәңгелек кыйммәтләр иҗтимагый-социаль тирәлек белән бәйләнешләрдә, геройларның шәхси дөньясын өйрәнү аша күрсәтелә. XX йөзнең икенче яртысында һәм яңа гасыр башында татар прозасына М.Маликова алып килгән яңалыклар сүз сәнгатебезнең үсешенә уңай йогынты ясый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, М.Маликованың дөньяга киң карашлы булуы, иҗтимагый һәм рухи актив тормыш белән яшәве аның бөтен иҗатына тирән эз сала. Ул, язучы буларак, чорның актуаль мәсьәләләрен, өлгергән проблемаларын таба, мавыктыргыч сюжет һәм истә калырлык образлар ярдәмендә җәмәгатьчелекнең игътибарын шуларга юнәлтә белә. Бу иҗат образларының бай галереясе, кеше — мохит — чор бәйләнеше, стиленең төрле сурәтләү чараларына бай булуы белән дә әдәбиятыбызның кыйммәтле бер өлеше булып тора.

**Лилия ХИСМӘТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# «ДАЛАДАН КИЛҮЧЕ» ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА БЕР-ИКЕ СҮЗ

Хикәяләрдән, басылган кыйссалардан, бәяннардан мин нәрсә эзлим соң? Әлбәттә, үзенчәлекләре белән үз зәвыкыма ошаганнарын. Минем зәвыкыма нинди әсәрләр тәңгәл килә?

Иң беренче — Ана телебездә язылган затлы әсәрләр миңа ошый. Теле бозык икән, теле урысчадан туры күчермә икән, әсәр урысча уйлап, татарча язарга маташучы кулы белән язылган икән, никадәр генә мавыктыргыч шәкелдә язылган булуына карамастан, мин ул әсәрне укымыйм. Ана телебезне бозучы әсәрләр — Ана телебез эченә куелган һәм киләчәктә шартлаячак бомба. Жырчының тавышы никадәр саф-матур булса да, шул җырчы сүзләрне дөрес әйтми икән, мин ул җырлаучыны җырчыга да санамыйм. Аның концертларына йөрмим.

Әсәр корама телдә язылган икән, ул инде «әдәби» атамасын йөртә алмый.

Икенче — әсәрдәге серлелек. Тарихилык, холыкларның тулы канлы, ышандырырлык итеп сурәтләнүе, әсәрнең без көткәнчә (штамп белән) түгел, үзенчәлекле тәмамлануы, сатирик әсәрләрнең ахырда көлке чыганагына әверелүе.

Өченче — авторның әйтергә теләгән фикере, әсәрнең эченә салынган серле максаты. Максат (идея) төртеп торса, укучыга кире тәэсир дә ясавы ихтимал. Яхшы бул, тәүфыйклы бул, дип кенә язучы адәмнәрне үз артыннан ияртә алмастыр.

Озын сүзнең кыскасы, мин «Казан утлары»ның 1915 елгы 7нче санында күңелемә хуш килердәй бер хикәягә тап булдым, хикәя беренче җөмләсеннән үк үзенең кармавычлары белән сине урап ала.

«Ул нидер исенә төшергәндәй, барган жиреннән кинәт туктап калды... Зур итеп ачылган күзләрендә аптырау, курку, сискәнү иде».

Кунакханә нумирларының бер бүлмәсендә гүзәл кыз Хәдичәне атып үтергәннәре турындагы романның башы, «Фәхрине үтереп ташладылар» кебек классик башлангычлардан бер дә ким түгел.

Кеше (Юлаучы) ни өчен кинәт туктый, ни сәбәпле аның күзләре зур ачылган, ни өчен юлаучы курыккан, сискәнгән?

Бу сөальләргә җавап табар өчен, хикәяне алга таба укырга ихтыяри мәҗбүр булабыз.

Без ерак юлларга йөрүче, ярдәмчел шофёр белән дә, Яңа елга әзерләнүче бәхетле ата-ана, аларның бәхетле кызы белән дә очрашабыз, аларның бәхетле кызлары акчасыз юлаучыга Яңа ел бүләге тапшырганын да күрәбез. Юлаучы көнчел түгел, ул байларны каргамый, ул бәхетле ата-анага, аларның бәхетле кызларына карап соклана, аларны ярата башлый. Аның яратуын күңеле белән сизенеп, сабый кыз, аңа кыйммәтле бүләк суза. Менә сиңа сөенеч! Юлаучы Яңа ел кичендә үзенең кызына да кыйммәтле бүләк, нәфис-гүзәл курчак соначак. Аның гаиләсендә дә кечтеки генә сөенеч булачак. Шул куаныч белән өенә кайтканда, Юлаучы машина кырылышының шаһите булыр, аның кызына матур курчак бүләк иткән бәхетле гаилә юл казасында үз машиналарында янып һәлак булыр.

Юлаучы кадерле бүләкне күкрәгенә кыскан килеш шашып калыр, ул зиһенен югалтыр, ул кая барганын белмәс дәрәҗәдә тетрәнгән булыр, һәм аны юлбасарлар талар, кыйнап киемнәрен салдырыр, кулындагы курчак салынган тартманы таптап изәр. Рәхимсез талаучы ватык курчакны тотып бер якка томырыр, ботарланган

курчак изелсә дә, үзен имгәтүче юлбасарга тигез тешләрен күрсәтеп елмаеп ятып калыр.

Социаль гаделсезлек (кешегә Яна ел алдыннан да тиешле хезмәт хакын бирмәүләре), урамда да кансыз-рәхимсез хәтәр малайлар мохитендә кеше бөтенләй югалып кала. Әсәргә ялгыз бер кешенең генә тәкъдире түгел, аче язмышлы, хаста җәмгыятьнең фаҗигасе дә тупланган.

Бу хикәяне экзистенциализм әдәби агымына да кертеп булыр иде. «Экзистенциализм ул — төшенке рухлы буржуаз идеализмының бер төре», — дип аңлаталар әдәбият белгечләре. Шәриф Камалның «Уяну», «Буранда» хикәяләрен, Һади Такташның, Сәгыйть Рәминең, Сәгыйть Сүнчәләйнең кайбер шигырьләрен шушы «экзистенциализм» бизмәненә салып үлчәп булыр иде.

Әлеге каләм иясе: мин «экзистенция»ләләрчә хикәя языйм әле, дип эш башламагандыр, күрәсең. Ләкин автор бу өлкәдә мәгълүматсыз түгел.

Шушы җиде битлек хикәя романнарына торырлык әдәби кыйтга булып чыккан. Әсәрдәге язмышлар хәл итә әсәрнең язмышын. Анда тетрәндергеч тәкъдирләр, фаҗигаләр тезмәсе тасвирлана. Әсәрнең язмышын аның теле хәл итә. Рәмзия ханымның язма теле тәэсирле, сурәтле. Ару Ана телебездә иҗат ителгән шундый әсәрләр укучыны куандыра. Язучы өчен ихлас күңелдән сөенәсең. Аларны укуы үзе бер рәхәтият!

Бу хикәя «Даладан килүче» дип аталган. Ул язучы Рәмзия Габделхакова каләменнән өзелеп төшкән.

Бәлки бу хикәя Рәзмия ханым иҗатында очраклы гына пәйда булгандыр?

Шул ук санда аның тагын ике әсәре урын алган: «Мөгез», «Янгырдан соң» исемле хикәяләре. Юк! «Даладан килүче» язучының иҗатында очраклы гына түгел. Әлеге хикәяләр дә сюжет корылышы ягыннан да, теле ягыннан да Рәмзия ханымның иҗат эшчәнлегенә ят әсәр түгел.

Аннан соң Рәмзия Габделхакова инде иҗат эшендә шактый тәҗрибә туплаган язучы. Ул үз ысулын, үз алымын югалтмасын иде һәм ана шушы шәкелдә тагын-тагын да күп язарга кирәк. Язучыда адәмнәрнең рухи дөньясына тагын да тирәнрәк төшәргә омтылыш куәтле булырга тиеш.

Сезгә янадан-яна уңышлар телим, Рәмзия ханым!


**Рабит БАТУЛЛА**
*2015, 7 июль*

***Хата төзәтү***

*8нче санның 122нче битендәге «Башыннан азагына кадәр туктаусыз елап утырганым, «Син бит минем бер генәм»... җөмләсен, хата китү сәбәпле, «Башыннан азагына кадәр туктаусыз елап утырганым, «Эзләдем, бәгърем, сине»... дип укырга.*

# ТАРИХ БУЛЫП ДӘШӘ ЧУРА БАТЫР...

Халыкның киң кырлы эпик иҗатын аның бай тарихыннан, әдәби-мәдәни бәйләнешләреннән аерып карау мөмкин түгел. Фольклорда героик эпос яисә тарихи дастан дип аталган жанр реаль вакыйгалар җирлегендә барлыкка килә, иҗат мәйданына тарихи шәхес образын чыгара. Әлбәттә, эпос-дастаннар чынбарлык вакыйгаларының күчермәсе түгел. Вакытларны кичкәндә, төрле үзгәрешләр кичергән мондый ядкарьләр кайвакыт тарих тирәнлегеннән яңгыраган авазның үзенчәлекле аһәненә әверелгән булырга да мөмкин. Әмма эпоска, бигрәк тә героик эпоска, чорлар кайтавазы сеңми кала алмый. Иң беренче чиратта, нәкъ менә шуның белән җәлеп итә дә инде бу гаҗәеп истәлекләр.




Тамыры белән уртак нигезгә барып тоташучы кардәш халыклар иҗатында берсенә генә нисбәтләп булмый торган, бер үк вакытта берничә төрки халыкның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итә торган дастаннар бар. Чура батыр исеме белән бәйле эпос — әнә шундый истәлекләрдән. Әлеге дастаннарның казан, кырым татарлары, нугай, казакъ, башкорт, каракалпак һәм кыргыз халыкларының эпик иҗатында киң таралган булуының сере әлеге дә баягы тарихка барып тоташа. Уртак сюжетлы «Чура батыр» дастаннары, кайсы халыкның нинди генә варианты булуына карамастан, күпчелек очракта Идел буендагы Казан шәһәренең рус дәүләте тарафыннан яулап алыну вакыйгалары, шушы чор шәхесләре хакында бәян итә. Ә Казан шәһәре, мәгълүм булганча, 1552 елда яулап алынган, димәк, барлыкка килүе белән Чура батыр турындагы бу мәшһүр сюжет тәгаен XVI йөз уртасыннан соңгы чорга карый. Дастанның нәкъ менә югарыда санап үтелгән төркиләрдә популярлыгы исә — заманында Алтын Урда дәүләте составындагы халыкларның уртак рухи ихтыяҗларының, бердәм теләк-идеяләренең бер дастанда гәүдәләнгән чагылышы.

Чура образының төрки халыклар иҗатында популярлыгына галимнәр XX йөзнең 40нчы елларыннан алып игътибар итә киләләр. А.С.Орлов (1945), В.М.Жирмунский (1974), Х.Б.Паксой (1986), А.И.М.Сикалиев-Шейхалиев (1994), Д.Ф.Исхаков (1994), Ф.И.Урманчеев (1995), Л.Х.Ибраһимова (2000, 2002), М.Х.Бакиров (2012) кебек тарихчы-эпос белгечләренең бу мәсьәләгә багышланган, төрле елларда дөнья күргән хезмәтләре бар.

2014 елда шушы ук темага фольклорчы галим Болат Сагынбекулы Корганбековның казакъ телендә «Шора батыр» эпосы: нөсхәләре, генезисы, тарихилыгы» *[Корганбеков, 2014]* дигән өр-яңа саллы монографиясе басылып чыкты. Уртак мираска карата гаять дәрәҗәдә әтрафлы игътибар күрсәткән бу хезмәт Чура батыр турындагы моңа кадәрге монографияләрне һич кенә дә кабатламавы, киң масштаблы һәм бай

фәнни эчтәлеге, тирән теоретик нигезе, әле дә халык телендә булган «тере» эпик мисалларга таянуы белән кин колачлы тикшеренү дигән тәэсир калдыра.

Узган ел азагында дастаннар остасы атаклы Морын жырау Сенгирбек улының 155 еллыгы уңаеннан Казакъстанда үткәрелгән «Ногайлы эпосы һәм Морын жырау феномены» дип аталган халыкара конференциягә чакырылып, кин дала һәм тирән диңгез очрашкан гаҗәеп урындагы Актау каласында казакъ һәм нугай жырауларының Чура батырга һ.б. темаларга багышланган эпосны бүгенге көндә дә телдән башкаруларын үз колакларым белән ишетеп һәм үз күзләрем белән күреп кайту бәхете насыйп булды миңа. Бирелә эпосның импровизатор тарафыннан әйтелә торган традицион төренык үсеш алган, казакъ һәм нугайлар әдәби-мәдәни байлыкка гаять дәрәҗәдә игътибарлы, алай гына да түгел, думбра чиртеп жыру әйтү – кардәшләребезнең табигый халәте, бу эшне башкара алмаган берәр казакъ бар микән ул, дигән сорау да туды миндә хәтта. Шул ук Чура батырга яисә Гөроглына багышланган дастанны жырау ниндидер бер экстаз халәтендә тоташтан әйтә дә әйтә, әйтә дә әйтә. Жырау авазына ияреп, актарылып, әйтерсең, тарих үзе кире кайта... Шунысы игътибарны аеруча җәлеп итте: Казакъстанда эпос әйтү сәнгате махсус колледжларда аерым сабак буларак та укытыла икән. Яшь буын әлгәрләре хакында буыннан-буынга килә торган фольклор әсәрләрен ишетеп тә белә, шул дастанны үзе дә көйләп-әйтеп бирә. Онытылган, кайдадыр еракта торып калган шөгыль түгел бирелә жыру-эпос әйтү, ә көнел таләбе, рухи ихтыяҗ. 2013 елда, шулай ук халыкара конференциядә, Якутск шәһәрендә саха-якутлар белән аралашу нәтиҗәсендә, төньякта яшәүче төрки туганнарыбызның үз телләренә, мәдәниятенә, тарихына, эпик иҗаты – олонхоларына булган житди мөнәсәбәтен күреп тәэсирләнеп кайткан булсам, узган ел азагында Актауга сәфәрем минем казакъ кардәшләребезгә булган ихтирамымны бик нык үстерде. Эпос – ул халык тормышын эпик планда тасвирлый торган күләмле әсәр, шушы иҗатка булган мөнәсәбәте халыкның тулаем милли йөзен билгеләүдә катнаша торган зур бер фактор лабаса... Болат Корганбековның төрки «Чура батыр» дастанына багышланган яңа монографиясе дә эпоска карата шушы җылы мөнәсәбәтнең күркәм чагылышы.

Болат Корганбеков – казакъ халкының эпик фольклорын өйрәнүне төп фәнни юнәлеше итеп алган тәҗрибәле белгеч, филология фәннәре кандидаты. Әлеге монография Болатның беренче иҗат җимеше түгел, аның Әхмәт Ясәви һәм казакъ фольклорына багышланган монографиясе (2011, 2012) дөнья күргән, ул берничә коллектив монография, сигез дистәдән артык фәнни мәкалә авторы, күпсанлы жыентыклар, күптомлыклар төзүче дә. Хезмәтләренең барысы да казакъ халык иҗаты өлкәсенә, дастаннарга багышланган, кайбер мәкаләләре инглиз, төрек, рус, үзбәк телләрендә дөнья күргән. Болат 1990 елда Алма-Атада С.М.Киров исемендәге Казакъ дәүләт университетын тәмамлаган, кандидатлык диссертациясен уңышлы яклап, соңгы елларда докторлык диссертациясе әзерләгән, бүгенге көндә Казакъстанның Жетысай шәһәрендәге «Сырдария» университетының казакъ теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты. Казакъ халкының үз эпик мирасына зур ихтирам һәм игътибар шартларында тәрбияләнеп, озак еллардан бирле милли идеология юнәлешендә эшләп килә торган кафедра белән язмышын бәйләгән Болатның төрки «Чура батыр» белән житди кызыксынуы, әлеге мәшһүр эпосны барлык нөсхаләре, килеп чыгышы, тарихилыгы җәһәтеннән ныклап өйрәнергә керешүе һәм әлеге темага кин колачлы хезмәт башкарып, аны китап рәвешендә дөньяга чыгаруы һич кенә дә гаҗәп түгел, ә гаять тә көтелгән, табигый нәтиҗә.

Төрки «Чура батыр» – фәнни, тарихи, иҗтимагый, тәрбияви, мәдәни әһәмияте ягыннан гомумкешелек мирасы булырлык, дөнья эпосына торырлык рухи байлык. Бу бөек ядкарьнең дәрәҗәсен ачыклап, аның хакында зур тикшеренү эшләү – төрки дөнья өчен дә, гомумән, фәндә эпос өлкәсе өчен дә һәрвакыт гаять актуаль мәсьәлә, шуңа күрә казакъ кардәшләребез вәкиле Болат Корганбековның әлеге юнәлештәге эшчәнлеге бик зур мактауга лаек.

Үзенең күркәм тышлыгы белән үк игътибарны җәлеп итеп тора торган зур күләмле, фәнни аппараты камил

бу затлы китап Астанада дөнья күргән. Тиражы – 2000 данә. Монография Казакъстанның Жетысай шәһәрендәге «Сырдария» университеты һәм Алматыдагы М.Ауэзов исемендәге Әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми советлары карары белән чыгарылган.

Автор Чура батыр тирәсендә барган бетмәс-төкәнмәс сорауларны мантыйкый эзлеклелектә кабат мәйданга чыгара, тарихи чынбарлык белән эпик чынбарлык арасындагы бәйләнешләрне барлый, Чура батыр һәм аңа бәйле вакыйгалар турында бәхәсле мәсьәләләргә фәнни чишелеш тәкъдим итә. Чура батырга багышланган эпик истәлекләрдән нугай, кырымтатар, башкорт, казакъ, каракалпак, кыргыз халыкларында табылган 25 вариантын чагыштырып анализ ясый, дастан вакыйгалары, образ-персонажлар системасы белән тарихи чынбарлык арасында параллельләр үткәрә.

Монографиянең кушымтасы итеп бирелгән өлеше турында аерым әйтеп китү таләп ителә. Автор төрле халыкларның Чура батырга багышланган 25 варианттагы дастаннарын, шартлы билгеләр аша таблицага куеп, сюжетларындагы эрелеваклы вакыйгаларның, теге йә бу эпизодның очравы-очрамавыннан, билгеле эпик мотивларның булу-булмавыннан чыгып, чагыштырып чыккан. Дастан вариантларын әлеге яссылыкта карау – күп вакытны таләп итә торган гаять четерекле вак эш. Шушы таблица үзе генә дә галимнең дастан нөсхәләренең һәркайсына житди мөнәсәбәтен, аның дастан сюжетында булган һәр детальне нечкәләп белүен күрсәтә торган дәлил. Әлеге таблица Чураның атасы Нарыкның ятим үсүеннән алып, Шора үлгәннең соңында анасы, Казанга улын эзләп килеп, сыктау әйтүенә кадәрге – барлыгы 45 сюжет сызыгын үз эченә алган, автор игътибарына алынган барлык 25 вариантта, шул исәптән татар халкының ике вариантында, әлеге вакыйгаларның чагылыш кимәле эзлекле ачыкланган. Бу әһәмиятле эшне автор күп кенә төрки вариантларга карата җиренә житкереп эшләгән.

Әмма күңелне тырнап торган бер нечкәлек хакында да әйтеп китми ярамый. Темасы, сюжеты ягыннан татар «Чура батыр»ының шактый үзенчәлекләргә бай булуы, аның реаль вакыйгаларга да иң якын торган версия икәнлеге мәгълүм *[Ибраһимова, 2002]*. Бу аңлашыла да: Казан ханлыгының Мәскәүгә көчләп буйсындырылуы, иң беренче нәүбәттә, татар халкы өчен зур фаҗига булган бит. Казан алынганнан соң барлыкка килгән эпоста да бу моментка игътибар ителми калынмаган, әлбәттә. Шуңа күрә дә «Чура батыр»ның татар варианты берберсенә тирән керешкән ике зур теманы яктырта, алар – каһарман Чура язмышы һәм Казан җимерелү вакыйгасы. Шул ук вакытта бу әсәр, татар ханлыкларының бер-бер артлы рус дәүләте тарафыннан буйсындырылу фактын искәртеп, теманы тагын да киңәйтә. Б.Корганбеков төзегән чагыштырма таблицада гаять әһәмиятле әлеге вакыйгага ни өчендер урын бирелмәгән. Дастанның татар варианты мондый сүзләр белән тәмамлана: «Соңра урыс гаскәре галиб булып (өстенлек алып. – *Л.М.*), Казан шәһәрен алды. Урыс падишаһына табигъ булдылар (буйсындылар. – Л.М.). Бу Казан шәһәрен алганнан бер ел соңра Хаҗитархан шәһәрен янә алды. Чура батырның хикәяте тәмам булды» *[Татар..., 1984, Б.119]*. Дастанның тарихи чынбарлыкны чагылдыруы җәһәтеннән бик тә мөһим булган әлеге юлларга Б.Корганбеков монографиясендә артык игътибар бирелмәгәне күренә, ә инде кушымта-таблицада бу вакыйганың бөтенләй төшереп калдырылуы гаделсезлек булып аңлашыла. Югыйсә, татар халкының эпик иҗатында Чура батыр образына багышланган әсәрләрнең барысында да – китаби дастанмы ул, бәет, риваять, кечкенә хикәятме, йә булмаса шушы ук теманың соңгырак чор иҗатка караган язма характердагы дәвамымы – барысының да умыртка баганасы булып, иң беренче чиратта, нәкъ менә шушы тарихи вакыйгалар тора.

Хәер, бирелә «Чура батыр» дастаннарының башка халык вариантларында татар язмышына кагылышлы фаҗигаләрнең вакыт үткән саен онытыла төшкән, казакъ «Шора батыр»ының каһарман язмышын Казан ханлыгы вакыйгалары белән бәйләүдән читкәрәк тайпылган булуы үз ролен уйнаган булса кирәк. Б.Корганбеков элек язып алынган вариантлардан алып соңгы чор жыраулары авызыннан язылган вариантлар белән эш итә, төрки вариантларның күпчеле-

гендә зур әһәмият бирелгән вакыйгалар картинасын, образлар гәүдәләнешен ача, Чура батырга багышланган эпос генезисының вакыт чикләрен б.э.к.ге чорларга ук бәйләп, тирәнәйтә. Әлбәттә, дастан вариантларында очрый торган кайбер мотивлар яисә конкрет сарыннар килеп чыгышының бик борынгы чорларга ук барып тоташуы, аларның XVI йөз урталарына кадәр үк күп алда эпик кулланылышта булуы автор тарафыннан нигезле аңлатылган. Чыннан да, хронологик һәм географик яктан Казаннан ераграк торган саен, «Чура батыр»ның төрки версияләрендә татар вариантыннан аерылып торган үзенчәлекләрнең күбрәк очравын таныргa тиешбез. Шул ук вакытта бик борынгы, хәтта Казан ханлыгындагы трагик вакыйгаларга кадәр үк барлыкка килгән эпосның татар дастанында Казанга якынайтыбрак сурәтләнгән булу ихтималын да инкарь итмибез. Тик шулай да дастанның татар версиясендә дә, кырымтатар, нугай һәм казакъ версиясе вариантларында да дастан вакыйгаларында Идел буе Казан шәһәренә мөнәсәбәтен кире кагып булмый торган фактлар бик күп һәм аларны очраклылык дип кенә бәяләү дә гаделсезлек булыр иде.

Ничек кенә булмасын, Чура батырга багышланган эпос – тарихыбызның кыйммәтле бер кыйпылчыгы, үткәннәребезнең онытылмас кайтавазы, Чура батыр образы үзе исә – фольклорда төрки халыкларның үзара якынлыгын, туганлыгын һәрвакыт искәртеп тора торган героик образ.

Монографиядә тема 9 бүлеккә аерып тикшерелгән, һәр бүлектә үтә дә әһәмиятле проблема алга чыгарылган. Бүлекләрдә автор әйткән фикерләр гаять колачлы. Авторның тикшеренү ысуллары отышлы, әйткәне төпле, бәян кылу алымнары мавыктыргыч. Фактик материал куллану ягыннан Чура батырга багышланган мона кадәр билгеле хезмәтләр арасында Болатның монографиясе, шиксез, иң бай хезмәт. Файдаланылган әдәбият исемлегенең тулылыгы да авторның бик мәгълүматлы шәхес булуы хакында сөйли. Китап җиңел укыла, нәтиҗәләр, кайвакыт бәхәс уятсалар да, ышандыра.

Йомгак ясап әйткәндә, Чура батырга багышланган төрки эпик иҗатка казакъ галиме Б.Корганбеков биргән игътибар бик вакытлы һәм урынлы. Болат Корганбеков монографиясе теманы һәм материалны яратып, тирән теоретик әзерлек белән язылган төзек структуралы җитди хезмәт буларак күңелне куандыра. Төрки «Чура батыр»ны шушындый юнәлештә тикшерү һәм аның нәтиҗәсе буларак әлеге китапның басылып чыгуы – казакъ халык иҗаты өчен генә түгел, гомумән, төрки халыклар фольклористикасында, эпос-дастаннарны өйрәнү өлкәсендә бик зур казаныш.

**Әдәбият**

1. Ибраһимова Л.Х. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. – Казан: Фикер, 2002. – 190 б.

2. Корганбеков Б.С. «Шора батыр»: нускалары, генезисы, тарихилыгы. Монография. – Астана: Фолиант, 2014. – 304 б.

3. Татар халык иҗаты. Дастаннар. Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр язучы Ф.В.Әхмәтова. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1984. – 380 б.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ТАТАР МУЗЫКАСЫН ЯҢАРТУЧЫ

## АЛМАЗ МОНАСЫЙПОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ



XX гасырның 1960-1980 еллары татар музыка сәнгатендә яңа тенденцияләр белән билгеләнә. Ул үткәндәге һәм хәзерге көндәге тискәре якларны күрсәтә алу, иҗатта кайбер ирек мөмкинлекләре ачылу, илдәге сәяси климат җылыну белән бәйле. Музыкаль әсәрләр тәэсирлегенең һәм эчтәлек үзгәрүенең тагын бер сәбәбе — чаралар арсеналын тамырыннан яңарткан электрон-компьютер музыкасы, алеаторика, сонористика, серияләр, додекафонияләрдән торган яңа техниканың милли республикаларга үтеп керүе.

1960-1980 елларда, консерваториянең композиция кафедрасы мөдире, танылган музыкант, теория белгече һәм композитор Альберт Леман җитәкчелегендә, заманча ысул-чаралар белән коралланып, яңа идеяләргә омтылган бер буын үсеп чыга. Ә.Бакиров, Х.Вәлиуллин, Ф.Әхмәтов, Б.Мөлеков, А.Монасыйпов, Р.Еникеев, М.Яруллин, Р.Билалов кебек яңа исемнәр таныла башлый. Ә инде атаклы дирижёр Натан Рахлин җитәкчелегендә 1967 елда симфоник оркестр оешу нәтиҗәсендә, татар композиторларына симфония өлкәсендәге талантларын күрсәтергә дә мөмкинлек туа. Шул вакытта Н.Җиһанов, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов һ.б. бик күпләрнең симфонияләре дөнья күрә дә инде. Шактый санда камера-инструменталь музыканы башкаручылар да өлгереп җитә. Бу чорда иҗат ителгән әсәрләргә, нигездә, чынбарлыкны фәлсәфи күзлектән тасвирлау һәм замандашлар образына мөрәҗәгать итү хас.

Нәтиҗәдә, татар музыкасы тарихында алдагы дистәләгән еллар театр музыкасын эшкәртү белән бәйле булса, 60-80нче елларда күбрәк симфония һәм камера-инструменталь музыка жанрлары үсеш ала. Композиторларның стиль юнәлешләре күп төрле. Элегрәк стиль юнәлешләре дистәләгән еллардан соң алышынсалар, хәзер бер үк вакытта берничә стиль яшәргә, ул гына да түгел, шул бер үк композитор иҗатында берничә стильне бер үк вакытта янәшә кулланырга мөмкин.

Милли композиторларның яшь буыны арасында бу чорда иң күзгә ташланган вәкиле итеп Алмаз Закир улы Монасыйповны атарга кирәктер. 1925 елда Казанда туган егет башта музыка мәктәбендә, аннан соң музыка училищесында белем ала; консерваторияне өч мәртәбә тәмамлый: 1950 елда — виолончельдә уйнаучы буларак, 1956 елда — композитор буларак һәм 1962 елда — дирижёр белгечлеге буенча. Композитор опера театрында дирижёрлык вазифасын үти, берничә ел консерваториядә композиция дәресләрен алып бара. 1972 елда Мәскәүгә китеп, анда урнашып, күп кенә әсәрләр иҗат итә. Нәтиҗәдә, ул 60-80нче елларда үзе артыннан зур бер төркем яшь иҗатчыларга юл ярган иң танылган шәхес була.

А.Монасыйпов иҗаты консерваториядә — 1950-1960 уку елларында ук башланып китә, нигездә, бу чорда ул романслар һәм җырлар язу белән мавыга. «Башкалардан нәрсә белән аерылып тора?» дигән сорау куйсак, монарчы татарларда күренмәгән джаз ритмнарында һәм чалымнарында, дип әйтү дөрес булыр. Моның сәбәбе дә ачык: 1948 елда Казанга Шанхайдан джаз уйнаучы О.Лундстрем оркестры кайта һәм төпләнеп

кала. Алар еш кына концертлар бирәләр. Боларга мөкиббән киткән А.Монасыйпов үзе дә оркестрда уйный, бертуган Олег һәм Игорь Лундстремнар белән булган дуслыгы озакка сузыла, аларның Мәскәүдә яшәгәндә дә дуслык җепләре өзелми. Джаз тәэсире (дулкынлы интонация, бәрмә тембрларның муллыгы, синкопалы ритмнар һәм диссонанс гармония) А.Монасыйпов иҗатында моннан соң да шактый сизелеп тора. А.Монасыйповны татар милли музыкаль эстраданы башлап җибәрүче дип атарга хакыбыз бар, аның юнәлешен Р.Билалов, Р.Еникеев, Р.Кәлимуллин, Р.Ахиярова, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Болгарилар үзләренең иҗатлары белән дәвам итәләр.

Музыка җәмәгатьчелеген аның «Виолончель өчен романс», «Скрипка һәм фортепиано өчен соната» кебек әсәрләре җәлеп итә. Биредә ул Р.Яхинның романтик традицияләрен үстерә, чөнки аларда — шул ук хисләр муллыгы, ярылып яткан тойгылылык, эмоцияләр өстенлеге. Композиторның «Балет сюитасы» (ул «Шомбай» балеты өчен язылган була, әмма сәхнәгә барып җитми) — беренче чор белән икенчесе арасындарак туган әсәр. Биредә композиторның эзләнүләре икегә аерыла кебек. Әгәр беренче бүлекләрендә ул романтик традицияне дәвам итсә, соңгыларында XX гасырга хас арттырып күпертелгән, экспрессив образларга өстенлек бирә.

Композиторның өлгереп җиткән чоры 70-80нче елларда иҗат ителгән 4 симфония белән сыйфатлана. Боларда элеккеге хисләнеккә, йомшак яңгырашка урын калмаган, авторның үзенчәлекле стиле формалашып җиткәнлеге тоела. Образлар кырыслык һәм кырлылык белән аерылалар. Бу инде тормышны үзенчә күрү — симфонияләрдә аны борчыган проблемалар күтәрелә. Шунысы дикъкатьне җәлеп итә: аның әсәрләрен башкарган саен, музыка җәмәгатьчелеге йә аптырашта кала, йә кискен тәнкыйтькә күчә. Бик аз кеше аны татар музыкасы тарихының яңа бер чорын башлаучы дип таныса, күпчелеге бу хәлне традицияләрне җимерү дип кабул итә.

Автор үзенең симфонияләрендә бөтенләй көтелмәгән темаларга — заманыбызның күңелсезлекләренә, шәхес белән җәмгыять каршылыгына, кешенең иреген һәм минминлеген сангa сукмауга кагыла. Тышкы яктан яхшы булып күренгән тормышка алар җимергеч булып килеп керә, моңарчы авыз ачарга да рөхсәт ителмәгән проблемаларны ачып сала. Беренче кат тормышыбызның тискәре яклары сәнгать әсәрендә чагылыш таба башлый, каһарманнар булып халыкны ияртеп баручы алыплар түгел, рухи яктан өстен, әмма көчсез һәм сындырылган шәхесләр алга чыга. Композитор иҗатында рух — рухсызлык, нечкә күңеллелек — каты бәгырьлелек, updated уалучанлык — көч, акыллылык — мәгънәсезлек, югарылык — түбәнлек кебек фәлсәфи антитезалар баш калкыта. Аның әсәрләрендә тынгысыз бәргәләнгән фикер өстенлек итә. Ул мактамый, ә тикшеренү белән шөгыльләнә, тасвирламый — фаш итә, шатланмый — газап чигә. Каршылыклар ачып, үтә үткен итеп тасвирлау, психологик конфликтлар йомгагын чишәргә тырышу, рефлекс һәм арттырып күпертү, XX гасыр музыкасына ачыктан-ачык йөз тоту — А.Монасыйповны татар музыкасында аерып торучы иң көчле сыйфатлар.

Күпчелек симфонияләренең драматургия корылышы түбәндәгедән гыйбарәт: кереш эпизоды — темага әзерлек. Бу — авторның соңыннан шәрехләүгә күчә торган уйланулары — вакыйга-хәлнең үзгәлегеннән чыгып уртаклаша, хәленә керә яисә фаш итә. Автор шәхесе үзен һәрчак сиздереп тора, ул борынгы грек хорындагы корифей кебек, хисләр белән идарә итә: хуплый, юл күрсәтә, хөкем чыгара.

Образларның икенче катламы (алар ярдәмендә төп тема күтәрелә дә инде) идарә ителмәслек агрессив, төрлечә хәрәкәтле, туктаусыз агымны хәтерләтә. Бу образның үсеш сызыгы бәрмә ритмнарга, кискен, кырыс интонацияләргә корылып, куркыныч һәлакәт китереп чыгарыр дәрәҗәгә барып җитәрдәй тискәре хисләрне куертуга таба омтыла. Моның чыганагы — П.И.Чайковскийның, Г.Малерның, Д.Шостаковичның тискәре образлы скерцолары яки маршлары. Ләкин әлеге образлар А.Монасыйповта киңрәк урын алалар. Бу тәртипсез, юлында очраган һәрнәрсәне җимереп үтә торган көч симфония вакытының өчтән икесен диярлек били. Һәм шулай да, усаллык пәрдәсе аша башта зәгыйфь, аннан соң сизелерлек дәрәҗәдә, герой темасы ачыла башлый. Бу — образларның өченче төркеме яки симфониянең читтәрәк торган партиясе. Аларда рефлексия белән патетика сыңык яки үсешкә омтылган мотивлар, ритм өзеклеге, өзекләрнең үзгәртелеп кабатлануы

ярдәмендә бирелә. Автор монологлары бераз читләшкәнрәк, фәлсәфирәк булса, бу тема шартлау дәрәҗәсенә житеп куертылган, экспрессив була. Әсәрнең драматургия үзәге дә шушы ике каршылык көрәшендә. Алар арасындагы мөнәсәбәт еш кына каһарман файдасына тәгәлләнми. Финал, кагыйдә буларак, фажига белән тәмамлана. Ләкин бу — көрәштәге үлем. Шуның өчен симфониянең ахыргы өлеше, каһарман үлеменә реквием буларак, якты яңгырый.

Югарыда бирелгән «программа» әлегечә тасфирланмаган бер бүлекле яңа симфония-поэма жанрын ача. Симфонияләрдә еш кына бер түгел, ә берничә конфликт булырга мөмкин. Моның ачык мисалы — «Муса Җәлил» дигән Икенче симфониясе. Биредә үзәк дип саналган «халык — дошманнар» конфликтыннан тыш, рух ныклыгы һәм икеләнүләрне, геройларча омтылыш белән иронияне колачлаган шәхси көрәш конфликтлары да бар. Шунысын искә төшерү мөһим: композитор, кагыйдә буларак, һәр яңа әсәренә яңа бурычлар куя. «Беренче симфония»дә шәхси конфликтка күбрәк игътибар бирелгән булса, «Икенче», «Өченче симфония»ләрдә шәхес белән җәмгыять арасындагы низаг күрсәтелсә, «Дүртенче симфония»дә (автор аны «Дастан» дип тә исемли) — халык язмышы турында уйланулар, дөнья глобальләшүгә юл тотканда, милләтләрнең исән калу проблемасы күз алдына баса.

Дүрт симфониядән тыш бу чорда «Скрипка һәм оркестр өчен концертино», фортепиано өчен берничә цикл («Дүрт пьеса» һәм Марш», «Мозаика»), «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасы дөнья күрә. Беренчесендә автор испан ритмнарын милли көйләр белән кызыклы итеп тоташтыру бурычын куя. Композитор ерексездән борынгы Шәрыкка, үткәннең экзотик музыкасына, төркиләрнең әле бер кабилә булып, гарәп-фарсы дөньясы белән аралашып яшәгән дәверләргә тартыла. Әмма ул, Көнчыгыш белән бергә, Көнбатыш белән дә элемтәләрне истән чыгармаска омтыла. Фортепиано өчен язылган циклларга килгәндә (мәсәлән, «Мозаика» дигән әсәрендә), алар күбрәк кешенең эчке дөньясына юнәлтелгән. Аларда рухи тормышының төрле яклары, дөньяны тою, мохит, көндәлек яшәеш үзенә тарта. Безне чолгап алган тирә-як никадәр күптөрле булса, аның образлары да шулкадәр үк төрле. «Тукай аһәңнәре» дигән әсәрендә ул, джаз белән борынгы мөнәҗәт һәм шәрык көйләрен бергә кушып, Тукайның тәнкыйди-тискәре тойгыларын да ачып бирә.

Якынча 80нче елларның икенче яртысында, 90нчы елларның башларында А.Монасыйпов яңа бер яссылыкка күчә һәм «Идел-йорт», «Керәшен моңнары» кебек симфоник поэма белән вокаль-симфоник цикл иҗат итә, романслар яза (алар «Рамай» дигән җыентыкта бастырылганнар). Һәрбер әсәрендә яңа идеяләр һәм чаралар күзәтелә. Шуңа күрә А.Монасыйповның стилен билгеләү шактый кыен. Чынлыкта аның һәр әсәре үзенә күрә бер эксперимент.

Композиторның стиль эзләнүләрен ничек билгеләргә соң? Ул хәзерге музыкадагы неоромантик чалымнарны хәтерләтә. Шәхеснең гаять катлаулы эчке рухи тормыш нечкәлекләренә чумуы, уенга яки хыялый дөньяга йөз тотуы, соңгы чор романсларында сиземләнгән мәхәббәт шашкынлыгы шулай дип әйтергә мөмкинлек бирә. Моның белән бергә ул тагын берничә ысулны үз әсәрләрендә билгеләп китә. Алар арасында хәзерге вакытта мөһим булган неофольклоризм дигән ысул да (иске фольклор жанрларын заманча яңгырату, яңа чаралар белән баету) бар. Шулай ук неоклассицизм дигән ысулны кертеп җибәрә, ягъни, акыл белән хис арасында тәңгәллек, тормышка объектив мөнәсәбәт, барокко һәм классицизм инструменталь музыкасы белән кызыксыну, чаралар сайлауда рациональлеккә басым ясау. Аның беренчесе Ш.Шәрифуллин, Р.Кәлимуллин, М.Шәмсетдинова иҗатында дәвам итсә, икенчесе Ф.Әхмәтов, Р.Еникеев иҗатларында чагылыш таба.

Шулай итеп, А.Монасыйповның роле татар музыкасында гаять зур. Ул — үзе тойганнарны, үзе теләгәннәрне иҗат итүче композитор гына түгел, ә киләчәк буыннарга юл салучы да. Шуңа күрә ул — Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты да, әсәрләре күп илләрдә яңгырый торган зур, данлыклы шәхесебез дә.

**Аида АЛМАЗОВА,**
*сәнгать фәннәре кандидаты*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Сибгат ХӘКИМ

## Блокнотлар

Йөрим мин бүген Берлинда
Карт бер мосафир кебек,
Биетер идем дөньясын,
Булсам Мостафин[1] кебек.

* * *

Мусалар ныклыгына торган саен сокланам. Ныклар аз, сатлыкжаннар күбрәк хәзер.

## Таяныч

Мин сугышта сорый идем: артта
Катюшалар бармы?
Карыйм борылып хәзер: үз телемдә
Дәшүчеләр бармы?

* * *

Казанда әйтүләре житмәгән, хәтта Берлинда минем күзләргә бәйләналәр, хәйләкәр, диләр. Үзем түгел, күзләрем гаепле.

* * *

Торган урамым:
Unter den Linden.
Шуннан бүтәнен,
Үтер, мин белмим.

* * *

Германияда кая гына барма,
Кайсы урамга кермә: «Бах», — диләр.
Бахлар булмас бездә, бездә күбрәк
Адым саен нефть, «ах!» — диләр.

[1] Сүз Рафаэль Мостафин турында бара.

Гамил АФЗАЛ

# Юл башы

*(өзек)*

Мине 1956 елда яшь язучылар семинарына чакырдылар. Мин бик тырышып, әзерләнеп килгән идем. 27 юмористик шигырьне, кәгазьгә карар-карамас кына, чатнатып ярып салдым. Шуннан соң Сибгат Хәким белән күрештек. «Менә шәп шагыйрь килгән икән!» дип сикереп төшмәде. Буйга миннән бәләкәйрәк, сирәк чәчле, кызгылт-сары костюм кигән, төймәләрен төймәләмәгән, җәй иде, галстук такмаган. Күзгә чекерәеп карап, акыл өйрәтергә тотынып инде, дип уйлаган идем, юк, тотынмады. Гади генә күрештек, кулы да кызлар кулы кебек, бәләкәй, йомшак икән, дип уйлап куйдым мин. Әзрәк «дипломат» идем инде, якты чырай каттылар, дип, песи баласы кебек, агайларның куенына йомарланып кермәдем, чабуларына ябышмадым, әдәп саклап кына, һавалы гына, кирәген генә сөйләштем.

— Синең белем сайрак икән шул, егет, — дип тә куя.

— Гомер буе наданлык белән көрәшәм, Сибгат абый, — дим мин, — җиңеп булмады әле...

...Сибгат Хәкимнең шәкертләре күп иде. Беренче шәкерте Әнвәр Давыдов булгандыр.

Аннан соң төркем-төркем, дулкын-дулкын килә башладылар. Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Хисам Камаловлар төркеменә мин дә килеп кушылдым... Бу төркем тәпи басып, бер-ике китап чыгаргач, икенче төркем килде.

Әхсән Баянов, Сажидә Сөләйманова, Марс Шабаев, Рәшит Гәрәй, Роберт Әхмәтҗановлар Сибгат Хәкимнең чабуына килеп ябыштылар. Бу төркем аякка басып өлгергәч, өченче дулкын, дәгъвалы, шау-шулы төркем, традицияләрне танымаучы халык килде. Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимовлар иде. Болар ак шигырь дә, күк шигырь дә, рифмасыз-ритмсыз шигырь дә, атасыз-анасыз шигырь дә язып карадылар, боларның аллалары Тукай түгел иде инде. Сибгат Хәким аларга да ярдәм итте, берсен дә читкә какмады, каш җыермады, эзләнсеннәр, диде.

Бу төркемнән соң Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Харрас Әюпов, Нияз Акмалов килделәр. Боларга да Сибгат Хәкимнең җан җылысы җитте... Ул әле композиторлар белән дә дус иде, алар белән бергә-бергә йөздән артык җырлар иҗат итте...

— Син ничә опера карадың? — дип сорый ул миннән.

— Евгений Онегинны, телевизордан, — дим мин, — аны да яратмадым.

— Ә ничә балет карадың?

— Берне дә карамадым, ул ыштансыз кызларны кычыткан белән ярып төшерер идем мин сәхнәдән.

— И, шагыйрь әфәнде, син кара мунча янында, кычытканлы читән буенда үскәнсең икән шул, — ди Сибгат Хәким, елмаеп.

— Мин пролетариат бит, — дигән булам мин.

— Ә мин буржуазиямыни, мин дә авыл малае...

Утыз елдан артык нәшрият, язучылар арасында булганып, мин Сибгат Хәким турында бер әшәке сүз дә ишетмәдем, әмма аның турында әллә булган, әллә булмаган көлкеле легендалар сөйлиләр иде. Имеш, кичкырын Сибгат Хәким өенә кайтып бара икән, хулиганнар бүреген талаганнар. Шуннан соң Сибгат Хәким:

— Башка берни дә кирәкми... — дип җырлап кайтып киткән. («Башка берни дә кирәкми» дигән җыры бар).

Имеш, хулиганнар Казан урамында Сибгат Хәкимнең акчасын талаганнар. Милициягә килеп әйткән:

— Мин фәлән-фәлән шагыйрь, депутат, суд утырышчысы, сезнең борын төбендә минем акчамны таладылар...

— Акчагыз күпме иде соң? — дип сорыйлар икән.

— Күпме булсын шагыйрьнең акчасы, өч сум иде...

Шуннан соң, ике көн узгач, бер егет килгән, гафу итегез, без белмәдек, без

ялгышканбыз, дип, Сибгат Хәкимнен өстәленә йомарланып беткән өч сумны куеп чыгып киткән ди.

Имеш, Аккош күлендә су колонкасы янында Сибгат Хәким чиләк тотып чират тора икән. Зәки Нуриның малае килгән дә әйткән:

— Сибгат абый, борыныңны бармак белән казыма, бармагың сынар да, ни белән шигырь язарсың? — ди икән.

— Сул аяк белән язармын, синең әтиең кебек, — дип җавап биргән, имеш, Сибгат Хәким.

Ирек ЗӘКИ-ҖАНЫЙ

## Бу да вәгъдә

*Йөрәкләр турында язасы бар әле,*
*Атылган йөрәкләр,*
*Ватылган йөрәкләр,*
*Сатылган йөрәкләр турында.*
*(Атылган йөрәкләр күптәннән кабердә,*
*Сатылган йөрәкләр йөриләр хәзер дә.)*

Гәрәй Рәхим

Аяклар турында язасы бар әле,
Төк үскән аяклар,
Төз үскән аяклар,
Күз төшкән аяклар турында.
(Күз төшкән аяклар кирәләр төшләргә,
Вәсвәсә уятып тәвәккәл эшләргә).

Аяклар турында язасы бар әле,
Шәм кебек аяклар,
Шыр-сөяк аяклар.
Шалкандай аяклар турында.
(Шалкандай аяклар еректан ялтырый,
Шыр сөяк аяклар шом салып шалтырый).

Аяклар турында язасы бар әле,
Атылган аяклар,
Ватылган аяклар,
Сатылган аяклар турында.
(Ватылган аяклар — авыр эш казасы,
Сатылган аяклар — замана мазасы).

Аяклар турында язасы бар әле...

## Рашат Низами ачышлары

- Сүзнең күләгәсе булмас.
- Салкын мичтә ипи пешермиләр.
- Сүзнең зурысы яки кечкенәсе булмый.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### САЙЛАУ

Мәгълүм ки, ТР Президентын сайлау 13 сентябрьдә — бердәм тавыш бирү көнендә үткәрелә. Республика башлыгы булу өчен ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов, КПРФның Татарстан бүлеге лидеры Хафиз Миргалимов, «Гадел Россия» партиясенең төбәк бүлеге җитәкчесе Рушания Билгилдеева һәм ЛДПРдан Дәүләт Советы депутаты Руслан Йосыпов көрәшә. Кандидатларның һәркайсы рәсми рәвештә теркәлү өчен кирәк булган 386 имзаны җыеп, ТР Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырды. Сайлау бюллетенендә кандидатларның исем-фамилияләре алфавит тәртибендә урнаштырыла.

### КАЗАН САБАН ТУЕ

Казанда милли бәйрәмебез — Сабантуй булды. Бөтен Евразиядән конгресска килгән мэрлар, спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатында катнашучылар да күрсен, татарның милли гореф-гадәтләрен, йолаларын карап-белеп китсен өчен, Сабантуй 1 августка күчерелгән иде.

Быелгы бәйрәм Казанның 1010 еллыгына багышланды. Сабан туе кунакларын ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов, Халыкара йөзү федерациясенең башкаручы директоры Корнел Маркулеску, Кырым Республикасы башлыгы Сергей Аксёнов, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин сәламләде. Халык бөтен бәйгеләрне бер мәйданда тамаша кылды. Сабантуйның абсолют батыры булып Әлмәттән Ильяс Галимов калды.

### ТАНТАНАЛАР

Парклар һәм скверлар елы кысаларында Түбән Камада Габдулла Тукай исемендәге парк һәм бирედәге үзәк китапханә яңартылды. Уку һәм ял паркы 3,2 гектар мәйданны били. Анын үзәгендә гаҗәеп фонтан. Парк буйлап Тукай әсәрләре персонажлары сыннары урнаштырылган. Үзәк китапханә фондында 35 мең китап саклана. Аны яңартуга республика бюджетыннан 9 миллион сум акча бирелгән. Уку һәм ял паркын ачу тантанасында ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов чыгыш ясады. Ул Түбән Кама халкын әлеге вакыйгалар белән котлады, китапханә белән тематик паркны бергә урнаштыруның бөтен республика өчен үрнәк булып торуын әйтте. Тантанада ТР Президенты ярдәмчесе Наталья Фишман, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Түбән Кама муниципаль районы башлыгы, Түбән Кама шәһәре мэры Айдар Метшин катнашты.

***

Баулыда Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин һәм анын хатыны Нурсөя ханымга һәйкәл ачылды. Анын авторы — шушы районның Шалты авылында туып үскән сынчы Рәсим Шәрифуллин. Һәйкәл ачу тантанасында катнашкан ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үзенең чыгышында әлеге шәхесләрнең мондый дәрәҗәгә бик лаек булуын әйтте. Тантанада Россия Дәүләт Думасы депутаты Ришат Әбүбәкеров, ТР Дәүләт Советының Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин, «Татнефть» ААҖнең генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, «БлагоДарение» хәйрия фонды рәисе Фәрит Салихов һ.б. катнашты.

### ИСКӘ АЛУ

Казандагы 1 Май мәйданында Муса Җәлил һәм анын көрәштәшләрен искә алу мәрәсиме булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Наил Гаетбай, М.Җәлил исемендәге республика премиясенең быелгы лауреаты, язучы Рөстәм Галиуллин, театральләштерелгән күренешләрдә республикабызның сәнгать осталары катнашты. Соныннан Җәлил һәм җәлилчеләрнең рухына дога багышланды. Муса Җәлил һәйкәленә, анын көрәштәшләренең барельефына чәчәкләр салынды.

### ҖӘЛИЛ ПРЕМИЯСЕНЕҢ ЯҢА ИЯЛӘРЕ

Татарстан Министрлар Кабинеты 2015 елгы Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреатларын игълан итте. Быелгы премия лауреатлары:

«Идел» яшьләр үзәге — милли тәрбия өлкәсенә керткән хезмәтләре өчен;

КДМУның фармацевтик химия кафедрасы ассистенты Александра Буховец — фармацевтик химия һәм медицинада инновацион тикшеренүләр өчен;

композитор Эльмир Низамов — музыка сәнгате үсешенә керткән хезмәте һәм «Алтын Казан» мюзиклы өчен;

язучы-прозаик Рөстәм Галиуллин — татар әдәбияты үсешенә керткән хезмәте өчен;

шагыйрә Луиза Шарова (Луиза Янсуар) — яшьләр арасында актив иҗтимагый-агарту эшчәнлеге һәм «Болан кызы» шигырьләр җыентыгы өчен.

## ДЕРЖАВИН ПРЕМИЯСЕНӘ ЛАЕК БУЛДЫЛАР

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Лаеш муниципаль район хакимияте, Россиянең Әдәби фонды һәм Татарстан Язучылар берлеге гамәлгә керткән Гавриил Державин исемендәге Бөтенроссия әдәби премиясе быел Мәскәүдә яшәп иҗат итүче Михаил Дадашевка («И от смеха иногда болит сердце» китабы өчен), Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевкә («Поэзия духа» китабы өчен) һәм тәрҗемәче Гәүһәр Хәсәнова-Мәһдиевага бирелде.

## ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның тууына 80 ел тулуга багышланган чаралар Мәскәүдә һәм аның туган ягы — Кама Тамагы районында башланды. Россиянең башкаласындагы Асадуллаев йортында зур кичә үткәрелде. Аны ТРның Мәскәүдәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин ачып җибәрде. Кичәдә ТРның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, щепкинчылар Ринат Тажетдинов, Әзһәр Шакиров, әдипнең хатыны Нәҗибә Ихсанова (ул да — щепкинчы), кызы Әлфия Миңнуллина, Г.Камал театры артистлары катнашты. Кама Тамагы районына да язучылар, артистлар, җәмәгать эшлеклеләре, әдипнең туганнары, дуслары, якыннары, күрше республикалардан кунаклар килде. Сәфәргә кузгалганчы, алар Казанның Яңа Бистә зиратында Туфан Миңнуллинның каберен зиярәт кылды, истәлек-хатирәләр белән уртаклашты. Монда әдип рухына дога багышланды. Кама Тамагында Туфан Миңнуллинга бюст ачылды (авторы — Венера Абдуллина). Ул район үзәгендә язучының музее ишегалдына куелган. Аны ачу тантанасында ТР Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева, РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Павел Лоханов, ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Наил Гаетбай җитәкчелегендәге делегация һәм Казаннан килгән кунаклар катнашты. Кичен әдипнең туган авылы Олы Мәрәтхуҗада, ачык һавада Г.Камал театры артистлары Туфан Миңнуллинның «Мулла» пьесасы буенча куелган спектакль (режиссёры — Фәрит Бикчәнтәй) күрсәтте.

## ОЧРАШУЛАР

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза) белән шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова урып-җыю чорында туган якларында — Актаныш районында игенчеләр янында булдылар, алар белән әңгәмә кордылар, үзләренең өр-яңа шигырьләрен укыдылар.

***

Казан федераль университетында Россиянең төрле төбәкләрендә эшләүче татар теле укытучылары республикабызда чыга торган газета-журналлар редакцияләре вәкилләре, шул исәптән «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов һәм бүлек мөхәррире Камил Кәримов белән очраштылар. Очрашуда «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең генераль директор урынбасары Сөмбел Таишева да чыгыш ясады.

***

Әдәбият елы уңаеннан «Бәкер» шифаханәсендә ял итүчеләр өчен әдәби-музыкаль кичә оештырылды. Анда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), «Сәхнә» журналының баш мөхәррире, прозаик, шагыйрь Зиннур Хөснияр, язучы-прозаик Нәбирә Гыйматдинова, галим, театр белгече Мөхәммәтгали Арсланов чыгыш ясады.

## АКАДЕМИК БУЛДЫ

Әдәбият тарихы галиме, педагог, публицист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Әнвәр Шәрипов Россия Энциклопедияләр академиясенең хокукый әгъзасы итеп сайланды. Фәнне үстерүнең изге идеалларына ирешү максатында зур фәнни хезмәтләрен һәм уңышларын рәсми тану билгесе буларак, аңа әдәбият белгечләре буенча «Энциклопедик фәннәр академиясенең почётлы фәннәр докторы» дигән исем дә бирелде.

2015 елның 3 августында 77нче яшендә язучы-сатирик, журналыбызның актив авторы **Сәетбатталов Фәнзаман Сәетбаттал улы (Фәнзаман Баттал)** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Интервью И.ИБРАГИМОВА с заместителем Премьер-министра РТ, министром образования и науки РТ Э.ФАТТАХОВЫМ.
«Проза и поэзия»: роман Р.КАРАМИ «Куда бежишь, скакун моей жизни?»; рассказ А.ХАЛИМА «Четыре Ивана на чересполосице»; стихи Н.АХМАДИЕВА, Ш.ЗИГАНГИРОВОЙ, Р.ШАГИЕВОЙ.
«Конкурс на повесть малого формата»: С.ЗЫЯЛЫ. «Змеиный яд».
«100-я страница»: Дж.СУЛЕЙМАН. «Село снова молодеет».
«Из литературы родственных народов»: статья Х.МИННЕГУЛОВА «К вопросу взаимовлияния тюркских литератур»; отрывок из эпоса Гороглы с предисловием М.ВАЛИЕВА; рассказы Я.ОМАРОГЛЫ; стихи О.СУЛТАНОВА, А.ДОДУЕВА, М.АХМЕТОВА, Т.ГАНИЕВОЙ, С.СУЛЕЙМАНА.
«Наши юбиляры»: М.САТТАРОВ. «Две бомбы, зуб и Изольда»; статья Л.ХИСМАТОВОЙ, посвящённая 80-летию М.Маликовой.
«Литературная критика»: рецензия Р.БАТУЛЛЫ на рассказ Р.Габдулхаковой.
«Книжное обозрение»: рецензия Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ на книгу Б.Корганбекова «Чура батыр».
«Искусство»: статья А.АЛМАЗОВОЙ, посвящённая 90-летию со дня рождения А.Мунасипова.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Под старой яблоней». Работа Ш.Шайдуллина; памятник Кул Гали в парке «Тысячелетия Казани». Авторы: скульпторы А.Балашов, А.Миннуллина, архитектор Р.Нургалиева.

## IN THIS ISSUE:

Interview by I.IBRAGIMOV with Deputy Prime Minister of the Republic of Tatartstan, Minister of education and science of the Republic of Tatarstan E.FATTAKHOV.
«Prose and poetry»: novel by R. KARAMI «Where are you running, the steed of my life?»; story by A.HALIM «Four Ivan on the strip farming»; poems by N.AKHMADIEV, SH.ZIGANGIROVA, R.SAGAVA.
«Competition for a small format novel»: S.ZYALY. «Snake venom».
«100th page»: J.SULEYMAN. «Village is younger again».
«From related peoples' literature»: article by H.MINNIGULOV «To the question of the interaction of Turkic literatures»; excerpt from the epic Gorogly with Foreword by M. VALIEV; stories by YA.OMEROGLY; poems by O.SULTANOV, A.DODUEV, M.AKHMETOV, T.GANIEVA, S.SULEIMAN.
«Our heroes of the day»: M.SATTAROV. «Two bombs, tooth and Isolde»; article by L.HISMATOVA dedicated to the 80th anniversary of M.Malikova.
«Literary criticism»: review by R.BATULLA on the story by R.Gabdulhakova.
«Book review»: review by L.MUHAMETZYANOVA on the book by B.Korganbekov «Chura warrior».
«Art»: article by A.ALMAZOVA dedicated to the 90th anniversary of A.Munasipov.
«Pages of humor»: rubric is led by M.GALIEV.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Under the old apple tree». Work by SH.Shaydullin; Kul Gali monument in the Park «Millennium of Kazan». Authors: sculptors A.Balashov, A.Minnullin, architect R.Nurgaliev.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Карт алмагач төбендә». *Рәссам Шамил Шәйдуллин эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казанның меңьеллыгы паркындагы Кол Гали һәйкәле. *Авторлары: сынчылар Андрей Балашов, Асия Миңнуллина, архитектор Розалия Нургалиева.*

# КАРДӘШЛЕК ТӘ, ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТӘ









КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)